Васил Гайфуллин

Гомерем мизгелләре

Гомерем мизгелләре
Васил Гайфуллин

Васил Гайфуллин

Гомерем мизгелләре

Казан
"Сүз"
2010

ББК 63,3(2)
УДК 93/94
Г14

Төзүче-мөхәррире ***Шаһинур Мостафин***

Китапта ***Васил Гайфуллин*** архивында сакланган фоторәсемнәр файдаланылды.

Васил Гайфуллин

Г14 Гомерем мизгелләре. Казан: "Сүз" нәшрияты, 2010. – 264 б. + вкл. 40 б.

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының шәрәфле профессоры – данлыклы мөгаллим, кин колачлы, абруйлы галим, күп еллар җитәкче урыннарда фидакарьләрчә эшләгән В.Г.Гайфуллинның әлеге китабы элеккеләреннән нык аерыла. Аларында автор – Васил Габдуллович – урта мәктәптә һәм югары уку йортларында физика фәнен укыту мәсьәләләрен, милли мәгарифне үстерү, кадрлар әзерләүнең четерекле проблемаларын яктырткан иде. Хәзерге китабында исә ул, 2007 нче елда дөнья күргән "Язмыш борылышлары" дигән әдәби-документаль китабындагыча, үз тормышының башкалар күзенә артык ташланып тормый торган кызыклы-мавыктыргыч сәхифәләрен ача. Автор үзе яшәгән чорның вакыйгаларына, замандашларына карата шәхси мөнәсәбәтен белдерә, уй-фикерләре белән ихластан уртаклаша.

ISBN 978-5-98356-101-4 © Васил Гайфуллин, 2010

...Без кемлекне җирдә әйткән чакта,
Безнең өчен тыныч бул, Мөслим!
Горур килеш һәм гел данлы килеш
Яңгырар да торыр бу исем!...

Шәмсия Җиһангирова,
шагыйрә, Татарстан Республикасының
атказанган сәнгать эшлеклесе.

Кереш сүз

2007 нче елда Казанда — үзебезнең "Сүз" нәшриятында — "Язмыш борылышлары" дип исемләнгән китабым басылып чыкты. Анда гомер юлымның аерым мизгелләре тасвирланган иде.

Әлеге китабым белән танышкач, күпләр миңа: "Моңа кадәр Сезнең фәнни хезмәтләрегезне генә белә идек, әдәби әсәрләр дә язасыз икән, әлеге китабыгыз җиңел укыла, теле дә әйбәт", — диделәр. "Китапта хезмәт юлыгыз турында гына язгансыз, үзегез турында, шәхси сыйфатларыгыз, дөньяга карашыгыз турында мәгълүматлар бик аз", — диючеләр дә булды.

"Тормыш иптәшегез, аның белән ничек танышуыгыз турында да беләсебез килә", — дип тә әйттеләр. Туган авылыбыз, аның кызыклы кешеләре, туганнарыбыз турында язуымны сораучылар да булды.

Әлеге китабымда мин укучыларыбызның теләкләрен, өлешчә булса да, канәгатьләндерергә тырыштым. Шул уңайдан, бер хакыйкатьне искә төшереп үтәсем дә килә: язучының язган әсәрләреннән аның үзе турында мәгълүматлар туплап була, диләр. Язучы булмасам да, бу тәгъбир миңа да кагыладыр. "Дустыңның кем икәнен әйтсәң, мин синең кем булуың турында әйтермен", — дигән халык мәкален дә истә тотыйк.

Югарыдагы таләпләрне куючылар, әлеге яңа китабым белән танышкач, үзләренең теләкләренә ирешерләр, шәт.

Бу язмаларда әдәби сюжет та, уйлап чыгарылган образлар да юк. Бары тик үзебез яшәгән заман, безне чорнаган тормыш һәм миңа якын кешеләр турында чын дөресе генә язылган. Монда мин үзем белән бергә эшләгән һәм аралашкан хезмәттәшләрем, дусларым, авылдашларым турында сөйләүне дәвам итәм.

Мине борчыган, уйланырга мәҗбүр иткән, фикер әйтергә җилкендергән күп кенә проблемалар турында язуны киләчәккә — чираттагы китабыма калдырыйк!..

Ә хәзер Сезне, хөрмәтле Укучым, үземнең күңел бакчама сәяхәткә чакырам...

Күренекле замандашыбыз

Укытучы, галим, җитәкче

...1937 нче елның эссе җәй көне. Малайларның шырпы сызып уйнавыннан, сарык абзарлары янып китә. Ут тиз генә күршедәге салам түбәле йортка да күчә. Йорт тиз арада ялкынга чорнала. Авылдагы барлык халык колхоз эшендә, басуда вакыт.

Өй тирәли бер карчык йөгереп йөри: "Бишектәге балалары янып үлә бит, коткарыгыз, зинһар!" – дигән сүзләрне кабатлый. Авыл аркылы узып баручы юлчы, атын туктатып, йөгереп өйгә кереп китә. Бишеге белән баланы тәрәзәдән урамга ыргыта. Чүпрәкләре яна башлаган бала бишектән урамга тәгәри. Шулай итеп, бала исән кала!..

Бу хәл Мөслим районының Югары Табын авылында була. Баланың исеме – Васил Габдулла улы Гайфуллин. Янгыннан исән калып, ул 7 яшенә җитә, Югары Табын башлангыч мәктәбен тәмамлый, аннары Түбән Табын җидееллык мәктәбенә китә. Бу мәктәп заманында районның иң көчле мәктәпләреннән берсе була. Юкка гына, 1951 нче елда мәктәпнең җиденче классын тәмамлаучыларның өчесе – Васил Гайфуллин, Гегель Гәрәев, Флюс Газизов – соңрак, фәннәр докторы югарылыгында гыйльми дәрәҗә алмагандыр?!

Аннары – Минзәлә педагогия училищесында уку еллары.

– Тормышымдагы иң матур еллар педучилищеда узды, дип саныйм, – ди В.Г. Гайфуллин. – Уку йортлары нинди булырга тиеш, дисәгез, нәкъ менә педучилище кебек, дияр идем. Анда тирән белем бирәләр, тәрбия эше дә шәп куелган, кешенең сәламәтлеген ныгыту, сәләтен ачу өчен дә шартлар бар. Педагог, тәрбияче булып җитлегү өчен дә мөмкинлекләр җитәрлек. Һәм эзләнүче-фәнни тикшеренүче, галим булып үсеп китү өчен дә беренче "оеткы"ны шунда салалар. Без укыган чорда Минзәлә педучилищесы коллективының да иң көчле чагы булгандыр, дип саныйм. Безне анда чын остазлар укытты. Кызганычка

каршы, пединститутларда укытучы өчен кирәк булган сыйфатларны педучилищедагы кебек бирә алмыйлар.

Педучилищедан соң мин Мөслим районының Ташлыяр җидееллык мәктәбендә эшләдем. Башлангыч классларда да, V-VII классларда да укыттым. Җәмәгать эшләренең дә күбесе миндә – пионер, комсомол эшенә җитәкчелек итәм; лозунглар язучы, бригада газетасын чыгаручы, агитатор да – мин; укучыларның үзешчән сәнгатен оештыручы да, драмтүгәрәк җитәкчесе дә – үзем! Педучилищеда алынган чыныгу, тәрбия, күнекмәләр миңа эшләргә бик нык ярдәм итте. Мәктәп мәшәкатьләренә башым белән күмелеп, шулкадәрле яратып эшләдем. Шулай да укуны дәвам итәргә кирәк иде. Мәктәптән вакытлыча аерылып, Казанга – педагогия институтының физматына барып кердем. Педучилищены да, институтны да бик әйбәт билгеләр белән (“с отличием”) тәмамладым. Институтта калдырырга бик тырышсалар да, туган якта эшлисе килү теләге мине Мөслимгә алып кайтты. Физика укытучысы, завуч булдым, директор вазифасын башкардым. Бөтен барлыгымны биреп, яратып эшләдем. Дәресләрем дә бик нәтиҗәле уза иде. Физика буенча район олимпиадаларында җиңүчеләр – минем укучылар, югары уку йортларына керү имтиханнарын да минекеләр уңышлы тапшырды!

Мәктәптәге нәтиҗәле эш район җитәкчеләренең дә игътибарыннан читтә калмый. 1965 нче елның мартында В.Г. Гайфуллин район мәгариф бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Бу елларда Мөслим районы Татарстан Мәгариф министрлыгының эксперименталь базасына әйләнә, дисәк тә, дөрес булыр. Район мәктәпләрендә күп кенә яңа теорияләр сынала, гамәлгә кертелә. Әйтик, укытуны тормыш белән бәйләү, укучыларның танып-белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерү, программалаштырылган укыту, белем бирүне индивидуальләштерү, укытуны оптимальләштерү, проблемалы һәм үстерешле укыту мәсьәләләре һ.б. буенча Татарстан укытучылары тәҗрибәсе сынала, күптөрле фәнни-гамәли конференцияләр уза. Тәҗрибәле педагоглар, мәгариф органнары җитәкчеләре һәм галимнәрнең бергәләп, үзара ярдәмләшеп, иҗади эшләүләренең уңай нәтиҗәсе бу.

Мәктәпләрне яңа уку елына әзерләү, төзелеш эшләре, кечке мәктәпләр эшен оештыру, укытучыларның белемнәрен күтәрү, укучыларның җәйге ялларын оештыру һ.б. юнәлешләр буенча район республикада алдынгылардан санала.

Мөслим районы бу елларда үзешчән сәнгать көчләрен оештыру буенча да республикада нык таныла. Бу эштә иң актив

катнашучыларның берсе Васил Гайфуллин була. Болар турында аның истәлекләрен укып үтик әле:

"...Педучилищеда безгә музыка дәресләре керде. Шунда мин мандолинада, пианинода, скрипкада уйнарга өйрәндем. Минзәләдән соң, авылга кайтып эшләгәндә, һәр атна саен бер концерт йә бер спектакль куярга туры килә иде безгә. Аннан мин тальян гармун, хромка, баян алдым, шуларда уйныйм. Үзем кешеләрне җырлатам, үзем кушылып җырлыйм. Институтта укыганда сәнгать түгәрәкләренә йөри башладым. Укытучылар йортында үзешчән сәнгать буенча бик яхшы коллективлар бар иде. Ул заманда Хәбиб абыйның эстрада группасы бар, драма, бию түгәрәкләре эшли. Бер кышны вокал түгәрәгенә дә йөрдем. Горький исемендәге клубта Сара апа Садыйкованың хоры барлыгын ишетеп, анда йөри башладым. Шул елларда Казанда беренче тапкыр халык театры оешты. Театрга һәвәскәрләр туплаганда, "Мехкомбинат" клубында 500ләп кешене төрле яктан: тавышын да, сәхнә сәләтен дә, сөйләү куәсен дә, музыкага һәвәслеген дә тикшерделәр. Шул конкурстан үтеп, мин сезон ярым халык театрына йөрдем. Җәләл ага Садриҗиһанов музыка җитәкчесе иде, Разия апа Яруллина – хор җитәкчесе, Али Гыйззәтуллин балет, биюләр буенча җитәкче иде. Ә төп оештыручы, режиссер – Хәким ага Сәлимҗанов. "Кандыр буе" спектаклен әзерләп, бик күп урыннарда куеп йөрдек. Ә бервакыт опера театрында хор группасын киңәйтергә уйладылар. Конкурс булды. Мин дә кереп карадым. Алдылар. Анда бик катлаулы, җидешәр тавышлы партияләрдә җырлау – бу инде зур мәктәп иде!

Студент өчен үзешчән сәнгатьтә йөрүнең "табышлы" ягы да бар. Опера театры хорында катнашучыларга 20 сум булса да акча түлиләр. Хәбиб абый безне атна саен берәр авылга алып китә, ипи-чәйлек эшләп кайтабыз. Өйдән ярдәм юк бит инде – колхозда "таяк"ка эшлиләр – ашау-эчү генә түгел, киемгә дә акчаны үзең табасы! Әле өйгә дә ярдәм итәм. Әлбәттә, тамак кайгысыннан бигрәк, рухи ихтыяҗ зур иде... Мөслимдә эшләгәндә дә үзешчән сәнгатьтә бик күп катнаштым. Безнең мәктәп ул яктан бик көчле иде. Район күләмендә дә урыпҗыю чорында агитбригадалар оештыралар. Билгеле, райком мине алырга тырыша иде, чөнки анда кеше күп кирәк түгел, күпкырлылык кирәк. Анда – бер пәрдәлек пьесада уйнау да кирәк, сөйләү дә, җыр-музыкада да катнашу кирәк!"

1971 нче елда Васил Гайфуллин А.И.Герцен исемендәге Ленинград пединститутына аспирантурага керә. Анда керү тарихын ул болай сурәтли:

"...Аспирантурага ике генә кешене алалар икән. Керергә теләүчеләр 18 кешегә җыелды. Арабызда, югары уку йортында 10-15 ел эшләп, күпләп фәнни хезмәт бастыручылар да бар. Соңгы имтиханны бирдек. Комиссия членнары үзара киңәшләшә башладылар. Ике кешенең берсе итеп, мине сайлаганнар. Шулай итеп, аспирант булдым!..

Аспирантурага керүен-кердем, ә мине эштән җибәрмиләр. Янәсе, РОНОны башка кешегә тапшырып булмый. Мәгариф министры М.И.Мәхмүтовка, обкомга кадәр җитеп, юл ачарга туры килде".

Аспирантураны уңышлы тәмамлап, В.Г.Гайфуллин Казан дәүләт педагогия институтына эшкә кайта, югары уку йортында барлык инстанцияләрне дә үтеп чыга: ассистент, өлкән укытучы, доцент, профессор, өч кафедраның мөдире, ике факультетның деканы вазифалары. 1990 нчы елда ул Ленинградта докторлык диссертациясен яклый. Шул ук елда аны Татарстан Республикасының Мәгариф министры итеп сайлыйлар.

XX гасыр азагында килеп туган кискен үзгәрешләр дулкыны җәмгыятьне, иҗтимагый тормышны дер селкетеп, сискәндереп җибәрде. Узып барган гасырның буеннан-буена бертуктаусыз алмашынып дәвам иткән берсеннән-берсе киеренке, драматик вакыйгалар мәгариф эшен дә читләтеп узмады. Аны шактый дәрәҗәдә зәгыйфьләп, белем һәм тәрбия бирүнең милли-әхлакый, дини, рухи-гуманистик традицияләрен какшатты.

Журналист Рәйсә Юсупованың "Ватаным Татарстан" газетасында "Очар кошның кыйбласы" исеме астында чыккан мәкаләсендә мондый юллар бар:

"...Тәүге тапкыр мин аның исемен узган гасырның 90 нчы еллары башында ишеттем. Дөньяның давыллаган бер мәле: Балтыйк буе, Кавказ, Урта Азия халыкларының инде мөстәкыйльлек алып, үз дәүләтләрен төзегән һәм бу вакыйгаларның татар халкына да зур йогынты ясаган, Казан урамнарында "Мөстәкыйльлек", "Ана теле", "Үзбилгеләү" кебек илаһи сүзләр яңгыраган, ә калын диварлы бүлмә-кабинетларда Ил-Республика язмышы, татар милләте, аның киләчәге хакында кызу-кызу бәхәсләр барган тарихи кошпәр иде ул.

Аннары...

Аннары, шифалы яңгырдан соң калыккан гөмбәләр кебек, татар мәктәпләре, татар гимназияләре пәйда була башлады. Һәм бу куанычлы хәлләрне Татарстан Мәгариф министры Васил Габдулла улы Гайфуллин исеме белән бәйләделәр. Педагогия өлкәсендәге һәр яңалык әнә шулай аның исеме белән тәңгәл йөри башлады.

Чыннан да, милли мәгарифне торгызуда ул чорда бик күп эшләр башкарылды. Әгәр ул елларда татар мәктәпләренең саны 200гә арткан икән, дистәләрчә татар гимназияләре, лицейлары, 100дән артык татар балалар бакчалары ачылган икән – бу инде шул чорда эшләнгән эшләрнең куанычлы нәтиҗәсе дигән сүз. Министрлыкка килүенең беренче көннәрендә үк, мәктәпләрдә тарих фәнен укытуга багышланган зур киңәшмә уздырылган иде. Анда бөтен республиканың танылган тарихчы-галимнәре катнашты. Шул вакытта ук алар алдына татар халкы тарихын язу, дәреслекләр төзү бурычы куелды. Шул елларда, 5 нче класстан алып 10 нчы класска кадәр, татар халкы тарихы дәреслекләре гамәлгә керде. Бу – милли мәгарифтә милли белем бирүнең башлангычы иде!

1991нче елда "Татар мәгарифен үстерү концепциясе" эшләнде. Бу эш белән, министр буларак, В.Г. Гайфуллин турыдан-туры җитәкчелек итте. Шул ук елларда "Милли мәгарифне үстерү программасы" да төзелде. Шуннан соң, мондый программаны, республикабыздагы һәр шәһәр һәм район, үзенең үзенчәлекләренә һәм үз мөмкинлекләренә туры китереп, аерым төзеде. Соңрак бу юнәлештәге эшләр тагын да җитдирәк төс алды: шәһәрләрдә һәм районнарда әлеге мәсьәлә һәр елны сессияләрдә көн тәртибенә махсус рәвештә куеп өйрәнелә, тикшерелә башлады. Республиканың халык мәгарифе министры буларак, аңа ул сессияләрнең күбесендә катнашырга туры килде. Билгеле, алга куелган зур планнарны тормышка ашыру җиңелдән булмады, әмма һәр елны аларның үтәлүенә ирешелә барды. Хәзер кайберәүләргә бу эшләр үзеннән-үзе килеп чыккан кебек тоеладыр, ләкин һәр яңалык – татар гимназияләрен ачу, аларга уку биналары табу еш кына җитди каршылыкларны үтеп кенә уңай хәл ителде.

90нчы елларда хәтта башкалабыз Казандагы татар балаларының нибары 0,1 проценты гына туган телендә белем ала иде. 1997нче елда исә бу сан 42 процентка күтәрелде. Аерым шәһәр һәм районнар тагын да югарырак нәтиҗәләргә ирештеләр. Мәсәлән, Чаллыда ул 1 проценттан 58 процентка җитте.

Бүген республикабыздагы барлык татар балаларының яртысыннан күбрәге ана телендә белем ала икән, бу инде милли мәгариф, милли мәктәп, милли белемгә карата В.Г.Гайфуллинның нинди мөнәсәбәттә булуын бик ачык күрсәтә".

1997нче елдан В.Г. Гайфуллинның тормышында яңа этап башлана. Аңа республиканың беренче милли югары уку йортында ректор вазифасы йөкләнә.

Шул уңайдан Васил Габдулла улының үзенә сүз бирик әле:

– Үз ана телендә югары уку йорты да булмаган милләтнең киләчәге юк. Шуны истә тотып, 90 нчы еллар башында Мәгариф министрлыгы бу кимчелекне бетерү өчен, күп кенә чаралар күрде. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1992нче елның августында, Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән, милли югары уку йорты туды. Башта ул Татар дәүләт колледжы сыйфатында иде, туксан алтынчы елда Татар дәүләт гуманитар институты исемен алды. Үзең тудырган "бала"ны үзең җитәклә, дигәннәрдер инде, туксан җиденче елда ректор вазифасы үземә йөкләнде...

Татар тарихында беренче югары уку йорты шактый катлаулы үсеш чоры үтә. Яңа туган баланы бәләкәй бишеккә салган кебек, Татар дәүләт гуманитар институты да башта бәләкәй генә балалар бакчасы бинасында "оя кора". Ректорның тынгысызлыгы, югары оешмаларның ярдәме белән, әкренләп, эшләр өчен уңай шартлар барлыкка килә: уку бинасы, студентлар өчен тулай торак, укытучылар өчен фатирлар булдырыла.

Институтта белгечләрнең иң кирәклеләре генә әзерләнә: татар теле һәм әдәбияты, тарих, инглиз, немец, гарәп, фарсы, төрек телләре белгечләре, башлангыч класс укытучылары, балалар бакчалары өчен тәрбиячеләр, мәктәптән тыш тәрбия учреждениеләре педагоглары, түгәрәк җитәкчеләре, социаль педагоглар һ.б.

Республикада татар мәктәпләренең үсүе, "Телләр турындагы Закон" нигезендә, барлык балаларның да татар телен өйрәнә башлавы татар теле укытучыларына мохтаҗлыкны китереп чыгарды. Яңа институт бу проблеманы чишәргә мөмкинлек бирде.

Чит тел укытучылары җитешмәү инде традициягә әйләнгән иде. Моның белән бигрәк тә авыл мәктәпләре интекте. Республиканың 600гә якын мәктәбендә чит тел укытылмады. Сәбәбе дә ачык: чит телләрне укытмагач, педагогия институтларының чит телләр факультетына авыл балалары керә алмый. Ә институтны тәмамлаган шәһәр баласы авылга бармый.

Яңа институт мәсьәләне үзенчә хәл итте: чит телләр факультетында мәктәптә чит тел өйрәнмәгән авыл балаларыннан аерым төркемнәр оештырыла һәм махсус методика белән 5 ел эчендә бер дигән белгечләр әзерләп чыгарыла башлады. Факультетта тагын бер яңалык: чит телләрне, рус теле нигезендә түгел, ана теле – татар теле нигезендә өйрәтәләр. Телләрне өйрәнүдә бу алымның өстенлеген институт әзерләгән югары сыйфатлы кадрлар раслый.

Институт кадрлар әзерләүдә чит республикалардагы һәм өлкәләрдәге туганнарыбызга да булышты. Студентлар якын күршеләребез – Башкортстан, Чувашия, Удмуртия, Мордовия, Мари-Эл республикаларыннан. Ерактагы бәйсез дәүләтләр – Әзербайҗан, Казахстан, Украинадан, киң Рәсәйнең Киров, Пермь, Чиләбе, Омск, Свердловск, Төмән, Курган, Ульяновск, Самара, Красноярск, Кемерово һ.б. өлкәләреннән килгән студентлар да укыды әлеге институтта.

Татар дәүләт гуманитар институтында югары белем бирүнең төп юнәлеше турында бер-ике җөмлә белән дә әйтеп була. **Анда, белгечләр әзерләү өчен, уку планнары югары профессиональ белем стандарты нигезендә, милли-региональ үзенчәлекләрне исәпкә алып төзелә. Институт уку-укытуны, белем алуны гуманитарлаштыруга йөз тота.** Кафедраларында уку һәм фән лабораторияләре, методик һәм гадәти мәктәп кабинетлары оештырылган институт үзенең фәнни-тикшеренү, фәнни-гамәли эшләрен республиканың төрле уку йортлары белән ныклы бәйләнештә алып барды. Чит илләр белән элемтә дә сокланырлык иде! Ел саен фәнни-теоретик һәм фәнни-гамәли конференцияләр үткәрелде.

Студентлар төрле фәнни түгәрәкләргә йөрделәр, курс һәм диплом эшләре яздылар, олимпиадаларда, конференцияләрдә актив катнаштылар. Белгечләрне ике баскычлы системада әзерләү республикада беренче тапкыр шушы уку йортында башланды.

Чит телләр факультеты укытучылары һәм студентлары Төркия, Иран, Мисыр, Англия, АКШта стажировка үттеләр. Институтны тәмамлаучыларның 15%тан артыгы ел саен аспирантурага укырга керде. Бу инде институтта алган белемнәрнең төпле булуы турында сөйли иде.

Дәрестән тыш эшләрнең төрле формалары ярдәмендә укытучылар студентларның иҗади активлыкларын үстерәләр, аларның сәләтләрен ачарга тырышалар иде. Моның өчен өстәмә белгечлекләр кертелде: музыка, рәсем сәнгате, декоратив сәнгать, башлангыч классларда татар һәм инглиз телләрен укытучы, балалар бакчасында – музыка җитәкчесе, балалар бакчасында – милли төркемдә тәрбияче. Өстәвенә, институтта күптөрле үзешчән коллективлар да эшләде.

Татар дәүләт гуманитар институтында укырга теләүчеләр саны елдан-ел арта барды. Монда гасырлар буена сакланып килгән традицияләрне дә, югары профессиональ белем тәртипләрен дә истә тотып эш итәләр һәм, максатка омтылып, киләчәккә ышаныч белән карап яшиләр иде.

Институтның 10 еллык юбилеен бәйрәм иткәндә, Республикабызның Беренче Президенты М.Ш. Шәймиев болай дигән иде: "Яшь институт булуга карамастан, ТДГИны Татарстанда гына түгел, чит өлкәләрдә һәм республикаларда да беләләр. Хәзер ул яшьләрнең иң популяр уку йортына әйләнде. Бу институтның киләчәктә элиталы университет булачагына шикләнмим. Монда әзерләнгән белгечләр Татарстан кадрларының "алтын запасы"на әйләнәчәк, XXI гасырда Республика үсешен шулар билгеләячәк".

Шушы юнәлештә В.Г.Гайфуллин армый-талмый эшләвен дәвам итте. Институтның университет дәрәҗәсенә җитүе өчен, барлык шартларны тудырырга омтылды ул. Милли университетның концепциясен булдыруда ТДГИ ректоры Васил Габдулловичның хезмәте аеруча зур булды. (Бу хакта аның "Язмыш борылышлары" дигән мәгълүм китабында тәфсилләп сөйләнелә).

В.Г.Гайфуллинның фәнни эшчәнлеге дә зур игътибарга лаек. Ул – 300дән артык фәнни хезмәтнең авторы. Шулар арасында 7нче –11нче класслар өчен физика дәреслекләре, физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыклары, укытучылар өчен күп төрле методик ярдәмлекләр, милли мәгарифнең методологиясенә багышланган монографияләр, татар милли университеты концепцияләре һәм йөзләгән фәнни мәкаләләр бар. Алар Казан, Мәскәү, Ленинград һәм чит ил нәшриятларында басылып чыккан.

Укучылар өчен дәреслекләр язуны да безнең республикада Васил Габдуллович башлап җибәрде. Сүзне аңа бирик әле:

"...Соңгы елларга кадәр республика мәктәпләре Россия Мәгариф министрлыгы раслаган һәм Мәскәү нәшриятларында басылган дәреслекләр белән эшләде (татар теле һәм әдәбияты дәреслекләреннән башкалары). Математика, физика, химия, биология һ.б. фәннәрдән дәреслекләр рус теленнән тәрҗемә ителеп әзерләнде. Әмма мондый дәреслекләрнең зур кимчелеге бар – без үзебезнең җирле шартларны һәм милли үзенчәлекләрне файдалана алмыйбыз. Әлбәттә инде, һәр фәннән үзебезнең республика тормышын чагылдырган үз дәреслекләребез булырга тиеш.

Гомумән, дәреслекләрне Мәскәүдән алып, тәрҗемә аша укыту заманы узып бара. Милли мәгариф стандартлары мәсьәләсе көн тәртибенә баскач, үзебезгә дигән дәреслекләрне үзебез язарга тиешбез! Бу очракта без берничә максатны күздә тота алабыз: 1) элекке дәреслек эчтәлегендәге хаталарны төзәтәбез; 2) иң

уңышлы методиканы сайлап алабыз; 3) җирле материалларга таянабыз.

7нче – 11нче класслар өчен физика дәреслекләрен, шушы принциплардан чыгып, без коллегам – Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләре белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү институты ректоры, профессор Рәшит Әхәт улы Исламшин белән бергәләп төзедек. 9нчы класс дәреслеген эшләгәндә безгә ТДГПУ доценты Әзбәр Сәмигулла улы Габидуллин да нык булышты, соавтор булды. Безнең дәреслекләрне укытучылар уңай бәяләделәр һәм аны укучылар да яратып кабул иттеләр".

Галимнәр тәрбияләүдә дә нәтиҗәле эшли Васил Габдуллович. Аның шәкертләре 3 докторлык, 16 кандидатлык диссертацияләрен яклады инде...

В.Г. Гайфуллин – педагогия фәннәре докторы, профессор, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе.

...2005 нче елда Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты оешкач, Васил Габдулловичны биредә физика факультеты деканы итеп билгеләделәр. Әнә шулай итеп, ул Татарстан Мәгариф министрлыгына эшкә киткәнче башкарган хезмәтенә 20 елдан соң яңадан әйләнеп кайтты. Һәм элеккечә, җиң сызганып, ир-егетләрчә дәртләнеп эшли башлады. Бүгенге көндә Васил Габдуллович берләштерелгән физика-математика факультеты деканы вазифасын да җан җылысын, күңел яктысын биреп, илһамланып башкара.

– ...Мөхтәрәм Васил Габдуллович, чын мәгънәсендә, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының горурлыгы! – ди аның турында әлеге югары уку йортының булдыклы яшь ректоры, филология фәннәре докторы, профессор Рәдиф Рифкатович Җамалетдинов. – Гыйльми Советыбызның 2009 нчы елның 21 нче октябрендә үткән чираттагы утырышында Васил ага Гайфуллинга, күпьеллык нәтиҗәле фидакарь хезмәте өчен, "Университетның шәрәфле профессоры" дигән мактаулы исем бирелде. Әлеге олуг исемгә ул бик тә лаек!

Хак сүзләр! Әлеге бәядә, иртәнге чык бөртегендә Кояш чагылгандай, чын дөреслек ялтырап ята...

Рамил Хәернас улы Минһаҗев,
Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының физика-математика факультетындагы математика-информатика кафедрасы мөдире, педагогия фәннәре докторы, профессор.

Хәтер кайтавазы

Туган авылым

Югары Табын – минем туган авылым. Ул Мөслим районының төньяк-көнбатышында, Мөслимнән 16 км ераклыкта, Сарман һәм Минзәлә районнары чигендә урнашкан. Авылның барлыкка килүе XVI гасыр ахырларына туры килә. Тарихи язмаларда бу авылны Урал ягыннан килгән Табын кабиләсе кешеләре нигезләгән, дигән мәгълүмат бар. Безнең якларда ул иң борынгы авылларның берсе. Элек-электән авыл халкы игенчелек, терлекчелек һәм умартачылык белән шөгыльләнгән.

Югары Табында укыту-тәрбия эшләре авыл барлыкка килгәч үк башланган. Малайлар мәчет каршындагы мәдрәсәдә, кыз балалар абыстай кул астында укыган. Бөек Октябрь революциясеннән соң, укуларын Түбән Табын урта мәктәбендә дәвам итәләр. 1995 нче елда авылда яңа мәктәп бинасы салына. Барлык уңайлыклары булган һәм заманча җиһазландырылган әлеге бинада урта мәктәп оеша. Бу эшләрне, Татарстан Республикасының Мәгариф министры буларак, миңа башкарырга туры килде.

Хәзерге вакытта авылдагы 140тан артык хуҗалыкта 400дән артык кеше яши. Авылда тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы, медицина пункты, терлекчелек биналары бар. Авылга газ һәм су кертелгән, асфальт юл авыл кырыеннан уза.

Безнең авылны башлап җибәрүче, үзенә беренче йортны салучы искиткеч акыл иясе булган. Ул авылыбыз кешеләренә яшәү өчен гаять уңайлы урынны сайлаган. Без үскәндә авылда озын-озын ике урам бар иде. Шул урамнар арасындагы тыкрыкларда да берничә йорт сакланган иде әле. Түбән урам, бәрәңге бакчалары белән, инкүлеккә барып тоташа. Ул инкүлектән, Атлас авылы ягыннан, кечкенә инеш ага иде. Инеш безнең авылның буеннан-буена уза һәм Түбән Табын аша Ык елгасына барып кушыла. Җәйләрен инеш буып куела. Шактый зур сулык – буа барлыкка килә.

Без яшь чакта әлеге буаны “Амурский буасы” дип йөртәләр иде. Буаның аръягында безнең колхозның яшелчә бакчасы башлана. Яшелчә бакчасында җаваплы кеше булып озак еллар Габдерәүф абзый Амурский эшләде. Яшелчәне үстерү өчен су күп кирәклеген истә тотып, буаны Амурский будыра торган булгандыр. Шуңа күрә аның исеме дә “Амурский буасы” дип аталгандыр инде.

“Амурский” фамилиясе – авылыбыз өчен гадәти түгел. Безнеке кебек чын татар авылында “ский” белән тәмамланган фамилияләр булмый торган иде. Габдерәүф абыйның баштагы фамилиясе Бухарин булган. Ул яшьтән үк авылдан чыгып киткән, укыган, җаваплы эшләрдә эшләгән, партия эшендә, хуҗалык эшләрендә җитәкче булган. Узган гасырның 30 нчы елларында күренекле партия-совет эшлеклесе Николай Бухарин, Сталин тарафыннан гаепләнеп, “халык дошманы” дип игълан ителгәч, партия эшлеклесе Габдерәүф абзый Бухарин фамилиясеннән ваз кичә, Амурский фамилиясен ала. Элекке фамилиясе комачаулагангамы, башка сәбәпләр булганмы (моньсы миңа билгесез), 40нчы елларның ахырында ул авылда иде инде. Бәлки, Габдерәүф абзый инде ул елларда пенсия яшендә булгандыр. Ләкин авылда оештырылган һәр күмәк эштә, җыелышларда ул чыгыш ясамый калмый торган иде. Калын гына күзлеген киеп, кулындагы кәгазьгә караштыра-караштыра, төпле чыгышлар ясавы, эшлекле тәкъдимнәр кертүе истә калган.

Яшелчә бакчасының хуҗасы Амурский иде. Көнен дә, төнен дә ул шунда булды. Төнлә йоклау өчен, үзенә куыш та ясап куйды. Сәрвәр абзыйлар тыкрыгыннан без буага су керергә төшәбез, су коенабыз. “Мин бүген – 10 тапкыр, мин – 12, мин 13 тапкыр су кердем”, – дип мактанышып алабыз. Амурский куышына кереп китсә, бакчадан кишер, шалкан, кыяр ише яшелчәләрне элэктерергә ашыгабыз. Ләкин бу омтылыш һәрвакытта да нәтиҗәле булмый, чөнки хуҗа куышында озак тоткарланмый.

Хәзерге вакытта буаны авылның Түбән Табынга чыгып китә торган башында зур итеп будылар. Мөслим-Чаллы асфальт юлы янәшәсендә буа мәһабәт булып җәелеп ята. Аның ярларын таллыклар каплаган. Авыл халкы буага кармак белән балык тотарга йөри. Яздан көзгә кадәр яр буенда кармак салып утыручыларны күрәсең. Ыкка терәлеп утырган күрше Тамьян, Тугаш авыллары халкы хәзер: “Югары Табыннарның казлары да йөзә белми!” – дип әйтә алмый инде... Безнең буа Ыктан киңрәк тә, тирәнрәктер дә әле!..

Буа аръягында, Мәлләтамак авылына кадәр, уңдырышлы кара туфраклы җирләр китә. Ул җирләр 8 км га сузыла. Шуның яртысы безнең авыл җирләре булып санала. Авылдан көньякка таба Тойгелде авылына юнәлгән юл белән бераз баргач, Каенлы күл иңкүлегенә җитәсең. Ул иңкүлектә җиләк күп була, печән чабалар. Көньяк-көнбатыш юнәлешендә Атлас авылына карап бер километр чамасы барсаң, Ачы чокырына килеп чыгасың. "Ачы" атамасы торфлы ачы туфрактан алынгандыр. Бу тирәдә җирләр торфлы булуы белән аерылып тора. Элегрәк җәйнең эссе көннәрендә, янып яткан торфны күрә идек. Хәзер дә янамы ул, юкмы – әйтә алмыйм, ул тирәдә булырга туры килгәне юк.

Ачыдан бер чакрымлап баруга, безнең авылның имәнлеге башлана. Элек ул, бәлки, имәнлек кенә булгандыр, хәзер инде ул – катнаш урман. Югары Табын башлангыч мәктәбендә укыганда безне шул урманга экскурсиягә алып баралар иде. Шунда җыйган үлән, чәчкә, агач яфракларыннан гербарий ясый идек.

Безнең имәнлекнең артында ук Атлас авылы урнашкан. Атластан көнбатыштарак, безгә таба, зур булмаган тагын бер урман бар. Бусын "Мәчет рушасы" дип йөртәләр иде. "Руша" сүзе "роща"дан алынган булгандыр. Бу урманга якын җирләрне Бәйсән, ди торганнар иде. Авыл халкының күпчелеге җиләкне шуннан җыя иде.

Авылдан көнбатышка һәм төньяк-көнбатышка таба 8 чакрым ераклыкта Саклаубаш, Карашай Саклау, Чураш авыллары китә. Элегрәк ул авыллар арасында Сөренчәк исемле рус авылы да бар иде. 60нчы елларда ул авыл бетте. Авыл урынында хәзер – бодай басулары. Саклаубашка карап юл тотканда, Болан яткан һәм Кара тал чокырларын үтәсе. Бу иңкүлекләрдә (халык аларны "сыза", дип йөртә иде: Каратал, Болан яткан сызалары) печән шәп үсә иде. Авыл кешеләренеке дә, колхоз көтүләре дә шунда йөрде. Маллар өчен ул сызаларда җәй көне күлләр, буалар ясалды. Төньяк-көнчыгышка таба күршебездә Тегермәнлек, Тугаш, Тамьян, Түбән Табын авыллары урнашкан.

Безнең авылдан күренекле кешеләр күпләп чыккан, дип мактанып булмый. Ләкин бармакны бөгеп саный башласаң, андыйларны шактый табарга була. Габдерәүф абзый Амурский турында әйткән идем инде. Ул кайсыдыр өлкәдәме, республикадамы – партия өлкә комитетында җитәкче вазифада булган. Сугышка кадәр безнең районның күршесе – Ворошилов районында район партия комитетының беренче секретаре булып авылыбыз кешесе Тажи абый Җиһангиров эшләгән. Эшләгән

дим, чөнки ул чорны без белмибез. Тажи абыйның сугышка җибәрелмәвен раслаучы броне булган. Әмма ул, район хуҗасы буларак, беренче суктырылган ашлыктан колхозчыларга да өлеш чыгарган. Ә шул чордагы тәртип буенча, башта дәүләткә икмәк тапшыру планы үтәлергә тиеш, аннары киләсе елга чәчүлек орлыгы калдырыла. Аннан калганы гына колхозчыларга бүленә, калмаса – юк. Бу соңгысы бик еш була иде. Яшәп килүче тәртипне бозганы өчен, җәза бирү чарасы итеп, беренче секретарьны сугышка алып җибәргәннәр...

Авылның күренекле кешеләре арасыннан мин, иң беренче итеп, Гариф Хафизович Хафизовны күрсәтер идем. Аны мин бик яхшы беләм. Безгә 13-14 яшьләр тирәсе чагында, ул армия хезмәтеннән кайтты. Флотта хезмәт иткән. Киң җилкәле матур буй-сын, матрос формасыннан, ялтырап торган кара туфлиләр, күкрәк турысыннан зәңгәр полосалы күлмәге күренеп тора, козырексыз баш киеменең артында ике лента җилферди. Бу формага, мондый күркәм фигурага бер генә авыл малае да кызыкмый калмагандыр.

Гариф Хафизович башта авылда эшләде, аннары аны "Михайловка" совхозына алдылар. Бераздан ул "Маяк" колхозы рәисе булды. Монда инде ул үзен булдыклы җитәкче, зур эшләрне башкара алу сәләтенә ия шәхес итеп күрсәтте. Шуңа күрә дә аны Мөслим район Советы башкарма комитеты председателе итеп сайладылар. Райондагы хуҗалыкларның көндәлек эшләрен, социаль мәсьәләләрне, төзү эшләрен барлык нечкәлекләре белән белгән җитәкче буларак, ул әлеге чорда районны уңай якка үзгәртте. Аның тырышлыгын республикабыз җитәкчеләре дә күрде. Гариф Хафизовичны яңа оешкан Яңа Чишмә районының партия комитетына беренче секретарь итеп сайладылар. Аның җитәкчелегендә бу район оешып, тулы көченә эшли башлады.

Мөслим районына бу елларда килгән яңа җитәкчеләр район халкы белән килешеп эшли алмады. Район халкы, Гариф Хафизовичны үзебезгә кайтаруны сорап, Татарстан өлкә партия комитетына делегация җибәрде. Райондашларыбызның үтенечләге канәгатьләндерелде. Шул көннән башлап, лаеклы ялга киткәнче, Гариф Хафизович Мөслим район партия комитетын җитәкләде, соңрак, партия бетерелгәч, район хакимиятенең администрация башлыгы булды.

Заһир Фазылович Хәбибуллин да – безнең авылныкы. Ул башта – Ворошилов районы партия комитетында, аннары

озак еллар дәвамында Мөслим районының партия контроле (соңрак – халык контроле) комитеты җитәкчесе булды.

Үзебезнең авылда да, күрше авылларда да колхоз рәисләре булып эшләгән Габдрахман Мәрданов, Идрис Җиһангиров, Әслах Салахов, Ризатдин Гафуровлар да – безнең авылдашлар!

Мәрьям апа Җиһангирова турында аерым китап язарлык. Агрономия белгечлегенә сугышка кадәр үк укып, ул Мәллә-тамак авылында "Кызыл Октябрь" колхозының агрономы булып эшләде. Эшне фәнни нигездә оештырып, ул югары уңыш алу буенча һәрвакыт районда алдынгы урыннарның берсен яулап килде. "Татарстанның атказанган агрономы" исеменә, орден-медальләргә лаек булды, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Казанышлары Күргәзмәләрендә дә катнашты, съездларга делегат итеп сайланды. Соңгы елларда ул район орлыкчылык лабораториясен җитәкләде.

Фидакарь хезмәте өчен Ленин ордены белән бүләкләнгән терлекче Фәйрушина Мосаллия апа да – безнең авылныкы!

Эшләре белән үзләрен данлаган Гайфуллиннар турында да әйтми кала алмыйм. Талибулла абый белән Сабира апаның 4 баласы да, Казандагы югары уку йортларында укып, югары квалификацияле белгечләр булып чыктылар. Фәһия, нефтьче буларак, Әлмәттә баш инженер булды. Расих һәм Рәзиф – Түбән Кама шәһәрендә, Рәис исә Казанда зур җитештерү комбинатларының Генераль директорлары дәрәҗәсенә үсеп җиттеләр.

Вәзир абыйның улы Заһир Гайфуллин Түбән Кама химкомбинатында цех башлыгы вазифасында.

Авылдашларыбыздан Ягъфәр Вәҗиев, Казан дәүләт университетын тәмамлап, авылыбызда балаларга физика-математика фәннәре укытты. Югары белемле укытучылар Саһира Җиһангирова – Тамьян мәктәбендә, Сәвия Габдуллина – Мухан мәктәбендә, Илюс Исрафилов үзебезнең мәктәптә эшләделәр.

Авылдашыбыз Рәис Хөсәеновның кызы Казан дәүләт университетында кафедра мөдире булып эшли – фәннәр докторы, профессор.

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә куйган тырыш хезмәтләре өчен, Вәзир Гайфуллин, Рафаэль Нуретдинов, Әзһәм Садриевлар "Татарстанның атказанган механизаторы" исеменә лаек булдылар.

Авылыбызның тагын бер күренекле гаярь шәхесе – хәрби очучы Фәрдетдин Сәхәбетдинов турында да язып үтәсем килә. Бөек Ватан сугышы вакытында ул, Советлар Союзы Герое Ни-

колай Гастелло үрнәгендә, зур батырлык күрсәтә. Шуңа күрә дә аны "Югары Табын Гастеллосы" дип атыйлар.

Фәрдетдин Сәхәбетдин улы 1919 нчы елның 29 нчы октябрендә Мөслим районының Югары Табын авылында туа. Авылда башлангыч мәктәпнең өч сыйныфын, Ижау шәһәрендә исә урта мәктәпне тәмамлый. Армия хезмәтенә алынгач, Сарытау өлкәсендәге Балашов шәһәрендә хәрби очучылар әзерли торган уку йортында укый. Аннары ул, үзенең "Ил-2" штурмовигы белән, дошман аэродромнарындагы хәрби очкычларны, радиолокация станцияләрен, зенит батареяларын, танкларны, фашистларның җанлы көчләрен тар-мар итүдә нәтиҗәле катнаша.

1943 нче елның 27 нче мартында кече лейтенант Фәрдетдин Сәхәбетдинов, укчы-сержант Егор Кретов белән бергә, Ленинград өлкәсенең Карбусель авылы янында дошман төзегән хәрби ныгытмаларны, аларның җанлы көчләрен, техникаларын утка тота. Шунда самолетка снаряд тия һәм ул яна башлый. Фәрдетдин дөрләп янучы самолетын фашистлар өстенә юнәлтә...

2009 нчы елда, Татарстан Хөкүмәте карары белән, Казан-Ижевск арасында йөрүче электр поездына, авылдашыбызның истәлеген мәңгеләштереп, "Батыр Фәрдетдин" дигән исем бирелде.

Бу турыда тулырак язманы танылган әзтабар язучы Шаһинур Мостафинның "Яңа меңъеллыкка очыш" (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2008) дигән китабыннан укырга мөмкин.

Нәсел тармагы

Әти ягыннан безнең әби-бабайлар крестьяннар булганнар. Әтинең әтисе Гайфулла бабай, безнең Югары Табын авылыннан 25 км ераклыкта утырган Җәмәк авылыннан Мәргубә исемле кызга өйләнеп, гаилә корган.

Мәргубә әби белән Гайфулла бабайларның 12 балалары була. Аларның зурысы Бибифатима күрше Сарман районының Кәүҗияк авылына кияүгә чыга.

Әбидән: "Син ничә яшьтә инде, әби?" – дип сорасалар, аның җавабы һәрвакыт бертөрле булды: "Баш балам Бибифатимага – 58 яшь, шуннан үзегез чамалагыз," – ди торган иде. Әби озак яшәде. Ә бу сүзләрне ул шактый еллар кабатлады әле. Баш баласына һаман 58 яшь булды.

1955 нче елда, Ташлыяр җидееллык мәктәбендә эшләгәндә, мин Кәүҗиякта булдым. Бибифатима әби исән түгел иде инде. Аның улы Хатип абый (ул 1917 нче елда туган) белән таныштым. Хәзерге көндә Хатип абыйның малае Шәих, Шәихнең

улы Шамилләр белән аралашып торабыз. Алар Сарманда яшиләр.

Бабай белән әбинең 12 баласыннан дүртесе генә исән калганнар. Калганнары озак яшәмәгән. Исәннәрдән (Бибифатима ападан тыш), әти, аның энесе Талибулла абый, аларның апасы Гайшә апа калган. Гайшә апа Тугаш авылындагы Гыйльметдин исемле егеткә кияүгә чыккан.

Бөек Ватан сугышы елларында Гайшә апа 6 баласын калдырып үлеп китә. Кече малае Сәлахетдин дә аның артыннан озак тормый, гүр иясе була.

Гайшә апа әле дә күз алдымда. Безгә килгәч, мич буендагы скамьяда чәчен тарап утырганы хәтердә калган. "Май сөртеп тарыйм әле!" – дип, әбидән май сорап алды. Тугаш җизнәй (Гыйльметдин) – фронтта, 5 бала үзләре генә калдылар: Әсләхетдин абый (13 яшьтә), Гөлсимә апа (11 яшьтә), Кәшбетдин абый (9 яшьтә), Гыйлаҗетдин (6 яшьтә), кечкенәсе Вәсимә (3 кенә яшьтә). Бик авыр еллар – сугыш чоры. Аннан да авыры сугыштан соңгы еллар булды. Өйне җылытырга да, киенергә дә, ашарга табарга да кирәк.

Без дә биш бала: Сәвия апа, Вәзир абый, мин, Һәдия, Фәһия. Зурысына – 10 яшь, кечесенә – 1 яшь...

Әти – фронтта, әнкәй – колхоз эшендә. Әнинең яман чир белән чирли башлаган вакыты. Әби мунча яга, Тугаштагы ятимнәрне дә чакыра. Мунчада барыбызны да, кызуны бик каты салып, себерке белән чаба, юындыра, киемнәрне кыздыра. Шулай көн күреп ятканда, әтиебез сугыштан кайтты. Эшли башлады. 10 бала үлемнән котылып калды! Шулай дим, чөнки ул елларда ачлыктан шактый кеше кырылды.

Әти дә, аның энесе Талибулла абый да Тугаштагы туганнарны гел истә тоталар, мөмкин булган ярдәмнәреннән ташламыйлар иде. Әйтик, безнең яктагы авыллар өчен тегермән Тугашта гына иде. Ык елгасының җайлы урынына көйләнгән әлеге су тегермәненең тарту сыйфатын мактыйлар иде. Әти дә, абый да тегермәннән кайтканда: "Монысы – балаларга!" – дип, Гөлсимә апаларга он калдырып китүне матур бер гадәткә керттеләр.

Әсләхетдин абыйны, ФЗОга алып, Чиләбегә җибәрделәр. Ул шунда паровоз йөртүче булып китте. Аның янына Кәшбетдин абый барып төпләнде. Гомер буе электровоз йөртте. Хәзер инде лаеклы ялда. Гөлсимә апа Лениногорск шәһәрен төзүдә катнашты. Шунда ул безнең күрше авыл – Саклаубаштан килгән шофер егет Миргазиянга кияүгә чыгып, ике кыз, бер егет үстер-

делэр. Алар янына Гыйлэҗетдин белэн Вэсимэ дэ килеп, тернэклэнеп киттелэр.

Сугыш беткэч, бер кулын югалтып, Тугаш җизнэй дэ кайтып керде. Бер куллы гына булса да, шактый эшлэрне бик оста башкара иде җизнэй. Бигрэк тэ тимер, калай эшенэ оста булды: түбэ япты, чилэклэр, комганнар ясады, самавырлар төзэтте h.б. Бу эшлэрдэ аңа Эслэхетдин hэм Кэшбетдин абыйлар булыша башлады.

Эти ягыннан эби-бабайлар крестьян хуҗалыклары белэн шөгыльлэнгэннэр, дигэн идем. Тырыш, уңган авыл кешелэре булганнардыр. Этидэ дэ, Талибулла абыйда да, Вэзир абыйда да, башкаларыбызда да бу сыйфатлар сизелэ иде. Колхозлар төзелмэсэ яки күмэк хуҗалыклар иртэрэк таралса, алар үрнэк хуҗалык тотучы хэлле кешелэр булырлар иде.

Сэвия апа, педучилищедан соң, Мөслим районының Мухан җидееллык мэктэбенэ укытучы итеп эшкэ билгелэнде. Берничэ елдан ул, читтэн торып укып, Алабуга педагогия институтын тэмамлады. Мухан авылы кешесе Галимҗан Эхмэтҗановка кияүгэ чыкты. Өч бала үстерделэр. Олы кызлары Элфия Чаллы шэhэрендэ табиб булып эшли. Гөлүзэ – Мөслимдэ балалар бакчасы мөдире, Гөлшат исэ Югары Табын урта мэктэбендэ укыта. Апа да гомере буе Мухан балаларын укытты. “Халык мэгарифе отличнигы” исеменэ лаек булды. Апа да, җизни дэ Мухан халкының ихтирамын казандылар. Апа – хэзерге көндэ лаеклы ялда, җизни, кызганычка каршы, бу дөньядан китеп барды...

Ападан соң, безнең гаилэдэ икенче бала – Вэзир абый.

Ул миннэн ике яшькэ олырак. Математикадан көчле иде. Кайвакытта мин чишэ алмый интеккэн мэсьэлэлэрне Вэзир абый җиңел генэ чишеп ташлый иде. Укырга сэлэте булса да, аңа алга таба укырга туры килмэде. 7нче класстан соң ул колхоз эшенэ кереп китте.

Яшьтэн үк аның кул эшенэ осталыгы хэйран калырлык иде. Эле дэ хэтердэ, без бэлэкэй чакта, ул курчаклар ясый иде. Курчакларга күлмэк, кофталар тегеп кигерэ. Йон җебеннэн башлык бэйли. Йонын үзе җегерли, җеп ясый.

Бервакыт ул миңа үзенең “хуҗалыгы” белэн мактанды: өйалды астына кечкенэ генэ баз казыган. Ул, базның авызын ачып, андагы байлыкларын чыгарып күрсэтте. Анда ни генэ юк?! Брынза да, эремчек тэ, каймак та, катык та шунда! Безнең “Ак бэкэл” кушаматлы бик зур гэүдэле сарык бар иде. Аның

сөте күп булыр иде. Вазир абыйның базындагы байлыклар "ак бәкәл" нигъмәтләре булып чыкты.

Вәзир абый безнең барыбызга караганда да шаянрак иде. Шуңа күрәдер, аңа әтидән бераз эләккәли дә иде. Берәр сәбәп белән үзенә кырынлык килүен сизсә, ул шунда ук иске туның киеп куя. Җәза бирелгәндә туны "шап-шоп" килеп торса да, үзенә авыртырлык зыян килми иде бугай.

Безнең авыл Сарман районына бара торган юл өстендә урнашкан иде. Петровский аракы заводыннан тауар ташучылар безнең авыл аша үтәләр иде. Элекке вакытта юлларда асфальт та юк, чуер таштан да булмый иде. Транспорт сирәк йөргәнгәме, авыл эчендә юл тип-тигез, чокыр-чакырсыз булды. Ләкин безнең каршыда тар гына чокыр бар. Ул язгы ташу суыннан шулай чокырланып кала.

Бер җәйге җылы көндә, без Вәзир абый белән капка төбендәге эскәмиядә утырабыз. Югары очтан шактый зур тизлектә бер машина килә. Безнең турдагы теге чокырны чамаламый калды бугай, тизлеген киметмичә чокырга килеп керде. Машина, трамплиннан сикергән кебек, зур сикереш ясады. Машинага ящиклар белән аракы төялгән булган. Ящиклар өстендә ике ир кеше утырып кайткан. Машина сикергәч, безнең күз алдында бик кызык тамаша пәйда булды. Кузовтагы теге ике агай һавада очалар, өскә таба машинага төялгән ящиклардан аракы шешәләре атыла. Җиргә шактый гына аракы шешәләре сибелде.

Машина туктады. Сибелгән шешәләрне җыйдылар. Аларның кайберләре ватылган. Ватылганын да, ватылмаганын да исәпләп карадылар. Берничә шешә җитми. Алары кая киткән?

– Машина тирәсендә бер малай йөрде, – ди берсе.

Мин ул тирәгә бармадым, әллә Вәзир абый микән? Өйдән әнкәй чыгып, Вәзир абыйны нык кына кысып сорады. Яшереп куйган җиреннән өчме, дүртме шешә аракы чыгарып бирде Вәзир абый.

Бу шешәләрне кай арада алып кереп яшереп өлгергән, диген – исең китәрлек! Мин күрми дә калдым. Ул вакытта аңа 10-11 яшьләр тирәсе булгандыр...

Без үскәндә ашау яклары нәкыс иде бит инде. Ипи бик аз эләгә. Анысы да, күпчелеге, кырылган бәрәңгедән була. Беркөнне өстәл тирәли утырып, бәрәңге ашыйбыз. Безгә берәр кисәк ипи дә эләкте. Бу кисәкне без бик озакка сузмадык. Вәзир абый да безнең белән рәттән ипиен ашаган кебек итеп утыра. Соңыннан беленде, аның ипие шул килеш. Кабып та карамаган. Ипи-

ен күрсәтеп, безне кызыктырып кына утырганда, кулыннан шул кисәге төшеп тә китте һәм идәнгә тәгәрәде. Ул өстәл башында, стена буенда утыра иде, шуңа күрә ул тиз генә ипие артыннан идәнгә төшеп китә алмады. Беренче сүзе шул булды:

– Тотыгыз песине, тотыгыз!..

Песи эләктереп чапса, ипидән колак кагасын ул шундук аңлады. Песине тотсак, ипие исән кала, янәсе!..

Вәзир абый, 7нче классны тәмамлауга, колхоз эшенә тартылды. Башта ферма малларын, тайлар көтте, тракторда прицепщик булды. Армиядән кайтуга, Чаллыга механизаторлар курсына китте. Гомере буе тракторчы һәм электро-газосварщик булып эшләде. Эшен бик яратты, һәрвакыт алдынгылар рәтендә йөрде, бүләкләрне күп яулады, "Татарстанның атказанган механизаторы" исеменә лаек булды.

Вәзир абый үзебезнең авылдан Хәерлевәрә исемле кызга өйләнде. Аларның уллары Заһир, Казан химия-технология институтын тәмамлап, Түбән Кама химия комбинатына эшкә килде. Бүгенге көндә ул – әлеге комбинатның цех начальнигы.

Олы кызлары Зөлфия Әлмәттәге сәүдә техникумын тәмамлады һәм шул юнәлештә Әлмәттә эшли. Зөлфиянең улы Ирек тә әнисе юлыннан китте. Ул хәзер Әлмәт сәүдә техникумында укый.

Вәзир абыйның кече кызлары Рәмзия, Казан финанс-экономика институтын тәмамлап, Чаллыда яши. Бүгенге көндә ул – Чаллы политехника академиясенең баш бухгалтеры.

Сеңлебез Һәдиянең дә хезмәт юлы мәгариф системасында үтте. Ул балалар бакчасында тәрбияче булды. Үзе кебек булдыклы ире Камил белән Мөслимдә яшиләр. Кызлары Альфира Түбән Кама шәһәрендә яши, музыка укыта; малайлары Илнур Чаллыда инженер хезмәтен башкара.

Әнкәй ягыннан безнең нәсел – муллалар токымыннан. Бабай тиешле кеше – әнкәйнең әтисе Җәмәк авылы мулласы – 1921 нче елгы ачлык вакытында гаиб була. Чаллыдан кайтып барышлый, караңгы төшеп килгәндә, аның Хуҗәмәт авылына җәяүләп кереп киткәнен күрүчеләр булган. Мулла абзыйның авылдан чыкканын күрүче, кая киткәнен белүче дә юк. Ачлык ел булуын исәпкә алсаң, аның юкка чыгуының сәбәбен гоманларга да була. Шуннан соң Бибигайшә абыстай – безнең булачак әби – кызы Тәгъзимә белән туганнары янына Түбән Табынга кайта. Алар Миңнеямал, Шаффа апалар, Тимер абыйлар белән шунда яши башлыйлар.

Бибигайшә әбине Тамьяннан Гобәйдулла бабай икенче хатын итеп алып китә. Безнең булачак әнкәй – Тәгъзимә – Түбән Табында Шаффа апалар янында үсеп җитә. Һәм безнең әтигә – Габдуллага кияүгә чыга.

Без биш бала булдык: Сәвия апа, Вәзир абый, мин, сеңелләребез Һәдия белән Фәһия. 1944 нче елда яман чир белән әнкәй үлеп киткәч, әтигә өйләнергә туры килде. Без икенче әни – Разия белән үстек, бергә яшәдек. Үги әни турында язганда яки сөйләгәндә, күпчелек очракта, аны тискәре яктан күрсәтәләр. Безнең икенче әнине мин алай димәс идем. Безнең ил өчен, бигрәк тә авыл халкына, бу еллар бик авыр иде. Фәкыйрьлекнең иң түбән дәрәҗәсендә идек. Ашарга ризык, кияргә кием булмады. Гаиләдә тавыш-гауга да җитмәүчелектән килеп чыга бит ул. Безнең гаилә тавышлы булды, димәс идем. Гаиләдә һәрберебезнең вазифасы билгеләп куелган, шуны тәртип белән генә башкарып барабыз. Җәй көне булса, күбрәк вакыт бәрәңге бакчасында үтә. Яз көне ул җирне казыйбыз, бәрәңгене утыртабыз, бераздан чүпләрен утыйбыз, кәтмәнлибез, аннары бәрәңге төпләрен күмәбез. Эшнең һәр төре алдыннан бәрәңге җире өлешләргә бүленә. Һәркем үз өлешен эшләп чыга. Әле дә хәтердә: апа, Вәзир абый һәм мин бәрәңге күмәбез. Эссе көн. Тамак та кибә, ашыйсы да килә. Шунда апа миңа әйтә:

– Апаем Васил (безнең якта "апаем" дип үзеңнән кечерәк кешегә әйтәләр), синең ике рәтеңне Вәзир белән бергә эшләп бетерербез! Ә син бар әле, яланнан җиләк җыеп алып кил! Катыкка салып, ашап алырбыз...

Ул елларда безнең бәрәңге бакчалары артындагы яланда җиләк күп булыр иде. Үлән дә олы болындагы кебек үсә иде. Хәзер инде ул урыннар авыл хуҗалыгы техникасы, машиналар белән тапталып беткән. Җиләк түгел, яшел чирәмен дә таба алмассың. Ул елларда (40-50 нче еллар) җиләк күп иде. Мин, каен тузыннан ясалган тырыс алып, тиз арада җиләк тә җыеп китердем. Баздан салкын катык алып чыгып, җыйган җиләкне шунда болгатып, тәмләп ашадык.

Кыш көне эш төрләре алышына. Иртән торуга, кар яуган булса, тиз генә юлларны ачып куясың. Аннары бәрәннәрне имезеп аласың, ягарга әзерләгән әйберләрне (салам, тирес кирпече яки утын) өйгә кертәсең, сыерны өйдә савасың, бозавын имезәсең. Аннары малларны абзардан лапаска чыгарып, ашарларына саласың. Шуннан соң мичкә тәгәрәткән бәрәңгене капка-

лап аласың. Күп вакыт ипи булмый. Булса да, ул ипинең күп өлеше кыргычтан чыгарылган бәрәңгедән тора. Аннары күрше Түбән Табын җидееллык мәктәбенә йөгерәбез. Мәктәптән кайтуга, караңгы төшә башлый. Әле көндәлек башкарыласы эшләр эшләнеп бетмәгән: абзардагы малларның төн уздыра торган урыннарын тизәкләрдән чистартасы бар. Бу эшне дә белеп башкарырга кирәк. Сыер ятасы урында каты әйберләр калмасын дип, тикшерү өчен, ятып, аунап та аласың. Аннары ул ятасы урынның саламнарын яңартасың. Төнгә ашарына саласың. Аннары бәрәннәрне кичке имезү, сыерны кичке саву башлана...

Кичке аштан соң, дәрес әзерләргә утырабыз. "Җитәр сезгә, иртәгә иртүк торасыгыз бар!" – дигән кисәтү сүзләреннән соң йокларга ятабыз...

Шундый тәртип мин җидееллык мәктәпне тәмамлаганчы дәвам итте. Аннары Минзәләгә, педучилищега укырга киттем. Ул уку йортында миңа кадәр Сәвия апа укый башлаган иде инде. Ике ел без бергә укыдык. Апаның анда булуы миңа Минзәлә шартларына ияләнергә ярдәм итте.

...Әнкәйнең әнисе Бибигайшә әбинең Гобәйдулла бабай белән өч баласы була: Нурлыгаян, Миннегаян апалар һәм Нурулла абый. Нурлыгаян апа гаиләсе белән Мөслимдә яшәде, почта, заготконтора хезмәткәре булып эшләде. Миңнегаян апа гаиләсе белән Мөслим районының Мухан авылында яшәде. Ялга чыккач, алар Әлмәт районының Мактама поселогында яши башладылар.

Нурулла абый, минем кебек, гомерен мәгарифкә багышлады. 1955-56 нчы уку елында мин Ташлыярда булсам, ул Михайловка мәктәбендә мөгаллимлек итте. Ташлыярда әбинең сеңелләрендә бергә тордык. Икенче елны мин Казан пединститутына укырга киттем. Нурулла абыйны Михайловка мәктәбенә директор итеп билгеләделәр.

Әбиләр картая башлагач, ул алар янына Тамьянга кайтты, Түбән Табын урта мәктәбенең директоры булды, уңышлы гына эшләде. Әбиләр бакыйлыкка күчкәч, ул Лениногорск шәһәренә китте. Анда мәктәп җитәкчесе булып эшләде, хезмәт юлын Алабуга пединститутының Лениногорскидагы филиалында тәмамлады, студентларга физика фәненнән укытты.

Кече туганы Талибулла абый белән әти чын туганнарча яшәделәр. Бер-берсен бер көн күрми тору алар өчен мөмкин булмаган хәл иде. Эштән кайтканда, һәркөн диярлек, абыйлар-

га әти кереп чыга, әти керә алмаган көнне Талибулла абый безгә килеп җитә.

Мунча ягылган яки берәр затлырак ризык пешерелгән көн булса, әтинең кайтып керүгә беренче сүзе: "Абыеннар чакырылганмы?" – булыр иде. Безнең берәребез, бу эш эшләнмәсә, шул минутта ук аларны чакырырга йөгерер идек.

Талибулла абый авылның хөрмәтле кызы Сабира апага өйләнде. Ул колхозның бригадиры иде. Аның белән атка утырып, басулар карап йөрү минем өчен матур ядкарь булып истә калган.

Апа белән абый бик тату, матур яшәделәр. Дүрт балалары туды. Балалар яхшы укыдылар, тәртипле булдылар. Расих белән Разифны Мөслим урта мәктәбендә миңа укытырга туры килде. Икесе дә мәктәпне алтын медальгә тәмамладылар. Расих, Разиф, Фәһия Казанда химия-технология институтын тәмамлап, инженер булдылар, Расих белән Разиф – Түбән Камада, ә Фәһия Әлмәттә җитәкче урыннарда эшләделәр.

Рәис Казанда пединститут тәмамлады, математик булды, армиядә хезмәт итеп кайткач, мәктәптә, пединститутның физмат факультетында студентларга математика укытты.

Шушы эшне дәвам итеп, галим булырлык сәләте дә бар иде Рәиснең. Әмма ул иптәш егетләре йогынтысында промышленность предприятиесенә китте. Сәләтле белгеч буларак, аны башта – бүлек мөдире, аннары – директор урынбасары, аннары Казандагы "Татметалл" предприятиесенең генераль директоры итеп сайладылар. Бу эшне ул шактый уңышлы башкарды. Россия өлкәләре, СНГ илләре белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштырды. Рәис хәзер дә шушы юнәлештә уңышлы гына эшләп йөри.

Балалык елларының истә калган мизгелләренә тукталам.

Көз көне авылда урып-җыю эшләренең иң кызган вакыты. Авылның барлык эшкә яраклы кешесе кырда, ындыр табагында, фермаларда. Безнең әни дә ындыр табагында, ашлык җилгәрәләр. Мин дә шулар тирәсендә чуалам. Чамалавымча, миңа 4-5 яшь тирәсе.

Мондый кызу эш вакытында колхозда эшләүчеләргә гомуми туклану оештырыла. Бу көнне ындыр табагында эшләүчеләргә умачлы аш пешергәннәр иде. Колхозчылар, икмәк өстенә таралышып утырып, аш ашарга керештеләр.

– Өйдә балаларым ач утыра, – дип әнкәй ашны чиләгенә күбрәк итеп салдырды, һәм без өйгә юнәлдек. Чиләкнең бер ягыннан – әнкәй, икенче ягыннан мин тотып, өйгә кайтып барабыз. Борынны чиләктәге аштан килгән тәмле исләр кытыклый.

Апа, абый, мин һәм сеңлем (ул вакытта әле сеңлебез Фәһия юк) аш ашап калдык, әнкәй ындыр табагына эшенә ашыкты. Кысыр аш булса да, арыш оныннан уылган умачлы аш безнең күңелләргә бик хуш килгән иде.

Әни белән булган тагын бер истә калган хатирә – ул безнең Тамьян әбиләргә кунакка баруыбыз. Әбиләрдә кунак булганнан соң, үзебезнең авылга кайтып барабыз. Тып-тыныч төн, кышкы юлда чана шыгырдавы гына ишетелә. Авылдан чыгып киләбез. Шулвакыт бер егет җыр башлады. Егетнең тавыш мөмкинлекләре дә, халкыбызның моңын бирү сәләте дә югары дәрәҗәдә иде. Мине бу җырны башкаручының урамда бөтен кеше ишетерлек итеп җырларга кыюлыгы һәм осталыгы сокландырды. Шәп җырлый иде егет. Әнкәй юл буе шул җырны әкрен генә шыңлап кайтты. Авыз эченнән сүзсез генә шыңсыса да, аның бу көйне җиренә җиткерүе сизелә иде. Димәк, әнкәйнең җырга битараф булмавы, чыннан да, дөрес.

Нурлыгаян апа һаман әйтә иде: "Муллаттәй (әнкәйнең мулла кызы булуына ишәрә) бик матур җырлый иде, тавышы да бик матур иде. Сезнең барыгызның да (Сәвия апа, Вәзир абый, мин, Һәдия сеңлебез) җырлау сәләте шуннан килә," – дип. Мин дә шулай уйлыйм! Әтине матур җырлый, дип әйтә алмыйм, әмма тавыш мөмкинлекләре зур иде. Әнкәйнең әйткәне истә калган. Әтигә ул әйтә иде: "Синең тавышың гөргелдәп чыга!" – дип...

Тихния

Минзәлә педагогия училищесында 1951-1955 нче елларда без Тихния белән бер төркемдә укыдык. Ул елларда училищега һәр елны 75 укучы алалар иде. Алар өч төркемгә бүленеп укыйлар: ике татар төркеме һәм бер рус төркеме. Без татар төркемендә идек. Барыбыз да диярлек – авыл мәктәпләреннән, Минзәлә тирәсендәге районнардан. Мөслим районыннан без өчәү идек: Яңа Сәеттән – Тихния Миргалимова, Метрәйдән – Нурия Абдуллина һәм Югары Табыннан – мин...

Безнең төркем башкалардан тыйнаклыгы һәм тәртипле булуы белән аерылып торды. Моңа безнең төркемнең житәкчесе, педагогика укытучысы Сания Гомәровна Гобәйдуллина булуы да сәбәпче булгандыр. Ул бездә тату коллектив, булачак укытучы сыйфатлары тәрбияләү өчен күп көч куйды.

Педучилищеның читтән килүчеләр өчен тулай торагы бар иде. Нишләптер, безнең төркемнән анда беркем дә тормады.

Без Минзәлә кешеләрендә фатирда яшәдек. Мин торган фатирдан ерак түгел генә Тихния, Гөлҗәүһәр Газизова, Фәймә Низамова, Рәйсә Самаркиналар яшәде. Дәресләрне бергәләп әзерләү, имтиханнарга да бергә әзерләнү практикасы бар иде. Тихния белән Гөлҗәүһәр бергә торганлыктан, шунда җыелып, дәрес әзерләүләр истә калган. Арабызда Гөлҗәүһәр кыюрак та, шуграк та иде. Бераз дәресләрне карагач, тәнәфес ясап алабыз. Гөлҗәүһәр шунда тәкъдим кертә. "Миндә Рәмзия ападан калган бизәнү әйберләре бар. Әйдәгез, бизәнеп алабыз!" – ди ул. Көлешә-көлешә битләрен буйый башлыйлар, бер-берсенә карап көлешәләр. Әлбәттә, бу эш белән шөгыльләнү тәҗрибәсе берсендә дә юк.

– Әйдәгез әле, Василны да бизәндерик, аңа бизәнү килешә микән?

Бусы да – Гөлҗәүһәр тәкъдиме.

– Китегез әле, нинди бизәнү ди ул, якын килмәгез! – дип мин көч-хәл белән котылып калам.

Бергәләп дәрес әзерләү күбрәк математика фәннәреннән була иде. Арифметикадан өйгә бирелгән мәсьәләләр шактый катлаулы булыр иде. 15-16 гамәл ярдәмендә чишелгәннәре бар. Бергәләп аларны җиңә идек. Алгебрадан бирелгән биремнәрнең күплеге истә калган. Бу фәннән безне Газизов абый укытты. Бик таләпчән иде. Дәрескә звонок булуга, бер секунд вакытын әрәм итмичә, ул класска килеп керә. Ишекне ачуга, һәрберебезгә эш куша башлый:

– Мидхәт, син тактаның теге ягында 1 нче мәсьәләне чишәсең; Рәисә, син – тактаның икенче ягында 2 нче мисалны чишә тор, Тихния – өстәл янында, Гөлҗәүһәр – тәрәзә төбендә, ә Тәнзилә – телдән кагыйдәне әйтә торсын.

Шулай итеп остазыбыз үзенең өстәле янына барып җиткәнче, ярты төркемгә эш кушып өлгерә. Көчле укытучы иде. Шуңа да алгебрадан билгеләр, гадәттә, "4"ле һәм "5"ләр генә булды.

Тәнәфес вакытларында танцыга өйрәнүләр истә калган. Монда бигрәк тә Нурия актив иде. Ул үзе белгән "Краковьяк", "Вальс", "Танго" кебек танцыларны безгә теләп өйрәтә иде.

Педучилищеда уку культы көчле иде. Дәрескә әзерләнмичә килүне мин хәтерләмим. Башкалар да шулай булгандыр. Нәзирә Фәтхетдинова дигән кызыбызга гына кайбер фәннәр авыр бирелә иде. Аны да, дәрескә кадәр, өй эшен сөйләп бирерлек дәрәҗәгә китерергә тырыша идек.

Тихниялəр торган фатирга барып йөргəлəү, дəреслəр əзерлəү, танцыларга өйрəнү, педучилищедагы төрле чараларда катнашу вакытында ошату, якын итү хислəре уянгандыр миндə Тихниягə карата.

Тихния яхшы укучылар рəтендə иде. Ул һəрвакыт стипендия алучылар арасында булды. Стипендиясез уку мөмкин дə түгел иде. Аның да əти-əнилəре колхозчылар иде. Колхозчыга ул елларда хезмəт хакы итеп акча бирү тəртибе юк. Колхозчы, бераз гына икмəк алуын санамаганда, бушка эшлəде диярлек. Анысы да ел буена ашарга җитми. Ə ул икмəкнең бер өлешен, онга əйлəндереп, сатасы да бар – чөнки колхозчының күп сандагы налогларны һəм заемнарны түлисе бар.

Тихния матур итеп яза иде. Шуңа күрə ул педучилищеның стена газетасында редколлегия члены булды. Өстəвенə, газетаның секретаре да иде. Ул елларда компьютер турында уйлыйсы да юк, машинка да булмагач, газеталарны Тихния кулдан яза иде. Матур почерк белəн язылган ул стена газеталарын яратып укый идек.

Педучилищены тəмамлагач, төркемебез белəн җыелып чəй эчү мəҗлесе исемдə калган. Анда Тихния, Гөлҗəүһəр, Нургаян, Нурия Габдуллина һ.б. бар иде. Шуннан соң без таралыштык. Аннары Тихния белəн мин, институт тəмамлап, Мөслим урта мəктəбендə завуч булып эшли башлагач, яңадан очраштык. Ул инде Мөслим РОНОсының методик кабинеты мөдире иде.

Үзешчəн сəнгатьтə дə Тихния сизелерлек эзен калдырды. Ул нəфис сүз остасы һəм концертларны алып баручы – конферансье ролен җиренə җиткереп башкара иде. Мөслим клубындагы концертлар аның катнашыннан башка узмады.

Бервакыт, 1964 ел булып истə калган, республиканың күп кенə районнарыннан урып-җыю чорында концертлар белəн чыгыш ясаган агитбригадаларны Казанга җыйдылар. Казан клубларында без концертлар куйдык. Махсус комиссия безнең чыгышларны бəялəп барды. Яхшы номерларны республиканың “Уңыш бəйрəме” көнендə Муса Җəлил исемендəге опера һəм балет театрында булачак концертка сайлап алдылар. Ə безнең Мөслим районы агитбригадасының программасын бу концертка тулысы белəн керттелəр. Безнең концерт, чыннан да, шəп иде. Җырчылар Гаяз Авзалов, Рафаэль Əхмəтов, Халидə Уразаева, Рəзинə Абиева, мин фəкыйрегез, биюче Əдип Салихов, баянчы Изаил Хадиуллин, нəфис сүз остасы Тихния Гайфул-

линаларның чыгышлары югары профессиональ дәрәҗәдә, дип бәяләнде.

Шуннан соң безне телевидениегә чакырдылар. Безнең чыгышны республикага яңгыраттылар, уңышлы чыгышларыбыз белән котладылар.

Телевидениенең өлкән редакторы Әминә Сафиуллина шунда безгә китми торырга кушты:

– Кайчаннан бирле телевидениегә хатын-кыз диктор эзлибез, күпме конкурслар уздырдык, безгә кирәкле кешене таба алмыйбыз, әле тегс, әле бу ягы ошамый, – диде ул. – Менә, ниһаять, таптык! Сезнең коллективтан Тихния Гайфуллинаның тавышы да, дикциясе дә, сөйләү техникасы да, төсе-бите дә безгә ошады. Без аны хәзер директорыбызга күрсәтәбез һәм үзебезгә эшкә калдырабыз!

Мондый бәяне ишетү безгә ошаса да, кинәт кенә ясалган тәкъдимгә әзер түгел идек. Безнең әле яңа гына гаилә корган чорыбыз иде бу. Әлеге тәкъдимне кабул итә алмадык, Мөслимебезгә кайтып киттек...

Минем уйлавымча, без бер-беребезне дөрес таптык, яратып яшәдек, тату гаилә кордык, бер-беребезне хөрмәт иттек, менә дигән балалар үстердек. Кызыбыз Лилия дә, улыбыз Айрат та урта мәктәпне алтын медальгә тәмамладылар. Алар ул елларда бик дәрәҗәле саналган югары уку йортларына укырга керделәр. Лилия – медицина институтын, Айрат Казан дәүләт университетын кызыл дипломга тәмамлады. Үзләренең эшләре буенча югары дәрәҗәле профессионаллар, белгечләр булдылар.

Хатыным Тихния барлык эшне бөтен күңелен биреп, яратып башкара иде. Районда укытучыларның методик осталыгын үстерү өчен, аның инициативасы белән яңалыклар күп керде ул елларда. Әйтик, һәр мәктәпнең үзенә хас эш алымы, уңай нәтиҗә бирә торган тәҗрибәсе була. Моны башкаларга ничек җиткерергә? Әлеге мөһим эшне башкару юлын да уйлап таба Тихния. Район методика кабинетында “Алдынгы тәҗрибә” альбомы булдырыла. График буенча, бу альбом мәктәпләргә җибәрелә. Һәр мәктәп үз тәҗрибәсен шунда язып, әлеге альбомны күрше мәктәпкә җибәрә. Альбом, мәктәпләрне йөреп чыгып, РОНОга кире әйләнеп кайтканда анда кыйммәтле хәзинә тупланган була. Аннары язмаларның иң яхшылары, район газетасы битләрендә методик бюллетень рәвешендә бастырылып, мәктәпләргә таратыла.

Без, өйләнгәч, икебез дә берничә ел РОНОда эшләдек әле. Шул еллар турында уйласаң, хәйран калырлык. Яшь-яшь ике балабызны Хәят апага калдырып, атналар буе мәктәпләр тикшереп йөрибез. Әмәкәй, Тат. Бүләр, Сикия, Үрәзмәт, Баек һ.б. Бу мәктәпләргә ат белән барып җитү өчен генә дә бер көн кирәк. Ул мәктәпләрне тикшергәндә, шунда яшибез. Мөслимгә бер атнадан соң гына кайтабыз. Ел буена мондый командировкалар шактый җыела иде.

Аннары Тихния эшкә Мөслим урта мәктәбенә күчте. Мәктәптә эшләгәндә дә Тихния беренче урынга эшне куя иде. Төннәр буе дәфтәр тикшереп, дәрес планнары төзеп утырса да, беренче дәресенә ул һәрвакыт кимендә ярты сәгать алдан бара торган иде.

Эшен яратып башкару, даими рәвештә иҗади эзләнү, балаларда ана теленә, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү үзенең җимешләрен дә бирде. Ул "Татарстанның атказанган укытучысы" дигән мактаулы исемгә лаек булды. Аның күп сандагы шәкертләре уку йортларына укытучылары юлы белән китте. Хәзер аларның байтагы – танылган укытучылар, шагыйрьләр, язучылар, журналистлар!..

Тихния һәрвакыт эзләнә, яңалыкка омтыла. Шул эзләнүләренең матур нәтиҗәсе буларак, аның күп сандагы мәкаләләре фәнни-методик журналларда басылып чыкты. Шуңа күрәдер, дәреслекләр чыгаручы күренекле галимнәр, бу эштә соавтор итеп, үзләре янына Тихнияне алырга да тырыштылар. Алар, шулай итеп, урта мәктәпләр өчен татар теленнән уңышлы дәреслекләр яздылар.

Тихниянең таләпчәнлек сыйфатын да әйтеп үтәсем килә. Укучыларга билгеләр куйганда, бу сыйфат бигрәк тә ачык чагыла. Кемдер тарафыннан укучыга ташлама ясау, билгесен күтәрү турында соравны ул бервакытта да кабул итмәде. Ул үзенең гадел таләбеннән чигенүне белми иде.

Мондый катгыйлык безнең балаларда да сизелә. Бер мисал китереп үтим әле.

...Туганнарның балалары, Казандагы теге яки бу уку йортына укырга керергә килгәч, бездә торалар иде. Ул балаларның укуга керүе өчен җаваплы кеше буларак, аларны кабул итү имтиханнарына әзерләү – минем контрольдә. Физика-математика фәннәренең әзерлек дәрәҗәсен үзем тәэмин итәм. Рус теленнән изложение, сочинениегә әзерләнүдә безнең балалар булыша. Алар көн саен "абитуриент"лардан берничә сочине-

ние, изложение яздыралар, аларны тикшерәләр, әзерлек дәрәҗәсен яхшырталар.

Бер көнне эштән кайтып керсәм, Лениногорскидан килгән сеңлебезнең кәефе китеп, елап, күзләре кызарып беткән."Нәрсә булды?" – дип сорыйм. "Айрат сочинениегә "4"ле куйды. "5"ле куярлык иде", – ди ул. Айраттан сәбәбен сорыйм. Аның җавабы әзер: "Бер хата да булмаса гына сочинениегә "5"ле куела. Мин сочинениене бәяләү нормаларын беләм. Аның бер орфографик хатасы бар иде", – ди ул. Гадел таләпкә каршы бер сүз дә әйтеп булмый.

Таләпчәнлек белән бәйле тагын бер сыйфат турында әйтим әле. Бу сыйфат – кемнең кем булуына карамастан, кешенең күз алдында дөресен әйтү. Тихниядә инде бу сыйфат артыгы белән.

Шулай бервакыт Марсель Әхәтович белән эштән соң бер танышларда булдык. Күптән очрашмаган булганбыздыр, күрәсең, озаграк утырылган. Кайтып киләбез Марсель белән, безнең турга җиттек. Нидер җитеп бетмәгән булды микән: "Безгә кереп, бер стакан чәй эчеп чыгыйк инде!" – дип Марсельне кыстый башладым. Кыстый торгач, ризалаштырдым да. Бишенче катка мендек. Звонокка басам. Ишекне Тихния ачты. Беренче сүзе шул булды:

– Оятыгыз бармы сезнең, юкмы? Сәгать беренче китте бит. Кайда йөрдегез бу гомер?

– Менә Марсельне чәй эчәргә чакырдым.

– Бу вакытта нинди чәй ди ул?!

Моңа кадәр сәгатькә каралмаган икән. Карасам, үземә дә читен булып китте. Сәгать төнге уникె үтеп, бергә якынаеп бара. Артка борылып карыйм – кунагым юк. Тихниянең беренче җөмләсеннән үк ул юк булган иде инде.

Марсель Әхәтович Бәширов – гаиләбез дусты. Бу чорда ул безне фатирлы итү өчен биниһая зур хезмәт куйган кеше. Бер ялагай хатын булса, еландай телләрен чыгарып, кунакны өйгә чакырыр иде. Бу инде Тихния булмас иде.

Икенче көнне без үзебезне соңгы сүзләр белән сүктек. Шушы көннән соң, Марсельнең Тихниягә ихтирамы тагын да арта төште. Туган көннәр, юбилейлар булганда, без очрашабыз. Гадәттә, мондый чараларда юбилярга мактау сүзләре күп ява. Марсель Әхәтович исә сүзен һәрвакыт Тихнияне мактаудан башлый: "Василның ирешкән уңышларында да Тихниянең хезмәте 90% ка тигез!" – ди ул. "Әзрәк киметмисеңме бу процентны, хотя бы 10%ка", – диючеләр дә була. Ә бит, чынлап та, Марсель Әхәтович дөресен әйтә.

Ирешкән уңышларымда аның өлеше зур, дип саныйм мин дә. Ленинградка 3 еллык аспирантурага киткәндә, гаиләне алып бару Тихния өстендә калды. Балалар әле яшь. Лилия белән Айрат балалар бакчасына йөриләр. Аларны илтәсе, алып кайтасы бар. Авыл шартларында тормышның башка мәшәкатьләре дә җитәрлек. Өч ел буе шушы вазифаларны Тихния үзе генә башкарды.

Аспирантура тәмамлангач та тормыш җиңеләймәде әле.

Мине Казан дәүләт педагогия институтына эшкә җибәрделәр, гаилә һаман Мөслимдә калды. Пединститут миңа фатир бирә алмый. Мин башта Равил Шамиловичлар фатирында тордым. Аларның да фатиры үзләренеке түгел. Бераздан мин студентларның тулай торагына күчтем. Аннары Равил һәм Котдус ярдәме белән бер фатир таптык. Федосеевка урамында Хәмәт абый белән Мәйсәрә апаларда яши башладым.

Ниһаять, 4 ел асрым яшәгәннән соң, фатир юнәтеп, гаиләмне Казанга алып килдем. Фатир дигәне дә әллә ни түгел инде. Пар бүлмәле бер "куыш"та ике гаилә торабыз. Безгә дигән бүлмә 9 кв.м чамасы булыр. 115 сумлык минем ассистент хезмәт хакының 50 сумын фатир хуҗаларына түлибез. Кечкенә генә бүлмәдә дүртәү яшибез. Шуның өстенә, еш кына Мөслимнән килгән кунакларны да кабул итәбез, йокларга да калдырабыз.

Бу шартларда яшәү Тихниягә дә җиңелдән булмады. Ләкин ул әлеге авырлыкларга түзде. Мөслимдәге ярыйсы гына фатирны калдырып, мондый шартларга дучар итүдә мине гаепләмәде. Авырлыкларны бергәләп уздырдык. Моның өчен Тихниягә рәхмәтем чиксез!

~139196(1)

Тихниянең уңай сыйфатлары күп инде аның. Шуларның берсе – ул үзенең туганнарын да, минем туганнарны да бердәй якын итә. Безнең нәселдә туганнар белән үзара аралашып-саклашып яшәү гомер-гомергә булган. Минем бәхеткә, Ходай Тәгалә мондый сыйфатларны Тихниягә дә мулдан биргән. Якын туганнар булса да, ерак туганнар килсә дә, бездә бәйрәм була. Дуслар, туганнар белән аралашу, бәйрәмнәрне бергә уздыру, мәҗлесләр җыю – бездә матур бер традиция ул.

Тихниянең тагын бер уңай сыйфаты – бакча эшен яратуы. Бакчадагы эшләрдән ул ләззәт ала. Бакчабызның Казаннан ерак булмавы, якында гына Идел елгасы, күлләр, урман булуы да аның күңеленә хуш килә. Иртә яздан көзгә кадәр ул бакчада яшәргә риза. Андагы эшләрнең дә тәртибен яхшы белә. Яшелчәләрне вакытында утырту, җиләк-җимеш куакларын

эшкәртү, өлгергәннәрен тозлау, консервалау, как кою һ.б. эшләр югары профессиональ дәрәҗәдә башкарыла.

Тагын бер яраткан шөгыле – үзебезнең бакчада мунча керү. Тиешенчә парланып, каен себеркесе белән чабынып, мунча керүне һәрвакыт яратып башкара. Кайвакытта бер яккан мунчага икешәр-өчәр кат керә. Әнә шундый инде ул минем Тихния!.. Ул, Гаилә кояшыдай балкып торганга, тормышыбыз матур дәвам итә...

Печән кыйссасы

Без яшь чакта авыл баласы крестьян хуҗалыгында була торган эшләргә өйрәнеп үсә иде. Кыш көне, иртүк торып, башта сарык бәрәннәрен имезәсең. Аның өчен бәрәнле сарыкларны өйгә кертәсе, сарыклар өйгә кергәч, бәрәннәрне үз әниләренә кушып, карап торып имезәсе. Электр булганчы, әлеге эш ярым караңгы бүлмәдә башкарылды. Бәрәннәрне үз әниләренә кушу өчен бик сизгер булырга кирәк. Сарыкларны чыгарганнан соң, өйгә сыерны кертәсе. Бозауны имезү һәм саву процессы өйдә башкарыла. Аннары, кар яуган булса, аны көрәп, ишек алдындагы сукмаклар ачыла, маллар көне буе тора торган түбәсез абзар чистартыла, малларга печән салына. Бу эшләр бик кызу темпта башкарыла – чөнки иртәнге чәйне эчеп алырга һәм күрше авылдагы җидееллык мәктәпкә беренче дәрескә өлгерергә кирәк!..

Җәйләрен бәрәңге бакчасындагы эшләр көзгә кадәр бара. Шуның өстенә, малларга кышлык печән әзерләргә кирәк. Колхозда печән өсте, урып-җыю эшләре башлангач, без колхоз эшенә чыгарга тиеш. Безнең кебек малайларга ат җигү эше тапшырыла. Гадәттә, без эшкә күрше Рафаэль белән бергә йөрибез.

Беркөнне, эш көне тәмамлангач, Рафаэль белән үзебезнең печәнне алып кайтырга планлаштырдык.

Безнең авылдан 2-3 км ераклыкта Атлас урманы кырындагы аланлыкларда эшкә бармаган көнне чабып ташлаган печәннәребез бар иде. Печәнне озак яткырырга ярамый, алып китүләре мөмкин. Безнең печән инде кипкән. Ләкин без аны күбәләп яки чүмәләләп тә куймадык. Алай иткәндә, ул чит кешенең күзен кызыктырып торачак, дидек.

Алдан планлаштырганча, эштән соң, без ике ат белән үзебезнең печәнлеккә киттек. Үзебезгә ярдәмчеләр дә алдык. Ярдәмчеләребез Рафаэльнең сеңлесе Лиза һәм минем сеңлем Һәдия иде. Печәнне төягәндә, алар йөк өстендә торырга тиеш.

Печәнлеккә барып җиттек. Кояш баеп килә. Ниһаять, печәнне җыеп төяргә кирәк. Рафаэль – үзенең йөгеп, мин исә үземнекен ашыга-ашыга төйи башладык. Караңгы төшкәндә йөкләрне төяп бетердек, тырыша-тырыша тарттырып бәйләдек. Кайтырга чыктык. Ай калыкты. Кызлар – үзләренең йөкләре өстендә, без Рафаэль белән йөк артыннан кайтабыз. Күңелләр күтәренке. Чапкан печәнебез әрәм булмады. "Кышлык печәннең бер өлеше ихатага кайта!" – дип сөенәбез.

"Ачы" чокырына җиттек. Ел саен торф янып ята торган бу урынны "Ачы" дип йөртәләр иде. "Ачы" чокыры шактый тирән һәм анда юл да кинәт борыла. Шул борылмада Рафаэльнең йөге ауды. Биек итеп төялгән печән ишелде дә төште. Ярый әле, йөк өстендә кайткан Лизага зыян булмады.

"Печән төягәндә йөк өстендә юньләп тормагансың!" – дип, Лизаны сүгә-сүгә, йөкне бергәләп төядек. Печәнне бер йөккә сыйдырып та бетерә алмыйча интектек. Әкренләп-җайлап кына таптый-таптый төягән печән, ашыгып, тиз-тиз төягәндә үз урынын алып бетерә алмый. Ничек итсәк-иттек, йөк төялде. Печәнне өйгә алып кайтып җиткердек, ишек алдына бушаттык.

Атларны колхоз абзарына илтеп кайтканда, төн уртасы узып бара иде инде. Иртәнге дүрттән дә соңга калмыйча йокыдан торып, тагын эшкә китәсе бар!..

...Шушы вакытларны искә төшерәм дә уйлап куям. Кешене тормыш шартлары, яшәү рәвеше тәрбияли. Яшьтән үк печән чабарга, чалгы көйләргә һәм башка эшләргә авыл кешесе үзлегеннән өйрәнә, мөстәкыйльлек, үзеңнең вазыйфаларыңны вакытында һәм тиешенчә үтәү сыйфатлары тәрбияләнә. Безне печән чабарга да, ул печәнне алып кайтырга да мәҗбүрләүче булмады. Без бу эшнең кирәген аңлап, үзебез башкардык. Рафаэль белән миңа ул вакытта 12-13 яшь булгандыр. Ә бит Лиза белән Һәдия бөтенләй бала булганнар. Аларга нибары – 9-10 яшь тирәсе. Шуларны: "Йөк өстендә тиешенчә тормагансыз, тигез итеп таптап төямәгәнсез", – дип ачуланабыз бит әле. Шушы яшьтәге хәзерге балаларга әлеге без башкарган эшне эшләтеп буламы? Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт ага Мәһдиев әйткәнчә, "едва ли!"

Бишнаратка барган идек...

Мөслим авылының урынын бик акыллы кеше планлаштырган. Авылның төньяк-көнчыгышында гүзәл Ык елгасы җәелеп ага. Ык аръягында – җиләк-җимешләргә бай әрәмәләр.

Көньяк-көнчыгышта иркен болыннар. Көньяк-көнбатышта – күпереп торган уңдырышлы кара туфраклы иген кырлары. Мөслимдә яше-карты җәй буе су коена, кызына, әрәмәдә җиләк-җимеш җыя. Кыш көне төрле маршрутларда чаңгы юллары салына. Ял көннәрендә Бишнарат тавына яратып йөри халык. Беркөнне Карл Мухатович белән телефоннан бәйләнешкә кереп, без дә киттек шунда чаңгылар тагып. Юлда безгә врач Рафис Хәбибуллович та кушылды. Кояшлы, җилсез кышкы көн. Күңел булырлык итеп, кичкә кадәр чаңгы шудык. Кайтырга чыктык. Карл әйтеп куйды: “Менә хәзер бер “перцовка” мешайть итмәс иде!”

Безнең хөкүмәтнең махсус политикасы идеме соң ул, өздереп әйтә алмыйм. Халык өчен кирәк товарларны тиешенчә кайтармыйлар иде кибетләргә. Элита дәрәҗәсендәге кешеләр таләп итә торган әйберләр турында әйтмим дә әле. Кинәт кенә кибетләрдә тоз, тәмәке, шырпы, ипи, конфет, прәннек, шикәр яки савыт-саба бетә. Спирт, аракы заводлары өзлексез эшләп торса да, кибетләрдә эчемлекләр бетә.

Без чаңгы шуган көндә дә кибетләр буш иде. “Хөлия кибетенә “перцовка” кайтарганнар икән!” – дигән хәбәр ишетелгән иде ишетелүен. Карлның бу эчемлекне искә төшерүе шул хәбәрнең хәтергә төшүе булгандыр, күрәсең. Карлның идеясе кабул ителде. Безнең юл өстендә иң беренчесе – Карллар торган йорт. Шунда кереп киттек. Шәмсеямал апаны Хөлия кибетенә йөгерттек. Ул тапшырылган бурычны үтәп тә кайтты. Өстәл өстенә теге “перцовка” матур гына менеп кунаклады. “Бу әйбер дә гел ярамаслык түгел икән!” – дип тота торгач, ул “явыз”ны бушатып та куйдык. Таралышырга булдык, көн дә бетеп килә иде. Шунда Рафиста тагын бер тәкъдим туды. “Мин чаңгы шуарга киткәндә хатын, бәрәңге тәкәсе пешерәм, дип калган иде. Инде ул пешкәндер, киттек безгә, “перцовка” артыннан начар булмас!” – диде ул.

Без каршы килмәдек. Киттек Мөслимнең икенче башына, тагын чаңгыларны тагып. Чаңгыларны салып, өйләренә керсәк, күзебез дүрт булды. Анда олы мәҗлес бара, кунаклар да шактый җыелган икән! Безне дә мәҗбүриләп утырттылар. Үзләре өчен генә бәрәңге тәкәсе пешерү булмаган бу, алдан ук планлаштырылган олы мәҗлес булган. Теге борычлы нәрсә тәэсирендә булса кирәк, Рафис безне әзрәк алдаган.

Өйгә соңарыбрак кайтырга туры килде инде. Мин кайтканда, төн уртасы узып бара иде.

Безнекеләр йоклаганнар, ишек бикле. Мин шакыганга, Тихния чыкты. Мин, чаңгыларымны күтәреп, басып торам. Беренче сүзе шул булды:

– Кайда йөрдең бу гомер?

– Бишнаратка чаңгы шуарга барган идек, – дим.

– Ул текә тауларда шушы караңгыда ничек шуа алдыгыз? Ничек имгәнеп бетмәдегез?! – ди хатыным.

Аңа барысын да аңлатырга туры килде инде...

Авылдаш-якташларым

Зифа Басыйрова

Халкыбыз күңеленә, җырчы Зифа апа Басыйрова кебек, онытылмаслык булып кереп калган шәхесләребез күп түгелдер?! Драматик артист буларак та, аңа искиткеч югары бәя бирәләр иде. Кызганычка каршы, миңа ул катнашкан спектакльләрне карарга туры килмәде. Шулай да берсен караганмын икән... Күптән инде, Бөек Ватан сугышы беткәннән соң, безнең Мөслим районына Татар дәүләт академия театры гастрольләр белән килде. Артистлар безнең авылда да булды. Мирсәй Әмирнең "Тормыш җыры" спектаклен күрсәттеләр. Авыл халкы өчен, бигрәк тә безнең кебек малай-шалайлар өчен, бу олы вакыйга булды. Тамашачы белән шыгрым тулы клубыбызда халык спектакльне тын да алмыйча карады, артистларның уенынан биһуш калды. Безгә бигрәк тә малай роле ошады. "Малай ролендә хатын кыз икән, ул безнең Мөслим районыннан чыккан икән!.." — дигән сүзләргә без ышанмадык та хәтта. Хатын-кыз ничек шулай оста итеп, малай ролен уйный алсын ди?!. Бу рольне шулай килештереп уйнаучы артистның Зифа Басыйрова икәнен мин соңрак белдем...

Башка малайлар ничек булгандыр, кечкенәдән үк минем колакка "кара тәлинкә аша" "Телеграм баганасы", "Идел бит ул...", "Рамай" һәм башка көйләр килеп кергәч, бу җырларның җиренә җиткереп башкарылуы, тавыш тембрының матурлыгы, сүзләренең мәгънәлелеге мине җыр-моң дөньясына алып кереп китә иде. Җырларның Зифа Басыйрова тарафыннан башкарылуы әйтелә. Зифа апаның һәр башкарган җыры күтәп алына. Зифа апаның җырлау техникасы шулкадәр камил, ул башкарган җырның артык җире дә, җитмәгән җире дә булмый иде. "Рамай" көе ишетелә башлагач, күп кенә профессионал җырчылар да, һәвәскәрләр дә бу җырны кабатлый башладылар. Ләкин аны Зифа апа кебек оста башкаручы булмады. "Габ-

драхман", "Утыр әле, яннарыма...", "Син – яшь, диләр" һәм башка югары темп белән башкарыла торганнарына да Зифа апа үзенчәлекле җан кертә, күңел күтәренкелеге, яшәү дәрте өсти иде.

...Мөслимдә чагымда, миңа берничә тапкыр Зифа апа белән очрашу бәхете тиде. Мөслим районы, Ташлыяр җидееллык мәктәбендә эшләгәндә, башлангыч классларда укытучы Рәшидә апа Әхмәтова сөйләгәннәре истә калган. Мөслимдә Рәшидә апа Зифа апа белән күршеләр булып яшәгәннәр. Зифа апа туганнары Гатаулла йортында торган. 50 нче еллар башында Кооператив урамындагы кечкенә генә агач йортны мин хәтерлим әле. Капка төпләрендә кое бар иде. Суы тәмле, дип, халык ул коега күпләп йөрде. Соңрак ул иске йорт урынына укытучылар Мидхәт Гомәрович Фәтхуллин һәм Фиалка Мөхәммәтовна Хәйруллиналар яңа йорт җиткезде.

Рәшидә апа сөйли торган иде: "Зифа яшьли ятим калды. Абыйларында яшәде, эшләп үсте, ир-ат кына булдыра торган – сабан сөрү, тырмалау, урманга утынга бару кебек эшләрне дә башкара иде. Аның, атка атланып, басуга чыгып китүләре бүгенгедәй хәтеремдә. Еш кына икәү җырлый идек. Мин югары тавыш белән – беренче партия, ул альт тавышы белән икенче партияне алып бара иде, халык бик ошата иде".

Институтны тәмамлаганнан соң, Мөслимдә эшләгәндә, Зифа апа белән әңгәмә хәтердә калган...

Бик еш булмаса да, ул Мөслимгә кайткалый иде. Бер кайтуында Зифа апа безнең үзешчәннәр концертын караган. Шуннан соң миңа үзенең фикерләрен әйтте: "Хезмәтең сәнгатьтән ерак булса да, физика укытучысының музыка, җыр белән якынлыгын хуплыйм. Җырлавың миңа ошады. Музыкант, аккомпониатор белән күбрәк эшләргә тәкъдим итәр идем. Үземнең тәҗрибәдән чыгып әйтүем. Мин Мөхтәр Әхмәдиев, Фәйзи Садыйков, Гали Җәмлиханов, Оркыя Ибраһимова, Гани Вәлиев, Рәис Сафиуллин һәм башка күренекле музыкантлар белән эшләдем. Аларның һәрберсе үз стиле, үзенчә башкару практикасы булган чын профессионал иде. Кайвакыт аккомпаниатр үзенең ролен дә бутап җибәрә, баян телләрен "лыбыр-лыбыр" китереп, көйне боза, үзен алга чыгарып куя. Югыйсә бит, ул җырчының башкару осталыгын тәэмин итүче генә. Бу яктан мин пианинода аккомпаниатор Екатерина Соколованы үрнәк итеп күрсәтә алам. Рус милләтеннән булса да, ул татар музыкасын тирән аңлап, җырчыга татар моңын кирәгенчә бирергә булыша.

Минем улым да – булачак инженер, КАИ студенты. Музыканы якын итүегез белән сез бер-берегезгә охшагансыз".

Мондый чагыштыруны ишеткәч, күңелле булып китте.

...Зифа апа белән тагын бер очрашу Казан телевидениесендә булды. Телевидениенең бер тапшыруы Мөслим районына багышланган иде. Районнан Казанга зур коллектив булып килдек. Безнең арада партиянең район комитеты секретаре да, колхоз рәисе дә, авыл хуҗалыгы белгечләре дә, үзешчәннәр дә бар иде. Спартак Әхмәтов белән Карл, Гаяз Авзалов белән мин татар халык көе "Мәрфуга"ны квартет белән җырларга килдек. Бу көйне безнең белән Казаннан килгән белгеч – композитор Мәсгут Латыйпов әзерләде. Безнең бу җырны Зифа апа да ошатты. Ләкин киңәшен дә әйтте: "Күп тавышлы итәм дип, композитор җырның диапазонын чамадан тыш арттырып җибәргән, тенор һәм бас партияләре чын профессионаллар өчен эшләнгән. Бераз гадиләштерергә кирәк, бәлки, киләчәктә бу турыда уйларсыз!"

Тапшырудан соң, "Маяк" ресторанында чәй мәҗлесе оештырылган иде. Зифа апа мәҗлеснең күрке булды. Аның кәефе бик яхшы иде. Үзенең хезмәт юлы, сугыш еллары, елның нинди вакыты булуга карамастан, авылдан авылга концерт белән йөрүләр, салкын клублар, кандалалы фатирлар һәм тормыштагы башка хәлләр хакында, композитор Касыйм Бакировның Мөслим турындагы җырны язуы, аның сүзләрен үзенең тудыруы турында иренмичә сөйләде, Мөслимдә узган яшьлеген исенә төшерде. Мөслим, аның өчен, газиз туган җире, кешеләре, табигате белән дөньяның иң матур төбәге иде!..

Зифа апа тавышының байлыгы, матурлыгы – башкару осталыгы ягыннан кабатланмас шәхескә табигать тарафыннан сирәк бирелә торган бүләк иде. Кызганычка каршы, аның хезмәте җитәкчеләр тарафыннан тиешенчә бәяләнмәде. Кабатланмас талант, "Халык артисты" исемен дә ала алмыйча, арабыздан китеп барды. Әмма татар халкы аны инде бик күптәннән һәм озак елларга үзенеке итте!..

Агрономия конференциясе

Элекке вакытларда, ел саен, Казанда Татарстан партия өлкә комитеты җитәкчелегендә, агрономиягә, зоотехникага яки башка авыл хуҗалыгы темасына багышланган республика конференцияләре уза торган иде. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера-балет театры бинасында республика-район җитәк-

челәре, колхоз председательләре, авыл хуҗалыгы белгечләре җыела. Монда партия өлкә комитеты секретаре, авыл хуҗалыгы министры зур докладлар белән чыга, җирле житәкчеләрнең, белгечләрнең тәҗрибә уртаклашу урыны да була театр бинасы.

Конференциядә катнашучылар кунакханәләрдә яшиләр. Бер елны Мөслимнән килгән колхоз председательләре "Татарстан" кунакханәсенә туры килә. Алар кичләрен, бер бүлмәгә җыелып, матур гына итеп утыралар. Һәрберсенең өйләреннән алып килгән күчтәнәчләре бар. Өстәлгә пешкән яки тозлаган каз, тавык, бозау, сарык, ат ите, йомыркалар куела, эчемлекләр дә үз урынын ала. Берничә кич шулай күңелле генә үтә...

Бу утыруларда, пишләптер, колхоз председателе Хәсәннурыев катнашмый. Ул никтер башкалар белән аралашмый. Мөслим районындагы коллегаларын, хезмәттәшләрен үз итми. Җыелышып утырганда, шул турыда сөйләшү була. Арадан берсе: "Әйдә, Хәсәннурыевны кызык итәбез!" – дип әйтеп куя.

– Ничек итеп?

– Менә болай: хәзер без аның номерына телефоннан шалтыратып бер хатын-кызны сөйләштерәбез. Ул аны "свидание"гә чакырыр!..

Бүлмәдә кич утырырга килгән кызларның берсе белән бу сөйләшүнең "репетиция"се уздырыла һәм ул үз ролен уңышлы гына башкара.

Хәсәннурыев бүлмәсендә телефон шалтырый. Телефонны Хәсәннурыев ала, сөйләшү башлана:

– Алло! Миңа Хәсәннурыев кирәк иде...

– Хәсәннурыев тыңлый. Кем әле бу?

– Мин Тәслимә булам. Казаннан. Җәй көне сезнең авылга кунакка кайткан идем, Хәниф абыйларга. Мин сезне шунда күргән идем. Бик ошаган идегез. Очрашасы да килгән иде. Сез бит бик олы кеше – колхоз председателе. Минем кебек гади кешегә игътибар да итмәдегез, ә очрашырга була иде.

– Хәзер очрашыйк, Тәслимә. Мин – "Татарстан" кунакханәсендә.

– Мин дә еракта түгел, сезнең янда гына, Бауман урамындагы 12нче аптекада. Зав. аптекой – мин. Килсәгез, әйбәт булыр иде. Мин ишекне эчтән бикләп утырам. Килгәч, шакылдатырсыз...

– Көтегез, Тәслимә, мин хәзер киләм!..

Хәсәннурыев, әзерлек чараларын күреп, кунакханәдән чыгып барганда:

– Төнгә каршы кая барасың? – дип сораган бер коллегасына “туганнарга гына барып киләм” дип, теге аптекага юнәлә.

Председательләр, җыелышып, бу уенның ахырын уйлап бетерәләр. Аптека күптән бикләнгән, аптека мөдире үзе дә председательләр янында сыйланып утыра ич!..

Хәсәннурыев аптекага килә. “Әчтә Тәслимә булырга тиеш!” – дип, ишекне кага башлый. Ишекне ачучы юк. Шактый вакыт ишекне кагып басып тора да, борчылып, кунакханәгә кайта. Йокларга ята, иртәгә иртүк Мөслимгә очасы бар бит!

Иртән иртүк телефон шалтырауга уянып китә председатель. Күрше бүлмәдән шалтыраталар. Тагын сөйләшү башлана:

– Бауман районы прокуратурасы бу. Кичә төнлә Бауман урамындагы 12нче аптеканы талаганнар. Монда сезнең фамилия “фигурирует”. Тиз генә безгә килегез! – дип боералар телефоннан.

– Сез ни сөйлисез, нишләп мин аптека басып йөрим? Мин бит – колхоз председателе!

– Мине сезнең кем булуыгыз кызыксындырмый. Сезнең аптека ишеген каерып яткан чагыгызны күрүчеләр бар. Так что, без сезне көтәбез!

– Мин сезгә бара алмыйм. Минем самолет иртәнге 8дә Мөслимгә оча. Миңа өйгә кайтырга кирәк...

– Прокуратура белән шаярмагыз сез! Кирәк булса, Мөслимнән милиция белән китертербез!..

Хәсәннурыевның авыр хәлдә калуын барысы да күреп тора. Бу хәлне аңламаган булып, аннан сорашкан булалар: “Кем шалтырата, ни өчен?” Хәсәннурыев мәсьәләне аңлата, бер гаебе дә юк икәнне иптәшләренә сөйли, прокуратурага бармыйча булмый инде, самолет билетын тапшырырсыз, дип иптәшләренә бирә.

Председательләр мәсьәләне җиңеләйтәләр, аптека басып йөри торган кеше түгеллегеңне прокурорга үзебез аңлатырбыз, дип Хәсәннурыевны Мөслимгә үзләре белән алып кайтып китәләр. Шаяртулары турында әйтмиләр...

Соңрак Хәсәннурыевның шактый вакыт, Казан прокурорыннан хәбәр килүен көтеп, куркып йөрүен әйттеләр.

–Аптекасына кереп, шул Тәслимәне дә күрә алмадым бит, ичмаса, бер гөнаһсызга зыян күрә яздым бит, – дип сөйләгән ул бер иптәшенә...

Һади абый

Узган гасырның 50-70 нче елларында безнең авылның халкын тәрбияләүдә төп рольне Һади абый үтәгәндер!.. Элегрәк авыл халкының тәртибен Ислам дине, муллалар билгеләгән. Бу елларда дин юк дәрәҗәсенә җиткерелгән, Ислам кагыйдәләрен тоту гаеп санала иде. Безнең “Лена” колхозын күрше колхозга кушканнан соң, авылда председатель дә, партия оешмасы секретаре дә калмады. Авылдагы төрледән-төрле чараларны уздыру да Һади абыйга йөкләнде. Ул – мәктәптә укытучы да, мәктәп мөдире дә, культура-агарту, масса-политик эшләрне оештыручы да!

Авыл клубында календарьдагы барлык “кызыл көннәр”не дә билгеләп үтәләр иде. Октябрь бәйрәмеме ул, Совет Армиясе көнеме, Халыкара Хатын-кызлар көнеме – клубта доклад укыла. Докладны, әлбәттә, Һади абый Сабиров ясый. Докладтан соң, авыл үзешчәннәре я спектакль, я концерт күрсәтәләр.

Гадәттә, клубка халык әкренләп җыела. Һади абый бу вакытны да оста файдалана: кычкырып, әдәби китап яки газета уку оештырыла. Моның өчен, мәктәпнең яхшы укучылары сайлана. Башлангыч класс укучылары, бер-берсен алыштыра-алыштыра китап укыганда, бу балаларның әти-әнисе, туган-тумачасы, күрше-күләннәре зур ләззәт хисләре кичерә. “Менә бит, үзе икенче (өченче) класста гына булса да, ничек матур укый. Кеше чыгачак бу баладан!” – дип уйлап утыралар, һәм шулай була да. Ул балаларның күбесе – хәзер югары белемле белгеч!

Спектакль беткәч тә, халык тиз генә таралмый клубтан, “вечер”га кала. Клубта оештырылган уеннарны авыл халкы шулай дип йөртә иде. Монда да Һади абый яшьләрне үзенчә оештыра. “Әйдәгез әле, Хөсәенов Әмирҗанны биетик!”– ди ул. Аның матур гына бии торган гадәтен ул яхшы белә. Әмирҗан да ялындырып тормый. Ялтыратып чистарткан күн итеге белән, үзенә генә хас адымнар белән, кырт-кырт басып, биеп тә китә.

Озак еллар Һади абый Югары Табын башлангыч мәктәбендә мөдир булып эшләде, анда балалар укытты. Районда бу мәктәпнең дәрәҗәсе зур булды. Мәктәптә укыту-тәрбия эшләренең торышы югары иде. Бу эштә Һади абыйның тормыш иптәше Маһия апа да бик тырышты. Район мәгариф бүлеген җитәкләгән чагымда, әлеге мәктәптә еш булдым. Балаларга контроль эш эшләтеп белемнәрен тикшергәндә, нәтиҗә һәрвакыт

көткәннән дә артык була иде. Бигрәк тә балалар математиканы яхшы белделәр. Бу фәнне аларга Һади абый укытты.

Һади абый аракы эчә иде микән, белмим, эчмәгәндер?! Эчсә, авыл кешесе аны күрми калмас иде. Ул һәрвакыт аек иде, кешеләр арасында йөрде. Әмма пивоны якын итә иде. Якын итү генә дә булмагандыр, ярата иде ул аны.

Бервакыт, Минзәлә педучилищесында укыган чакта, мин яшәгән фатирга безнең авылдан Һади абый белән Ситдыйк абыйлар килеп керде. Ситдыйк абый Минзәлә медицина училищесында укучы хатыны Хәмдия апа янына килгән. Килеп керүгә, Һади абыйның беренче сүзе шул булды:

– Минзәләнең пивосы шәп була, киттек пиво эчәргә!

Минзәлә шәһәренең Вахитов урамындагы ашханәсендә пиво сатуны оештырганнар. Һади абыйның заказы буенча, без бер өстәлгә пиво ташый башладык. Өстәл өсте пиво кружкалары белән тулды. (Кеше башыннан бишәр кружка исәбеннән бирелгән икән заказ).

Һади абый шундый ләззәт белән эчә пивоны – бу минутларда аннан да бәхетле кеше юк, диярсең! Вакыт-вакыт әйтеп тә куя: "Ну, тәмле дә инде, чукынган".

Ул вакытта мин, пиво тәмен белеп бетермәгән малай, тырыша-тырыша бер кружка пивоны көчкә эчеп бетердем. Ул арада сатуда пиво бетте. Безнең өстәлгә килә башлады халык, бездән пиво сорыйлар. Аларны кызыктырып, өстәлдә пиво тулы кружкалар тора. Мин торып китәргә дә уйлаган идем, "эчәсең килмәсә дә, эчкән кыяфәткә кереп утыр" дип, Һади абый мине өстәл яныннан җибәрмәде. Алар пивоны эчеп бетерделәр. Гәүдәгә әллә ни зур булмаган ике кешенең шушы күләмдәге пивоны эчә алуларына хәйран калган идем шул чакта...

Һади абыйның пивоны яратуы өлкән яшенә кадәр сакланды. Машинасы белән ул Минзәләгә еш йөрде. Шешәле пиволарны ул барган саен күпләп алып кайтып, базына куя. Шуны әкренләп файдалана. Күрше-тирәсенә, килгән кунакларына да өлеш чыга иде.

Безнең авылда беренче машиналы кеше дә Һади абый булды. "Жигули" ләр чыга башлаганчы ук, аның "Москвич" машинасы бар иде. Соңрак җиңел машиналарның башкалары, югары сыйфатлылары чыга башлагач та, ул "Москвич"ка тугрылыгын ташламады. Искергәнен яңага алыштырганда, һаман шул маркадагысын сайлады. "Мин "Москвичка" өйрәнгән инде, аның гадәтләрен яхшы беләм", – ди торган иде. Гадәтләрен яхшы белгәнгәдер, бертуган абыйсы Самат абзый белән

Мөслимгә барганда, Мәллә күперен чыгып, үргә менгәндә Самат абзыйны машинадан төшерә торган була. “Абый, машинага авыр була, син тауны җәяү генә менәрсең инде”, – ди икән.

Авылда, колхозда хезмәте белән күренекле кешеләр бакыйлыкка күчкәч, аларны җирләүне дә һәрвакыт Һади абый оештырды. Әтине җирләгәндә дә, Һади абыйның зыяратка җыелган халыкка мөрәҗәгате минем һаман истә:

– Безнең арабыздан авылыбызның ихтирамга лаек колхозчысы, коммунисты, озак еллар партия оешмасын җитәкләгән иптәшебез китте. Гайфуллин Габдулла колхозда күп кенә җитәкчелек вазифаларын башкарды – бригадир да, колхоз председателенең ярдәмчесе дә булды. Безнең авылның һәр кешесе аны хөрмәт итте. Аның күркәм үрнәге, якты истәлеге безнең күңелләрдә озак сакланыр! – диде ул.

Хәзер безнең арада Һади абый үзе дә юк инде. Ләкин аның узган гомере мәгънәле иде. Балаларның яраткан укытучысы, авыл халкының мөхтәрәм тәрбиячесе булды ул!

Асия апа Лотфуллина

Хезмәт юлым шуннан башлангангамы, Ташлыяр мәктәбе күңелемә онытылмаслык булып кереп калган! Мин эшләгәндә, мәктәпнең махсус салынган бинасы да юк иде әле. Мәктәпнең класслары яраклаштырылган берничә агач бинага урнашкан иде. Материаль як бик иркен булмаса да, укытучылар коллективы бервакытта да күңелен төшермәде. Мәктәп директорыбыз Рабига апа Нуретдинова югында һәркемнең уен-көлке корырга, мәзәкләр сөйләргә тырышуы истә калган. Монда инде бигрәк тә башлангыч класс укытучысы Асия апа активлык күрсәтә. Асия апа үзе –Баланлы авылыннан. Минзәлә педучилищесын тәмамлагач, аны Ташлыяр мәктәбенә җибәргәннәр. Асия апа сөйли: “Сугыш беткән ел. Авылга егетләр кайта башлады. Минем дә егетләр күзенә күренәсе килә. Күлмәгемне көненә икешәр тапкыр юып киям. Ак тапочкамны теш порошогы белән агартып, клубка чыгам. Бик бии белмәсәм дә, бөтен уеннарда катнашам, биим, бер көнне клубтан соң мине дә берәү озатып кайтты. Икенче көнне дә озатты бу. Шулай сөйләшеп киттек. Егет үзенең планнарын да әйтә башлады. Өйләнергә дә уйлый икән. Миңа өйләнү нияте бар. Сәбәбен дә әйтте. “Укытучының шунысын яратам, җәй буе тик ята. 30 сутый бәрәңге бакчасы бар. Җәй буе шуны эшкәртергә иде”, – ди. Сәламәт ке-

шегә 30 сутый бакча нәрсә ул?! Эшкәртәм мин аны! “Чыгам мин моңа кияүгә”, – дип, уйлап йөрим.

Беркөнне, клубтан кайтканда, егетем сүз башлады: “Бүген минем кайгылы көн әле, Асия”, – ди бу.

– Нәрсә булды соң? – дип сорадым.

– Энекәшне тегермәнгә җибәргән идем, онны бозып кайткан.

– Оны күп идеме соң?

– Күп иде шул, ярты пот иде!

Күңелем әллә нишләп китте. Яңа танышкан кызга ярты пот онны олы кайгы итеп сөйләп йөргәч, бик вак кешедер бу, моның белән ничек гомер итәрмен, дип уйлап куйдым. Очрашуларны туктатырга булдым. Егеткә әйттем: “Син яңадан минем янга килеп йөрмә инде. Миңа әле кияүгә чыгарга иртәрәк, минем алга таба укыйсым да бар”, – дидем. Котылдым мин моннан”.

Авыл халкын заемга яздыру кампаниясе башланса, бу эш укытучылар җилкәсенә төшә иде. Берсендә мине Асия апа белән җибәрделәр бу эшкә. Безгә бирелгән хуҗалыкларда йорт башына ничә сумга яздырырга икәнен әйтеп чыгаралар. Билгеле бер сумманы җыеп кайту бурычы куела. Ул сумманы һәр йортка бүлеп чыгабыз. Хәллерәк хуҗаларга – күбрәк, фәкыйрьләренә әзрәк куярга тырышабыз.

Авыл халкының барысы да диярлек фәкыйрь иде ул елларда. Колхозчылар еллар буе бер тиен дә хезмәт хакы алмый. Икмәк уңса, һәр хезмәт көне исәбенә чамалап, күпмедер икмәк бирелә. Сыерлы кеше сөтеннән май ясап сата, үзенә сыек сөттән ясалган катыгы кала, тавыклары булса, шуннан йомырка җыеп сата. Менә шулардан түли инде колхозчы күп төрле налогларны һәм заемны.

Асия апа белән өй саен кереп йөрибез. Боларны 300 сумга яздырып булса, әйбәт булыр иде, дип план корабыз. Бер өйгә килеп кердек. Өйдә кичке ашны ашап утыралар. Сөтле аш пешергәннәр. Итле аш бик еш пешми иде авылда, үзләре мал асрасалар да. Ит “натуралата” дәүләткә тапшырыла, һәр йортка 40 кг итне мәҗбүри тапшыру каралган. Шуңа күрә, ит налогы түләү өчен, итнең күп өлеше сатыла.

Сүзне Асия апа башлый:

– Гел баеп беткәнсез бит, аш бүләр өчен, һәрберегезгә бер савыт булдыргансыз, сәкегезгә сыер тиресе җәйгәнсез..., – дип тезеп китә.

Баю дигән әйбер юк та юк инде. Өйдә мич, сәке, бер өстәл һәм ике урындыктан башка бернәрсә юк. Киемнәре дә шул – өсләренә кигән киемнәр генә. Савыт-саба да үзләре санынча гына. Әле алай ук булмаган кешеләр күп. Асия апа "баеп беткәнсез" дип, бераз күңелләрен күтәрерлек җай эзләп кенә әйтә.

– Менә заемга яздырып йөрибез. Ашыгызны бүлдереп тормыйбыз. Менә 400 сумга кулыгызны куегыз да без чыгып китәбез. Сезнең күрше Шәмсетдин абзыкайлар 500 сумга язылдылар.

– Асия, син бигрәк инде! Шул кадәр сумманы ничек түләп бетермәк кирәк. Шәмсетдиннең мөмкинлеге бар аның, шахтада эшләгән малае акча салгалап тора. Безнең бар карап торганыбыз шул сыер инде!..

– Абзый, без дә үзебезгә җыймыйбыз бит, Совет хөкүмәтенә җыябыз. Шушы заем акчаларына илне алга җибәрәчәкбез бит! Менә трактор, комбайн, машиналар кайта башлады, электр станцияләре төзелә, барысы да үзебез өчен бит. Менә бу керосин лампасының да кирәге калмый киләчәктә. Авылга электр керәчәк, Ходай кушса!

Шулай сөйли-сөйли, сатулаша-сатулаша, хуҗаларны 350 сумга ризалаштырабыз. Димәк, бу йорттан без, үзебез уйлаганнан тыш, 50 сум запас белән чыгабыз, әмма барлык йортларда да безнең тактика барып чыкмый. Хуҗалар без уйлаган санга риза булмый, кимрәк суммага килешә. Шулай итеп, безнең запас бетә.

Авыл буйлап шактый йөрибез. Кайбер кешегә икешәр-өчәр тапкыр да керәбез. Планны тутырмыйча, безне йөрүдән туктатмыйлар.

Бу – узган гасырның 50 нче еллары. Асия апа хәзер өлкән яшьтәге пенсионер карчык инде. Авылда да хәлләр икенче төрле хәзер. Заемнар белән борчулар бетте. Ләкин заманалар үзгәрү белән, яңа борчулар барлыкка килә. Шыр ялкау булмаган сәламәт кешегә авылда яшәргә була хәзер үзе. Замана чирләренә генә бирешмәскә иде!

Мәрданов абый

Латыйпов Зәки абзыйдан соң, Түбән Табын авыл Советы рәисе булып Мәрданов Габдрахман абзый эшләде. Узган гасырның 50 нче еллары. Авыл Советы җитәкчеләренә түгел, районныкына да машиналар юк вакыт. Авыл Советының төп транспорт чарасы – ат. Мәрданов абый авылдан авылга ат белән

йөри. Һәр елны авыл Советы атына печән әзерләнә. Әзерләнгән печән яңа печән өлгергәнгә кадәр җитәргә тиеш.

Бер көнне рәиснең күзе печәнгә төшә. Ул соңгы көннәрдә шактый кимегән икән. Ни сәбәпле кимеп киткән соң әле авыл Советы печәне?! Бу сорауны ул бинаны җыештыручыга бирә.

– Кимеми нишләсен инде ул печән, Мәрдәнов абый, печәнне үзебезнең авыл Советы аты да ашый, күрше авыл Тамьяннан килгән агроном Галләмов абый аты да ашый, – ди тегесе. Аннары Галләмов абый, чанасына салып, печәнне күршедәге Разияларга да алып керә бит...

Мәрдәнов абыйга бу яңалык ошамый. Ул парторг Хәмит Әхмәтович Әхмәтовка шалтырата: "Хәмит, тиз генә килеп җит, "серьезный" мәсьәлә бар! Монда авыл Советы печәнен талыйлар, чара күрергә кирәк".

Хәмит Әхмәтович, без Түбән Табын мәктәбендә укыганда, тарих укытучыбыз иде. Аннары ул Күбәк урта мәктәбенең директоры булды, бик уңган директор иде. Авылларда парткомнар оештыра башлагач, аны Мулланур Вахитов исемендәге колхозның партком секретаре итеп күчерделәр. Җитәкчелектә партиянең роле зурайган чорда, парткомнар шактый дәрәҗәле иделәр. Мәрдәнов абыйның "килеп җит" дип чакыруына Әхмәтовның буйсынуы мәҗбүри булмаса да, алдагы елларда Мәрдәнов абыйның дәрәҗәле колхоз рәисе булып эшләвен истә тотып, Хәмит Әхмәтович авыл Советына килеп җитә. Алар, икәүләп, Разия йортына юнәләләр.

Хәмит Әхмәтович сөйли: "Йортка килеп кердек. Сорау алу башланды".

Сорауны Мәрдәнов ала:

– Галләмов сездә нишләп йөри ул?

– Атын ишек алдына куеп тора ул...

– Авыл Советы печәнен нигә сезгә кертә ул?

– Чана төбендә бераз печәне була инде аның...

– Аны сезнең маллар ашыймы?

– Үзенең аты да, безнең маллар да ашый инде...

– Әһә, димәк, ул сезгә печән китерә. Әллә сез йөрисезме?

– Йөри, дип инде, олы кеше бит инде мин, Мәрдәнов абый, йөри торган чаклар үтеп бара...

– Алай димә әле, синең бу бүлтәеп торган арт саныңа мин дә кызыгып утырам!..

Хәмит Әхмәтович сөйләвен дәвам итә:

"Бу йортка килүнең максаты үзгәрде дә куйды. Мин ни әйтергә дә белмим, мондый хәлдән ничек чыгарга – тәҗрибә

юк. Аптырагач: “Мәрдәнов абый, ашыгыч эшләрем бар иде, китим әле мин,” – дидем һәм чыгып киттем.

Укытучы Хөршидә апа сөйли иде: “Колхозның идарә утырышында да, колхозларның гомуми җыелышында да беркетмә язуны миңа тапшыралар иде. Каралган мәсьләләр буенча карар чыгарырга кирәк була. Ул колхозчыларның яки идарә членнарының ачык тавыш бирүләре белән хәл ителә. Кайбер вакытта идарә членнары яки колхозчылар куелган мәсьәләне председатель әйткәнчә хәл итәргә теләмиләр. Ә район җитәкчеләре куелган мәсьәләне хәл итүне таләп итә. Мәрдәнов абый моны үзенчә башкара иде.

– Кем дә кем мәсьәләне мин әйткәнчә кабул итәргә риза, шул иптәшләрнең кул күтәреп тавыш бирүен сорыйм, – дип Мәрдәнов абый көн тәртибен тавышка куя һәм, үзенең тәкъдимен яклап, кул күтәрә. Башкалар бу тәкъдимгә каршы. Берсе дә кул күтәрми.

– Мәсьләлә бертавыштан кабул ителде! – дип, язарга миңа боера Мәрдәнов абый. Миңа шулай язарга туры килә. Беркетмәнең күчерелмәсе районга җибәрелә. Мәсьәләнең уңай чишелеше председательгә мактау китерә. Хәл ителәсе мәсьләләгә бер генә кеше уңай, калганнарының каршы булуы турында уйлап та карамыйлар.

– Ә кемнәр бу мәсьләләгә каршы? – дигән сорау бирелми. Бу һәрвакыт шулай, махсус эшләнә...”

...Узган гасырның 40-50 нче еллары бу. Тоталитар партия диктаты чоры. “Партия шулай куша!” – дип, колхозчыларны тыңлата алыр иде председатель. Каршы килә алмаслар иде – 37 нче елларның афәте әле онытылып бетмәгән. Әмма Мәрдәнов абый мәсьәләне үзенчә чишә, тыңлаучан крестьян психологиясен үзенчә файдалана, мәсьәләне хәл итүне катлауландырып тормый...

Сәгыйть Шәйхрамов

Сәгыйть белән мин педучилищеда бер елларда укыдым. Ул безнең күрше Тугаш авылыннан. Бу елларда без аның белән якыннан аралашмадык. Кыллы инструментлар оркестрында уйнаганда гына, бер-беребезне белә башладык. Оркестрда мин думрада прима-I партиясендә булсам, ул, Әгъзамов Фирдәвес белән, бас партиясен башкара иде. Иң түбән тондагы аккордларны бик тырышып бирәләр иде алар. Сәгыйтьнең педучи-

лицеда чакта җиңел атлетлар командасында һәм чаңгыда уңышлы чыгыш ясаганы истә калган.

Педучилищены тәмамлаганда ук, бер төркем егетне армиягә алдылар. Шулар арасында Сәгыйть тә бар иде. Шуннан соң, безнең юллар аерылды. Укуны тәмамлап, бер ел эшләгәннән соң, мин Казан пединститутына укырга кердем. Аннары Мөслимгә кайтып эшли башладым. Бер ял көнне, авылга әтиләргә кайткач, шунда Сәгыйтьне очраттым. Ул – хәзер офицер, капитан дәрәҗәсендә, авиациядәгеләрдә генә була торган алтын сыман погоннар таккан. Ул безнең күрше кызы Лизага өйләнгән. Минзәлә чорларын искә төшереп алдык. Ленинградта яшиләр, тиздән китәләр икән шунда. Мин дә алар белән китәргә булдым. Ленинград педагогия институтына бер фәнни мәкалә җибәргән идем. Мәкаләгә уңай бәя биреп, мине фәнни конференциягә чакырганнар.

Сәгыйтьләрнең әйберләре күп. Сәгыйтьнең әти-әниләре дә, Лизаның туганнары да авыл күчтәнәчен мул төягәннәр: берничә йөз йомырка, тозлы казлар, бал, варенье, тагын әллә ниләр. Җитмәсә, яшь балалары да бар. Лизаның куллары баладан бушамый. Әйберләрнең күбесен Сәгыйть күтәрде, миңа да эләкте: бер кулда – чемодан, икенче кулда чүпрәк сумкага утырткан бер бидон бал. Поезд килде, вагонга утыра башладык. Нишләптер, безнең вагонга утырырга халык күп җыелды. Вагонга тәртип белән генә кереп булмый, этеш-төртеш башланды. Бал салынган сумка пассажирлар арасында кысылып калды, шунда аның бер як тоткасы өзелде, сумка кыйгаеп, бидоннан бал түгелә башлады...

Бидонны кочакка алып, ничек кирәк алай, вагонга кердем. Әйберләрне урнаштырдык. Әмма бер проблема килеп чыкты – бал минем костюмны шактый буяган икән, костюмны ничек чистартырга?! Ул арада пассажирлар да канәгатьсезлек күрсәтә башладылар. Бал ишек тоткаларына да, башка җирләргә дә буялган икән. Ул урыннарны “балсызландыру” мәсьәләләре белән Сәгыйть белән миңа нык кына тырышырга туры килде.

Ленинградта Сәгыйтьләр фатирына барып төштек. Өч көн шунда яшәдем. Конференциядә катнашучы буларак, миңа гостиницада урын әзерләп куелса да, алар мине үзләреннән җибәрмәделәр. Кичләрен Сәгыйть белән алардан ерак түгел генә урнашкан стадионга чыгуыбыз истә калган. Сәгыйть бу чорда Можайский исемендәге хәрби инженерлар академиясендә укый иде. Ул академия спортчыларының җыелма командасында икән. Стадионны әйләнеп чыгабыз. Берничә әйләнешне ураганнан

соң, минем түземлек бетте, туктадым. Сәгыйть аннан соң да сәгатьтән артык йөгерде әле. "Авылда ял иткәндә калган физик нагрузканы да үтәргә кирәк", – диде ул.

Спортчыларның тормышы да җиңел түгел икән! Ленинград поездында барганда пассажирларның, балга буялганнан соң, ризасызлык белдерүләре турында әйттем бит әле...

Шушы урында бу темага охшаш бер вакыйганы искә төшерәсе килә. 1966 нчы елның җәе. Казанга "Кукурузник" дип аталган "АН-2" самолеты оча. Самолетның җилкүенә чыдар әмәл юк. Күңелне болгата, күп вакытта костыра да. Казанга барып җиткәнче, хәлдән таясың. Шул мәхшәрләрне күз алдында тотып, иртән чәй дә эчеп тормыйча, Мөслим аэропортына киттем. Ашамадым – янәсе, самолетта күңел болганмасын!

Аэропорт Мөслимнең үзенә үк терәлеп тора. Барып җиттем. Аэропорт начальнигы Исмәгыйль Бикбаев миңа игътибар итте:

– Бик кәефсез күренәсез, әллә авырыйсызмы? – ди бу.

– Авыруын-авырмыйм. Очуны авыр кичерәм мин, күңелне болгата, шулар куркыта, – дим.

– Миндә аның даруы бар, әйдә, минем бүлмәгә! – дип алып керде бу мине бүлмәсенә. – Эчеп җибәр әле шушыны, – дип, миңа ару гына "Вермут" салып бирде.

– Эч, эч, даруы шушы аның! – дигәч, ышандым белгечкә, эчеп куйдым. Самолет килгәнче, пассажирлар өчен дип куелган олы савыттан бер алюмин кружка салкын суны да эчеп җибәрдем. Ышанычлы була, янәсе.

Самолет килде. Кереп утырдык. Кемнәрдер пакет сорап алды. Элиталы тәртиптә очу тәэмин ителгәч, мин пакет алып тормадым. Һавага күтәрелдек. Самолет әйбәт кенә болгата да башлады, упкынга егылып төшкән кебек хәрәкәтләр ясый. Пакетларын авызларына каплап утыручылар күренә башлады. Мин бернәрсә дә уйламыйча утырам, "даруланып" чыкканыма сөенеп туя алмыйм. Кинәт самолет чираттагы "упкын"га томырылды. Үпкәм авызымнан чыга, дип торам. Шулвакыт Исмәгыйльнең "дарулары" чыгып ычкынганын сизми дә калдым. "АН-2" самолетына утырып караган кеше белә булыр – анда бит утыргычлар ике ян стена буйлап тезелгәннәр, уртада бушлык. 13ме, 14ме пассажир бер-берсенә карап утыра. Исмәгыйльнең "даруы" калай идәннән елга булып ага, самолет янтайганда, ул "елга" тармаклана, пассажирларга юнәлә, алар аякларын җыялар. "Вермут" дигән вино кып-кызыл була икән ул. "Үзе ару гына кеше, кан косты бит!" – дигән сыман, миңа шикпә-

неп карыйлар. Аларга ни эчкәнемне аңлата алмыйм бит инде мин?! Бу юлы Казанга бару минем өчен олы җәза булды...

Сүз Ленинград турында иде бит әле – Ленинградның гүзәллегенә соклануымның чиге юк. Безнең конференциядә чыгышлар кичке дүрттә тәмамланды. Аннары мин Можайский академиясенә, Сәгыйть янына киттем. Аның белән кайтып барганда, урамдагы игъланга күзебез төште. Анда Мөслим Могамаев концерты булуы турында язылган иде.

Могамаевның әле дөньяга чыга гына башлаган вакыты. Концерт стадионда була икән. Киттек шунда. Стадион уртасында сәхнә көйләнгән. Башта сәхнәгә Азербайҗан дәүләт симфоник оркестрының күп сандагы музыкантлары чыгып урнашты. Мөслим Могамаевны стадион тулы халык басып каршы алды. Ул Арно Бабаджанян, Александра Пахмутова, итальян җырларын шундый да профессиональ югарылыкта башкарды ки, күп меңләгән тыңлаучы тынсыз калды. Башкарылган һәр җырдан соң кул чабулар, “Браво, Муслим!” – дигән сүзләр чиксез күп булды. Әле болары баласы гына булган икән! Итальян композиторының “Севилья чәч алучысы” операсындагы Фигаро ариясеннән соң, стадионда булган хәлне сүз белән генә аңлата торган түгел! Бу җыр, Мөслимнең искиткеч баритоны, башкару техникасы, дикциясе, үзен тотышы тыңлаучыларны әсир итте. Кул чабуларның чиге булмады! Мөслимнең кабат-кабат җырлавын сорадылар. Артистның гадәттән тыш талантын халык бик югары бәяләде! Ә бит ул вакытта аңа 25 яшь тә юк иде әле!..

Бу концертка бару идеясе минеке иде. Мондый ләззәт өчен, Сәгыйть миңа рәхмәтен кабат-кабат әйтте.

Кайткач, хатынына да сөйләде: “И, Лиза, син генә булмадың, без гомергә бер генә тапкыр була торган тамаша карадык. Мондый җырчы яңадан туар яки тумас?! Менә аны җырчы дисәң дә була!” – дип, соклануын белдерде. Минзәлә педучилищесында укыганда бирелгән музыка тәрбиясе яши иде анда. Аның янында һәрвакыт мандолинасы булыр иде, уйнап-җырлап утырыр идек...

Икенче көнне Сәгыйть: “Монда безнең авылдан бер абый бар. Әйбәт абый. Сиңа да ошарга тиеш ул, барыйк әле шуларга”, – диде ул. Шул абыйларга киттек. Хәеретдин исемле абый иде ул. Сугыш алдыннан аны ФЗОга алганнар. Анда ул һөнәргә өйрәнеп чыга, эшли башлый. Сугыштан соң аны Ленинградны торгызырга җибәрәләр. Актаныш ягыннан килгән эшче кызны – Сәмәрә апаны очрата. Алар гаилә коралар. Бик матур

гаилә иде бу. Ачык күңелле, кунакчыл, юмарт иделәр. Бу очрашудан соң, мин алар белән туганлашып калдым. Сәгыйть белән Лизаның миңа зур ярдәмнәре тиде. Ленинград пединститутындагы аспирантурада укыган елларымда өч ел буе мин алар белән аралаштым. Аспирантурадан соң да, Ленинградка күп мәртәбәләр килдем әле. Һәр килүемдә Хәеретдин абый, Сәмәрә апаларга бара идем. Һаман Сәгыйтьләргә, яхшылыклары өчен, күңелемнән рәхмәт укый идем.

Академиядән соң, Сәгыйтьне эшкә Себер ягына җибәрделәр. Сәләтле инженер буларак, аңа эшнең җаваплысын тапшырдылар. Сәгыйтьнең ул еллардагы шөгыле ракеталарны очырту белән бәйле булды кебек. Эш урыны да шифрлар белән генә языла иде. Соңгы эш урыны аның – Мәскәүдә, үз юнәлешендәге конструкторлык фәнни-тикшеренү институтында җаваплы бүлек мөдире – полковник дәрәҗәсендә булды.

Сәгыйтькә карыйм да, сокланып туя алмыйм. 50 елдан артык гел руслар арасында гына яшәсә дә, бер генә рус сүзен дә катнаштырмыйча, саф әдәби телдә сөйләшә ул. Рус телендә язуы да, сөйләшүе дә аның руслар көнләшерлек!..

Мәскәүдә мин берничә тапкыр белем күтәрү курсларында булдым. Мәскәү университетының тулай торагында яшәгәндә, ул минем янга еш килә иде. Сәгыйтьне эшендә руслар "Сагыйт Гыйниятович" дип түгел, ә "Александр Григорьевич" дип атаганнарын мин белә идем. Безнең бер бүлмәдә яшәүче коллегаларым алдында мин Сәгыйтькә "Александр Григорьевич" дип эндәштем. Сәгыйть тә сер бирми, русча сиптерә.

Сәгыйть, чын йөрәге белән, балыкчы. Һәр ялын ул Әстерхан өлкәсендә уздыра иде. Анда Идел елгасы янындагы бер авылда вакытлыча фатирга урнаша, көн саен балыкка йөри, ул балыкны тозлый, киптерә. Кышлык запас белән Мәскәүгә кайта. Аларга кайчан гына барып керсәң дә, балык белән сыйлар иде.

Озын ялга чыккач, аның хәзерге төп шөгыле – бакчачылык. Бу эшне дә ул ратып башкара. Казанда бакча урыны 15-20 километрдан артса, ерак, дибез. Аларга җирне Мәскәү өлкәсенең иң читендә биргәннәр, ераклыгы 300 километрдан арта бугай. Башта электричка белән Мәскәүнең Ярославль вокзалына барасы, аннан ике сәгать ярым тагын поезд белән, аннары – автобус белән, аннары җәяү барасы. Алты гына сәгать барасы, диләр.

Элек ул җирләр ташландык урман булган. Сәгыйть башта, шул җирдә агачларны төпләп, төзү материаллары җыйган.

Аннары үз кулы белән шул урында бакча йорты, мунча, сарай салды, җиләк-җимеш, яшелчә, чәчәкләр үстерү остасына әйләнде. Лиза белән ике кыз үстерделәр. Алар икесе дә университет тәмамлап, югары квалификацияле белгечләр булдылар, матур гаилә кордылар. Сәгыйть хәзер, оныкларының кадерле дәү әтисе буларак, аларга физика-математика фәннәрен үзләштерергә ярдәм итә.

Таңкыр Әфтах

...30 еллар дәвамында СССР дигән зур дәүләтнең башында торган Иосиф Сталин акылсыз кеше булмаган. “Барысын да техника хәл итә!” – дигән лозунгны да беренче мәртәбә ул әйткән. Әмма дә ләкин илебездә гомер-гомергә техникага кытлык булды. Узган гасырның 60 нчы елларында безнең тирәдәге 5 авылны берләштергән Мулланур Вахитов исемендәге колхозда да шул ук хәл иде. Бигрәк тә йөк машиналары җитми. Җиңел машина турында әйтмибез дә – алары юк та юк инде. Колхозларга Горький шәһәрендә эшләнгән “ГАЗ-51” машинасы кайткалый. Урманга барырга да, сөт, икмәк ташырга да, тирес түгәргә дә, районга барырга да шул машина булды. Шул машиналарның берсе ватыла бервакыт.

Колхоз рәисе Хәкимулла Шайхрамов бу уңайдан идарә утырышы җыя. “Нишлибез?” – дигән сорауны кабыргасы белән куя. Идарә әгъзаларының тәкъдимнәренең берсенә тукталалар. “Иваново шәһәрендәге заводка барып, ватык машинаны яңартып алып кайтырга!” – дигән тәкъдимне барысы да хуплый.

–Бу эшне кемгә тапшырабыз соң? – ди колхоз рәисе.

Бу сорау да бик мөһим. Иваново шәһәре ул – Мөслим “Сельхозтехника”сы гына түгел. Машинаны тапшырасы да, чиратсыз гына төзәтеп чыгасы да бар!

Уйлый-киңәшә торгач, мондый мөһим эшне башкарып чыгарга тиешле җаваплы кешеләр дә табыла. “Колхозда баш инженер вазифасын башкаручы Әфтах белән Әмиргалимгә тапшырырга кирәк бу эшне!” Шәйхрамов фикеренчә: “Әмиргалим – колхозның “әйбер табучысы” – күптәннән инде “Шпион №1” кушаматын уңышлы йөртә, кая гына җибәрсәң дә, тапмыйча кайтмый. “Әфтах та соңгы вакытта шактый шомарды, ул “Шпион №2” булыр!” – ди ул.

Аллага тапшырып, боларны ерак юлга җыйнаштырып чыгарып җибәрәләр.

Ничек кирәк алай, Иваново шәһәренә барып җитәләр бо-лар. Юлда күргән михнәтләрен язып тормыйбыз. Беренче эш итеп, тамак туйдырып алырга уйлыйлар. Машинаны урамда калдырып, ресторанга юнәләләр. Күнелле генә сыйланып чы-галар. Чыксалар, машина куйган урынында юк. Машинаны уг-рылар алып киткәннәр. Эзләп-эзләп карыйлар, машинадан җилләр искән...

"Шпионнар" авыр хәлдә кала. Ә бит әле аларның авыл халкы алдында данлыклы кушаматлары – исемнәре бар. Ыша-нычны ничек тә акларга тиешләр! Башларына йомры фикер килә: "Безгә дә бер машинаны урларга кирәк!" Һәм шундый ук маркадагы бер йөк машинасын урлыйлар да. Үзләренеке итеп, шул машинаны заводка төзәтергә тапшыралар. Шпион-лык сыйфатлары бу эштә булышмый калмагандыр...

Заводта машинаны төзәткән арада, авылдан алып килгән машинаның урлануы турында милициягә хәбәр итәләр.

Күп тә үтми, заводтан төзәтелгән машинаны алып чыга-лар. "Шпионнар"ның күңелләре күтәрелеп китә. Уңышлы баш-карылган эшне "юып" та алалар. Юуны мулрак җибәргәннәр, ахрысы. Иртән торуга Әхтафиның бер күзен таба алмыйлар. Куелган ясалма күз, шиплэптер, урынында түгел. Эзләп-эзләп тә таба алмагач, аптекадан яңа күз сатып алып куялар. Тик күзнең боларга кирәк төсе генә булмый. Элекке коңгырт күз урынына, яшел күз куярга туры килә.

Машинаны колхозга алып кайтып тапшыралар, Шәйхра-мовның мактау сүзләренә лаек булалар.

Бер атнадан Иваново милициясеннән колхозга телеграм-ма килеп төшә. Анда урланган машинаның табылуы турында әйтелгән, аны тиз арада килеп алырга кушылган була.

"Шпионнар"га хәлнең ничек булуын сөйләп бирергә туры килә.

–Ике төрле күз белән кайтып керү белән үк шикләнгән идем аны, монда ниндидер безгә билгеле булмаган вакыйга бу-лырга тиеш, дип. Ярый инде, ике машиналы булдык, бусын алырга да үзегезне җибәрәм! – ди Хәкимулла Мөхәммәтович Шәйхрамов...

Ногманов абый

Исмәгыйль Галимуллович Ногманов мәктәптә укучыларга авыл хуҗалыгы машиналары фәненнән укытты. Үз эшен яра-тып башкара иде. Бөек Ватан сугышы алдыннан техник юнә-

лештәге хәрби училище тәмамлаган. Сугыш беткәч, өлкән лейтенант булып, Мөслимгә кайтып, гомере буе шунда эшләде. Район үзәгендә почта бүлегендә эшләгәндә, радио, телефон челтәренә контрольлек итү аның җаваплылыгында иде. Авыл халкы аның Мөслим радиосыннан ясаган чыгышын әле дә кызык итеп искә төшерә. Аерым фатирда радио һәм телефон өчен вакытында түләмәгән кешеләрне кисәтеп: "Радио һәм телефон өчен вакытында түләмәгәннәргә бүгеннән чара күрә башлыйбыз: Галимәрдановныкын – өзәбез, Афанасьевныкын – кисәбез, Фазлыевныкын – кыскартабыз..." – дип сөйли икән Исмәгыйль абый Ногманов...

Аннары ул эшкә Мөслим урта мәктәбенә күчте. Озак еллар укучыларны хезмәткә әзерләде. Узган гасырның 60нчы елларыннан башлап, мәктәпләрдә, укучыларга гомуми урта белем бирү белән бергә, башлангыч профессиональ белемнәр һәм күнекмәләр дә бирелде, ир-балалар "Механизатор яки машина йөртүче" таныклыгы алып чыкты. Булачак механизаторларга трактор, комбайн һәм башка авыл хуҗалыгы машиналарының серен Ногманов абыйлары өйрәтте. Аны олысы да, кечесе дә фамилиясе белән генә атады. Ул техниканы тирәнтен белә, катлаулы процессларны гади сүзләр белән, җиңел генә аңлата иде. Мәктәпнең завучы буларак, аның дәресләрен шактый тыңладым. Шулай, бер дәрестә дизельле һәм карбюраторлы двигательләрнең үзенчәлекләрен аңлата бу, чагыштырулар китерә: "Карбюратордан эчке яну двигателенең цилиндрына ягулык кечкенә малай "пес" иткән кебек бирелсә, дизельле двигательләрдә исә ягулык цилиндр эченә, кер үтүкләгәндә авызга алган суны бөркегән кебек, бирелә. Мондый бөркүне форсунка башкара", – ди.

Ногманов абый юморга бай иде. Шулай бервакыт, мәктәптә укытучыларның гомуми җыелышы билгеләнгән вакытта башланып китте. Бераздан, соңарып, мәктәпнең яшь укытучылары Рәис Назаров һәм Фаил Ягудин килеп керделәр. Җыелышны алып баручы мәктәп директоры В.А.Иванов аларны, соңга калулары өчен, каты гына шелтәләп алды. Ногмановның репликасы җитди атмосфераны йомшартып җибәрде:

– Туктагыз әле, иптәшләр! Безнең бу егетләргә дәгъва белдерүебез гадел буламы соң? Алар нигә җыелышны бездән башка башладыгыз, дип, ризасызлыгын белдермәде бит, – диде ул...

Бервакыт укытучылар бүлмәсендә сөйләшеп утырабыз. 8 нче Мартта хатын-кызларыбызны нинди бүләкләр белән сөендерүебез турында сүз бара. Ногманов абый сөйли:

– Бу 8 нче Март минем өчен онытырлык булмады ул, “арт як”ны тотып карарлык итте!

– Нәрсә алдың ул кадәре? – дибез.

– 5 тиенлек открытка бүләк иттем, – ди.

– Кит инде, Ногманов абый, бигрәк вак кеше икәнсең, – дип Әнисә Каюмовна чын күңелдән битәрләп ташлады. Шулай, һәр сүзне чынга ала торган гадәте бар иде аның.

– Алай димә, – дип дәвам итте Ногманов абый. – Открыткаларның, 5 тиенлеге янында, 3 тиенлекләре дә булган икән, шуны күрмәгәнмен. Бер тиен тормаган хатынга күбрәк булды инде...

Кызык булсын өчен генә сөйли инде. Гаиләсе белән матур яшәделәр алар.

Икенче тапкыр мәктәпнең укытучылар бүлмәсендә кабинетларны җиһазландыру турында сүз бара. Ногманов абый машиноведение кабинеты өчен, директорга дәгъва белдерә:

– Җиһазлар искерде, яңалары кирәк. Бухгалтериягә күрсәтмә бирегез, зинһар! Аның бар белгәне – акча экономияләү, – диде ул.

Бу сүзләр мәктәп бухгалтеры Нәҗия апага ошап бетмәде:

– Син, Ногманов, югары белемең дә булмаган башың белән, күрсәтмәләр биреп утырма монда, – диде ул.

Ногманов абый җавапны кыска тотты, өздереп әйтте:

– Нәҗия ханым, үземнең предметымны укытырга минем белемем бик җиткән. Әгәр дә югары белемем дә булсамы, мин бит Мәскәүдә, Кремльгә үк эләкмәсәм дә, “Охотний ряд” урамы тирәсендә булыр идем?! Монда сезнең кебекләр белән чиләнеп ятмас идем...

Шаярып сөйләшү осталыгы көчле иде Ногманов абыйның. Бер көнне, укытучылар бүлмәсенә килеп керүгә, беренче сүзе шул булды:

– Буфетка балан бәлеше китергәннәр, и тәмлелекләре!..

Шул сүзне ишетүгә, быел гына кияүгә чыккан укытучы кыз буфетка чыгып та йөгерде. Шундый ризык теләгән чагы булгандыр балакайның. Алданганын белми калды шул, мескенкәй...

Хәзер мәктәптә яңа буын укытучылар укыта. Укыту да яңача!

Күңелләребездә Ногманов, Иванов, Назаров, Ягудин кебек хөрмәтле укытучыларның якты истәлекләре генә калды инде!..

Әкрәм абый

Балаларның җәйге каникулларын һәм үзебезнең ялларны уздырырга һәр җәйне авылга кайтабыз. Ял итәбез, туганнарга, әти-әнигә булышабыз. Авыл кешесенең җәйге эшләре, тавык чүпләсә дә, бетә торган түгел бит аның: бәрәңге, яшелчә бакчасындагы эшләр, маллар өчен печән әзерләү, кышка утын әзерләү кебек эшләр берсе артыннан берсе ялганып кына тора.

...Шулай беркөнне урманнан утын алып кайтып кистек тә Вәзир абый белән шуны ярып ятабыз. Минсалих килеп керде. Эшне туктаттык. Ишек алды чирәменә утырып, әңгәмә корып җибәрдек. Сүз арасында Минсалих минем башка игътибар итте:

– Карале, Васил абый, башыңда чәчең шактый кимегән, нидән коела икән ул синең чәчләр?

Моңа кадәр бу турыда бер дә уйланганым юк иде. Әлбәттә, чәч коелуның сәбәпләре бар инде аның. Кайбер кешегә ул нәселдән килә, акыл эше белән күп шөгыльләнүдән, дигән фаразлар да бар, кайбер авырулардан соң да чәч коелу очраклары була. "Безнең нәселдә пеләш башлы кешеләр моңа кадәр булмады, авыру кичерүне хәтерләмим, әллә күп вакытны уку-язу, фән белән үткәргәнгә микән?" – дип җавап бирергә торганда, Минсалих әйтеп куйды:

– Васил абый, әгәр дә күп укыганнан, дип әйтергә уйласаң, әйтим, Әкрәметдин абый хәреф танымый, ә башында бер чәче дә юк.

Чыннан да, шулай иде шул. Әкрәм абый укый да, яза да белми, ә бер чәчсез шәрә башы ялтырап тора иде!..

Әкрәм абыйның яшьлегендә гомуми мәҗбүри уку закон белән кертелмәгән була. Аңа мәктәпләрдә укырга туры килмәгән. Әмма да ләкин, Әкрәм абыйның кулы алтын иде: агач эшенә дә, металл белән эшләүгә дә оста иде ул. Иске чалгылардан аның ясаган пычакларына, пәкеләренә сугым суючылар, чәч алучылар олы бәя бирәләр иде. Ул ясаган тәрәзә рамнары, йөзлекләре, арба, чана һ.б. көнкүреш кирәк-яраклары чын сәнгать дәрәҗәсендә булырлар иде.

Башка тирә-як авылларда да, бездә дә, коймалар урынына, читән үрәләр иде. Тактадан яки ташлардан җыеп ясалган койма сирәк күренеш булды. Ык буендагы әрәмәләрдән алып кайткан талдан Әкрәм абый үргән читән күзнең явын алырлык була торган иде. Талларның ялганган урынын, җөен табу мөмкин түгел. Әкрәм абыйлар турын кешеләр тиз генә үтеп

китә алмады. Һәр кеше читәнгә карап сокланып басып тора. Аннары, читәннән аерыла алмыйча, артына карый-карый, кузгалып китә.

Әкрәм абый гомере буе колхозның мастерскоенда һәм алачыкта эшләде. Алачыкта эшләгәндә, күләмле кызган тимерләрне авыр чүкечләр белән "кыйнау" өчен аңа яшьрәк ярдәмчеләр бирәләр иде. Беркөнне, Әкрәм абыйның ярдәмчесе итеп, Минсалихны куйганнар. Эш көне ахырында Минсалихка эшләгән эшләрне язып бирергә куша Әкрәм абый. Үзе Минсалих язып биргән кәгазьне тотып, бухгалтериягә "наряд" яздырырга китә.

Бухгалтерлар бүлмәсенә килеп керә. "Наряд" яздыру өчен, көне буе эшләгән эшләр язылган кәгазьне хисапчы Нажия апага бирә, тиз генә "наряд" язып бирүен сорый.

Нажия апа кәгазьне алып укый да өстәлгә ятып көлә башлый. Бүлмәдәге башка бухгалтерлар да кәгазьне килеп укыйлар, барысы да, тыела алмыйча, көләләр.

Әкрәм абый бернәрсә дә аңламыйча карап тора һәм сабырлыгы бетеп әйтә:

– Эшләгән кешедән көлеп утырасыз, бүген эшләгән эшнең күләме көлерлек кенә булмады, куллар әле дә сызлап тора...

– Монда бернинди дә эш язылмаган бит, Әкрәм абый?!

Кәгазьдә, чыннан да, бернинди эш тә язылмаган була. Әкрәм абыйның язу танымавын исәпкә алып, Минсалих шаярткан, кәгазьгә "китап та эшләмәде", дип язган. Китап сүзендәге кайбер хәрефләрне китапча булмаганнары белән үзгәрткән.

Соңрак Минсалихка, тупас шаяруы өчен, Әкрәм абый каршында гафу үтенергә туры килде.

Минсалихны тимерче ярдәмчесе итеп юкка гына куймаганнар инде?! Ул, авылда сигез классны тәмамлагач, Минзәләнең зоотехникумын тәмамлады. Анда укыган елларында ул спорт белән актив шөгыльләнгән. Зоотехникумны тәмамлап чыккач, чын атлет булып кайтты. Безнең авылда, буа аръягында, ул, көрәш белән шөгыльләнү өчен, махсус мәйдан җиһазлады. Анда герләр ташыды, капчыкларга ком тутырып, "көрәшче муляжлары" булдырды. Бу тренировкалар аңа матур нәтиҗәләрен дә бирде. Башта ул сабантуй мәйданнарында үзебезнең авылда һәм күрше-тирә авылларда батыр калды! Аннары Кадыйров Минсалих район күләмендә танылды, район сабан туйларында берничә мәртәбә батыр калды. Авыр үлчәү категориясендә, чын пәһлеваннарча көрәшүен исәпкә алсаң, Минсалихның батырлыгына сокланмый мөмкин түгел!..

Минсалих сөйләргә бик оста. Аның белән әңгәмә кору күңелле. Бервакыт сөйләшеп утырабыз. Минсалих үзенә өй салып йөрүе турында сөйли. Мин әйтеп куйдым:

– Зур эш башлагансың, Минсалих. Бетереп чыгарга язсын. Только акча күп кирәк булыр инде!..

– И, Васил абый, – диде ул. – Өйне акча белән салалармыни?! Төзү материалы кирәк монда!

Минсалих ул елларда лесник булып эшли иде. Әйткән сүзен чамалап әйткәндер. Йортын ул, җиренә җиткереп, шул елны ук төзеп керде...

Йомры сүзле авылдашлар

...Колхозда көрәк, сәнәк саплау, тырма тешләрен төзәтү, тәрәзә, ишекләр алыштыру белән шөгыльләнүче Салах абзый мастерскоена эшкә соңарып килгән. Колхоз рәисе аның килүен көтеп тора икән. Шунда ул Салах абзыйга ризасызлыгын белдергән:

– Эшкә соңарып йөрисең, Салах абзый! – ди икән.

Салах абзый да югалып калмаган:

– Аның урынына, мин эштән иртә кайтам! – дигән дә, мастерскоена кереп киткән. Колхоз рәисе, халкыбызның әйтеммәкальләренә тиң мондый җавапны ишетеп, телсез калган...

...Бервакыт колхозның техникасы, машиналары өчен запас детальләр складында төбендә механизаторлар, шоферлар җыелган. Склад мөдире Әхмәтҗанов Галимҗанны көтәләр. Һәркемгә складтан нидер алырга кирәк. Сәгать 9 тулып килә. Галимҗан юк та юк. Болар янына колхоз рәисе дә килеп туктый. Складның эшләмәвенә ризасызлыгын белдерә.

Шулвакыт тыкрыктан Галимҗан килеп чыга, болар янына якынлаша.

– Ну, бирә моңа хәзер председатель! – дип, халык кызык күрергә җыена.

– Оятың бармы синең, конца-концов, колхозчы эшкә шушы вакытта йөримени?! – дип, рәис Галимҗанга ачу белән кычкыра.

– Мин бит – колхозчы түгел, мин бит – завсклад! – дип, Галимҗан тыныч кына үз эшенә керешә.

– Тьфү, “икылымыны”, моның белән ачуланышып та булмый бит, ичмасам! –дип рәис китеп бара...

Авыл халкының җор телле булуының мисалы булып, безнең авылның гомуми җыелышы истә калган.

...Узган гасырның 50 нче еллары бу. Авыл җыенындагы көн тәртибендә колхоз рәисенең эшләгән еллары өчен отчеты һәм яңа срокка рәис сайлау булачак икән. Клубта энә төртерлек тә урын юк. Ул елларда халык шактый актив иде шул! Авылга кино киләме, концерт яки спектакль куеламы – клуб тулы халык булыр иде. Ә бу җыелыш үзенчәлекле – монда эшләп торган колхоз рәисен алыштыру һәм яңаны сайлау булырга тора. Һәм шулай булды да. Колхозчылар колхоз рәисенең күп кенә гаепләрен күрсәттеләр. Районның партия райкомы рәисне яңа срокка урынында калдырырга тырышса да, колхозга яңа рәис Әслах Салахов сайланды.

Элекке рәис Габдрахман Мәрдәнов соңгы сүзен дә әйтте:

– Энәдән курыктыгыз, лом йоттыгыз, иптәшләр! – диде ул.

...Чибәрлеге белән аерылып тора иде Надя. Медсестра булып эшли иде. Кешеләргә мөлаем, рус булса да, татар телен дә камил белә иде. Ире үлеп киткәч, ялгыз калды.

Шахтадан ике аягын да имгәтеп кайткан Фоат Надялардан ерак яшәми. Күрешкән вакытларда Надя Фоатка ачык итеп сәлам биреп йөри. Фоатка шул җитә кала. "Гарип булсам да, Надя мине якын итә, бәлки, ярата да торгандыр әле?!" – дип уйлый Фоат. Шул уй белән, ул, караңгы төшкәч, Надяларга китә. Эчтән бикләнгән ишекне кага башлый. Эчтән Надяның тавышы ишетелә. Сөйләшү башлана:

– Кто там?

– Бу – мин, Фоат.

– Что тебе надо, Фоат?

– Ач әле, сине күрәсем килә.

– Фоат, тебя никто не видел?

– Беркем дә күрмәде, Надя, ач инде?

– Уходи к чертовой матери, пока никто не видел!..

Мөнәвәр абый

Патша Россиясе чорында, Советлар вакытында да авыл кешесе, илнең башка категорияле гражданнарына караганда, авыр шартларда яшәде. Авыл кешесе һәр көнне иртәнге дүрттән калмый йокыдан тора, малларын карый, көтүен куа, колхоз эшенә китә, төн булгач кына эштән кайта. Аның ял көне дә, чираттагы ялы да юк. Аңа паспорт та бирелми, каядыр китәргә дә рөхсәт ителми.

Шуның өстенә, аңа күпме салым, күпме заем түләү мәҗбүри?! Ә эшләгән өчен акча бирелми.

Халыктан салым җыючы вәкилләр авылга еш киләләр иде. Алар колхоз идарәсе йортына яки клубка авыл халкын җыя. Халыкны "кысу" башлана. Акчасы булганы түләп, яки фәлән көнне түләргә вәгъдә биреп, кайта тора. Бу эш күп вакыт төн уртасына кадәр бара.

Бер көнне, соңгы кеше булып, Мөнәвәр абый кала. "Бүген үк салымыңны (заемыңны) китереп түлисен, бүген үк!" – дип кысалар икән тегене. Бу сүзләр берничә мәртәбә кабатлангач, Мөнәвәр абый әйткән: "Ә-ә, и-и-иртә-гә ни була?" Ул тотлыгып сөйләшә иде.

Вәкилләр ни әйтсен, җавап юк. Мөнәвәр абый, салымны иртәгә түләсәм ярамасмы, дип әйтергә уйлаган икән...

"Сыеры савылган"ны кем белә?

Безнең күрше-тирәдә урнашкан Югары Табын, Түбән Табын, Тегермәнлек, Тугаш, Тамьян авыллары бер авыл Советы территориясенә керә иде. Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң (50 нче елларның башында), авыл Советы рәисе булып берничә ел безнең авыл кешесе Зәки Латыйпов эшләде. Түбән Табын җидееллык мәктәбе директоры Әмир Гәрәевич Гәрәевкә партия оешмасы секретаре вазифасы йөкләнгән. Әмир Гәрәевичкә Зәки абзыйның хатыны Зәкия апа килә. Алар арасында шундый сөйләшү булып ала. Зәкия апа башлый:

– Син, Гәрәев, "партиец"ларыңны тота беләсеңме, юкмы?

– Нидән чыгып әйтәсең әле син моны, Зәкия апа?

– Белмәмешкә салынып торма инде син, иптәш Гәрәев, Зәкинең йөрүен бөтен авыл белә. Син генә белмисең, имеш. Зәки йөри, тыярга кирәк!

– Ялгышасыңдыр, Зәкия апа! Зәки абый йөрсә, мин белми калмас идем...

– Син аны миңа сөйләп торма инде, иптәш Гәрәев. Сыерымның савылып кайтамы, савылмый кайтамы икәнен генә беләбез без!..

Гәрәевнең "партиец"ка йогынтысы булмый калмагандыр. Зәкия апаның парторг янына икенче тапкыр баруы турында авыл халкы белми. Ләкин Зәки абзыйның кайбер шуклыклары турында сүзләр булгалады.

...Ул чорда авыл клубына бильярд кайтардылар. Авылдагы ир-ат затыннан – яше дә, карты да бильярд белән мавыгып китте. Өлкәнрәк яшьтәге Миргасим, Габит, Талибулла абыйлар, клубтан яшьләр таралгач та, бильярд уйнарга калалар иде. Зәки абзый да бильярдны бик ярата, дип сөйлиләр иде. Зәкия апа олы кешенең бу гадәтенә, әлбәттә, каршы. Зәки абзый да тактиканы үзгәртә. Клуб кайгысы юк әле, йокы килә, дип Зәкия апа белән йокларга ята, Зәки хатынының йоклап киткәнен көтә. Ул йокыга китүгә, абзый, саклык белән генә торып, өстенә толып кына бөркәнеп ала да, ак ыштанын җилфердәтеп, клубка чаба. Клубка гына чапкандырмы, әллә аны башка урыннар да кызыксындыргванмы – бусы безгә мәгълүм түгел...

"Чекист"

Район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгән еллар. Беркөнне иртән үк партия райкомыннан шалтыраталар. Безнең районга Татарстан Мәгариф министры Мирза Исмәгыйлович Мәхмүтов килә икән. Аны каршы алырга әзерләнергә кушалар. Безнең районга ул Сарман районыннан киләсе икән.

Сарман РОНОсына телефон аша чыктым. РОНО мөдире Ш.М.Гайнетдинов белән килештек. Министрны без Сарман һәм Мөслим районнары чигендәге Рантамак авылы янында каршыларга булдык.

Район Советы башкарма комитеты рәисе Г.Н.Аксаков белән министрны каршыларга олы юлга чыгарга гына торганда, Сарманнан яңа хәбәр килде. Безнең районга министрны икенче юлдан китерәләр икән, Түбән Табын ягыннан. Шунда чыгып киттек. Министрны каршыладык. Мөслимгә юл тоттык. Түбән Табынны чыгып барабыз. Министр әйтеп куйды:

– Бу авылда мәктәп бардыр бит!..

...Бу авыл мәктәбе соңгы елларда директордан уңмады. Элекке елларда уңышлы гына эшләп килгән мәктәп аксый башлады. Уку елы алдыннан гына куелган яңа директорда да әллә ни өмет күренми. Ул Актаныш районында бер колхозның партком секретаре булып эшләгән. Югары партия мәктәбендә безнең беренче секретарь белән бер чорда укыганнар. Беренчегә эш сорап мөрәҗәгать иткәч, аны мәктәп директоры итеп билгеләгән идек.

Бу эштә тәҗрибәсе юклыгы үзен сиздерде. Белем стандартлары алышынган чор бу. Һәр фәнне яңа программалар ниге-

зендә, яңа дәреслекләр белән укытабыз. Укытучыларның үзләрен дә моңа әзерләргә кирәк. Шуңа күрә, мәктәпләрдә дә, район үзәгендә дә күп төрле курслар эшли башлады.

Мирза Исмәгыйлович министрлыкта күптән эшли иде инде, тәҗрибәсе зур. Мәктәп директорына сорауны "кабыргасы" белән куйды:

– Яңа программаларга ничек күчәргә уйлыйсыз?

Беренчесең тәкъдиме белән директор булып килгәнлектән, ул үзен шактый эре тота иде, мин-минлеге дә, Тукай әйткәнчә, "бер вагон". Министр соравына җавап бирергә җитешә алмый калдым, директорыбыз сиптерә генә:

– Укытучылар өчен курслар оештырабыз.

– Ә укучыларны кем укыта?

– Үзем укытам.

– Ә башлангыч класс укытучыларын кем укыта?

– Аларын да үзем укытам.

– Сезнең белемегез ничек соң, нинди уку йортын тәмамладыгыз?

– Югары партия мәктәбен тәмамладым мин, бу районның беренче секретаре белән бергә укыдык.

Министр Аксаков белән миңа карый. Аның гаҗәпләнүеннән чиге юк.

"Кая алып килдегез сез мине? Мәктәпне нинди хәлгә төшергәнсез!" – диде ул.

Директорның урынсыз мактануын, укытучыларны курсларда укыту өчен, Казанда укытучыларның белемен күтәрү институтында махсус әзерлек үтүләре, шулар ярдәмендә, район мәктәпләрендә яңа программаларга күчү өчен, махсус курслар уздыруыбыз турында аңлатырга туры килде.

Министрның кәефе кырылган иде. Хәлне җайларга теләп, мин аңа мөрәҗәгать иттем:

– Мирза Исмәгыйлович, кәефегез дә күтәрелер, безнең башка мәктәпләрне дә карап чыгыйк әле, – дидем.

–"Рисковать" итәсез бит... Мин бу районда бүгенге көн таләпләре югарылыгында эшли торган мәктәпләр бардыр, дип китәм. Ә хәзер барачак мәктәпләрегез дә ошамаса, нәрсә була?! – диде ул.

– "Риск" булса-булыр, – дип мин министрны Күбәк урта мәктәбенә, аннары Бәкәбез башлангыч мәктәбенә алып киттем.

Күбәк мәктәбе коллективына, аның директорына ул югары бәя бирде. Мәктәп директоры Д.Г. Галиевны, кичекмәстән, "Та-

тарстанның атказанган укытучысы" исеменә тәкъдим итәргә кушты.

Бәкәбез башлангыч мәктәбендә булуны ул үзенең министрлыкта эшләгән елларының иң бәхетле минутлары, дип атады. Мәктәп, чыннан да, сокланырлык иде! Яхшы нарат бүрәнәләрдән салынган мәһабәт бина – иркен сыйныфлар, укытучылар бүлмәсе, методик кабинет, спорт залы, ашханә. Бүлмәләрнең оста бизәлеше, методик кабинетның байлыгы, фәннигметодик әдәбиятның, газета-журналларның күплегенә хәйран калды министр.

Мәктәп яны тәҗрибә участогындагы җиләк-җимеш, яшелчә культураларының фәнни нигездә үстерелүенә игътибар итте. Гаҗәеп матур чәчәкләргә су сибеп йөрүче балаларны күреп, шатлыгын яшерә алмады. Казанга кайту белән, бу мәктәп турында язып чыгарга журналистлар җибәрергә вәгъдә итте. Әмма дә ләкин журналистларны күрергә насыйп булмады. Казанга кайткач, министр вәгъдәсен онытты...

Сүзебез Бәкәбез мәктәбе турында иде бит әле... Мәктәптә мөдир һәм укытучы булып, озак еллар Галия Кашаповна эшләде. Мәктәптә укыту-тәрбия эше югары дәрәҗәдә, үрнәк булырлык иде. Мәктәпкә колхоз рәисе – Галиянең ире Вәлихан Кәшбиев – һәрвакыт ярдәм итеп торды. Укучыларга һәр уку елында укучылар формасы, дәреслекләр, колхоз исәбеннән бирелде, бушлай туклану оештырылды, мәктәпне җылыту өчен ягулык вакытында ташып куелды һ.б. Укучылар өчен һәр җәйдә Казан, йә Ульяновск шәһәрләренә экскурсияләр оештырылды.

Беркөнне минем янга, РОНОга, Галия апа килеп керде. "Үзем өчен укытып торырга укытучы билгеләдем, мин Бөгелмәгә, "Учколлектор" кибетенә барып кайтыйм әле. Күчергән акчабыз бар иде. Үзең бармасаң, теләсә нинди кирәксез әйберләр тутырып җибәрәләр," – диде ул.

Рөхсәт бирдем. Үзем уйлап куйдым: "Эшен һәрвакыт җиренә җиткерә торган укытучыларыбыз, мәктәп җитәкчеләребез бар бит!" – дип шатландым. Казандагы "Учколлектор" кибетенең Бөгелмәдә филиалы бар. Мөслим районы мәктәпләренә – укыту өчен кирәк-яраклар, карталар, таблицалар, физика-химия-биология кабинетлары өчен, җиһазлар, приборлар белән тәэмин итү аңа тапшырылган. Башлангыч мәктәп мөдирләре бу кибеткә барып йөрми инде. Аларга үзләренең кустыдагы урта яки тугызеллык мәктәп мөдирләре үзләреннән арткан уку әсбапларын бирәләр.

“Менә бит, – дип уйлыйм. – Мәктәбе, укучылары өчен янып йөри, кирәкле җиһазларны китереп бирерләр, дип көтеп утырмый, 150 км ераклыктагы Бөгелмәгә барып, үзенә кирәген алып кайта. Җитмәсә, үзе – хатын-кыз!”

Бер атна чамасы вакыт үтте микән, райбашкарма председателе Г.Н. Аксаков мине үзенә чакырта. Бардым. Кабинетында икәү утыралар. Берсе – колхоз рәисе Кәшбиев. Мәсьәлә болай була: Кәшбиевнең Казанда бер ханым белән якынаеп китүе беленә. Казанга баргач, ханымның фатирында очрашалар. Күрешмәгән араларда, сагынуларына түзә алмыйча, хатлар алышалар. Авылга килгән хатларны почта бүлеге начальнигы Кәшбиевкә тапшырып тора. Бервакыт почта начальнигы белән Кәшбиевның арасы бозылып китә. Хатлар Галиягә тапшырыла. Хатлардагы хисләрнең кайнарлыгы Галиягә дә күчә. План өлгерә. Ул Бөгелмәдә генә тукталмый, Казанга ук барып җитә. Хаттагы адрес белән ханымның квартирасына барып керә...

– Вәлихан абыйның тормышы җимерелергә тора. Синең хатлар аның хатынына эләккән. Абый мине сиңа җибәрде, киңәшегез, риза булса, мин Казанга күчәр идем, – ди бу.

Шушы сүзләрдән соң ул ханымның якын кешесенә әйләнә. Ханым Галияне ике көн кунак итә. Вәлихан белән танышу тарихын, аның белән булган истәлекле вакытларны, аның бүләкләре һ.б. турында мәгълүматларны бәян итә. Болар турындагы Галия райком секретарена җиткерә.

Аксаков кабинетына мин килеп кергәндә, сүз шул турыда бара иде. Аксаков миңа да олы гаеп ташлады:

– Ничек инде син – район мәгариф мөдире – үзеңнең укытучыңның кайда йөрүен белмисең?! – диде ул.

– Бөгелмәгә сорап киткән иде ул. Бөгелмәдә генә туктамаганын безгә хәбәр итмәде шул, – дидем. Ни әйтим тагын?!

– Нәрсә дип әйтәсең инде син моңа, Вәлихан Кәшбиевич? – диде Гурий Николаевич.

– Нәрсә дип әйтим, – “Чекист”, – диде ул, үзенең яңгыравыклы тавышы белән.

Озакламый Вәлихан Кәшбиевичны эшеннән алдылар. Галия апа да Мөслимгә җәяү йөри башлады. Җәяү йөрмәде инде ул. Олы юлга чыгып, кулын күтәреп, машина көтте. Утыртсалар, юлдагы машиналар аны барасы җиренә алып барды. “Чекист” хезмәтенең файдасы шул булды...

Шигъри мәҗлестә

Мөслимдә район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгән елларым. Мәгариф министрлыгы безне Казанга киңәшмәгә җыйды. Гадәттә, кунакханәдә урын әзерләп кую тәртибе юк иде. Килгән кешеләрне Зур Кызыл урамындагы Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтының тулай торагына урнаштыралар. Анда бер бүлмәдә 12шәр кеше яшәп, күңелле итеп, берничә көн торып китә идек...

...Бу баруымда "Казан" кунакханәсенә юллама бирделәр. Шунда ике кешелек бүлмәгә барып урнаштым. Күрше бүлмәдән генә безнең районның финанс бүлеге мөдире С.З. Акулов урын алган. Коридорда аның белән күрешеп алдык.

Әлеге көнне, эшләрне бетереп, кичен кунакханәгә кайттым. Бүлмәгә икенче кешене керткәннәр. Аның белән таныштык. Мәскәүдә, Әдәбият институтында укучы студент Разил Вәлиев иде ул.

— Абый кеше, — диде ул, — кичкә минем янга иптәшләр килергә булдылар, Сез каршы килмәссез бит инде?!

Мин ризалыгымны белдердем. Әкренләп бүлмәгә кунаклар җыела башлады. Араларында мин бераз белгәннәре дә, белмәгәннәре дә бар иде. Белгәннәрдән – Равил Фәйзуллин, Фәрит Гыйльметдинов (Әлмәт шәһәреннән килгәннәр), Батулла, Гәрәй Рәхим, Зөлфәт (Казаннан), Рахмай Хисмәтуллин (Түбән Кама шәһәреннән) икәнлекләре хәтердә калган...

Разил Вәлиев, минем аңлавымча, бу чорда танылып килүче, өметле шагыйрь. Аның берничә көнгә Мәскәүдән Казанга кайтуы – поэзия яратучылар өчен олы вакыйга! Шул уңайдан шигъри мәҗлес тә планлаштырылган.

Шактый кеше җыелды. Утырырга урын тапканы – утырып, урын җитмәгәннәр басып торды. Мәҗлес башланды. Тәрәзә төбенә утырып, мәҗлесне Батулла алып барды. Мондый мәҗлесләрнең беренчесе генә булмагандыр?! Һәркем үзенең ролен яхшы белә. Батулла, чират буенча, һәркемгә сүз бирә. Сүз бирелгән кеше соңгы вакытта иҗат иткән отышлырак бер шигырен укый, калганнар шигырьгә карата үзләренең фикерләрен белдерә.

Фикерләрнең төрлесе булды, Разилнең шигыре уңай яктан гына бәяләнгәне истә калган.

Батулла мәҗлесне бик оста алып бара. Һәркем шигырь турында үз фикерен әйтергә тиеш.

Менә сүз Әлмәт язучылары оешмасы җитәкчесе Равил Фәйзуллинга бирелә. Бу елларда аның исем-фамилиясе, талантлы яшь шагыйрь буларак та, еш яңгырый иде. Ул шигырь укып тормады:

— Җәмәгать, алдагы атнада Әлмәттә фронтовик шагыйрь Әдип Маликовка багышланган шигырь кичәсе була, барыгызны да шунда чакырам! — диеп, сүзен бик тиз төгәлләде.

— Бу "әсәр"гә карата Сезнең фикерегез ничек? — дип, Батулла миңа да мөрәҗәгать итте.

Башка шигырьләргә карата үз фикеремне белдереп килдем. Педучилищеда укыганда татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мөхәммәт абый Гарифуллин тәрбиясен алу һәм "Совет әдәбияты" журналында басылган тәнкыйть мәкаләләрен системалы укып бару моңа мөмкинлек биргәндер. Равил Габдрахман улына карата: "Фәйзуллин яңа әсәрен укырга теләмиме, әллә аның бүгенге халәте шушындый "әсәрләр" язу дәрәҗәсендә генәме?" – дидем.

Минем тарафтан куелган бу сорауга Фәрит Гыйльми бик борчылды. Рәттән утыра идек, минем колакка пышылдады: "И, абый, Равил Фәйзуллин – бик олы кеше бит ул. Ул бит – зур шагыйрь, безнең Әлмәт язучылары оешмасының рәисе. Аңа алай диеп әйтеп, дөрес эшләмәдең инде!" — диде. Нишлим соң, әйткән сүз – аткан ук!..

Мәҗлескә күрше бүлмәдән Сәлман Акулов та килеп кушылды. Рахмай Хисмәтуллин шигыренә бәя бирергә Батулла аңа кушты.

Шигырь мәҗлесләрдә укыр өчен генә язылган кебек, ике юлы гына хәтердә калган:

> Миңа барыбер – хатынмы син, кызмы син,
> Сал аракы, бир кыярның тозлысын!..

Акулов "тотыбрак" кергән иде бугай, шигырь фәлсәфәсенә караганда, аны финанс мәсьәләсе кызыксындыргандыр.

— Район финанс бүлеге мөдире буларак, миңа әйт әле, синең шушы "чепуха"ңа күпме түлиләр инде? — диде ул.

Блокнотына һәр сүзне эләктереп баручы Батулла да җанланып китте:

– Бу кызык сүзне онытмыйк әле, мин язам, сез дә истә калдырыгыз, җәмәгать!

Әлеге мәҗлестә, һәрбер шагыйрь шигырь сөйләп, һәрбер тыңлаучы яңа шигырьгә фикерен белдереп, бик кирәкле һәм файдалы эш башкарды, дип уйлыйм мин.

Бу кичәнең Разил Вәлиев кайткан көнгә туры килүе дә очраклы булмагандыр. Ул чорда – алтмышынчы еллар ахырында ук – Разилгә олы өмет баглыйлар иде. Күренекле шагыйрь, әдип, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, алдагы тормышында безнең ышаныч-өметләрне тулысынча аклады ул.

Батулланың да әдәбиятның барлык жанрларында да "иркен сулавы" шушы елларда ук башлангандыр...

"Бумеранг"

Авыл җирендә хәбәрләр бик тиз тарала. Халыкның авылда бер-берсен яхшы белүеннән дә киләдер бу гадәт, һәр авылда хәбәрләрне оста йөртүче кешеләр дә була. Алар бу эшне җиренә җиткереп башкара. Мөслим урта мәктәбендә эшли башлаганда, мин фатирда Миңнеямал апаларда тордым. Аларның күршесендә генә Җинан карчык яши иде. Иртән торуга, ул йөгереп кереп җитә, яңалыклар чәчә: кем өйләнгән, кем кияүдән аерылып кайткан, теге кеше кемнәрдә йоклаган... Кичә кибеттә нинди товарлар сатканнар, күрше Арслановларга "Урожай" колхозының ничә кешесе кереп кунган, килене белән кем талашкан һ.б., һ.б... Җинан карчык колакка каты иде, ишетүе дә булыр-булмас кына. Шулай да хәбәрләрне мул җыя иде, бер чыгып кайтуда күп нәрсәләрне белә.

Шулай беркөнне иртүк кереп җитте ул. Миңнеямал апага тезә дә башлады:

– Исполкомда эшләгән Кәшифразов Рәисне беләсеңдер? Ул элек авыл хуҗалыгы идарәсендә агроном булып эшли иде. Хәзер ул исполкомның райплан председателе икән. Эштән кайтып керми, хатынына бер дә булышмый икән. Хатыны моңа әйткән: "Рәис, син берәр әйбер уйлыйсыңмы, юкмы? Син хәзер безнең йортта "квартирант"ка әйләндең бит. Бер эш тә эшләмисең, кайтып йоклыйсың гына. Мин балаларны да карыйм, ашарга да пешерәм; яшелчә бакчасында, бәрәңге бакчасында күпме эш; кышка утын әзерләнмәгән, сыерга печән чабу турында да уйламыйсың, мин барысына да ничек җитешим?!"

– Беләсеңме, малакаем, Рәисе нәрсә дигән? "Соң, хатын, син җитешә алмый дип, мин синең янга икенче хатын алып кайта алмыйм бит инде?" – дигән, имансыз!

Миңнеямал апа янына чәй эчәргә йөрүче карчыклар бу сүзләрне авылга бик тиз тараттылар.

Рәиснең шулай җайлап кына әйтә торган гадәте бар иде. Сүз әйтергә бервакытта да кесәгә керми иде. Райондагы олы киңәшмә истә калган. Район клубында бара җыелыш. Докладчының чыгышы бик озынга китте. Минем кулда “Огонек” журналы бар. Шуны караштырып утыра башладым. Бер мәкаләдә кайсы илнең балыкны күпме тотуы турында язылган. Безнең илнең күрсәткече Япония, Норвегия һ. б. илләрнекеннән түбән. Минем кырда утырган Рәискә мөрәҗәгать итәм:

– Карале, Рәис, никадәр океаннар, диңгезләр, елгалар, күлләр булса да, безнекеләрнең нәтиҗәләре шактый тыйнак икән! – дим.

Рәис, күп уйлап тормады:

– Монда бит әле Бубековлар, Дуфак Мансуровичлар тоткан балыклар исәпкә кермәгән! – диде.

Алар – Мөслимнең мәшһүр балыкчылары иде...

Бер очрагач, Рәисне күреп, хатынына әйткән “йомры” сүзе белән котладым.

– Малай, бу “йомры” сүзләр җайлы гына үземә әйләнеп кайтты әле. “Бумеранг” булды ул! Исполком председателе Гариф Хафизовичны беләсең бит. Күп сөйләшми, ну, әйтсә, өздереп әйтә инде. Кабинетына чакырды да әйтә бу: “Кәшифразов, эшеңнең бер дә рәте юк бит әле – районның план комитеты председателе бит син! Бөгелмә, Әлмәт, Чаллы районнарында товар базалары белән бәйләнешне син булдырырга тиеш. Лесничестволарда әзерләнгән утыннарны, деловой материалларны, киселәсе делянкаларны бүлеп бирергә; мәктәпләргә, балалар бакчаларына, сәламәтлек саклау, культура учреждениеләренә кышлык утын әзерләүне хәл итәргә кирәк. Колхозларга – ашламалар, сәүдә оешмаларына җиһазлар кайтарту да планлаштырылырга тиеш!”

“Гариф Хафизович, барысына да ничек җитешим, мин берүзем бит!” – дим.

“Син җитешә алмый дип, синең янга тагын бер райплан председателен сайлап куя алмыйбыз бит инде, – дип һушны алды Гариф Хафизович. – Хатынга әйткән сүзләр өчен үкенеп йөрим менә...”

Илгизәр Гыйльфанов

Илгизәр Гыйльфанов белән без Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетында бер елларда укыдык. Зур Кызыл урамындагы тулай торакта 5 ел бер бүлмәдә яшәдек. Беренче көннәрдән үк без бер-беребезгә якынаеп киттек. Якынаюның төп сәбәбе – икебез дә спортны ярата идек. Мин көрәш, шахмат, ату спорты белән мавыктым. Илгизәр волейболны бик якын итте. Беренче курста укыган елны институтта истә калырлык ике вакыйга булды. Беренчесе – шахмат буенча халыкара спорт мастеры Рәшит Нәҗметдинов белән очрашу. Ул елларда СССР беренчелегенә ярышлар ел саен оештырыла иде. Безнең илдә генә түгел, бөтен дөньяда Рәшит Нәҗметдинов һәрвакыт көчлеләр арасында булды. Соңгы чемпионатында да (1956 нчы ел) ул алдынгы урыннарны алды. Таль, Спасский, Петросян, Полугаевский, Смыслов кебек мәшһүр гроссмейстерларны бирелергә мәҗбүр итте. Аны "Гроза гроссмейстеров" дип атадылар. Мавыктыргыч итеп сөйли дә белә иде ул. Аңа сораулар да күп бирелде. Кызыклы партияләр турында сөйләвен дә үтенделәр. Шахмат тактасы өстендә ул күп партияләргә анализ бирде. Соңыннан 30дан артык тактада берьюлы уйнау сеансы уздырды. Миңа да даһи шахматчы белән кара-каршы уйнау бәхете тигән иде.

Икенче очрашуга да без Илгизәр белән бардык. Бусы инде күренекле волейболчы Нил Фасахов белән очрашу иде. 1956 нчы елда волейбол буенча дөнья чемпионаты Франциядә үтә. СССР дигән зур илнең җыелма командасына безнең институтның физик культура факультеты студенты Нил Фасахов та алына. Безнекеләр анда өченче урынны яуладылар. Ә Нил Фасахов бу чемпионатта дөньяның иң көчле уенчысы дип игълан ителде. Аның гадәттән тыш сикерү сәләте, сетка өстенә бөтен гәүдәсе белән күтәрелеп, ике кулы белән дә бердәй уңыш-

лы атака ясый алуы күпләрне сокландырды. Соңгы уенда аның кедасы (ул вакытта әле уңайлы аяк киеме – кроссовкалар булмый) яраксызга әйләнә. Ул яланаяк уйный. “Босой татарин” дигән кушамат та тагалар үзенә!..

Һәр чемпионатта да уеннар ахырында дөньяның иң көчле спортчыларыннан символик җыелма команда төзиләр. Шушы командага беренче номер булып – Нил Фасахов, җиденче номер запасындагы уенчы булып, Ленинград волейболчысы Геннадий Байковой керә.

Н. Фасахов белән очрашу ахырында безнең институт волейболчылары белән Казан шәһәре вузлары студентларының җыелма командасы арасында волейбол уены булды. Нилнең оста уены, көчле сәнгать әсәренә тиң булып, спорт сөючеләрне ләззәтләндерде.

Әлеге истәлекле очрашу тәэсиреннәнме, Илгизәр шул көннән башлап волейбол секциясенә йөри башлады. Һәм ул тора-бара бу уенда уңышлы гына чыгышлар ясады, физмат факультетының төп уенчысына әверелде.

Институтта һәр семестрдан соң каникуллар була. Ул еллардагы транспорт белән тәэмин ителү дәрәҗәсе Мөслим районы кебек ерак араларга кышкы каникулга кайту мөмкинлеген бирми иде. Каникулны тулай торакта уздырырга туры килә.

Беренче семестрны тәмамлауга, Илгизәр мине үзләренә чакырды. Каникулны шунда уздырдым. Аларга кайту да бик уңайлы икән. Буа поездына утырып, Каратун станциясенә кадәр барасы. Каратуннан Илгизәрләрнең авылы Ябалак – өч кенә чакырымда. Матур итеп ял итеп килдек. Илгизәрнең туганнары белән таныштым. Илгизәрләрнең әтисе Бөек Ватан сугышыннан кайта алмаган. Әнисе Наһар апа ире белән өч кенә ел торып калган. Илгизәргә кыенлык килмәсен, дип, яңадан кияүгә чыкмаган, гомерен улына багышлаган. Алгарак китеп булса да әйтим, Илгизәр дә әнисе өчен үлеп торды. Ананың йөзенә кызыллык китермәде. Эше белән дә, тәртибе белән дә үрнәк булды. Наһар апа соңгы көннәренә кадәр яхшы тәрбиядә булды.

Без каникулга кайтканда, Илгизәрнең әтисенең әнисе исән иде әле. Безнең кебек яшьләргә дә гел яхшылыклар гына теләүче, намазын калдырмаучы диндар әби булып истә калган ул.

Без бәләкәй чакларда, бигрәк тә әбиләр янында, ашаганнан соң, амин тотып кую гадәте була иде. Әбидән күреп, Илгизәрләрдә мин дә амин тоткалаганмындыр. Әбигә бу гадәт бик тә ошаган.

– Илгизәр улым, әйбәт иптәш тапкансың, бер-берегезне ташламагыз, – дигән сүзләре истә калган.

Әбинең сүзләренә игътибарыбыз көчле булгандыр, күрәсең. Менә 50 елдан артык инде бер-беребезне хөрмәт итеп, аңлашып-аралашып яшибез.

Илгизәр гомере буе мәгариф системасында эшләде. Башта ул укытучы булды. Аннары Балтай урта мәктәбендә завуч вазифасын башкарды. Укытучылар укытучысы булса да, ул бер эштән дә чирканып тормады. Техниканы ул һәрвакыт үз итте. Студент елларында Казахстанның чирәм җирләрен күтәрү буенча эшләгәндә дә ул, мөмкин булган саен, машина руле артына утырырга тырыша иде. Әлеге күркәм гадәте аның гомере буе дәвам итте. Шулай бервакыт Балтай авылына, Илгизәрләргә барып чыктым. Аларның капка төбендә "Владимировец" тракторы эшләп тора иде.

– Нигә монда алып килеп эшләтәләр бу тракторны? – дим.

– Бу трактор белән мин мәктәпкә утын ташыйм, чәй эчеп чыгарга гына өйгә кайттым, – ди Илгизәр.

Шушындый завучлар булганда, мәктәпне яңа уку елына яхшылап әзерләргә була, әлбәттә. Мәктәп директоры Нәби абыйның бәхете инде бу!

Бераздан Илгизәрне Бакырчы мәктәбенә директор итеп күчерделәр. Әлеге мәктәп игътибардан читтәрәк яшәгәнгә күрәдер инде, аның хәле әллә ни мактанырлык түгел иде. Мәктәпне кадрлар белән баету, материаль-техник яктан ныгыту юнәлешләрендә Илгизәр Хаҗиевич күп эшләде.

Илгизәр Гыйльфановның "Учколлектор" магазинына килүе истә калган. Татарстан Мәгариф министрлыгы каршысындагы бинага урнашкан әлеге кибет Республика мәктәпләрен техник чаралар, физика, химия, биология кабинетлары өчен приборлар, башка фәннәр буенча җиһазлар, күргәзмә материаллар белән тәэмин итә иде. Магазин үзендә булган байлыкны күрсәткән бланкларны мәктәпләргә тарата. Мәктәпләр үзләренә кирәк җиһазны күрсәтеп, магазинга заказ бирә, бланкны кире кайтара.

Бу магазинның директорын мин белә идем. "Бәлкем, ярдәмем тияр", – дип магазинга Илгизәр белән икәү киттек.

– Безнең заявкага никтер җавап бирмәдегез сез, – дип башлады Илгизәр сүзен магазин хезмәткәренә.

– От вас к нам заявок не поступало! – дип тупас кына җавап алынды.

– Вы нас с кем-то путаете, мы заявки прислали! – дигән сүзебез теге хезмәткәргә бөтенләй ошамады.

– Мы никогда не путаем, выбирайте выражения! – дип, ул китеп тә барды.

Директорга кереп эшне җайлау миңа калды. Теге хезмәткәр үзенең хатасын төзәтте...

Үз эшен белеп башкаручы югары квалификацияле белгеч буларак, Илгизәр Хаҗиевичны Апас районы мәгариф бүлеге мөдире итеп билгеләделәр. Бу эшне ул 25 елдан артык башкарды. Республиканың иң хөрмәтле район мәгариф бүлеге мөдире булып җитеште. Аның нәтиҗәле хезмәтен югары бәяләп, Татарстан Мәгариф министрлыгы аңа "Россия Федерациясенең атказанган укытучысы" дигән мактаулы исем бирде.

Мәгариф бүлеге мөдире булып Илгизәр Хаҗиевич Гыйльфанов эшләгәндә, Апас районында файдалы эшләр күп башкарылды. Шуларның берсе – районны югары квалификацияле укытучылар һәм җитәкчеләр белән тәэмин итү. Югары уку йортына ул мәктәп тәмамлаучы әзерлекле укучыларны җитәкләп алып килә иде. Барлык факультетлар белән дә ул тыгыз элемтәдә торды. Ә физиклар һәм математиклар әзерли торган факультетлар аның туган йорты иде. Институтны, университетны тәмамлаучылар арасыннан да үзләренең районына иң белемлеләрен сайлый иде. Шуңа күрәдер, районның уннан артык мәктәбендә мәктәп директорлары булып физика-математика факультетын тәмамлаучылар эшләде.

Илгизәр Хаҗиевичның тагын бер нәтиҗәле хезмәтен искә төшерәсем килә. Бусы мин Татар дәүләт гуманитар институтында ректор булып эшләгәндә булды. Апас районындагы мәктәпләрдә чит телләр буенча укытучыларның җитмәвен исәпкә алып, ул укытучылардан һәм тәрбиячеләрдән читтән торып уку төркеме оештырды. Педагогик белемнәре булган әлеге укытучылар кыскартылган срокта остәмә белгечлеккә – чит тел укытучылары булып әзерләнергә тиешләр иде.

Әлеге эш уңышлы гына башланып китте. ТДГИның чит телләр факультеты бу эшкә иң тәҗрибәле укытучыларын билгеләде. Галим-мөгаллимнәрнең Апастагы эшчәнлеге өчен тиешле уңай шартлар тудырылды. Аларның торакка һәм туклануга кагылышлы бөтен проблемалары уңышлы хәл ителде. Чөнки аларны Илгизәр Хаҗиевич үз контрольлегендә нык тотты. 60тан артык укытучы 4 ел эчендә инглиз теле укытучысы белгечлегенә өйрәнеп чыкты, кулына тиешле документ алды. Бу инде телләр турындагы Татарстан Хөкүмәте законын үтәүнең ачык мисалы иде.

Гаденәп Садриев

Гаденәп белән без институтта бер елларда белем алдык. Ул татар теле-тарих бүлегендә укыды. Шуңа күрә, аның уку бинасы да, тулай торагы да икенче иде. Без аралашмадык. Ул факультеттан безнең тулай торакта Хәнәфи Гыйлаҗев яшәде. Хәнәфи белән без тулай торакта 5 ел бер бүлмәдә тордык. Ул үзләренең группа студентлары Карл Әхмәтов, Марсель Бәширов, Альберт Хәсәнов һ. б. турында еш сөйли иде.

Гаденәп турында да шул сөйләүләрдән бераз мәгълүматым булгандыр. Гаденәп спорт белән актив шөгыльләнә иде. Озын дистанцияләргә йөгерү буенча һәм чаңгы ярышларына катнашып, алдынгы урыннарны алганы хәтердә. Өлкән курсларда ул безнең тулай торакта күренгәли башлады. Чит телләр факультетында укучы Дамира исемле кыз белән дуслыклары бар иде. Тора-бара ул Дамирага өйләнде дә. Хәзерге көнгә кадәр менә дигән итеп яшәп яталар.

Институтны тәмамлап, шактый еллар үткәч, мин тагын Казанга килдем. 1980 нче елда мәктәп директорларының белемен күтәрү факультетын оештырып, шуның деканы булып эшләгәндә, безнең факультетка укырга Гаденәп дә килде. Ул Казанда мәктәп директоры булып эшли иде. Элегрәк, бер-беребезне белеп калган кешеләр буларак, без аралашып, хәл белешеп яши башладык. Безнең факультет институтта яңа гына оешкан булганга, безнең деканат, уку бүлмәләре, коридорлар да бизәлеше ягыннан фәкыйрь иде. Сөйләшкәндә, Гаденәпнең дизайнерлык сәләте беленде. Мин, үзебезнең диварларны бизәү өчен, материаллар җыйный башладым. Ике айлык белем күтәрү курслары үткәндә, Гаденәп Гыйльмиевич ярдәме белән, безнең факультетта күп кенә бизәү эшләре башкарылды. Аның кулы бу эшкә ятып тора иде.

Эш йомышлары белән Чаллыдан Казанга Карл килеп чыккач, без аның белән Гаденәпнең фатирында да булдык. Гаденәпнең, үз кулы белән эшләп, фатирыннан җәннәт ясаганын күргәч, хәйран калдым. Табигый сәләтләр аңа, чыннан да, мул бирелгән.

Якын дустым Марсель Әхәтович Бәширов һәм безнең институтның ректоры Мирфатыйх Зәкиевич Зәкиев ярдәме белән, 1984 нче елда безнең гаилә яңа фатирлы булды. Ф.Әмирхан урамындагы бу 14 катлы йортны төзүчеләр сыйфат ягына игътибар биреп тормаганнар. Тәрәзә-ишекләре ябылмый, идәнгә җәелгән линолеум астында тигезсезлекләр абынып егылыр-

лык, обойлары кубып-кубып тора. Бу кимчелекләрне бетерү өчен, мин осталар ялладым. Осталар эшли башлады.

Эшне тәмамлауны билгеләгән көнне хатыным Тихния белән шунда киттек. Йорт янына машина белән килеп туктадык. Шактый халык җыелган. Тамаша күзәтәләр. Чыннан да, тамаша иде бу күренеш. 4 нче каттагы бер фатирның балконыннан урамга кайнар су ага.

Җыелган халык, акырып-бакырып: "Бу фатирның хуҗасы кая?", "Ул бәндәне фәлән итәргә, төгән итәргә кирәк!" – диядия ачулы сүзләр кычкыра.

Йә Ходa, безнең фатир бит бу! Баскычтан йөгереп менеп ишекне ачсак, йөзләргә кайнар пар бәрелде. Идәннән су ерып барып, кайнар су кранын яптым. Кулга ни эләгә, шуның белән, идәндәге суны ваннага ташый башладык.

Астагы фатирларның хуҗалары килеп керде. Алар үзләренә чакыра. Кереп карыйбыз. 1 нче катка кадәр түшәмнәрдән су ага, мәхшәр! Таләпләрен куя башладылар: "Паркетларны, обойларны алыштырасың, японский электро-радио техниканы, коверларны яңасын аласың!"

Төне буе хатын белән су түктек. Хатынның да түземлеге чигенә җитте: "Дөньяда миннән дә бәхетсез кеше юктыр!" "И, үлсәм генә иде шушында!" – дигән сүзләр тикмәгә генә әйтелмәгәндер?!

Бу афәтнең сәбәбе дә ачыкланды. Эшнең соңгы көнен осталар буяучы хатынга тапшыралар. Ул 5 яшьлек малае белән килә безнең фатирга. Әнисе эшли, малай уен белән мәшгуль. Кайнар су кранын борып та уйный бала. Кайнар су кранынннан су килмәгән чак була бу. Кран ачык кала. Эшне бетереп, буяучы хатын, баласын алып, кайтып китә. Алар кайтып китүгә зур басым белән кайнар су килә башлый. Унитаздан китүче су юлы төзүчеләр тутырган чүп-чар белән бикләнгән була. Су үтә алмый, идәнгә ага, идән тулгач, балконга чыга, астагы катларга китә!..

Безнең фатирдан чыккан бу афәтне дүрт фатирда төзәтү дә безнең өскә төште. Кирәк әйберләрнең берсе дә сатуда юк: паркет та, линолеум да, обой да. Шул әйберләрне эзләп йөргәндә, бервакыт Гадинән очрады. Килеп чыккан мәшәкатьләр турында сөйләдем. Шунда Гадинән:

– Өйдә хәзер бер кеше дә юк. Минем мәктәптә ашыгыч эшләрем бар. Мәктәптән китә алмыйм. Синең бездә булганың бар, адресны беләсең. Менә сиңа фатирның ачкычы. Балконда

линолеум һәм ремонттан калган обойлар бар. Ошатсаң, алырсың шуларны. Аннары ачкычны миңа китерерсең, – диде.

Мин шунда йөгердем. Фатирны ачып кердем һәм, шатланып, рәхмәтләр әйтә-әйтә, алып киттем мин ул әйберләрне. Файдасы тиде аларның. Шундый ярдәмле кешеләр аркасында, без теге бәлане, ниһаять, җиңеп чыктык!

Гаденәннең ул вакытта кылган гамәле турында искә төшкән саен, уйлап куям. Ул вакытларда Гаденән мине бөтенләй белми диярлек. Чит кешегә өй ачкычын биреп, аннан нәрсәләрдер алып чыгарга рөхсәт бирү өчен, кешеләргә ышану да, киң күңеллелек тә, юмарт, ярдәмчел булу да, башка кешеләр хәленә керә белү дә кирәк. Гаденәндә исә бу сыйфатларның барысы да бар.

Гаденән белән без Татарстан Мәгариф министрлыгында эшләгән чагымда тагын очраштык. Демократия елләре исә башлаган чор бу. Татар халкының да үзенең хокукларын даулый башлагын вакыты. Татар мәгариф системасын торгызырга кирәк. Нәрсәдән башларга? Шактый баш ватканнан соң, мин мәгариф министрының милли мәгариф буенча ярдәмчесе һәм министрлыкта милли мәктәпләр бүлеге булырга тиеш, дигән фикергә килдем. Милли мәктәпләр буенча министр урынбасары урынына Гаденән Гыйльмиевич Садрыевны, милли мәктәпләр бүлегенә мөдир итеп, Әнвәр Нуриәхмәтович Хуҗиәхмәтовны тәкъдим иттем.

Халкыбыз өчен, милли мәгарифне торгызу өчен, Гаденән Гыйльмиевич гаять нәтиҗәле эш башкарды. Бәхетем шундадыр, кайда гына эшләсәм дә, миңа гел юньле кешеләр туры килде. Мөслим районы мәгариф бүлегендә дә, Казан дәүләт педагогия институтында да бу шулай булды.

Татар авылында чын милли тәрбия алган Гаденән Гыйльмиевичны безнең коллектив тиз арада үз итте. Күп тә үтмәде, ул минем ярдәмчеләр белән җылы мөнәсәбәт урнаштырды...

Г.Г. Садрыев – җаны-тәне белән бирелгән милләт вәкиле. Ул үз вазифаларына бик авыр чорда кереште. Татар һәм башка милли (чуваш, удмурт, мари, мордва) мәктәпләренең эшләрен җанландырып җибәрү, яңа татар мәктәпләре, гимназияләре, татар класслары, татар балалары бакчалары ачу өчен, Мәгариф министрлыгы күп эшләде. Бу эшләрне башкарып чыгуда район шәһәр хакимияте, мәгариф бүлекләре җитәкчеләре, ата-аналар, җәмәгатьчелек вәкилләре бер булып тотынганда гына уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин иде. Олырак түрәләргә кискен таләпләр куярга кыенсына иде Гаденән Гыйльмиевич. Бу аның бердәнбер кимчелеге иде. Мәгариф министрлыгындагы катгый

таләпләр режимында ул әкренләп бу сыйфатын да уңай якка үзгәртте. Хезмәт юлын үткән барлык урыннардагы кебек, Татарстан Мәгариф министрлыгында да Гаденән Гыйльмиевич бөтен барлыгын биреп эшләде. Аның Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез белән бәйләнеш булдыру буенча тырышлыгын да әйтергә кирәк. Бу чорда без татарлар яши торган 20ләп өлкә һәм республика белән мәгариф юнәлешендә килешүләр төзедек, тыгыз бәйләнеш урнаштырдык, Якутия-Сахадан башлап Литвага, Санкт-Петербургка кадәр, татар мәктәпләрен барладык, яңаларын ачарга булыштык. Әлбәттә, бу эшләрнең авырлыгы Г.Г.Садрыевка төште.

Төркиянең уку йортлары белән багланышлар да шул елларда башланды. Башта без Төркия Мәгариф министрлыгы белән килешү төзеп кайттык. Анда минем белән Г.Г.Садрыев, мәгариф министрлыгының милли мәктәпләр бүлеге хезмәткәре Р.А.Зарипов та булды. Шушы килешү нигезендә, Төркия уку йортларына укучылар җибәрә башладык. Безнең балаларның уку, яшәү шартларын җайга салу өчен, Садрыев һәм Зариповка Казан — Төркия юлын күп таптарга туры килде.

Татарстанда татар-төрек лицейлары булдыру буенча да күп эшләргә туры килде безгә. Бу эшләрне җайга салу, контрольдә тоту эше дә Г.Г.Садрыевка йөкләнде.

Әйбәт уку йортлары булдылар алар — татар-төрек лицейлары. Төрек белгечләре, безнең укытучылар белән бергә, халкыбызның матур киләчәген хәл итәчәк яшьләр тәрбияләделәр. Яман гадәтләрдән азат бу яшьләр фәннәрне тирәнтен өйрәнделәр; татар, рус, төрек һәм инглиз телләрен камил белүче белгечләр булырга әзерләнделәр. Ни кызганыч, бүгенге көндә бу лицейларны юк итү буенча хәрәкәт бара...

Мәгариф министры булып Ф.Ф.Харисов эшли башлагач, беренче эше итеп Гаденән Гыйльмиевичны эшеннән җибәрде. Бер сәбәпсез. Милли мәгарифне торгызып кына килә идек бит әле. Әле бу юнәлешне алга таба үстерәсе, ныгытасы бар иде. Эшенә чын күңелдән бирелгән милләтпәрвәр Г.Г.Садрыев үз вазифасында, һичшиксез, милләтебезгә күп файда китерер иде әле.

Гаденән министрлыктан китте. Ләкин мәгариф системасын ташламады. Шактый еллар ул Казанның Авиатөзүчеләр районында мәгариф бүлеге мөдире булып эшләде. Хәзер дә ул шушы юнәлештә — югары уку йортларының берсендә эшләвен дәвам итә.

Миргалим Әюпов

Мөслимдә мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгәндә, яңалыкларны күп керттек. Миңа әле – тулыр-тулмас 28 генә яшь! Консеваторлык сыйфаты әле миндә утырып җитмәгән. Татарстан Мәгариф министрлыгында күтәрелгән һәр яңалык минем тарафтан кулланма итеп алына. Мәгариф министры М.И. Мәхмүтов та яңалыклар кертүдә шактый актив эшли. Бер киңәшмәдә ул республика шәһәрләрендәге һәм районнарындагы җитәкче кадрларның белем дәрәҗәсенә анализ ясады. Мәктәп җитәкчеләренең шактые югары белемле булмавын тәнкыйтьләде. Мөслим районының хәле дә бу яктан мактанырлык түгел иде. Бу кимчелекне бетерүнең бер юлы, дип, мин читтән торып укуны җанландырырга уйладым. Мәктәп җитәкчеләренең (директор, завуч) күбесе укытучылар институтын тәмамлаганнар. Учительский институт, дип аталган ике еллык мондый уку йортлары Алабуга һәм Бөгелмә шәһәрләрендә бар иде. Заманында безнекеләр дә шуларны тәмамлаган, тулы булмаган югары белемле саналалар. Безнең чорда бу уку йортлары юк иде инде. Бөгелмәдәгесе – ябылды, Алабугадагысы педагогия институтына әйләндерелде...

Безнең укытучыларны һәм мәктәп җитәкчеләрен Казан һәм Алабуга пединститутларының читтән торып уку бүлегенә урнаштырырга кирәк. Үзебезнең районда Казан пединститутының читтән торып укучылар белән эшләүче филиалын булдырырга ниятләдем. Ният барып та чыкты: Мөслимдә КДПИның читтән торып уку бүлегенең фәнни-консультатив үзәге оешты. Укырга керүчеләргә имтиханны үзебездә алабыз, консультация, имтихан, зачет тапшыруларны да үзебездә оештыра башладык. Кирәк вакытта Казаннан укытучыларны чакырабыз. З.З. Закиров, Г.С. Камалов, В.М. Акимов, М.М. Мирзаянов, С.М. Зарипов кебек өлкән яшьтәгеләр дә уңышлы гына укып киттеләр. Бу елларда без район укытучыларының белем дәрәҗәсен уңай якка сизелерлек үзгәрттек.

Алабуга пединституты һәм Казан дәүләт университеты белән дә бәйләнешләр яхшырды. Аларда да безнекеләр, читтән торып, күпләп укыды. Әйтик, Баланлыдан М.Ә.Әюпов – Казан дәүләт университетының биология факультетында, Түбән Табын мәктәбеннән Я.Р.Вәҗиев – механика-математика факультетында, Г.Ш.Шәмсиев география факультетында укыдылар.

Университетның уку планында соңгы елның бер семестры диплом яклау эшенә багышланган. Ул елларда, Татарстан мәгариф министры М.И. Мәхмүтов тырышлыгы белән, проблемалы укыту теориясе һәм практикасы тормышка ашырыла башлады. М.Ә.Әюпов та диплом эшенең темасы итеп, "Биологияне проблемалы укыту"ны алган. Бу эшкә ул формаль яктан гына карамыйча, төпле фәнни тикшеренү оештырмакчы. РОНОга килеп, ул үзенең планнары белән мине дә таныштырды. Педагогикада һәм методикада яңа юнәлеш буларак, бу тема мине кызыксындырып җибәрде. Бергәләп, диплом эшенең эзләнү-тикшеренү планнарын төзедек. Монда мин диплом эшенең тагын бер үзенчәлеген аңладым. Университетның биология кафедрасы профессоры аңа бу теманы тәкъдим итмәгән, икенче теманы кулай күргән, проблемалы укытуны танымавын, Мәхмүтов дигән галимнең дә аңа таныш булмавын әйткән. Мәгариф министры Мәхмүтовның хезмәтләрен бик ошатканмы, әллә биологияне проблемалы укыту методикасы кызыксындырганмы, Миргалим Әюпович бу теманы җиренә җиткереп башкарып чыгачагын белдерде: "Бу теманың юк-бар тема гына түгеллеген, укучыларны мөстәкыйль шәхес итеп тәрбияләүдә иң алдынгы методика икәнен исбатлап күрсәтәчәкмен мин!" – диде ул, һәм шулай эшләде дә.

Хезмәтен язып бетереп, аны яклау вакыты җиткәч, М.Ә.Әюпов Казанга китте. Бу диплом эшен яклау процессы дәгъвале булачагы студентларга да, укытучыларга да көн кебек ачык була. Процесс шактый кискен шартларда бара. Профессор да позициясеннән чигенми, М.Ә. Әюпов та бирешергә теләми. ВУЗлар практикасында мондый хәлләр бик сирәк очрый. Ахырда соңгы сүзне Миргалим Әюпович әйтә:

– Данлыклы Казан дәүләт университетында укуым белән бик канәгатьмен. Диплом эшемне шундый игътибар белән тыңлавыгызга рәхмәт белдерәм. Ниһаять, диплом эшенең педагогика һәм методикада иң актуаль темага багышланганына барыгыз да ышандыгыз. Бу эш белән танышу күп сандагы биология укытучыларына, студентларга файдалы булачак. Диплом эшем университет укытучылары өчен дә кызыклы һәм файдалы булыр. Минем фәнни җитәкчем – мөхтәрәм профессор, мәсәлән, дидактикада укучыларның танып-белү активлыгын, фикерләү сәләтен үстерүче укыту тибы – проблемалы укыту икәнен хәзер инде беләчәк. Безнең республикада мәгариф министры, проблемалы укыту буенча күп хезмәтләр авто-

ры М.И.Мәхмүтов икәнен белү дә аның дәрәҗәсен күтәрәчәк!..

Диплом эшенә бәя кую буенча комиссия шактый озак киңәшә. Карашлар төрлечә булгандыр, ләкин эшкә уңай билге куела. Нәтиҗәсе шул булды: М.Ә.Әюпов Казаннан җиңүче булып кайтты!..

М.Ә.Әюповның гаделлек өчен ахырына кадәр көрәшү сыйфаты турында сөйли торган тагын бер вакыйга истә калган.

...Узган гасырның 50 нче елларында, Бөек Ватан сугышы афәтләренең нәтиҗәсе буларак, мәктәпләрдә балалар һәм класслар кимеде, укытучылар кыскарды. Кыскартылган укытучылар арасына М.Ә.Әюпов та әлегә. Ул биология укытучылары арасында иң алдынгылардан була, үз фәнен тирән белә, методикада алдынгы алымнарны куллана, кайда гына эшләсә дә, мәктәпнең биологик тәҗрибә участогы башкаларга үрнәк булырлык! Әмма бу сыйфатлары аны эштән азат иткәндә исәпкә алынмый. Шуның өстенә, ул – гаиләдә бердәнбер хезмәт хакы алып эшләүче дә. Ә гаиләдә берсеннән-берсе кечкенә алты бала була. Авыр хәлдә кала Әюпов. РОНОга эш сорап барулар нәтиҗә бирми. Аның туры сүзлелеге җыелышларда өстәгеләрне тәнкыйтьләү гадәте дә монда аның файдасына түгел, партия райкомы аны эшкә урнаштырырга каршы килә. Уйлана торгач, райкомның аңа каршы булуының сәбәбен искә төшерә ул. Сәбәбенең эчтәлеге болай: Әюповның Ташлыяр мәктәбендә эшләгән вакыты. Район Советына депутатлыкка кандидатлар күрсәтүгә багышланган җыелыш билгеләнә. Авылның партия оешмасы секретаре Миргалим Әюповка бер кәгазь тоттыра. Кәгазьдә бер фамилия язылган. Миргалим Әюпов җыелышта шушы кешене депутатлыкка кандидат итеп күрсәтергә тиеш. “Бу ни дигән сүз булды соң әле?” – дип үз-үзенә сорау бирә ул. Миргалим Әюпович үзен кимсетүләренә борчыла башлый. Ни өчен мин кемдер әзерләп биргән кәгазьне генә укып бирергә тиеш?! Депутатлыкка лаек кешене мин үзем күрсәтсәм, нәрсә була?! Укытучы, агитатор, пропагандист буларак, мин авыл кешеләрен начар белмим бит. Киресенчә, бик әйбәт беләм. Туктале, бу язуда кем фамилиясе булды соң әле?!

Бу кешене дә бик яхшы беләм мин. Эше буенча авылда башкалардан аерылып торган җире юк. Әмма, кирәк булса да, булмаса да, җыелышларда чыгыш ясарга ярата. Аның һәрвакыт йомгаклау сүзе шул була: “Мин партия линиясен яклыйм!” Салгалау гадәте дә халыкка мәгълүм бу кешенең. Әмма кимчелеге моның белән генә бетми әле. Мәктәптә ике баласы

укый, икесе дә – өлгермәүчеләр рәтендә, тәртипләрс буенча да һаман тикшерелеп торалар. Юк, бу кешене депутатлыкка күрсәтмим мин! Шулай уйлый Миргалим Әюпович. Бөтен яктан да уңай сыйфатлары өстен булган икенче кешенең кандидатурасын күрсәтә.

Бу тәкъдим җыелышның алып баручысын телдән калдыра. Нәрсә була соң әле бу? Кандидатлар исемлеге партия райкомына инде күптән җибәрелгән. Бәлки, исемлек инде партиянең өлкә комитетына да барып җиткәндер. Мондый исемлекләргә төзәтмә кертү практикасы район яки өлкә партия комитетларында булган хәл түгел. Җитмәсә, җыелышта район партия комитетының җаваплы работнигы утыра. Аның тарафыннан җыелышны алып баручы партоешма секретарена команда бирелә: элек билгеләнгән кандидатураны депутат итеп күрсәтергә! Партия оешмасы секретаре бу әмерне үтәп тә чыга. Хәзер ике кандидатның берсен ачык тавыш белән хуплыйсы гына кала.

– Тавышка куям, – ди җыелышны алып баручы партоешма секретаре, – кем дә кем мин күрсәткән кандидатураны яклый, шул иптәшләр кулларын күтәрә!

Шушы минутта М.З.Әюпов торып баса:

– Җыелышны алып бару тәртибен бозмавыгызны сорыйм. Тәртип буенча кандидатларны тавышка кую аларның тәкъдим ителүе тәртибендә булырга тиеш. Ягъни башта мин күрсәткән кандидатура тавышка куела, аннары – сезнеке. Шулай эшләсәк, дөрес була!

Бу урында җыелыш нык кына тавышланып ала, тәнәфес тә ясап алалар. Тәнәфес вакытында Әюповны райком кешесе каршына бастырып, үзенең тәкъдименнән ваз кичүен сорыйлар. Ләкин ул үз фикерендә кала. Һәм аның тәкъдиме күпчелек тавыш белән үтеп тә китә. Алда әйтелгән сәбәп шушыннан гыйбарәт...

Эшкә кире кайтаруны сорап йөргәндә, райкомда Әюповка бу вакыйганы да искә төшерәләр, аңа кире җавап бирелә...

Эшсез йөри дипломлы укытучы, уйлана, һәм бер фикергә килә: демократик җәмгыятьтә яшибез бит. Гадел хөкем чыгарса, халык суды минем эштән чыгарылуны тиешенчә бәяләргә тиеш. Үзенең эштән чыгарылуының гадел булмавын исбатлауны сорап, ул судка мөрәҗәгать итә. Суд карары аның файдасына була. Суд карары буенча, эштән читләтелеп, эшләмичә йөрергә дучар булган Әюповка барлык айлар өчен дә хезмәт хакы түләү карала. Шулай итеп, Әюпов эш урынына кайтарыла. Елдан

артык эшсез йөргән айлар өчен ару гына түләнә. Шул акчаның бер өлешенә мотоцикл сатып ала. Мәктәп директоры булып эшләгәндә, ул мотоцикл мәктәп йомышлары белән Мөслимгә йөрергә аңа ярап куйды.

М.Ә.Әюпов белән бәйле тагын бер вакыйганы искә төшерәсем килә. Вакыйга болайрак. Миңа райкомга килеп китәргә куштылар. Минем район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгән еллар бу. "Килеп кит әле!" – дип, райкомнан да, исполкомнан да еш әйтәләр иде. Кинәт кснә бер мәсьәлә килеп туа да, шуны чишәргә мин кирәк булам.

Райкомның идеология секретаре М.Г.Вәлитов бүлмәсенә килеп кердем. Аның йөзе бик кырыс күренә. Сүзне дә бик җитди башлады:

– Кирәк булса да, кирәк булмаса да мактый торгач, Баланлы мәктәбе директоры Әюпов үзен Кытай алласы итеп тоя башлаган. Партия райкомының решениесе аңа бармы-юкмы?! Безнең решениегә каршы кеше мәктәп җитәкчесе була алмый. Директорны эшеннән алу турында приказ яз. Приказның копиясен миңа китереп бир!..

Мин берни дә аңламый утырам. Мәктәп директоры буларак, Әюповның мактарлык яклары бар иде шул. Алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү, мәктәптә кабинет системасы булдыру, укучыларны җылы аш белән бушлай тукландыру, колхозчы яшьләрне кичке мәктәпләргә тарту, яшелчә, җиләк-җимеш бакчасында фәнни нигездә эш оештыру, яңа уку елына әзерлек, укытучыларның белемнәрен күтәрү, укучыларның төрле фәннәрдән уздырылган олимпиадаларда җиңүләре һ.б. мәсьәләләрдә аның эше районда үрнәк булырлык иде.

– Аны эшеннән алырлык бернинди сәбәп тә күрмим мин, – дидем.

– Синең күрүең кирәк тә түгел. Район бүген хөкүмәткә икмәк тапшыру планын тутырып, обкомга рапорт бирергә җыена. Ә Әюпов, мәктәп директоры буларак, бу эштә ярдәм итәсе урында, безгә аяк чала. Беренче секретарь үзенең карарын чыгарды инде: "Әюповны эшеннән алырга! РОНОңа кайт та, приказыңны яз. Копиясен безгә китерергә онытма!"

РОНОга кайтып киттем. Әюповны чакырдым. Мәсьәләгә бераз ачыклык керде. Эш болай була. Әюповларга ялга каршы Бөгелмәдән кунаклар килә. Ике көннән соң кунакларны озатырга кирәк. Авылда моның өчен машина табылмый. Машина эзләп йөргәндә, Әюповка ындыр табагы бригадиры очрый. Ул мәсьәләне бик җиңел чишә:

– Бездәге икмәкне Мөслимгә һәм Бөгелмәгә ташыйлар. Бөгелмә шоферлары пассажир утыртып йөрүне бик яраталар, өстәмә акча була чөнки. Алып кил кунакларыңны, үзем утыртып җибәрәм! – ди ул. Әюпов, кош тоткан кебек, шатланып кайтып китә. Кунакларны ындыр табагына алып килә...

Икмәк төягән машинага кунакларны утыртып ятканда, машина янына КПСС райкомының икенче секретаре Г.Н.Аксаков килеп туктый. Пассажирларның кая баруы белән кызыксына. Аларның Бөгелмәгә кайтуын, машинаның да Бөгелмәгә җибәрелергә тиешлеген белә һәм кискен таләбен куя:

– Бөгелмәгә бармыйсыз, бүген икмәкне Мөслим элеваторына гына ташыйбыз. Партия райкомының әмере шулай!

Бөгелмә автохуҗалыгы шоферына да, Әюповка да, аның кунакларына да бу әмер ошамый. Бәхәсләшүләр, тавыш күтәрүләр була, әмма һәрберсе үз фикерендә кала.

Аксаков Мөслимгә кайтып, Беренче секретарь янына керә һәм Баланлыдагы хәлне аңа җиткерә.

– ...Баланлы мәктәбе директоры Әюпов за сегодняшний поступок, в такой ответственный день, должен понести серьезное наказание! – дип тә өсти ул.

Беренченең әмере әзер – “Әюповны эшеннән алырга!”

Бер яктан караганда, Әюпов гаепле булып чыга. Райкомның: “Икмәкне Мөслимгә генә ташырга!” – дигән күрсәтмәсе бар. Ләкин бу күрсәтмә турында Әюпов белми.

Икенче яктан, ындыр табагы бригадиры, белепме яки белмичәме, Әюповка дөрес мәгълүмат бирми. Бөгелмәгә икмәк илтүче машинага үзенең кунагын утыртып җибәрергә тырышуда Әюпов үзен гаепле санамый, тегендә дә, монда да икмәк дәүләт элеваторына тапшырыла.

Әюповның гаделлек сакчысы, үз сүзендә ахыргача тора алу сәләте турында инде әйткән идем. Монда да ул бу очрак өчен эштән азат итүне гаделсезлек дип таный. РОНО мөдире буларак, минем дә бер дигән мәктәп директорыннан колак кагасым килми.

Райкомнан Вәлитов һаман шалтыратып тора, приказ язуны ашыктыра.

Әюпов белән әңгәмә вакытында кунакларның кем булуы белән кызыксынам.

– Аларның берсе – минем хатынның бертуган сеңлесе, ә икенчесе – аның ире. Бөгелмә механика заводының инженеры ул, Табиевның племяннигы, ягъни Табиевның бертуган абыйсының малае!

Кадерле укучым, игътибар ит әле, республиканың иң олы фигурасы, КПССның Татарстан өлкә комитетының Беренче секретаре, районнардагы Беренче секретарьләр Алла урынына күргән Табиевның якын һәм бердәнбер туганы нинди тыйнак урында эшли! Йөрергә машинасы да юк һәм, районга баргач, аны белүче дә юк. Хәзерге хәлләр белән чагыштыр, безнең олы түрәләрнең бик ерак туганнары, чыбык очы-тал башлары да нинди урыннарда утыралар, аларны нинди генә машиналарда гына йөртмиләр һәм ничек кенә сакламыйлар. Тыйнак булганнар икән элеккс җитәкчеләр, хәзергеләр белән чагыштыру да уңайсыз хәтта!

М.Ә. Әюпов белән киңәшләшеп утырдык та, без бу фактны файдаланырга булдык. Райкомнан приказ сорап шалтыратканда, әйттем:

– Приказны язганчы, бер киңәшәсе әйбер бар, сезгә барам әле мин, – дидем.

– Нәрсә уйлап таптың тагын? – дип коры гына каршы алды Марсель Галиәкбәрович.

– Приказны дәлилләп язу өчен, миңа райком бюросының карарын бирегез, –дидем мин.

– Андый карарны без бирмәячәкбез.

– Сәбәпсез килеш эштән алган өчен, мин җавап бирергә тиеш. Ләкин эш минем белән генә бетмәскә мөмкин. Таякның авыры Беренчегә төшмәгәе.

– Нәрсәгә намек ясыйсың?

– Мәсьәлә сез уйлаганча җиңел генә булмастыр, – дим мин. – Әюповның кунаклары гади кешеләр генә түгел. Әюповның хатынының сеңлесе һәм ире – Табиевның бертуган энесе икән бит. Әгәр дә мин Әюповны эшеннән алу турында приказ язсам, Әюпов ул приказны тотып Бөгелмәгә чыгып китәргә җыена. Шуннан соң көтелмәгән хәлләр килеп чыгуы бар. Ләкин мин бу мәтәвекле хәлдән шундый туйдым, пожалуй, кайтырмын да приказны язармын!..

Шуларны әйттем дә РОНОга кайтып киттем. Райкомның реакциясе ничек булыр, дип баш ватам, аннан хәбәр көтәм. Озак көтәргә туры килмәде, телефон шалтырады. Приказны язмый торырга куштылар. Әюповны тынычлыкта калдырдылар. Беренче шулай кушкандыр...

Озакламый укытучыларның традицион август конференциясе булды. Анда, гадәттә, район мәгариф оешмаларының еллык эшенә анализ бирелә, алдынгылар мактала, булдыксызлар тәнкыйть ителә. Райком секретаре чыгышында Баланлы мәктәбе

коллективының һәм аның директорының уңай эшләре бик күп яктан мактап телгә алынды.

Мондый мактауларны Миргалим Әюпович Әюпов алдагы киңәшмәләрдә дә күп ишетте. Мондый бәягә ул, чыннан да, лаек иде. Миргалим Әюпович үзе дә күп укыды, алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнде, тынгысыз булды, укытучылар һәм укучылар коллективларына да ялкауланырга ирек бирмәде. Баланлы сигезьеллык мәктәбен тәмамлаучылар урта мәктәптә укыганда башкаларга үрнәк булдылар.

Бүгенге көндә М.Ә. Әюпов – лаеклы ялда. Үзенең акыллы киңәшләре белән мәктәп коллективына, авыл халкына һәрдаим ярдәм итеп тора...

Директорлар киңәшмәсендә

Элегрәк булган язмаларымда мин мәктәпләрдә дәресләр тыңлау, аларга анализ ясау кебек эшләрне тасвирлаган идем. Мәктәп директорларының "йомры" сүзләре, юморга бай булуы истә калган. Бервакыт мәктәп директорлары белән Мәлләтамак урта мәктәбендә биология дәресе тыңладык. Дәрескә анализ ясарга җыелдык. Гадәттә, мин район мәгариф бүлеге мөдире буларак, башта сүзне белгечләргә бирәм, аннары үзем сүз алам. Шул тәртип буенча биология дәресенә анализ ясарга Баланлы мәктәбе директоры М.Ә.Әюповка тәкъдим ясадым. Казан дәүләт университетының биология факультетын тәмамлаган белгеч буларак, ул дәрескә тирән анализ ясады. Дәреснең фәннилек дәрәҗәсенә дә, педагогик-методик таләпләрнең тиешле үтәлүенә дә ул тәпле бәя бирде. Икенче булып, дәрескә анализ бирергә Вәрәшбаш урта мәктәбе директоры С.Н.Зариповка кушылды, ул да – биология буенча белгеч.

— Мин, алай, кайбер кешеләр кебек, изүне чишеп керешмәм, — диде ул. "Изүне чишеп", дигәне Миргалим Әюповичка төрттерүе була инде. Башка директорлар кебек, ул галстук белән түгел иде. Күлмәк якасын ул пиджагының якасы өстенә кайтарып салган. Бүген генә, дәрескә анализ ясау өчен эшләнгән эш түгел иде бу. Ул, гомумән, муенын иркендә йөртергә ярата иде бугай. Зариповның болай дип башлавы барысын да җанландырып җибәрде.

Тәнәфескә чыккач та директорларның юморы дәвам итте әле. Биология дәресендә укытучы китларга характеристика биргәндә әйткән иде:

– Балалар, кит – имезүче хайван. Ул балаларын имезеп үстерә. Алар озак гасырлар коры җирдә яшәгән. Хәзер инде алар суда гына яши. Ни өчен алай дип уйлыйсыз?

Сорау кызыклы иде, ләкин уңай җавап бирүче булмады. Укытучы ярдәмгә килде:

– Китлар һаман үсә барып, алар бик авырайганнар, коры җирдә хәрәкәтләнә алмый башлаганнар, алар океан-дингезләр кебек зур суларга китәргә мәҗбүр булганнар.

Бу мәгълүмат директорларның колагына кереп калган. Мәктәп ишек алдына ял итәргә чыккан директорларның берсе, соңгы елларда шактый калынаеп барган Түбән Табын урта мәктәбе директоры Гали Сәетович Камаловка, уенын-чынын бергә кушып, әйтте:

– Сиңа да, парин, Ыкка төшәргә туры килмәгәе!..

Юмор сәләте көчле иде директорларда. Икенче бервакыт киңәшмәгә килгән директорлар район мәгариф бүлеге бинасы янында басып торалар. Алар янына Тойгелде ярдәмче мәктәбе директоры якынлашып килә иде. Шунда берсе әйтеп куйды: “Иптәшләр, сак булыгыз, җүләрләр мәктәбе директоры килә!” Тупасрак яңгырады, әлбәттә, әмма директорлар бер-берсен гафу итә беләләр, ачу сакламыйлар иде.

Дәресләргә анализ, дигәннән, тагын бер дәрес искә төште әле. Директорлар семинарын Күбәк мәктәбендә уздырабыз. Мәктәп директоры Д. Г. Галиев, завуч К. М. Әхмәтов һәр яңалыкны, бик тиз “отып” алып, эшләрендә кулланма итеп алалар иде.

60нчы елларда Татарстан мәктәпләрендә укучыларның фикерләү сәләтен активлаштыру, укытуны тормыш белән бәйләү кебек юнәлешләр практикада кулланыла башлады. Болар Татарстан Мәгариф министры М.И.Мәхмүтов инициативасы белән эшләнде. Алда әйткәнемчә, мондый яңалыклар Күбәк мәктәбенә башка мәктәпләрдән алдарак керә иде. Боларны күрсәтү максатыннан, мәктәп директорларының бер семинарын Күбәктә уздырдык. Башта бер дәрес тыңладык. Геометрия дәресе планлаштырылган. Дәресне мәктәпнең математика укытучысы Асия Гомәрова алып бара. Тәҗрибәле укытучы, дәрестә укучылары актив эшлиләр.

Башта укытучыларның мөстәкыйль эше оештырылды. Укучыларга һәрберсенә аерым карточкалар таратылды. Аларга биремнәр язылган. Биремнәрне эшләп, дәфтәрләрен укытучыга тапшыруга, яңа бирем тәкъдим ителде.

– Кулларыгызны парта астына төшерегез, һәрберегез үзегезнең деталегезне тотыгыз да өстәл өстенә чыгарып салыгыз, – диде укытучы.

Тәнәфестә парта асларына укытучы авыл хуҗалыгы машиналарының детальләрен урнаштырып чыккан икән. Әңгәмә башланды:

– Зөфәр, синең деталең нинди формада?

– Цилиндр формасында, апа.

– Сания, синеке нинди?

– Бөҗра формасында.

– Хәзер шул детальләрнең ян өслеген, тулы өслеген, күләмен исәпләгез!..

Күргәнегезчә, дәрес тормыш белән бәйләнеп алып барыла. Геометриядән белемнәр, кагыйдәләр, теоремаларны абстракт белемнәрне кабатлау юлы белән генә түгел, авыл хуҗалыгы машиналарының детальләре ярдәмендә конкрет мисалларда ныгытыла.

Укучыларның эшләрен парта арасыннан укытучылары карап йөри. Биремнәрне башкарып чыгучылар да күренә башлады. Укучыга мөрәҗәгать итеп, ул сорап куйды:

– Сания, син чиштеңме әле, Зөфәр чыгарган инде?

Дәрескә анализны да бик актив ясады директорлар. Дәрескә югары бәя бирделәр. Тәкъдимнәр дә әйтелде: укучыларга бирелгән сораулар, тәкъдимнәр алдан уйланган булырга тиеш, сүзләрне башка мәгънәдә аңларга урын калдырмаска кирәк. "Үзегезнең деталегезне тотыгыз", "өстәл өстенә чыгарып салыгыз" кебек фразаларның булмаска тиешлеге әйтелде...

Иңкиләрен-тиңкиләрен

Мәгариф министрлыгында эшләгәндә беренче көннән үк хезмәттәшләр белән уртак тел табылды. Аларның күбесе чын профессионаллар иде. Әлбәттә, бу – миңа кадәр 10 ел буе Мәгариф министры булып эшләгән Равил Авзалович Авзалов хезмәте. Мин Равил Авзаловичка бер очрашуда бу турыда үзенә дә әйттем, рәхмәтемне белдердем.

Кайбер җитәкчеләр яңа эшкә билгеләнү белән, эшләп торган бер дигән белгечләрне җибәреп, үзенең командасын булдыра башлый. Гадәттә, ул командага булдыксызлар эләгә. Ул җитәкчегә аның бер генә сыйфаты кирәк була – буйсынуы һәм бервакытта да каршы килмәве!

Коллектив белән беренче очрашуда ук мин фикеремне белдердем: "Министр үзенә яңа команда туплар инде, дип курыкмагыз. Югары таләпләр дәрәҗәсендә эшләү сыйфаты булган һәркем үз урынында калыр," – дидем. Һәм ул шулай булды да.

Министр урынбасары Фәйзрахман Гыйлемханович Кәримовка профессиональ-техник училищелар белән җитәкчелек итү вазифасы йөкләнгән иде. Ул бөтен гомере буе шушы системада эшләгән, күп еллар профтехучилище директоры да булган. Башлангыч профессиональ белем бирүче уку йортлары озак еллар мәгариф системасыннан читтә, мөстәкыйль яшәгәннәр. 1989 ичы елда, мине бу эшкә билгеләү алдыннан гына профтехбелем системасын мәгариф системасына кушканнар. Мәгариф системасын алар чит итеп күрәләр иде. Училище директорлары да, Кәримов та моны һәрчак сиздереп тордылар. Алар бу кушуны кабул итмәделәр, аерылып, яңадан мөстәкыйльлекләрен кайтарасылары килде.

"Кәримов сиңа эштә комачаулык итә, җибәрик без аны, бу эшкә менә бу кеше кулай булыр", – дип өстәгеләр дә әйткәләделәр. Мин бу юлга бармадым. Фәйзрахман Гыйлемхановичка әйттем: "Системаны аерып алып чыгу ниятеңне ташла, бергәләп эшлик. Моны бездә генә уйлап тапмадылар, бу – Россия хөкүмәте политикасы. Синең бу өлкәдә зур белгеч һәм тәҗрибәле җитәкче булуыңны ихтирам итәм. Проблемалар бар, аларны бергәләп чишәрбез," – дидем. Фикердәш булып, берберебезне хөрмәт итеп эшләдек. Кәримов пенсия яшенә җитте. Көтеп кенә торганнар, диярсең, өстәгеләр бу урынга кандидатуралар күрсәтә башлады. Әмма берсенең дә бу эштә тәҗрибәсе юк иде.

Бу урынга җитәкчене үзем сайларга булдым. ПТУ директорлары арасыннан Таһир Гафурович Гафуровны чакырдым. Бер диган итеп эшләп китте. Фәйзрахман Гыйлемханович – хәзер ялда. Күрешкәләп торабыз. Бер-беребезне бәйрәмнәр белән котлыйбыз.

Совет мәктәбенең матур традицияләре бар иде – мәктәпләрдә пионер, комсомол, күп төрле укучылар оешмалары эше гөрләп торды.

Министр ярдәмчесе буларак, бу эшне республикада Вера Александрова Боговарова җитәкләде. Комсомол һәм партия өлкә комитетында эшләгәндә тупланган күпьеллык тәҗрибәсе аңа бу вазифаны җиренә җиткереп башкарырга ярдәм итте. Үз эшен ул белеп һәм теләп башкарды. Безнең бу тармак Россия

Мәгариф министрлыгы тарафыннан гел уңай яктан гына бәяләнә иде.

Мин министрлыктан киткәч, Вера Александровна Мәгариф министрлыгыннан читләштерелде. Хәзер ул – социаль-юридик институтында декан вазифасында.

Кадрлар белән эшләү юнәлешен министр ярдәмчесе Флера Әмировна Илдарханова җитәкләде. Мәктәптә, комсомол һәм партия эшендә шактый тәҗрибә туплап килгән иде ул министрлыкка. Ул тик торуны яратмый. Аның башында идеялар туып кына тора. Үзенең идеяләрен тормышка ашыру өчен, вакытын да, энергиясен дә кызганмый. Теге яки бу урынга кирәкле кадр сайлаганда да, отышлы кандидатуралар тәкъдим итә.

Укытучыларның аттестацияләрен уздыруда, “Ел укытучысы”, “Предмет укытучысы”, “Иң яхшы тәрбияче” һәм башка номинацияләрдә конкурсларны ул яңача уздырды. Җиңүчеләргә бүләкләр булдыру да җиңел эш түгел. Бюджет акчасына олы бүләкләр алып та булмый. Флера Әмировна спонсорлар таба, комсомол, партия эшендә бер елларда эшләгән дуслары, танышлары аңа булышалар иде.

Конкурсларда җиңүчеләргә бүләкләр зурдан әләгә: җиңел машина, чәшке тун, суыткыч, телевизор һ.б.

Гимназияләр, лицейлар, махсус мәктәпләр ачу буенча Мәгариф министрлыгы бу елларда күп шөгыльләнде. Бу юнәлештә дә Ф.Ә.Илдарханова нәтиҗәле эшләде.

Милли мәгарифне үстерү, мәктәпләрдә чит телләрне өйрәнү буенча безнең республика Россиядә аерылып торды. Укытучылар җитми иде. Бу мәсьәләне чишү юлын таптык. Арча, Казан, Минзәлә һәм Чаллы педучилищеларын колледж итеп үзгәрттек. Аларга, үз вазифаларыннан тыш, татар теле һәм чит тел укытучылары әзерләү бурычын йөкләдек. Флера Әмировнага тагын яңа мәшәкатьләр өстәлде. Мәшәкатьләрдән курка торган кеше түгел иде ул. Беркөнне минем янга яңа тәкъдим белән кергән: “Казан университетының татар теле факультетында имтиханнарын уңышлы тапшырган 50дән артык бала конкурстан үтмәгән. Аларны югалтмаска иде, берәр юлын табып булмасмы?” Кызык тәкъдим иде бу. Мин университет ректоры Г.Н.Коноплев һәм татар филологиясе факультеты деканы Т.Н.Галиуллинга чыктым. Киңәштек. Университет базасында татар теле укытучылары әзерли торган колледж ачарга булдык. Финанс чыгымнары Мәгариф министрлыгыннан булачак, дип килештек. Бер елдан соң безнең колледжга университетта урын җитми башлады. Безгә китәргә кушалар. “Кая

барырга?!" – дип баш ватабыз. Шулчак Флера Әмировнада яңа тәкъдим өлгерә: "Мин яшәгән йорт каршысында гына 5 нче төзелеш трестының 140 нчы номерлы балалар бакчасы бар иде. Ике ел инде ул эшләми, детсадны яптылар. Сез трест начальнигы Пипияне әйбәт беләсез. Сөйләшеп карарга иде", – ди ул.

Пипияне беләм, әлбәттә. Бу бинаны арендага сорарга тиеш инде мин. Аренда акчасы гына кызыксындырырмы? Ә аның башка уе булса?! План кора башладым. Бу бина Ленин районына керә. Әлеге район хуҗасы Ә.К. Мөхәмәтзакиров Казанда иң хөрмәтле җитәкчеләрдән санала. Мәгариф эшенә, укытучыларга да игътибары зур. Пипия – шушы район Советы депутаты. Башта Әнвәр Кадыйрович белән сөйләшергә булдым. Сөйләштек, киңәштек. Пипияне дә чакырдык. Аны ризалаштырдык. Колледж яңа урында эшләп китте.

Ф.Ә. Илдарханованың республикабыз укытучылары өчен ял йорты-профилакторий булдыру идеясе дә бар иде. Ул да хәл ителмәслек мәсьәлә түгел, югыйсә, ул чорда "хәле киткән" бер зур заводның профилакториесе ябылгач, без аңа күз салган идек. Ләкин министрлыктан мин киткәч, бу турыда уйлап караучы булмады кебек. Флера Әмировнаны да Мәгариф министрлыгыннан җибәрделәр. Аннан соң да ул Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе башлыгы булып, озак еллар уңышлы гына, министр дәрәҗәсендә эшләде.

Министрлыкта минем ярдәмчеләремнең берсе Р.Ә. Акбашов иде. Ул – Себер татары. Урал аръягында туган. Шунда укыган, укытучы, мәктәп директоры булып эшләгән. Тәҗрибә туплап, Татарстанга килгән. Гадәттә, югары урыннарга күтәрелгән кешегә кемдер ярдәм итә. Татарстанда аның бер кешесе дә юк иде, аңа ярдәм итүче дә булмады кебек...

Татарстанда Румин Әгъзамовичны Югары Ослан урта мәктәбенә директор итеп билгелиләр. Аннары партия райкомының идеология секретаре итеп күтәрәләр. Партия эшендә карьера ясау аны кызыктырмый. Бу эштән ул Мәгариф министрлыгына бүлек мөдире булып күчә. Мин министрлыкка килгәндә, ул укыту-оештыру бүлеген җитәкли иде. Аның бүлеге мәгариф эшенең иң мөһим вазифаларын башкара: гомуми мәҗбүри укыту законының тормышка ашырылуына, уку планнарының үтәлешенә, укыту-тәрбия эшенә җавап бирә. Моннан тыш, бу бүлек укучыларның белем дәрәҗәсен тикшереп тора, предметлар буенча олимпиадалар уздыра, киң колачлы уку

планнары төзи, укытучыларның январь, август конференцияләренең көн тәртибен билгели, эчтәлеген төзи.

Румин Әгъзамович җитәкләгән бүлек инспекторлары даими рәвештә республика районнарында һәм шәһәрләрендә инспекторлык тикшерүләре уздыралар. Тикшерү нәтиҗәләре буенча РОНО яки ГОРОНО Советлары утырышы һәрвакыт Румин Әгъзамович җитәкчелегендә уза.

Бүлек мөдире вазифасы гына аның мөмкинлекләре, сәләте өчен тар иде. Шуңа күрә, Румин Әгъзамович министр ярдәмчесе итеп тәкъдим ителде, аннары ул берничә бүлекнең эшенә турыдан-туры җитәкчелек итте.

Узган гасырның 90 нчы еллары демократик җәмгыять төзү теләкләренең ташкын булып агылган чоры булды. Мәгариф турында да яңа закон кирәклеге көн тәртибенә басты. Закон проектын эшләү өчен, минем җитәкчелектә комиссия төзелде. Комиссиянең иң актив әгъзаларыннан берсе Р.Ә.Акбашов булды. Иске закон кулланырга яраксыз иде. Яңа законга нигез итеп, Россия Мәгариф министрлыгы тәкъдим иткән проект вариантын алдык. Әмма аның күп кенә маддәсе (статьясы) безгә ошамый яки безгә туры килми иде. Мисал өчен, укытучы статусы турындагы маддәне алыйк. Россия Мәгариф министрлыгы вариантында укытучы өч категориягә бүленгән: икенче, беренче һәм югары категорияле укытучы. Укытучының мондый категорияләрдә йөрүе безнең беребезгә дә ошамады. Әйтик, мәктәптә, класс сәгате бара ди, класс җитәкчесе тәрбия моменты уздыра. Бер укучыны начар укыйсын, киләчәктә кем буларсың, син, дип орыша. Укучы шунда укытучыга әйтмәсме: "И, апа, син бит үзең дә икенче категорияле укытучы гына бит әле", – дип. Һәм әйтергә дә мөмкин, начар укучыдан моны көтәргә була. Уйлаша торгач, Румин Әгъзамович тәкъдиме белән, без укытучыларны 5 категориягә бүлдек: иң түбән дәрәҗәдәгесе – укытучы, аннары өлкән укытучы, методист укытучы, әйдәп баручы укытучы һәм бишенчесе – укытучы-галим. Бу соңгысын да кирәк санадык. Ни өчен дигәндә, соңгы елларда укытучылар иҗади эшләп, педагогикага яналыклар кертә, төрле тәҗрибәләр үткәрә башладылар – авторлык программалары, укытучылар язган дәреслекләр барлыкка килде, мәкаләләр, китаплар язылды, диссертацияләр якланды. Бу укытучылар, әлбәттә, укытучы-галим дәрәҗәсенә лаек иде. Укытучы статусын биш категориягә бүлүнең уңай нәтиҗәләре дә көттереп тормады. Аттестация вакытында укытучылар түбән категориядән югары категориягә күчәргә омтылдылар, аларның эшләре

яхшы якка үзгәрде, укытучыларның категорияләре үсә торды. Ә бу, үз чиратында, хезмәт хакының да артуына китерде.

Р.Ә. Акбашов киңәше белән, республикада август киңәшмәләрен яңача уздыра башладык. Элек ул Казанда гына уздырыла иде, анда катнашучылар саны да чикле булды. Берничә ел без укытучыларның август конференцияләрен 6 зонага бүлеп уздырдык. Министр өчен бу практиканың мәшәкате зур иде. Һәр зонага барырга, доклад белән чыгарга, укытучыларның, район җитәкчеләренең күп санлы сорауларына җавап бирергә, үзенчәлекләрен исәпкә алырга туры килә иде. Ләкин мондый практиканың өстенлекләре һәм файдасы әйтеп бетергесез.

Һәр зонага 6-7 район керә. Киңәшмәгә район җитәкчеләреннән тыш, РОНО, мәктәп җитәкчеләре, методик берләшмәләр җитәкчеләре чакырыла. Министр докладында һәр зона һәм районның еллык эшенә анализ ясала, бәя бирелә, алдагы уку елына бурычлар куела. Һәр мәктәп җитәкчесе, моннан кайткач, киңәшмә материаллары, алда торган бурычлар белән үз коллективын таныштыра. Киңәшмәләрне болай уздыруның өстенлеге бәхәссез. Республиканың мәгариф җитәкчесе укытучылар белән мөмкин кадәр еш очрашырга тиеш. Соңгы елларда, кызганычка каршы, моның киресе күзәтелә. "Өченче ел инде министрга кабул итүен сорап киләм, керә алганым юк," – дигән район мәгариф бүлеге мөдирләрен дә очратасың.

Алдагы елларда без август киңәшмәләрен республиканың төрле районнарында уздыра башладык. Моның да уңай яклары күп.

Күрше өлкәләргә, республикаларга барып, тәҗрибә уртаклашу, теплоход белән район мәгариф бүлеге мөдирләрен, профсоюз җитәкчеләрен ял иттерү, Мәскәү, Санкт-Петербург, Ульяновск шәһәрләренә экскурсияләр оештыруда да Румин Әгъзамович башлап йөрүчеләрдән булды. Соңгы елларда Мәгариф министрлыгына яңа ачылган уку йортларын лицензияләү, эшләп торган уку йортларын системалы рәвештә аттестацияләү бурычы да йөкләнде аңа. Гаять катлаулы һәм аеруча мәгълүматлы булуны таләп итә торган бу вазифаны Р.Ә.Акбашов җәмәгать эше тәртибендә, түләүсез башкарды. Үзе кебек энтузиастларны җыеп, алар атнага берничә мәртәбә, сәгатьләр буена, шушы эш белән нәтиҗәле шөгыльләнделәр.

Хәзер күләмле бу эшне Мәгариф министрлыгының махсус бүлеге башкара. Румин Әгъзамович үз һөнәренең чын профессионалы иде. Аңа тагын да җаваплырак эш йөкләгәндә дә ул аны намус белән башкарыр иде. Әмма эш ул юнәлештә

бармады, яңа килгән министрга андый сәләтле хезмәткәр кирәк булмады...

Минем бәхетем шундадыр: кайда гына хезмәт итсәм дә, миңа әйбәт кешеләр белән эшләргә туры килә. Мөслим район мәгариф бүлегендә дә, Казан дәүләт педагогия институтында да, Мәгариф министрлыгында да, Татар дәүләт гуманитар институтында да шулай булды...

Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Узган гасырның 80 нче еллар башында Әнвәр Нуриәхмәтович Хуҗиәхмәтов исеме радиодан ишетелә, газета-журнал битләрендә күренә башлады. Аның Спас районының Яңа Рәҗәп урта мәктәбендә директор булып эшләве, мәктәптә укучыларга хезмәт тәрбиясе бирүнең күркәм традицияләре, мәктәптәге укучылар бригадасының авыл хуҗалыгы культураларының уңышын арттыру юнәлешендә башкарылган фәнни тәҗрибәләре, мәктәпнең кечкенә фермасында йорт хайваннары үрчетү, аннан кергән акчага балаларны тукландыру, аларның хезмәтенә акчалата түләү, тарихи урыннарга экскурсияләр оештыру турында күп язылды.

Үзе белән турыдан-туры танышкач, минем аның турында мәгълүматларым тагын да күбәйде. Ул Спас районында, күп балалы гаиләдә туып-үсә. Урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлый. 1974 нче елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында профессиональ югары белем ала. Аннары мәктәптә – тарих укытучысы, укыту-тәрбия эшләре буенча директор ярдәмчесе. Ике елдан соң ул инде – мәктәп директоры. Мәктәп директоры булып эшләгәндә, ул 320 урынлы заманча яңа мәктәп салдыра, мәктәпкә интернат һәм, өстәп, балалар кафесы, икмәк пешерү биналары, укытучылар өчен дүрт йорт төзетә.

Мәктәп тиешенчә җиһазлана, һәр класс бүлмәсенә телевизор, видеомагнитофон, компьютер, төрле зурлыктагы проекторлар, микрофоннар урнаштырыла. Дәресләрне директор, завучлар бүлмәсеннән тыңлау, бәяләү мөмкинлеге тудырыла. "Үтә күренмәле" булган әлеге эш үзенчәлеге белем һәм тәрбия бирүнең дәрәҗәсен күтәрергә булыша.

Урта мәктәп комплекска әверелә. Комплекска урта мәктәп, балалар бакчасы, музыка һәм сәнгать мәктәбе керә. Мәктәптә урта белемнән тыш, производствога өйрәтү тормышка ашыры-

ла (механизаторлар, машина йөртүчеләр, сарык, сыер, чәшке, нутрия, куян үстерүчеләр әзерләнә), 5 гектарлы җиләк-җимеш бакчасы, 200 гектарлы иген басуы "Кече Артек" исемле хезмәт һәм ял лагере булдырыла. Бу мисалларны санавы гына җиңел; аларны булдыру күпме көч һәм тырышлык таләп иткәнен эшләп караган кеше үзе генә беләдер.

Соңрак Әнвәр Нуриәхмәтовичның, бер үк вакытта, колхоз председателе булып эшләве турында да ишеттек. Мәктәп житәкчесе булу да – бик авыр, катлаулы хезмәт. Ә колхоз житәкчесенең мәшәкатьле проблемалары "хәттин" ашкан. "Бу нинди кеше? Бу кадәр мәшәкатьләрне ничек берүзе алып бара икән?!" – дип соклана идем мин.

Чыннан да, Яңа Рәҗәп мәктәбе, аның директоры турында бөтен дөнья шаулады. Укучыларны чын кеше, хезмәт кешесе итеп тәрбияләү өчен, ул ниләр генә уйлап чыгармады!..

Аннары мин Әнвәр Нуриәхмәтовичның үзен тыңлау бәхетенә ирештем. Татарстан Мәгариф министрлыгының җаваплы хезмәткәре буларак, ул радио һәм телевидениедән чыгышларны еш ясый иде. Бераздан миңа аның белән Мәгариф министрлыгында бергә эшләү бәхете тиде. Министрлыкта милли мәктәпләр бүлеге ачтык. Әнвәр Нуриәхмәтович бу бүлекнең беренче мөдире булды һәм искиткеч нәтиҗәле эш башкарды. Милли мәктәпләрнең концепциясен эшләүдә, мәгариф турында закон проектын эшләгәндә, татар мәктәпләре, гимназияләре, лицейлар ачканда, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр, кулланмалар булдырганда, милли кадрлар әзерләү, чит өлкәләрдәге милләттәшләр белән багланышлар булдырганда, ул шушы хезмәтләр эчендә "йөзде".

Аның күпкырлы белеме, мәгариф проблемаларын тирән аңлавы күп кенә катлаулы мәсьәләләрне чишәргә булыша иде. Ул елларда мәгариф министрын, министрлыктагы хезмәткәрләрне радио-телевидение буенча чыгышлар ясарга еш чакыралар иде. Анда барганда, мин башка хезмәткәрләр арасыннан Әнвәрне сайлый идем. Турыдан-туры элемтәдә сораулар да күп була. Көтелмәгән сораулар да очрый. Сорау нинди генә авыр булмасын, Әнвәр Нуриәхмәтович җавапны оста таба иде.

Министрлыкта эшләр никадәр катлаулы булмасын, Әнвәр Нуриәхмәтович фән белән шөгыльләнергә дә вакыт тапты. Башта ул кандидатлык диссертациясе яклады, аннары актив фәнни эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак, докторлык диссертациясе яклады, профессор булды. Профессор буларак, гыйлем дөньясына якынаер өчен, педагогия университетына эшкә күчте.

Мин Татар дәүләт гуманитар институтында эшләгәндә, ун ел тирәсе без Ә.Н. Хуҗиәхмәтов белән аерылып тордык, ләкин хезмәттәшлек өзелмәде. Хәзер тагын бергә эшли башладык. Физика факультетында мин – декан, ул студентларга педагогика фәнен өйрәтә. Әнвәр Нуриәхмәтович хәзер – олы галим, дистәләгән саллы-саллы фәнни хезмәтләр авторы.

Югары һәм урта педагогия уку йортлары галимнәре, укытучылары аның хезмәтләрен үзләренең эшләрендә теләп файдаланалар. 2007 нче елда урта һәм югары педагогика уку йортлары өчен, "Татар милли педагогикасы" дәреслеге басылып чыкты.

Авторлары – Рафис Хәсән улы Шәймәрданов һәм Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов. Галимнәр тарафыннан бу хезмәт педагоглар, студентлар, укытучылар һәм тәрбиячеләр өчен генә түгел, һәр гаилә, һәр татар кешесенең "өстәл китабы" булырлык дәреслек дип бәяләнде.

Студентлар белән ул шундый яратып эшли, аны студентлардан аерып алып булмый. Студентлар да аны бик яраталар, "безнең остаз" дип кенә йөртәләр.

Аның укыту системасы башка педагоглардан аерылып тора. Студентларга билге чыгарганда, ул студентларның семестр буена алган балларын исәпкә ала.

2006 нчы елда Әнвәр Нуриәхмәтовичка "Университетның иң яхшы профессоры" дигән мактаулы исем бирелде.

Мәктәпләрдәге кебек, безнең физика факультетында студентларның әти-әниләренең җыелышларын системалы уздыру практикасы бар. Җыелышның гомуми өлеше дә, кураторларның үз студентлары төркеме белән аерым эшләү өлеше дә була. Әнвәр Нуриәхмәтович монда, ата-аналар белән эшләү өчен, махсус вакыт ала. Һәр ата-анага баласының уңышлары, җитмәгән яклары, кимчелекләре турында конкрет мисаллар китереп сөйли. Аеруча уңышлары булган студентның ата-анасына Мактау грамотасы тапшыра, бүләкләр бирә. Бу грамоталарны үз исәбенә төсле кәгазьләрдә, типографиядә бастыра.

Студентка мәдәни тәрбия бирүне дә ул белеп башкара. Аның укыткан студентлары барлык музейларда булалар, спектакльләр, концертлар карыйлар. Әнвәр Нуриәхмәтович бездә, татар төркемнәрендә эшләргә ярата. Татар студентларын ул барлык татар театрларына, концертларга, башка мәдәни чараларга үзе алып бара, керү билетларын да үз исәбенә ала.

Студентларыбызның талантлы педагог, атаклы галим, намуслы иҗат кешесе, гадел һәм югары әхлаклы җәмәгать эшлеклесе Әнвәр Нуриәхмәтович кебек остазлар тәрбиясендә булуына сөенеп туймыйбыз!..

Илдар Шакиров

Илгизәр Хаҗиевич Гыйльфанов турында язганда, аның кадрларны үстерү юнәлешендәге нәтиҗәле хезмәте турында әйткән идем. Перспективалы укытучыларны күреп алу сәләте көчле иде аның. Шундыйларның берсе – Илдар Габдуллович Шакиров.

Илдар, үз авылларындагы урта мәктәпнең 8нче сыйныфын тәмамлауга, Арча педагогия училищесына юл тота. Укытучы һөнәренә мөкиббән киткән егет тырышып укый. Булачак укытучыга кирәк сыйфатларны үзләштерү өчен, ул баянчылар һәм биючеләр түгәрәгенә дә, хорга һәм вокалга, ялгыз җырга да бик теләп йөри һәм теләгенә ирешә дә. Шуның өстенә, ул – спорт түгәрәкләрендә дә иң актив катнашучыларның берсе, чаңгы ярышларында, җиңел атлетикада һәм теннисга да һәрвакыт алдынгы урыннарны ала.

Педучилищены уңышлы тәмамлап, ул профессиональ белем һәм күнекмәләрне Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында дәвам иттерә.

Институтны тәмамлап Апас районына эшкә кайткач, тырыш укытучыны бик тиз күреп алалар. Мәгариф бүлеге мөдире И.Х. Гыйльфанов аны урта мәктәп директоры итеп тәкъдим итә. Укытучы өчен кирәк булган барлык сыйфатларга ия булган һәм төпле белемле яшь белгеч зур коллектив алдында да югалып калмый. Күп тә үтми, аның мәктәбе район күләмендә алдынгы урынга чыга. Бөтен сәләтен биреп эшләүче мәктәп җитәкчесенең уңай нәтиҗәләре район җитәкчеләренең күз алдында иде. Шуңа күрә дә ул, озакламый, Кайбыч районының мәгариф бүлеге мөдире итеп тәкъдим ителде.

Бу эштә И.Г. Шакировның югары профессиональлеге бөтен барлыгы белән күренде. Хәзерге вакытта төрле юнәлешләрдә какшатылган мәгариф системасын рәткә китерү, тотрыкландыру һәм үстерү өчен ул куйган хезмәт сокландырырлык! Укыту-тәрбия эшенең сыйфатын күтәрү, югары таләпләргә җавап бирә торган заманча уку йортлары булдыру, фәннәрне тирәнтен өйрәнү технологияләрен эшләү, милли төбәк компоненты-

ның ролен күтәрү, укытучыларның белемнәрен камилләштерү һәм кадрлар әзерләүне ул теоретик-методологик нигездә башкарып чыкты. Шундый тырышлыгы нәтиҗәсендә, дәрәҗәле гыйльми советта кандидатлык диссертациясе уңышлы яклан-ды. Илдар Габдуллович Шакиров кебек остазның фәнни эш-чәнлеге, иҗат процессы һәм нәтиҗәле оештыру-җитәкчелек эш-ләре һәрвакыт бергә бәйләнеп бара.

Илдар Габдуллович – киңкырлы шәхес. Аны сәнгать, әдәбият мәсьәләләре дә кызыксындыра. Үз эшен сөеп башкаруы, чыгыш ясау осталыгы, кешеләр белән аралашу сәләте тормышында уңышлар һәм хөрмәт китерә. Аның "Татарстанның атказанган укытучысы" дигән мактаулы исемгә лаек булуы – шуның ачык мисалы.

И.Г. Шакиров инициативасы белән безнең физика факультеты Кайбыч районы мәгариф бүлеге белән хезмәттәшлек итә. Факультет галимнәре район мәктәпләрендә укучылар, укытучылар белән очраша, чыгышлар ясый. Район мәктәпләре безнең университетка, физика факультетына кабул итү өчен сәләтле укучылардан булачак студентларны әзерли. Мондый хезмәттәшлек үзенең нәтиҗәләрен дә бирә – бездә укучы студентлар үзләренең тәртипләре һәм тырышлыклары белән аерылып торалар.

Илдарның тагын бер сыйфаты сокландыра. Ул физик хезмәтне ярата, үзенең улларын да шулай тәрбияли. Иртән иртүк торгач, беренче эш итеп ул малларын карый. Яшелчә, чәчәкләр үстерүдә дә бу гаиләнең осталыгына хәйран каласың. Ел буе алар үзләренең теплицаларында үстергән яшелчәләр белән тукланалар.

Мидхәт Шәрифуллин

Узган гасырның 70нче елларында педагогия институтларында мәктәп җитәкчеләренең белемен күтәрү факультетлары булдырыла башлады. Россия Мәгариф министрлыгы тарафыннан безнең институт каршында да шундый факультет ачу бурычы куелган. Ректор Мирфатыйх Зәкиевич Зәкиев мине үзенә чакырып, алда торган мәсьәләне аңлатты:

– Кайбер вузларда мәгариф системасында җитәкче постларда эшләүчеләрнең белемен күтәрү факультетлары эшли икән инде. Минем белүемчә, андый факультетлар Мәскәүдә, безнең күршеләрдән – Уфада бар. Безгә дә шундый бурыч йөкләнде. Мин факультетлардагы кадрлар мәсьәләсен карап чыктым.

Безнең институтта синнән дә кулай кеше юк. Мәгариф системасының барлык буыннарында да эшләгәнсең. Мәктәп җитәкчеләренең эше дә сиңа таныш. Бу факультетны оештыруны сиңа тапшырырга булдык. Бүгеннән шушы эшкә кереш! Факультетның штат расписаниесе билгеләнде. Методист һәм секретарь-машинистка алырсың, аларны үзең эзләп тап!

Күп тә үтми, факультет эшли дә башлады. Факультетның исеме "ФППК ОНО" дип аталды. Тутырып язганда, "Факультет подготовки и повышения квалификации организаторов народного образования" була. Димәк, без мәктәп җитәкчеләренең яңаларын да әзерләргә, эшләп торганнарының да белемнәрен күтәрергә тиеш идек.

Методист итеп, бер мәктәптә тарих укытучысы булып эшләгән Е.В. Владимировны алдык. Мәскәүгә, Уфага барып кайттым. Ул факультетлардагы хәлләр белән таныштым. Факультетка укырга килгән мәктәп җитәкчеләренең үзидарәсен булдыру нияте туды. Үзидарәне безнең курсларда укучылар советы җитәкли. Советның председателе һәм секторлары була, һәр секторга җитәкчеләр билгеләнә. Гадәттә, алты сектор ясый идек: идеология, культура-масса эшләре, уку, шефлык, стена газетасы чыгаручылар һәм факультетны бизәү секторлары.

Һәр "поток"ка укырга килүчеләргә регистрация ясау методист Евгений Владимировичка йөкләнде. Советның булачак председателен, сектор җитәкчеләренә кандидатлар сайлау да – аның вазифасында.

Минем бүлмәгә, кош тоткан кебек, килеп керде ул беркөнне: "Василь Габдуллович, Вы можете меня поздравить! Я считаю, что попал в десятку. На этот раз – председатель совета этого потока будет настоящий. Вот его анкета", – ди Евгений Владимирович.

Анкетаны укыйм. "Казанның 15 нче урта мәктәбе директоры Мидхәт Газизович Шәрифуллин", – дип язылган. Чакыртып, таныштым үзе белән. Мәһабәт буй-сынлы, матур гына сөйләшә, мөлаем гына. Факультетта укытучылар советы председателе итеп тәкъдим итәбез, дидем. Ризалыгын бирде. Бергәләп эшләп киттек. Һәр секторның җитәкчесенә җаваплы кешеләр билгеләдек.

Мин бу факультетта декан булып эшләгәндә, 6 ел эчендә 24 "поток"та ике мең ярым тирәсе мәктәп җитәкчесенең белемен күтәрдек. Һәр "поток"та ике ай укып чыктылар. Елга дүрт "поток" чыгара идек. Һәрберсендә дә – үзидарә сайлана. М.Г. Шә-

рифуллин житәкләгән үзидарәне мин аерып күрсәтер идем. Безнең чордагы кешеләргә хас сыйфат – тапшырылган эшкә җаваплы караш – Мидхәт Газизовичта югары дәрәҗәдә иде. Һәр секторда да тормыш гөрләп торды. Шәһәрнең кино-театрларына культпоходлар ясау, халыкара темаларга лекцияләр укыту өчен партия обкомының лекторларын чакыру, партия җыелышлары үткәрү, дәрес калдыручыларны, тәртибе нормадан чыккан мәктәп житәкчеләренең тәртибен тикшерү һ.б. чаралар уздырыла иде. Шефлык секторы бик файдалы эш башкара иде – һәр предмет иясе студентлар белән факультетларда эшләде, студентларны педагог профессиясенең нечкәлекләре белән таныштырды, институтта укыганда булдырылырга тиешле сыйфатларны күрсәтте. Бу “поток”та эшләнгән “Наша жизнь на ФППК ОНО” стенды күпләр өчен үрнәк булып торды.

Мидхәт Газизович көчле оештыручы гына түгел, сәләтле җырчы да иде. Культура-масса эшләре секторы оештырган концертларда аны кабат-кабат чакырып җырлаттылар. Аның җырлавы профессионаллар дәрәҗәсендә иде.

Шушы танышудан соң, Мидхәт Газизович белән без гомергә дус булып калдык һәм аның белән хезмәттәшлек алга таба да дәвам итте...

1990 нчы елдагы Татарстан Дәүләт Советына сайлауларда аны депутат итеп сайладылар. Дәүләт Советында ул халык мәгарифе комиссиясенең председателе вазифасын башкарды. Шушы елны мине Мәгариф министры итеп билгеләделәр. Хезмәттәшлек тагын да ныгыды.

Татарстанда халык мәгарифе турындагы закон шушы чорда эшләнде. Мәгариф министрлыгында эшләнгән бу законның проекты күп мәртәбәләр Дәүләт Советының мәгариф комиссиясендә тикшерелде. Тәҗрибәле педагог һәм мәктәп директоры буларак, законның һәр маддәсен тикшергәндә, Мидхәт Газизович үзенең тәкъдимнәрен әйтә иде.

Дәүләт Советы сессиясендә бу закон депутатлар тарафыннан кабул ителде. Законга яңалыклар шактый кертелде. Иң мөһиме – законда милли мәгарифнең статусы һәм милли мәгарифне оештырганда милли мәгариф концепциясе нигез итеп алынырга тиешлеге күрсәтелде. Аңа кадәр милли мәгариф концепциясе эшләнгән, һәм ул Татарстан Мәгариф министрлыгы коллегиясендә расланган иде.

Узган гасырның 90 нчы еллары демократик күтәрелешләр чоры булды. Милләтпәрвәрләр татар мәктәпләре, гимназиялә-

ре, татар телендә эшли торган балалар бакчалары булдыруны, укытучыларга, тәрбиячеләргә хезмәт хакларын күтәрүне таләп иттеләр. Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Лениногорск, Чистай һ.б. шәһәрләрдә пикетлар оештырдылар, олы тавыш күтәрделәр. Бу вакыйгалардан Мәгариф министрлыгы читтә кала алмый бит инде. Анда бару, күтәрелгән мәсьәләләрне тикшерү, хәл итү юлларын билгеләү өчен, министр буларак, миңа барырга туры килә иде. Еш кына бергә барырга, дип Мидхәт Газизовичны чакырам. Бәхетемә, ул бервакытта да каршы килми иде. Урыннарга барып, укытучылар коллективлары белән очрашабыз, таләпләрен өйрәнәбез, аннары шәһәр җитәкчеләре белән бу таләпләрне хәл итү юллары турында сөйләшәбез. Шул чорда шактый гына уңай үзгәрешләр дә булдырылды: шәһәр бюджетыннан укытучыларга өстәмә түләү − Укытучылар көнендә аларга материаль ярдәм күрсәтү, премияләр бирү, укытучыларга квартиралар бирү өчен махсус йортлар төзетү, класс җитәкчеләренә аерым өстәмә түләү, яхшы укучыларга стипендияләр булдыру, олимпиадаларда җиңүче укучыларның укытучыларына махсус премияләр бирү һ.б.

Күп йөргән кешегә юлда төрле авырлыклар да очрый. Бервакыт шулай М.Г.Шәрифуллин белән Әлмәткә барабыз. Салкын гына кыш көне бу. Бүген Әлмәткә барып кунасы гына, дип соң гына чыккан идек. Караңгы төшеп килә. Машинабыз ватылды. Әлмәткә җитәргә шактый ара бар. Мобильный телефоннар дигән әйберне әле белмибез. Юлдан шалтыратып булмый.

Машинаны төзәтү күп кенә вакытны алды. Әлмәткә барып җиткәндә, эш сәгатьләре беткән иде инде. Кунакханәгә барып урнаштык. Ә анда ресторан да, буфет та юк. Ашыйсы килә. Беребезнең сумкасыннан печенье килеп чыкты. Краннан су алып, шул печеньены капкаладык. Шундый хәлләр дә булгалады...

Депутат һәм комиссия председателе буларак, Мидхәт Газизовичның бу елларда Мәгариф министрлыгына ярдәме күп булды. "Бу эш миңа кагылмый, моны сез эшләргә тиеш" дигән сүзләрне мин аннан бервакытта да ишетмәдем. Район, шәһәр Советлары сессияләрендә мәгариф мәсьәләләре каралганда, татар мәктәпләре ачу, милли университет булдыруга багышланган чараларда ул теләп катнашты, эшлекле чыгышлар ясады.

Равил Галиәхмәтов

1965 нче елның март аеннан башлап, Мөслим районы мәгариф бүлеге мөдире булып эшли башладым. Күп тә үтмәде, районга Татарстан Мәгариф министрының беренче урынбасары Галиәхмәтов Равил Әлмиевич килеп төште. Мәһабәт гәүдәле, киң җилкәле, бөдрә чәчләре дулкынланып тора. Аның янында мин – беренче класс баласы кебек кенә. Равил Әлмиевичнең максаты районда мәгариф эшенең торышы белән танышу иде.

Мәгариф бүлеге мөдире итеп раслаганда, мине Галиәхмәтов янына алып кергәннәр иде. "Безнең районда мәктәпләр бик иске инде, аларны яңартырга кирәк, министрлыкның ярдәме кирәк булачак", – дидем мин. Ул булышырга вәгъдә биргән иде. Министр урынбасарының безнең районга килүен мин аның вәгъдәсендә торуы дип кабул иттем.

Райбашкарма комитеты председателе Мисбах Хөсәенович белән Галиәхмәтовны район буенча нинди маршрут буенча йөртергә, кайсы мәктәпләрне күрсәтергә, дип "баш ватып" утырабыз, хәлләр, чыннан да, аяныч хәлдә. Мисбах Хөсәенович төзегрәк, яңарак мәктәпләрне күрсәтү ягында:

– Министрлар ел саен килми. Гомергә бер килеп, район турында бик начар фикер белән китмәсен! – ди ул.

– Мин киресенчә уйлыйм, – дидем мин. – Район мәктәпләренең күбесе хәрабә хәлендә, хәтта терәү белән генә авып китмичә торганнары да бар. Исполком председателе булып Сез дә яңа гына эшли башладыгыз, мин дә бу эштә – яңа кеше. Күпме эшләп, райондагы мәгариф системасын нинди хәлгә төшергәнсез, дип, безне гаепли алмыйлар. Мәктәпләрнең җимерелергә торганнарын күрсәтик Галиәхмәтовка, күрсен безнең авыр хәлне! Аларны төзисе дә бар бит әле. Ярдәм сорап барырга уңайлырак булыр. Без ул җимерекләрне үзебез генә төзеп бетерә алмаячакбыз.

Мине тыңлап торды да әйтте Мисбах Хөсәенович:

– Яшь булсаң да, башың эшли синең! Тәкъдимең белән килешәм. Үзең уйлаганча маршрутны төзе. Минем машина белән чыгып китәрбез, – диде.

Чыгып киттек район буенча. Барган бер җирдә иске мәктәп биналарын күрсәттек. Вәрәшбаш мәктәбен карап йөргәндә, Галиәхмәтовка шушы мәктәп белән бәйле бер вакыйга турында сөйләдем: РОНО планы буенча Вәрәшбаш мәктәбендә мәктәп директорлары семинары уздырдык. (Гадәттә, мондый семинарлар укыту-тәрбия эшенең нindидер юнәлеше белән уңышлы

эшләгән мәктәптә уздырыла). Бу чорда кабинетлар системасына күчеп укыту бик актуаль мәсьәлә итеп күтәрелә иде. Бинасы заманча булмаса да, вәрәшбашлылар һәр фәннән кабинет булдырганнар. Мәктәп берничә агач бинага урнашкан. Һәрбер бинада бер яки ике укыту кабинеты эшли.

Ачык дәресләр тыңлап, аларга анализ ясап, район мәгариф бүлеге мөдиренең алда торган, кичекмәстән хәл итәсе мәсьәләләр турындагы чыгышларыннан соң, кайтырга чыктык. Ул елларда РОНОның да, мәктәпләрнең дә машиналары юк иде. Бу мәктәпкә Михайловка мәктәбенең йөк машинасының әрҗәсенә эскәмияләр куеп, шунда утырып килдек. Кайтырга да шул машина белән чыктык. Авылны чыгып киләбез. Караңгы төндә бер бинаның тәрәзәләреннән урамга яктылык сибелә. Матур гына төзек бина, бихисап күп тәрәзәләре тезелеп киткән, тәрәзәләрдән сибелгән ут яктысында яңа кирпеч диварлар бинаны тагын да бизәп тора. Иртән, яктыда бу бинага беркем дә игътибар итмәгән иде. Бер директорның күзе шушы бинага төште:

– Карагыз әле, бу якка. Бу нинди мәһабәт бина?! – дип соклануын белдерде ул.

– Киров исемендәге колхозның Вәрәшбаш сыер фермасы бит бу, – диде бер белдеклесе.

– Их, егетләр, безнең мәктәпләр кайчан сыер фермалары дәрәҗәсенә җитәр икән?! – дип уфтандылар мәктәп директорлары.

Бу турыда ишеткәч, Галиәхмәхтов та шактый уйланды:

– Кызганычка каршы, республикабызда мәктәпләр төзелеше белән әлегә мактана алмыйбыз шул. Нефть чыга торган районнар гына бераз “кыймылдый” башладылар. Күреп торам, сездә дә хәлләр яхшы түгел. Үзегезгә дә тырышырга туры киләр, Мәгариф министрлыгы да булышыр. Моны минем вәгъдә итеп аңлагыз! – диде ул.

Галиәхмәтов ул елларда мәгариф министрының беренче ярдәмчесе иде. Төзелеш эшләре, мәктәпләрне материаль-техник яктан тәэмин итү белән ул җитәкчелек итте. Ул вәгъдәсендә торды, күп мәсьәләләрдә безгә ярдәм итте. Төзелеш эшләрендә аның тәҗрибәсе зур иде.

– Яңа мәктәп салу, капиталь төзелеш турында гына сорап килмәгез сез. Мондый мәктәпләрнең исемлеге Мәскәүдә расслана. Мәскәү бу эшне бик кысып кына башкара. Сез мәктәпләргә капиталь ремонт, янкорма (пристрой) сорап мөрәҗәгать итегез. Боларны мин хәл итәм. Булышырбыз! – диде ул.

Эшләр алга китте ул елларда. Без проект-смета документларын әзерләп тордык, Равил Әлмиевич финанс ярдәмен бирә торды. Мөслим урта мәктәбенә 540 урынлы янкорманы бер ел эчендә өлгерттек. Капиталь ремонт акчасына Вәрәшбаш, Мухан, Метрәй, Шуган, Мәлләтамак, Симәк, Шуран, Түбән Табын, Горбуновка, Төйгелде, Октябрь мәктәпләре төзелде. Төзекләндерелгән биналарда күп сандагы балалар бакчалары, мәктәп яны интернатлары эшли башлады, министрлык ярдәме белән физика, химия, биология кабинетларына – җиһазлар, хезмәт дәресләре, производствога укыту өчен, техника, эш кораллары алдык.

Равил Әлмиевичка рәхмәтебез зур безнең. Ул чын җитәкче, Олы Кеше иде!

Шәйхенур Гайнетдинов

Мөслим районын 1962 нче елда Сарман районына куштылар. Сарман районы партия комитетының Беренче секретаре Михаил Константинович Мамаков республикада көчле җитәкчеләрдән санала иде. Шуңа күрәдер, район үзәген Сарманда ясадылар. Районда уздырылган чараларга шунда бара башладык. Сарманның район мәгариф бүлеге мөдире Ш.М. Гайнетдинов мине Мөслим урта мәктәбенең укыту эшләре буенча директор ярдәмчесе (завуч) итеп билгеләде. Мәктәп директоры В.А. Иванов мәктәп йомышлары белән РОНОга баруны миңа тапшыра башлады. Шәйхенур Мөхәммәтдинович белән шул елларда якыннан таныштым.

Мөслим районында мөдир булып эшләгәндә, күрше районнарның мәгариф бүлеге мөдирләре белән дуслык мөнәсәбәтләре урнашты. Тәҗрибә уртаклашу максатыннан, бер-беребезгә йөрибез. Шәйхенур Мөхәммәтдинович, заманында, Казан дәүләт педагогия институтында педагогика укытучылары әзерләү бүлеген тәмамлаган. Безнең институтта күп еллар педагогика кафедрасын җитәкләгән профессор Я.И. Ханбиков белән бер төркемдә укыган. Шуңа күрәдер, Шәйхенур Мөхәммәтдиновичта үзенең фикерләрен педагогика классиклары белән ныгытып кую гадәте бар иде. Үзенең әзерлек дәрәҗәсен сизгәндер, ул педагогика буенча аспирантурага да керде, читтән торып шөгыльләнде. Фәнни темасы – укучыларга хезмәт тәрбиясе бирүдә А.С. Макаренко принциплары белән бәйле иде кебек. РОНО эшенең мәңге бетмәс һәм иксез-чиксез мәшәкатьләре аңа диссертациясен төгәлләп, яклау дәрәҗәсенә җиткерергә ирек бирмәде.

РОНОдагы бихисап мәшәкатьләр, дигәннән, бервакыт хәбәр дә биреп тормыйча, Мөслимгә килеп чыкты бу. “Минем ашыгыч бер эш килеп чыкты. Симәк мәктәбенә барыйк әле”, — ди ул. Эш болай була: Симәк мәктәбендә хезмәт укытучысы булып күп еллар Фамулла Шәрифуллин эшләде. Хезмәт дисциплинасын бозулары белән аерылып торды. Безнең район Сарман районына кергән елларда Шәйхенур Мөхәммәтдинович Фамулланы район мәгариф бүлеге приказы белән эшеннән алган. Фамулла берничә ел эшсез торган. Шул арада моның башына бер уй килә: Мине бит эштән азат итү дөрес эшләнмәде. Приказ булганчы, мине мәктәп коллективы, профсоюзның җирле комитеты тикшереп карар чыгарырга тиеш иде. Боларның булуын мин хәтерләмим. Димәк, РОНО мине эштән дөрес бушатмаган. Эшләми йөргән берничә еллык хезмәт хакын Гайнетдиновның кесәсеннән каерып алам мин”, — дип план кора бу, һәм шул юнәлештә актив эшкә керешә. Эшне судка житкерә...

Район халык суды судьясы Фамулланың оту мөмкинлеге булуы турында РОНО мөдиренә хәбәр бирә.

Ашыгыч рәвештә Симәк мәктәбенә баруның сәбәбе аңлашылды болай булгач. Шунда киттек.

Мәктәп директоры булып, Симәктә озак еллар Сираҗетдин абый Ишматов эшләде. Акыллы җитәкче һәм кешелекле педагог иде Сираҗетдин абый. Халык алдында абруе зур булды. Ул ялга чыккач, директор вазифасын башкаруны аның улы Дилфин Сираевич Ишматовка тапшырдык. “Мин бу эшне башкара алмыйм, миндә җитәкче сыйфатлары юк һәм киләчәктә дә булмаячак”, — дип бик карышса да, ул менә дигән итеп эшләп китте, районда иң хөрмәтле директорларның берсе булды.

Дилфин Сираевичка алда торган мәсьәләне аңлатып бирдек. Алдагы еллардагы җыелышлар, утырышлар “беркетмәләр”ен актара башладык. Фамулланың кимчелекләре күп мәртәбәләр тикшерелгән, местком утырышы карары гына тиешенчә язылмаган була. Аны язып бирделәр. Шулай итеп, Шәйхенур Мөхәммәтдинович судта үзенең хаклы икәнен раслады.

Шушы уңайдан искә төшкән тагын бер хатирәне языйм әле. 1968 нче елда Казанга фәнни-практик конференциягә бардык. Безнең район делегатлары арасында Д.С. Ишматов та бар. Конференция Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында бара. Тәнәфестә минем белән Ш.М. Гайнетдинов күрешеп китте. Янәшәмдә булган Дилфин Сираевич

моңа игътибар иткән: "Күз күргән кешегә охшаган, кем булды ул?"– диде ул.

– Специалист по Фамулле, — мин әйтәм.

Шәйхенур ерак китмәгән булган, Дилфин белән безнең сөйләшүне ишеткән. Яңадан килеп Дилфин белән күреште, күрешмичә китүе өчен гафу үтенде. Теге вакыттагы ярдәме өчен, тагын бер кат рәхмәтен әйтте. Шул көннән үзенә яңа исем алды: "Специалист по Фамулле".

Шәйхенур белән күрешкәндә көлешеп ала торган тагын бер сәбәп булды. "Сездә аны ничек итәләр, Шәйхенур Мөхәммәтдинович", — дип сүз башлыйбыз. Болай сөйләшүнең сәбәбе бар: Татарстан Республикасы санэпидстанциясеннән килеп, Сарман районы мәктәпләрендә укучылар арасында санитария кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп йөриләр.

XX гасырның 60 нчы еллары бу. Кызганычка каршы, бер мәктәптә берничә кызның башыннан бет чыга. Бу балаларның мәктәп интернатында торуы билгеле була. Ул елларда мәктәптә чит авыллардан килеп укучылар өчен интернат биналары төзү тәртибе бар иде. Мәктәпнең интернатын тикшерә башлыйлар. Чисталык, тәртип яхшы гына кебек.

— Ничә бала тора интернатта? — дигән сорау бирелә.

Интернатта 50 бала тора икән. Койкаларны саный башлыйлар. Алар 25 кенә. Ничек болай? Һәр балага койка җитми бит?!

Бу сорауга җавапны мәктәп директоры бирә: "Бездә һәр койкада ике бала йоклый. 50 койка куярлык урыныбыз юк!"

Бу җавап санэпидстанция врачларына ошамый. Бер койкада ике баланы йоклату зур кимчелек булып кабул ителә. Мондый шартта бер баладан икенчесенә бет кенә түгел, башка чирләр дә күчәргә мөмкин.

Сарман районының республикада алдынгы саналган еллары иде бу. Төзелеш, яңа уку елына әзерлек мәсьәләләре буенча Әлмәт, Мөслим, Сарман районнары гел ярышып яшәде. Беренчелекне алар бүлеште.

Бүгенге тикшерүдән соң, санэпидстанция врачларының Казанга начар нәтиҗә белән китүләре мөмкин иде. Шәйхенур Мөхәммәтдинович моны теләми иде, әлбәттә. Ул үзенең тәкъдимен әйтте:

— Кызганычка каршы, бу мәктәптә без очраклы күренешкә дучар булдык. Бездә яхшы мәктәпләр күп. Әйдәгез, шуларның берничәсен карыйк, — диде ул. Күнеленнән ул, беренче чиратта, Азалак урта мәктәбен сайлый. Шунда барырга кирәк, дип

уйлый ул. Мәктәп һәрьяктан үрнәк булырлык. Балаларның белем дәрәҗәсе буенча да, кабинет системасын булдыру буенча да, тәҗрибә бакчалары, хезмәткә әзерләү буенча да – мәктәп алдынгылардан.

Комиссия мәктәпкә килеп төшә. Алдан телефоннан шалтырату буенча, мәктәп директоры Я.Шарифуллин тикшерүчеләрне каршыларга чыккан. Тикшерүчеләрне, беренче чиратта, интернат кызыксындыра. Шунда юнәләләр.

Алдагы мәктәп-интернатта булган бер койкада ике бала йоклау тәртибе бу мәктәптә булмаска тиешлеген раслау өчен, Шәйхенур Мөхәммәтдинович мәктәп директорына сорау бирә:

— Ядкәр абый, әйтегез әле, бер койкада ике бала йоклау тәртибе сездә юк бит инде ул?!

Директор күп уйлап тормый:

– Юк, юк, иптәш Гайнетдинов. Бездә – урын киң. Бездә аны болай итәләр: ике койканы бергә кушалар да, өчәү йоклыйлар.

Бу җаваптан Казан врачларының чәчләре үрә тора. Алар интернатка кереп тә тормыйча, кайтып китәләр.

Күрешкәндә, Шәйхенур Мөхәммәтдиновичка:

– Әйтегез әле, сезнең интернатта бер койкада ике бала йоклау юк бит инде ул?! — дигән сорау биреп:

– Юк, юк. Бездә – урын күп, – дигән җавап алабыз. Аннары күңел күтәренкелеге белән әңгәмә дәвам итә.

Сарманнан соң, Гайнетдинов озак еллар Арча педагогия училищесында педагогика фәне укытты. Республикабыз горурлыгы булган Шәйхенур Мөхәммәтдинович Гайнетдиновка “Татарстанның атказанган укытучысы” исеме бирелгән. Бүгенге көндә ул лаеклы ялда – гаилә җылысын тоеп яши...

Хәниф Хөсәенов

Безнең районны Актаныш, Минзәлә, Сарман һәм Азнакай районнары әйләндереп алган. Күрше районнар белән дуслыкта яшибез, хезмәттәшлек итәбез. Күрше районнарның мәгариф бүлекләре уздырган чараларда катнашабыз.

Бер елны, безнең районның пионерлар лагерен ачу көнендә, Минзәләнең РОНО мөдире Хөсәенов Хәниф Гизетдинович килде. Ул вакытта безнең районның пионерлагереның аерым бинасы юк иде. Табигатьнең матур урынында урнашкан берәр мәктәп янында оештырыла иде лагерьлар. Соңрак – Нарат Асты

авылы янындагы Ык буенда, нарат урманы эченә кертеп салынды. Монда, әкияттәге кебек, матур табигать, су коену, кызыну, балык тоту урыннары, җиләк-җимеш, үләннәр, чәчәкләр, гомбә җыю өчен киң мөмкинлекләр бар иде.

Хәниф Гизетдинович килгән елны без лагерьны Иске Авылның алма бакчасында урнаштырдык. Ике тау арасындагы матур үзәнлек көньяк тарафка җәелеп, Ык елгасына барып җитә. Сөзәк тауларда – мәһабәт алмагачлар, астарак – чиyәләр, карлыган, кура җиләге куаклары.

Балаларны йоклату өчен, "палаткалар шәһәрчеге" кордык. Ике, өч, дүрт кешелек палаткалар шактый зур мәйданны биләде. Урамнар, кварталлар, отрядларның исемнәре барлыкка килде.

Лагерьны тантаналы ачуга нык әзерләнгән идек. Бу чара күңелле генә узды. Катнашучыларга да, килгән кунакларга да ошады.

Хәниф Гизетдинович китәргә әзерләнде. Берничә кеше аны озата киттек. Минзәләгә юл Шуран аша уңайлы. Шул юлдагы урман аланында кунакка чәй эчереп җибәрергә уйладык. Машиналарны арты белән чигереп, аланның түренә туктаттык. Мәгарифнең четерекле проблемалары турында фикер алышып, кунакка чәй эчердек. Чәйдән соң, Хәниф Гизетдинович кайту юлына урман аланыннан машинасын чыгарып куйды. Мин дә үземнең машинага – "Запорожец"ка кереп утырдым. Үземнең, дим, ул елларда РОНОларга дәүләт машинасы бирелми иде әле. Ачкычны борам – машина кабынмый. Күпме тырышсак та, машинаны кабыза алмадык. Кич җитте. Хәниф Гизетдинович төнгә каршы мине урманда калдырып китәргә кыймады. Минем машинаны аныкына тагып, Мөслим ягына юнәлдек. Вәрәшбашка җиттек. Шушы кыяфәттә Мөслим урамы буйлап йөрү уңайсыз булыр, дип, Вәрәшбаш мәктәбе директоры З.З.Закировларга туктадык. Безне аларның йортлары авыл башында булуы кызыктырды. Хуҗа өйдә иде. Безне кыстап, өйләренә алып керде. Кунак та кунып китәргә булды. Зәки Закирович белән Хәниф Гизетдинович электән үк бер-берсен беләләр икән.

Иртән торып машинаны тикшереп йөрим. Ни булды моңа, дим. Бервакытта да болай интектергәне юк иде бит. Туктале, нәрсә булды? "Глушитель" көпшәсе урман балчыгы белән шыплап тулган. Урман аланында машинаны артка чигергәндә булган хәл инде бу. Мондый хәлдә машина, әлбәттә, кабынмый. "Глушитель"гә тулган балчыкны яхшылап чистарттым.

Машинам, җаныкаем, ачкычны бора башлау белән кабынып китте, сәгать кебек эшли.

Иртәнге чәйне эчеп утырабыз, Хәниф Гизетдинович әйтеп куйды: "Миңа эшкә кайтып җитәсе бар. Мин китәрмен инде, бигайбә. Син нишләрсең икән?"

– Әле кем тизрәк кузгалыр, карарбыз,– дим.

Машиналар янына чыктык. Машинаны кабызып куйдым. Барысының да ушлары китте. Кичә урманда булган хәлне аңлатып бирдем.

Озакламый Хәниф Гизетдинович белән Казанда, мәгариф бүлеге мөдирләре киңәшмәсендә очраштык. Мине кочаклап алды. "Син биргән "дәрес" аркасында мин Минзәләнең иң хөрмәтле, зур дәрәҗәле кешесенә әйләндем, рәхмәт сиңа", – ди.

Эш болай була. Казаннан Минзәләгә килгән кунакны сыйларга Минзәлә урманына алып чыгалар. Урманның матур аланына туктыйлар. Машиналарны артка чигереп, чыгу юлына каратып куялар. Программада каралганча, кунакны сыйлыйлар. Кайтырга вакыт җитә. Һәрберсе үзенең машинасын кабызып юлга чыгарып куя. Тик райкомның Беренче секретаре Мәгъсүм Шәйгзамович Хөсәенов машинасы гына кабынмый. Машинаның үз шоферы да, башкалар да тырышып карыйлар. Төрле тәкъдимнәр була: свечасын чистартып кара, коллектор капкачы чатнамаганмы, карбюраторга бензин киләме?! Нәтиҗә юк. Казан кунагы да шушы машинада кайтасы. М.Ш.Хөсәенов сүгенеп тә җибәрә.

Бу кампаниядә Хәниф Гизетдинович тә була. Ул җайлап кына глушительне карап килә. Эшнең нәрсәдә икәнен аңлый. Хөсәеновка тәкъдим ясый: "Мәгъсүм Шәйгзамович, бу кешеләрнең берсе дә машина белә торган түгел. Куып җибәрегез әле шуларны машина яныннан. Үзегез дә китегез. Машинагызны кабызып китереп бирермен", – ди

Һәм Хәниф Гизетдинович, минем тәҗрибәне уңышлы кулланып, машинаны хуҗасы янына чыгарып куя.

Әлбәттә, "могҗизаның" серен ачмый. Районда Х.Г.Хөсәеновка олы ихтирам шуннан соң башлана. Райондагы олы киңәшмәләрне беренче секретарь Хәниф Гизетдинович – "бөтен техникаларның төп белгече" килеп җиткәч кенә башлый торган була.

Авторитетның артуына Беренченеке белән Х.Г.Хөсәеновның фамилияләре очраклы гына туры килүе дә булыша, әлбәттә.

Марсель Бәширов

Пединститутта без бер елларда укыдык. Факультетлар гына аерым иде. Марсель – тарих-филология факультетында, мин – физика-математика факультетында. Марсель Казан егете иде. Шуңа күрә ул тулай торакта күренеп йөрмәде. Ул факультеттан безнең бүлмәдә Хәнәфи торды. Хәнәфи – Киров өлкәсеннән, Пенәгәр авылыннан. Аның белән бик тиз дуслашып киттек. Үзләренең студентлар төркеме һәм алардагы студент тормышы турында ул гел таныштырып торды. Ул төркемнән Карлны белә идем инде. Ул – Минзәлә педучилищесыннан. Алга таба Гадсьнән, Альберт, Мохәммәт, Камил, Илгиз, Марсель һ.б. курсташлар белән танышып киттем.

Марсельне беренче күрүем аларның факультетында нәрсәгәдер багышланган бер кичәдә булды кебек. Егет озын буйлы, матур гына киенгән, "стиляга" да түгел. Ул заманда яңа мода шаукымы яшьләргә кереп бара иде: тар балаклы чалбар, калын табанлы туфли, төрле рәсемнәр төшкән төсле галстуклар күпләрне кызыктыра иде. Марсель андый булмады. Шәһәрдә туып-үскән кешедә бераз андый гадәтләр булса да, ул гафу ителер иде. Без, күптәннән таныш кешеләр кебек, аралашып киттек.

Беренче курсны тәмамлагач, Казахстанга чирәм җирләрне күтәрергә киттек. Анда без июль башыннан октябрь урталарына кадәр эшли идек. Октябрь аенда Казахстан климаты үзен шактый сиздерә, температура минусны күрсәтә башлый.

Кайтканда, барлык районнардан да Павлодар шәһәренең тимер юл вокзалына җыелабыз. Физматлар – Бескарагай, тарих-филология факультетындагылар Май районыннан килде. Вокзалда төн кунабыз. Халык күп җыелды, вокзал эченә генә сыймый студент халкы. Өскә кияргә беребезнең дә җылы киеме юк. Казаннан чыгып киткәндә җәйнең иң кызу вакыты иде шул. Беребезнең дә җылы кием алырга башына килмәгән.

Шунда Марсельне күреп алдым. Өстенә сарык тиресеннән тегелгән тун, бүрек, аягына җылы ботинка киеп җибәргән. Тарих-филология факультеты студентларының бригадиры икән, шуларга нидер аңлатып тора.

– Каян башыңа килде бу әйберләрне алып килергә? –дим.

– Элегрәк бу якларда булучылардан сораштырдым – юлга чыкканчы! – ди бу.

"Дөньяны, тормышны аңлый белә торган, төпле, фикерле егет бу!" – дип уйлап куйган идем шул чакта. Чыннан да, шулай булып чыкты. Институтта укыганда ук аны җитәкче урыннарга "кодалый" башладылар. Аннары аны зур заводның баш инженеры итеп күтәрделәр. Оештыру сәләтен, кешеләр белән эшли белүен күреп, аны министр дәрәҗәсенә – Татарстан төзелеш материаллары җитештерү предприятиеләре җитәкчесе итеп билгеләделәр. Бу өлкәне ул бик белеп, яратып, озак еллар буе шунда эшләде. Аны эшкә кара "Волга"да йөрттеләр. Заманында кара "Волга" бик дәрәҗәле иде.

Институттан соң, мин эшкә Мөслимгә киттем. Район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгәндә, Казанга еш килергә туры килде. Марсель Әхәтович эшли торган оешманың офисы Татарстан Мәгариф министрлыгы белән бер бинада. Шулай итеп, күрешкәләп торабыз. Аның: "Бу авыл "гыйбаты" белән нигә вакланып торырга?"– дигән масаюын һич тә сизмәдем...

Шулай итеп, тагын берничә ел үтте. Мин дә Казанга килдем, пединститутның физика кафедрасында доцент булып эшли башладым. Фатир юк, гаилә – Мөслимдә, үзем Федосеевка урамындагы карт белән карчыкта өйдәш булып торам.

Марсельнең эш урыны Кремль эчендә, мин торган фатирдан ерак түгел, ул кергәләп йөри. Еш кына ул мине үзләренә кунакка алып китә. Бу чордагы аның киң күңеллелеге, ярдәмчеллеге мине тагын да сокландырды. Бу турыда тәфсилләбрәк языйм әле. Эш болай булды.

...Фатир булдыру артыннан йөри торгач, институт ректоры миңа булышырга булды. Институтның рус теле кафедрасы күренекле лингвист-профессор Богородицкий исемендәге кабинетны Пушкин урамындагы йорттан кафедрага күчерергә булды. Болай иткәндә, кафедра галимнәренә дә, студентларга да бу кабинетта эшләргә уңайлы булачак иде. Богородицкий кабинеты биләгән мәйданны ректор безнең гаиләгә бирергә булды. Бинаның урыны бик уңайлы, элекке обком бинасы каршында гына. Ләкин фатир итеп яшәргә уңайлыклары юк: газ да кермәгән, җылы суы да юк, туалеты да урамда. Боларны уздыру өчен, обком бинасы урнашкан мәйдан аша җир казу эшләренә дә рөхсәт бирәселәре килми.

Марсель Әхәтович миңа тәкъдим ясады:

– Бу бинаны син безгә бир! Мин анда управлениенең бер лабораториясен күчерәм. Ә сиңа безнең идарәгә бирелгән бер фатирны бирербез!

һәм шулай иттек дә. Пушкин урамындагы бинада лаборатория гөрләп эшләп китте. Ә безнең гаилә Әмирхан урамыннан барлык уңайлыклары булган өч бүлмәле фатир алды.

Мондый яхшылыкны Марсель кебек киң күңелле егетләр генә эшли ала. Аның белән безнең мөнәсәбәт болай да әйбәт иде. Алга таба без аерылмас дусларга әйләндек.

Марсель Әхәтович һәрвакыт кешеләргә ярдәмчел булды. Казахстанда "чирәм җирләр" эпопсясы турында әйткән идем инде. Павлодар шәһәренең тимер юл вокзалында поезд көтәбез. Октябрь аеның башы. Температура минусны күрсәтә, җиле дә бар. Себер бае кебек, җылы тун киеп, вокзал тирәсендә Марсель йөри. Минс күреп алды. "Җиңелчә киенгәнсең, суык тидерәсең бит. Миндә бер гимнастерка бар, киеп җибәр шуны ", – ди. Киеп куйдым, доньялар ямьләнеп китте.

Аннан ярдәм алган кеше бик күп булгандыр. Һәрвакыт җитәкче урыннарда эшләгәч, аның мөмкинлеге дә бар иде. Аның булышлыгы белән күпләр фатирлы булды, теләгән эшенә урнашты.

Үзенең булдыклылыгын да дөрес бәяли иде ул. Бервакыт аның бүлмәсендә сөйләшеп утырабыз. Арада районнан килгән колхоз председателе дә бар. Шул сөйли: "Иң авыр хезмәт ул колхоз председателе булу. Андый эшне сирәк кеше уңышлы башкара, менә минем кебек йөк атлары булса гына!"

– Мин ул эшне бик теләп башкарыр идем, – дип, Марсель председательгә каршы төште.

– Берегезнең дә авылга кайтканыгыз юк әле, шәһәр асфальтыннан йөрүне хуш күрәсез. Монда эшләү җиңел ул! – диюгә дә Марсельнең җавабы әзер иде:

– Республиканың барлык шәһәрләре һәм авыллары безнең продукция белән төзи. Безнең күп вакыт республиканың төрле почмакларында урнашкан кирпеч заводларында үтә, төнен көнгә кушып чабабыз, туктап торганыбыз юк. Нәтиҗәсе дә бар. Ә бер колхозны тарту ул теләсә нинди сәламәт кеше башкара торган эш!..

Председатель үзенең гадәттән тыш шәхес түгеллеген аңлады шикелле...

Икенче бер вакытта, безнең белән бер чорда укыган, хәзерге вакытта Кукмара районында укытучы булып эшләүче иптәш әйтеп куйды:

– Барыгыз да Казанда яшисез, мин дә киләм әле Казанга!

Марсель сорап куйды:

– Кем булып киләсең инде син Казанга?

– Менә син эшлисең бит әле, мин дә эш табармын!

– Мине Мәскәү министрлыгына да чакыралар. Монда теләгең булу гына җитми, рәтле эшең, фатирың булу, эшләү сәләтең кирәк, дигәндәй...

Иптәшне Казанга чакырып торучысы да, әзерләп куелган фатиры да юклыгын Марсель белми түгел иде.

Бу иптәш Казанга күченеп килде-килүен. Эшкә урнашырга мин булыштым. Тору урынын табарга Марсель ярдәм итте. “Кара сакалың, кая барсаң да, үзең белән ияреп йөри”, – дигән әйтем бар безнең халыкта.

Монда да шулай булды. Районда яшәгәндә, аракы белән дус булган икән. Бу гадәт Казанда да дәвам итте. Шуның аркасында эшеннән җибәрделәр. Яңадан авылына кайтып китте ул...

Ислам Әхмәтҗанов

Ислам Галиәхмәтович Әхмәтҗанов белән министр булып эшләү еллары бер чорга туры килде. Тәрбияләребез, дөньяга карашларыбыз, уй-фикерләребез бертөсле булгандыр, мөгаен. Татарстанның Матбугат чаралары министры И.Г. Әхмәтҗанов, Культура министры Марсель Мәзһарович Таишев, Радио һәм телевидение министры Тәүфикъ Камәретдинович Сәгыйтов һәм мин – Мәгариф министры – аралашып һәм аңлашып яшәдек.

Ислам Галиәхмәтовичны мин элегрәк тә бераз белә идем. Ул “Татарстан яшьләре”, “Ватаным Татарстан” газеталарында эшләде, саллы-саллы мәкаләләре еш чыга иде. Журналист буларак, ул сүзнең тәмен, һәр сүзнең егәрен белеп язды.

Ул – Буа районының Норлат авылыннан. Бу авылдан мин Мостаевларны әйбәт беләм. Шамил Әсгатович безнең республиканың зур җитәкчеләреннән берсе булды. Ул күп еллар Татарстан Финанс министры, Югары Совет Президиумының председателе булып эшләде. Аның энесе Наил Әсгатович яхшы журналист иде. Мөслимдә дә эшләде ул. Район газетасының редакторы булды. Бу шәхесләргә карата булган ихтирамым һәм хөрмәтем Ислам Галиәхмәтовичка да күчте.

Безнең министр вазифасын башкарган еллар гаять катлаулы, элекке яшәп килгән системаның җимерелү еллары иде. Республикада иң җаваплы министрлыкларның берсенең җитәкчесе буларак, катлаулы демократияләшү чорында матбугат һәм информацияләрнең нормаль тәрәккыятенә ул дөрес юнәлеш бирә белде. Бу эштә хаталар китү мөмкинлеге зур иде.

Ләкин И.Г. Әхмәтҗановның югары профессиональлеге һәм сәяси сизгерлеге үз эшен ялгышмыйча башкарырга ярдәм итте.

Күп кенә мәсьәләләрне без бергәләп чишә идек. Әйтик, “Мәгариф” нәшриятен булдыруны алыйк. Ул елларда Татарстан мәгариф системасындагы үзгәрешләр мөстәкыйль нәшрият тудыруны таләп итте. Татар телендә эшли торган уку йортларының артуы, дәреслекләр, күп сандагы уку әсбаплары басып чыгаруны мәҗбүр итте. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә дә дәреслекләр белән булышуны үз өстебезгә алдык. Татарстан китап нәшриятының мөмкинлекләре чикләнгән иде. Без мәгариф системасын тәэмин итәрлек аерым нәшрият булдыру өстендә эшли башладык. Матбугат министрлыгының элеккеге министры Ш.Ш. Хамматов безнең ниятне хуплап каршы алды. Кызганычка каршы, Ш.Ш. Хамматов бу вазифада озак эшли алмады. Бу урынга И.Г. Әхмәтҗанов килгәч, без, барлык каршылыкларны җиңеп, “Мәгариф” нәшриятын төзеп бетердек. Һәм бу нәшрият үзенә куелган бурычларны шактый еллар уңышлы башкарып килде...

Ислам Галиәхмәтовичның тагын бер яхшылыгын искә төшерәсем килә. Эш болай булды. Узган гасырның 90нчы еллары башы. Казан дәүләт университетында студент яшьләр өчен махсус газета оештырып йөриләр. Татар телендә нәшер ителәчәк бу газетага редактор итеп университетның журналистика факультетын әле генә тәмамлаган Рифат Фәттаховны сайлаганнар. Утырып эшләү өчен урыннары да юк, башка проблемалары да җитәрлек.

Яңа газетаның кирәклеге миндә шик уятмый. Әмма газетаның бурычларына укытучылар тормышын яктыртуны да кертәсе иде, дигән уй туды. Мин бу ниятем турында Рифат белән дә киңәштем. Ул риза булды. Шулай булгач, газета турында кайгыртучанлык та миңа кала бит инде. Мин аларга шартлар тудыру турында уйлый башладым һәм таптым да. Газета коллективы (аңа исемне “Мәгърифәт” дип бирдек) Бауман районының Галиәсгар Камал урамына урнашкан укыту-производство бинасында эшли башлады. Без аларны җиһазлар һәм телефон белән тәэмин иттек.

Бераздан редакция коллективы зурайды. Ике бүлмәгә генә сыймый башлады. Мин Ислам Галиәхмәтовичка киттем. Мәсьәләне аңлаттым. Һәр эшкә җаваплы карый торган кеше буларак, ул монда да эшне озакка сузмады. Чистай урамында төзелгән яңа биналарның берсендә – үзенең министрлыгына бирелгән мәйданның шактый өлешен “Мәгърифәт” газетасы-

на бирде. Алар бу бинада хәзер дә рәхәтләнеп эшләп яталар, Ислам Галиәхмәтовичка рәхмәт укыйлар!..

Ислам Галиәхмәтовичта алга карап фикер йөртү, олы бурычлар, максатлар куя белү, аларны җиренә җиткереп башкарып чыгу сәләте бар. Аның бу сыйфатлары яңа урынга – "Идел-Пресс" нәшрият-полиграфия комплексы" ачык акционерлык җәмгыятенә генераль директор булып килгәч тагын да калкурак күренде. Монда ул дөньядагы иң алдынгы технологияләрне кулланып, илдә иң күркәм-затлы китаплар, газета-журналлар һәм башка басмалар тудыручы коллектив туплады.

Аның зыялылыгы, нәфис сәнгатьне тирән аңлавы, тактлылыгы, кешеләргә хөрмәт белән каравы, таләпчәнлеге һәм коллективта яхшы психологик климат тудыра белү сыйфатлары хезмәтендә һәрвакыт уңай нәтиҗәләр һәм шәхси иҗат уңышлары китерә.

Карл Әхмәтов

Карл интеллигентлар гаиләсендә үскән. Шуңа күрәдер, аның күп нәрсәгә сәләте бар. Кайбер кеше аның сәләтлелеген педучилищеда укуы белән генә аңлатмакчы була. Янәсе, җырларга да, уен коралларында уйнарга да педучилищеда өйрәтәләр. Бусы да бардыр, ләкин алай дисәң, педучилищены тәмамлаучылар арасында да гомергә авызын ачып җырламаган, яки бер уен коралында да уйнамаган кешеләр дә бар. Карлга тумыштан вокаль мөмкинлекләре бирелгән. Мандолинада, баянда, пианинода уйный. Ә инде курайга килгәндә, ул аны профессиональ дәрәҗәдә башкара.

Мөслимдә эшләгәндә, укытучыларның август киңәшмәсе вакытында, укытучылар концертын кую традициясе бар иде. Мин район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгән елларда бу традиция тагын да көчәйде. Концертны оештыру өчен, алдан ук җаваплы кешеләр билгеләп куя идек. Алар арасында, гадәттә, Карл, аның абыйсы Спартак, Диксон Садретдинов була иде. Концерт программасында халык уен кораллары ансамбле дә чыгыш ясый иде. Бервакыт, чыгышка әзерләнү өчен, ансамбльдә катнашучыларны район Пионерлар йортына җибәрдек. Репетицияне шунда ясарга була. Анда мандолиналар, баяннар һәм башка уен кораллары да бар. "Боларның эшләре ничек бара икән?" – дип, шуны тикшерергә киттем. Күңелле генә уйнап утыралар. Шулчак бирегә район Пионерлар йорты директоры

Әхмәдулла Әхмәтгалиев килеп керде. Беренче эше итеп, ул уйнаучыларга үзенең канәгатьсезлеген белдерде:

– Бу нинди безобразие? Кем рөхсәте белән уен коралларына тотындыгыз? Аларның бит хуҗасы бар. Мандолинаның кылы өзелсә, кем җавап бирер?! Хәзер үк уйнауны туктатыгыз!

Әхмәтгалиевнең әмеренә ризасызлыгын белдереп, сүзгә Карл кушылды:

– Бар, кит, мешайть итеп йөрмә!

Карлның шулай өздереп әйтә торган гадәте бар иде.

Әхмәтгалиев, шактый кызып, үзенең таләбен кабатласа да, Карлның җавабы кыска булды: “Бар, кит!”.

Пионерлар йорты район мәгариф бүлегенә карый иде. Шуңа күрә Әхмәдулланы тынычландыру миңа калды. Шуннан соң уйнаучылар уңышлы гына эшләрен дәвам иттерделәр.

Карл башта Минзәлә педагогия училищесын, аннары Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлады. Укуын һәрвакыт яхшы укыды. Студент елларында Габдулла Тукай исемендәге стипендиягә дә лаек булды. Спорт белән дә ул уңышлы шөгыльләнде. Җиңел атлетикада ул көчле иде. Озынлыкка, биеклеккә сикерүдә, 100-200 метрлы дистанцияләргә йөгерүдә ул һәрвакыт алдынгы урыннарда булды.

Институтның соңгы курсында ул мединститут студенткасы Риммага өйләнде. Римма да – безнең районнныкы. Институттан соң алар Карамалыга эшкә кайттылар. Римма – шул авылда урнашкан больницаның баш врачы, Карл Күбәк урта мәктәбендә укытучы булып эшли башлады. Ике яшь белгеч больницаны да, мәктәпне дә җанландырып җибәрделәр. Белгечлекләре буенча тирән белемнәре булу өстенә, алар үзешчән сәнгатьтә дә күпьяклы сәләт ияләре иде. Карамалы авылы коллективының район үзәге – Мөслим сәхнәсендә куйган концертларында Римма һәм Карл Әхмәтовларның башкарган номерлары сыйфаты белән нык аерылып торды.

Бераздан Карл Мохатовичны Күбәк мәктәбенең директор ярдәмчесе (завуч) итеп тәкъдим иттеләр. Мәктәп тормышына яңалыклар кертү, укучыларның өлгерешен яхшырту, укытучыларның методик осталыгын күтәрү буенча ул нәтиҗәле эш башкарды – укытучылар, укучылар коллективының, ата-аналарның тирән ихтирамын казанды.

Әхмәтовларны эшкә район үзәгенә – Мөслимгә күчерүне аларның Карамалыда яшәгәндә һәм эшләгәндә куйган хезмәт-

ләрен район җитәкчелегенең тануы, дип аңларга кирәк. Монда Карл үзе башлаган эшне – Мөслим урта мәктәбе директоры ярдәмчесе вазифасын, ә Римма район үзәк больницасының баш врачы урынбасары хезмәтен башкарды. Шактый тәҗрибә туплап килгән белгечләр буларак, алар Мөслимдә дә тиз арада үз коллективларында ихтирамга лаек булдылар.

Мөслимдәге чыныгу Әхмәтовларга Чаллы шәһәрендә яңа җиңүләр алып килде. Карл Мохатовичның киңкырлы сәләте Чаллы шәһәренең культура бүлеген җитәкләгәндә тагын да тулырак ачылды. Сәләтле музыкант, вокал остасы, хореография, сәхнә сәнгатенең башка төрләрен тирән аңлаучы җитәкче ролендә ул яңа шәһәрнең культура үсешенә нигез ташларын ышанычлы салды, алдагы елларның уңышын хәл итте.

Ул еллардагы Чаллының Сабан туйлары күз алдыннан китми. Сабан туеның традицион төрләре сәнгать номерлары белән баетыла иде. Ике меңләп җырчыны берләштергән хор коллективы, йөзләгән музыкантны берләштергән оркестр, ансамбльләр чыгышы могҗиза булып кабул ителә иде.

Шәһәрнең 2 нче урта мәктәбе, аннары 12 нче урта мәктәп Карл Мохатович җитәкчелегендә милли мәгарифнең "карлыгачлар"ына әйләнде. Башка мәктәпләр, гимназияләр, лицейлар өчен тәҗрибә мәктәбе – юл башы булды.

Карлдагы кешелеклелек сыйфатлары ихлас ихтирамга лаек. Андагы кече күңеллелек, кешеләргә һәрвакыт ярдәм итәргә тырышу, бервакытта да күңелен төшермәү, оптимист булу, эшкә бирелгәнлек башкаларга да рухи көч бирә иде!..

Рафаэль Гарипов

Рафаэль белән без бер елны туганбыз. Безнең авылда безнең белән яшьтәшләр тагын икәү – Мөдәррис белән Марклен. Минем исемне гарәпчә "ирешүче", "кавышучы" мәгънәсендә дип аңлата иде Тамьян әби. Әби – мулла хатыны, абыстай – гарәпчә яхшы белгән, ахры.

Мөдәррис исеменең дә гарәп теленнән алынганлыгы сизелә – "хәлфә, укытучы" мәгънәсендә. Рафаэль – Европа илләреннән кергән исем. Ә Марклен исеме ул безнең ил халкының үткән гасырның 30 нчы елларында, революция, интернационализм идеяләре шаукымы белән хисләнгән чорда килеп чыккан – Маркс, Ленин сүзләреннән ясалган.

Мөдәррис белән без 7 нче классны тәмамлаганчы, бер класста, бер партада утырып укыдык, дус булдык. Марклен укырга

соңрак керде бугай – без бергә укымадык, авылның ике башында яшәгәч, аралашу да булмады.

Рафаэльне мин үземне белә башлаганнан бирле беләм. Ул да урамның безнең очында яши иде. Рафаэль әти-әнисен хәтерләми. Ул кечкенә чакта ук алар үлеп киткән. Ул әбисе белән кала. Бераздан әбисе дә үлеп китә. Рафаэльне әтисе ягыннан туганы Нәсихәттәй үзләренә ала. Нәсихәттәйнең ире Самат абзый сугышка киткәч, ишле гаиләдә яшәү шартлары үзгәргәндер, өскә кием табу яклары авырлашкандыр – Рафаэльне балалар йортына бирәләр. Сугыш бетеп, Самат абзый – Рафаэльнең жизнәсе дә кайткач, Рафаэльне авылга алып кайттылар. Без тагын очраша башладык, бер-беребезгә якынлаштык. Үзебезнең мон-зарларны уртаклаша идек. Ә моң-зарлар күп иде...

Нәсихәттәйләр гаиләсендә – 5 кыз, Рафаэль – алтынчысы. Авыл кешесенең эше бетеп тормый. Яздан ук бәрәңге бакчасында башланган эш көзгә кадәр бара. Малларны карыйсы, ашатасы, эчертәсе, асларын чистартасы, кыш буе кар көрисе... Барлык эшләр авыл баласы өстендә. Урман ераграк булгач, безнең авыл халкының тагын бер мәшәкате бар. Безнең авылда кыш буе җыелган тиресне, су белән болгатып таптый-таптый, үзләндереп, кирпеч итеп сугалар иде. Ул кирпечләрне әйләндерә-әйләндерә киптереп, өеп куясың. Кыш буе шуны ягып, өй җылытыла, мунча ягыла. Бу эшләрнең үзәгендә Рафаэль булыр иде. Мондый хезмәтләр безнең гаиләдә дә башкарыла. Ләкин бу эшләрне безнең барлык гаилә членнары бергәләп эшли.

Рафаэльнең җизнәсе Самат абзый гомер-гомергә колхозда җитәкчелек тирәсендә булды. Председатель үк булмады ул. Әмма һәрвакыт председатель тирәсендәрәк йөрде. Нәсихәттәй һәм аның 5 кызының да бәрәңге бакчасында да, башка эшләрдә дә эшләгәннәрен күргәнем булмады. Барлык эшләр Рафаэль өстендә булды. Авыл кешесенең яңа эш көне иртән иртүк малларны көтүгә чыгару белән башлана. Көтүче авылның бер башыннан малларны җыеп, авылның икенче башына куып алып китә. Һәм алар авылдан читтә урнашкан көтүлеккә юнәләләр. Көтүлек – авылдан 3-4 км ераклыкта. Һәркем үзенең малларын капка аша көтүчегә тапшыра. Шушы вакытта җитешә алмасаң, малларың абзарыңда кала, сыерың да савылмыйча кала. Хуҗабикәнең иртүк тора алмаган чаклары булгандыр – Рафаэльнең малларын көтү йөри торган җиргә кадәр йөгерткәнен күргәли идек.

Сугыштан соңгы еллар бик авыр булды. Колхозчыга хезмәт хакы түләнми. Ул еллар буе бушка эшли. Көз көне икмәкләрне игеп алгач, дәүләткә тапшырганнан соң калган икмәкнең беразын колхозчыларга бирәләр. Ләкин ул икмәк ел әйләнәсенә җитми. Язга чыгу белән халык төрле үләннәр белән туклана башлый. Кузгалак, юа, балтырган, кәҗә сакалы, әтник, күгәрчен ипие (клевер), алабута, чөгендер яфрагы һ.б. үләннәр булыр иде кешенең ризыгы.

Арыш өлгерә башлагач, басуга китәбез. Арыш башагын уалап, аны өрә-өрә чүбеннән аерабыз. Чиста бөртекләрне кесәгә салабыз. Бөртекләрне бер ашлык җыйгач, кайтып китәбез. Өйдә арыш бөртекләреннән ярма ясала. Ярма ясау болай башкарыла: башта кайнар табага салып арыш киптерелә. Кипкән арыш бөртекләре куна тактасына таратылып тигезләп җәелә. Түгәрәк шешәне көч куеп арыш бөртекләре өстеннән тәгәрәткәч, бөртекләр изелә, ярма барлыкка килә. Шул ярмадан ашап туймаслык өйрә барлыкка килә.

Рафаэль да арыш басуына безнең белән бара. Безнең кебек ул арыш башакларын басу читеннән генә җыймый, басуның эченә үк кереп китә. Безнең ният болайрак: басу каравылчысымы, бригадирмы, колхоз рәисеме килеп чыга калса, без авылга чабабыз, качабыз. Рафаэль алай итми. Ул басуның эченә үк кереп утыра. Биек арыш сабаклары арасыннан аны күрү мөмкин дә түгел. Ул кабаланмыйча, анда-монда каранмыйча, үз эшен эшли: арыш башакларын ике куллап уалап, чиста бөртекләр җыя. Бөртекләрне кечкенә капчыгына салып бара. Ул бу эшкә 1-2 кг икмәк сыешлы кечкенә капчык белән килә. “Капчык уңайлы, – ди ул. – Андый-мондый хәлләр килеп чыкса, капчыкны ташлап качып була. Арышны кесәгә тутырсаң, каравылчы аны бик тиз тентеп таба!”

Шулайдыр шул. Ул елларда халыкны тентү гадәте бар иде. Колхозчылар эштән кайтканда каравылчы һәрбер колхозчыны тентү аша уздыра иде. Кесәсенә салган 200-300 г икмәк өчен бишәр елга төрмәгә ябылган кешеләр булды ул елларда.

...Рафаэльләрнең йорты – авыл башыннан беренче.

Мин Минзәлә педучилищесында укыган чорда авылга кайтканда машинадан Тегермәнлек авылында төшеп калам. Тегермәнлектән үзебезнең авылга җәяү кайтам. Авыл башына җитүгә, бәрәңге бакчаларында Рафаэльне күрәм. Ул йөгереп минем каршыга чыга. Без бер-беребезне сагынганбыз. Мин – авыл хәлләре белән, Рафаэль Минзәләдәге минем уку шартлары белән кызыксына. Бәрәңге бакчасындагы эшен ташлап, минем

белән сөйләшеп торганын күрәләр Рафаэльнең. “Кичтән күрешербез, парин!” – дип, ул эшенә йөгереп китеп бара.

Рафаэльнең Казанда да әнисе ягыннан туганы – Бибиәсма апа бар иде. 7 нче классны тәмамлагач, ул шунда китте. Бибиәсма апа тәкъдиме белән, Рафаэль Казанда профессиональ-техник уку йортына керә, слесарь-сантехник хезмәтен үзләштерә. Эшкә аны Чабаксар шәһәренә җибәрәләр. Күпмедер эшләгәч, ул авылга кайтты. Авылда Сабан туе чоры иде. Элегрәк Сабан туен барлык авылларда да бер көнне уздырмыйлар иде. Һәр авыл Сабан туен үткәрү вакытын үзенчә билгеләгән. Сабан туйлары якын-тирәдә бер атнага сузыла. Рафаэль белән без дә берничә авылда булдык. Рафаэль инде ныгыган. Аңа 16-17 яшьләр тирәсе. Көрәшеп тә, аркан тартышып та ул бүләкләрне күп җыйды. Сабан туе батыры булырга әле аңа иртәрәк иде. Әтисен көрәшче булган, дип сөйлиләр иде. Шулайдыр. Әтисенең туганнан туганы Зариф абый безнең авылда да, күрше авылларда да күп тапкырлар батыр калды.

Безнең авыл көрәшчеләр авылы түгел. Сугыштан соңгы елларда Сабантуйларында Латыйпов Зәки абзый көрәшә иде, 50 нче елларда Зариф абый һәм Мулланур абый көрәште. 70 нче елларда мәйданга Кадыйров Минсалих чыкты. Минзәлә зоотехникумында укыганда алган физик әзерлеген ныгытып, ул район күләмендә дә уңышларга иреште, район батыры булды.

Күрше авылларда көрәшчеләр саллы иде. Тегермәнлектән һәм Түбән Табыннан шофер Задә абый, Нәҗмиев Мисхәт, Шамсиев Газиз, Рахманов Тавис, Фәрхетдинов Мөнирләр күп еллар авылда да, район Сабантуйларында да кемгә дә бил бирмәделәр!

Рафаэльдә дә шул традицияләрне дәвам итәрлек мөмкинлек бар иде. Көрәшчеләр нәселеннән иде ул. Әмма тормыш аны икенче юлдан алып китте. Армиядән ул туры Казанга кайтты. Сантехник булып эшкә урнашты, эшчеләр тулай торагында яшәде. Казан дәүләт педагогия институты студенты буларак, мин Рафаэль белән еш аралышып тордым. Аннары Рафаэль Казан кызы Рәидәгә өйләнеп җибәрде, квартира алды. Тверь урамындагы ул фатир безнең өчен иң якын урынга әйләнде. Казаннан китеп Мөслимдә эшләгәндә дә, Казанга һәр килүемдә дә Рафаэльләргә кагылып йөрдем. Рәидә дә киң күңелле булып чыкты, алар һәрвакыт ачык йөз белән каршы алалар иде. Рәидә азык-төлек кибетендә сатучы булып эшләде. Узган гасырдагы азык-төлеккә (бигрәк тә, ит, май, колбаса, сыр, шикәр)

кытлык заманда, аның безгә рәхим-шәфкате зур булды. Ул еллар өчен без Рәидәгә гомер буе рәхмәтле!

Рафаэльнең дә якын дусты Равил өйләнгәч, аның гаиләсен дә алар үзләренең бер бүлмәле фатирларына сыендырдылар. Ике студент – Равил белән Альфира, яшь балалары Ильдар, Рафаэльләрнең да кызлары бар – Илиза... 6 кешелек ике гаиләнең бер бүлмәле фатирда ничек торуын күз алдына китерәсездер, мөгаен.

Андагы санап бетергесез мәшәкатьләр, ике яшь баланың "тырыша-тырыша" елаулары, финанс кыенлыклары, балаларга сөт җиткерә алмау кебек мәшәкатьләрне күз алдына китерсәң, әлеге ике яшь гаиләнең бу вакыттагы тормышын аңлау авыр түгел. Алар бу авырлыкларга түзделәр. Әлбәттә, болар Рафаэль белән Рәидәнең чын кешелеклелеге, киң күңеллелеге аркасында булды.

Бервакыт Татарстан Эчке эшләр министрлыгы, үзләрендә эшләү өчен, кадрлар җыя башлады. Рафаэль да шул системага эләкте. Монда урнашу белән ул, профессиональ белемгә ия булу өчен, Алабугадагы махсус училищега укырга керде, анда әйбәт укып чыгып, лейтенант булды.

Һәр эшне җиренә җиткереп эшләүче гадел милиция хезмәткәре буларак, аңа эшнең җаваплырагын бирә тордылар. Намуслы хезмәт үз бәясен алды, ул капитан дәрәҗәсенә күтәрелде. Алга таба аңа эшнең тагын да катлаулырагын тәкъдим иттеләр. Моның өчен аңа укуын алга таба дәвам итәргә кирәк иде. Һәм ул Эчке эшләр министрлыгы өчен югары белемле белгечләр әзерләүче академиядә читтән торып укый башлады. Башлаган эш – беткән эш, дигәндәй, академияне дә уңышлы гына тәмамлап куйды Рафаэль. Шактый тәнәфестән соң, югары уку йортында укуы җиңел булмагандыр. Ләкин Рафаэльнең авырлыклар алдында җиңелеп кала торган гадәте юк. Ул еллардагы уку вакытындагы мәшәкатьләрне беребезгә дә сиздермәде.

Югары белемле милиция хезмәткәренә эшнең тагын да җаваплырагын бирделәр, майор дәрәҗәсенә күтәрделәр!..

Без һаман аралашып яшәдек, бәйрәмнәрне, туган көннәрен бергә уздырдык.

Рафаэль һәм Рәидәнең, лаеклы ялга чыккач, авылда яшиселәре килде. Хезмәт сөюче кешеләр буларак, алар авылда йорт салдылар. Хәзерге көндә авыл мәшәкатьләре белән яшиләр. Бәхетләрен үзләре эзләп тапкан чын шәхесләр алар!

Адаш

Минзәлә педагогия училищесына кабул итү без укырга кергән елларда үзенчәлекле иде. 1951 елда өстән төшерелгән план буенча, 1 курска 75 кеше алу каралган. Болар 25әр кешелек өч төркемгә бүленеп укыячак. Әмма 1 нче сентябрьдә һәр төркемдә 45ләп укучы иде. Болар, нигездә, керү имтиханнарын уңышлы тапшыручылар. Алар арасында минем кебек җидееллык мәктәпне "5"ле билгеләренә генә тәмамлап, имтихансыз гына кабул ителгәннәр дә бар иде. Ике атна буе безнең белән дәресләр уздырдылар, аннары татар һәм рус телләреннән диктант яздырдылар һәм математикадан контроль эш эшләтеп карадылар. Уңай билге ала алмаганнарны кайтарып җибәрделәр. Алар арасында Актаныш районыннан – Мәгъсүм, Фәһим, Минзәлә районыннан – Яманай, Мөслим районы, Бикмәч авылыннан Мөхәммәт Николаев бар иде. Шул кыска гына вакыт эчендә алар белән танышып, дуслашып өлгергән идек. Ямансулап калдым.

Безнең төркемдә малайлардан (безне егетләр дип әйтергә әле иртәрәк) Васил Сәрвәров (Актаныш районы), Мисбах Хуҗин, Нәҗәх Исмәгыйлев, Вагыйз Шагалиев, Камил Гыйльметдинов (Минзәлә), Мидхәт Исламов, Нургаян Җәмилев (Красный Бор) һәм мин (Мөслим) идек. Бер елдан соң армиядән кайтып, безгә Сәетҗан Фәттахов килеп кушылды.

Училищены тәмамлаганчы без бергә булдык, дуслаштык. Васил Сәрвәров белән без беренче курстан ук якынаеп киттек. Роза Люксембург урамында безнең фатирлар да күрше булды. Ул үзенең өлкән курста укый торган абыйсы Азат белән, мин үземнең Сәвия апа белән яшәдек ул фатирларда.

Сугыштан соңгы еллар халыкның бик фәкыйрь еллары иде. Без Минзәләгә чабата киеп килдек. Бераздан аны очсызлы туфлигә алыштырдык. Өскә кияргә костюмны күргән дә юк, өскә кияргә бер күлмәк бар да, телогрейка бар. Бер момент истә калган. Физкультура дәресе бара. Укытучыбыз Иван Павлович Остроумов безне биеклеккә сикерүнең яңа алымына өйрәтә. Киртә аша сикерүне чиратлап башкарабыз. Менә сикерергә Адашның чираты (без бер-беребезгә шулай, дип дәшә идек). Ул матур гына йөгереп килде дә, киртә аша чыкканда ялгышып китте, идәнгә егылганда күлмәге ертылды. Ул вакытларда әле беребездә дә майкалар юк. Адашның да ертык күлмәк аша шәрә аркасы ялтырап тора. Кеше күп вакыт гаепне кешедән күрә бит ул, үзеннән эзләми. Адаш та шулай булды.

Башта ул күлмәген кызганып елап алды, аннары укытучыны гаепләргә тотынды:

— Мондый сикертү буламыни? Кемнең шулай сикергәнен күргәнең бар? Мондый сикерүне мин барыбер өйрәнә алмыйм. Күлмәгем әрәм булды. Дәресләргә ничек йөрим инде мин хәзер? Күлмәгем ертылганчы, берәр җирем генә сынган булса?! — дип зарланды.

Әлбәттә, физкультура укытучысының монда гаебе юк. Биеклеккә сикерүнең бу алымы белән Иван Павлович Минзәлә Сабантуйларында ел саен җиңүче була иде. 30-40 елдан соң, биеклеккә сикерүнең бу алымын камилләштереп, Америка Кушма Штатлары спортчысы Фосбюри дөнья чемпионы булды. Хәзерге вакытта спортчылар биеклеккә шушы алым белән генә сикерәләр. Кызганыч, дөньяда Фосбюрины беләләр, ә сикерүнең бу алымын беренче булып уйлап тапкан, аны укучыларына өйрәткән Минзәлә педучилищесының физкультура укытучысы Иван Павлович Остроумовны, бездән башка, беркем дә белми.

Адашның теге вакыттагы хәләтен аңларга була. Аның да күлмәге берәү генә булгандыр. Арка ягы буеннан-буена умырылып чыккан күлмәк кияргә яраксыз иде инде. Ә дәресләргә йөрергә кирәк. Педучилищеда без дәресләрне калдырмый идек.

Күлмәкне эшкә кертүләрен сорап, без кызларга мөрәҗәгать иттек. Аларның күбесе авыл кызлары иде. Аларның ямаулык салу практикасы булгандыр. Кызлар күлмәкне киярлек хәлгә китереп бирделәр.

Педучилищены тәмамлагач, без бер ел эшләп алдык. Адаш — Минзәлә районының Калмыя авылында, мин — Мөслим районының Ташлыяр җидееллык мәктәбендә. Аннары без Казан дәүләт педагогия институтына килеп кердек. Адаш — химия-биология, мин — физика-математика белгечлегенә.

Студент елларында без үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә актив шөгыльләндек. Башта без Республика укытучылар йортына йөрдек. Анда Хәбиб абыйның драма һәм эстрада түгәрәкләренә язылдык. Бер пәрдәлек пьесалар һәм концерт номерлары әзерләп, концертлар куя идек. Хәбиб абый безне концерт белән Казан тирәсе авылларына да алып чыга иде. Ул концертларның безгә файдасы да тия иде. Концерттан кергән акчадан безгә дә өлеш чыга. Стипендиягә генә яшәгән студент өчен бу бик ярап куя.

Берзаман мин Бауман урамында урнашкан "Спартак" аяк киемнәре фабрикасы клубында эшли торган Сара Садыйкова хорына йөри башладым. Бераздан бу хорга Адаш белән икәү йөрдек. Үзешчән сәнгать түгәрәкләренә йөрү, осталыкны арттыру, драма түгәрәгендә чарлану нәтиҗәсе булгандыр, Адаш белән мине яңа оешкан башланган Халык театрына да алдылар. Татарстанның халык артисты, күренекле режиссер Хәким Сәлимҗанов җитәкчелегендә эшләячәк бу театрга булачак артистларны бөтен Казан клубларыннан сайладылар. Ул елларда Укытучылар, Медицина һәм Сәүдә хезмәткәрләре йортлары, "Татваленки", Маяковский исемендәге клублар һәм Ленин Сарае бик актив эшләде. Без йөргән Горький исемендәге клубта да уннан артык түгәрәк эшли иде. Яңа ачылачак драма халык театрына кандидатлар сайлау буенча өч комиссия эшләде. Хәким Сәлимҗанов һәм Гали Ильясов җитәкчелегендәге режиссерлар безнең тел мөмкинлекләрен, Җәләл Садриҗиһанов һәм Разия Яруллиналар музыкаль-вокал мөмкинлекләрне, балетмейстер Али Гыйззәтуллин бригадасы биюгә сәләтне тикшерделәр. Безнең әзерлек дәрәҗәсе алар таләпләренә туры килгәндер. Адаш белән мине булачак театрга алдылар. "Мехкомбинат" клубына репетицияләргә йөри башладык. Кәрим Тинчуринның "Кандыр буе" драмасын куярга җыенабыз. Салих Сәйдәшевнең гүзәл музыкасы пьесаның хор белән, ялгыз җырлау, бию мөмкинлекләрен шулкадәр арттыра, спектакль һәрвакыт алкышлар белән бара. Без бу әсәрне Казанның барлык клубларында да, хәтта Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында да куеп чыктык.

Спектакль-драмадагы тегермәнче карт башкаруында "Кандыр буе" җыры белән башлана. Бу җыр миңа да бик ошый иде. Хәким агадан бу рольне миңа бирүен сорадым.

— Тегермәнче ролен карт кеше башкарырга тиеш. Мин бу рольгә опера театрында җырлап пенсиягә чыккан Сәлимовны билгеләдем. Җырлы роль сиңа да бар. Син монтер ролен башкарырсың. "Монтерлар җырын" рәхәтләнеп җырларсың, — диде ул.

Әсхәт Мифтахов белән без бу спектакльдә монтерлар идек. Адаш Укытучылар йортында драма түгәрәгендә Хәбиб абый җитәкчелегендә шактый тәҗрибә туплаган иде. Әлеге спектакльдә Хәким ага аңа төп рольне — колхоз рәисе Акбирдинне бирде. Ул бу рольне бөтен барлыгын биреп башкарды.

Без укыган елларда колхозчыларга акчалата хезмәт хакы түләү юк иде. Шуңа күрә, без өйдән ярдәм алмыйча укыдык. Материаль хәлне ныгыту өчен төрле чаралар күрә идек:

мәктәпләрдә лаборант булып эшләү, берничә сәгать дәрес алып бару, вагоннардан күмер, цемент бушату, елга портында баржалардан утын бушату һ. б. Каникул вакытларында концерт бригадалары белән авылларга чыгабыз. Бер елны кышкы каникулда Рафаэль Ильясов безне Чүпрәле районына алып барды. Рафаэль, Хәдичә Гыйниятова, Адаш һәм мин концертның төп башкаручылары идек. Икенче елны бу бригаданы мин Мөслим районына алып кайттым. Партия райкомының пропаганда бүлеге мөдире Нурмый Закирович Исмәгыйлев ярдәме белән, без районда 30га якын концерт куйдык.

Соңгы концертны үзебезнең авылда — Югары Табында куйдык. Икенче көнне, ай буе авыр хезмәттән соң, ял иттек, Ык буенда кызындык.

Шул көнне булган бер вакыйга истә калган. Кызлар кер юуны оештырдылар. Юасы әйберләрне кызларга бирдек. Адаш ай буе шактый йончылган чалбарын да бирде юарга. Юылган керләр кояш астында киптеләр. Адаш үзенең чалбарын үтүкли башлады. Ул елларда әле лавсан дигән материя юк иде. Натураль җепләрдән эшләнгән материядән тегелгән чалбар, юып киптергәннән соң, бөгәрләнеп беткән. Адаш шул чалбарны тиешле формага китереп, "эзләре"н чыгарганчы, нык кына тырышты, сүгенеп тә алды. Аның бу эше кимендә ике сәгатькә баргандыр. Адаш иркен сулап куйды. Йөзендә анда сирәк була торган елмаю билгеләре күренде.

Шул арада әнкәй килеп, Адашка рәхмәт сүзләре җиткерә башлады.

— Картның чалбарын кичә юып элгән идем. Син шуны үтүкләп тә куйгансың. Гомергә чалбар үтүкләргә яратмадым. Малайлар кайткач үтүкләрмен, дип тора идем. Рәхмәт инде сиңа, гомергә рәхәт яшә, кулың-аягың сызлаусыз булсын! — диде ул.

Чыннан да, шулай булган икән шул. Адаш минем әтинең юып куелган чалбарын үтүкләгән. Туры килүен кара син аның, төсе дә, материясе дә бер үк икән чалбарларның...

Адаш нишләргә дә белмәде... Болай да тынгысыз кеше, кәефе бөтенләй кырылды. "Миңа бөтен нәрсә гел каршы килә, гомергә шулай булды," — дип үртәләнде. Мине дә гаепләде: "Адаш минем интеккәнне күрде ул. Күрсә дә, атасының чалбарын үтүкләтте. Оныта торган булмады инде бу!"

Монда минем гаеп юк иде. Әтинең чалбары юылганны да мин белмәдем. Адаш белән очрашканда, бу вакыйганы искә төшереп көлешәбез.

Институтны тәмамлагач, Адаш үзләренә, Актаныш районына кайтып китте. Сара апа хорына бергә йөргән Миңсафага өйләнде. Ике егет үстерделәр. Адаш химия-биология фәннәреннән укытты, мәктәпнең завучы булып эшләде. Минем уйлавымча, ул бик көчле укытучы һәм завуч булгандыр. Аның укучыларының районда уздырылган олимпиадаларда уңыш казанганын ишеткәнем бар иде. Үзешчән сәнгатьтә алган сәләтләрен дә ул нәтиҗәле кулланды. Ул эшләгән Куян урта мәктәбендә Адаш җитәкләгән драма, хореография, хор түгәрәкләре гөрләп торды. Адаш шулай ук туристлык эшенә бик хирыс иде. Бер елны ул укучылары белән Мөслимгә килеп чыкты. Мөслимдә кунып, велосипедлар белән Башкортстан районнарына юнәлделәр.

Шулай матур гына яшәп ятканда, Куян авылындагы колхозны күрше колхозга кушалар. Берләштерелгән колхозга рәис итеп күрше колхозныкын куялар. Урта мәктәпне дә Куян авылыннан күрше авылга күчерәләр. Мәктәпне үзләренең авылында калдырырга шактый тырышлык куя Адаш. Әмма да ләкин колхоз рәисен өстәгеләр яклап чыга.

Мәктәп өчен шул авылда яңа бина төзелү дә мәсьәләне алар файдасына хәл итә.

Бу үзгәрешләргә протест йөзеннән, Адаш күрше авылга эшкә бармый. Укытучылык эшен бөтенләй ташлый. Актаныш районы сәләтле укытучысын, оста җитәкчесен югалта. Адаш белән үзара аңлашып, чын күңелдән сөйләшүче да булмады кебек. Бик күп балага ул тирән белем һәм күнекмәләр, ә укытучыларга файдалы киңәшләр бирә ала иде. Ул вакытта аңа 45 яшь тә юк иде әле.

Сәләтле кеше һәрьяклап булган була. Ул балта остасы, столяр булып китте. Белүемчә, хәзер дә ул шушы һөнәрен дәвам итә... Рәхмәт Адашка, гомергә бәхетле яшәсен!..

Марсель Вәлитов

Институттан соң, Мөслимдә эшли башлауга, күпкырлы күңелле тормыш башланды. Мөслим мәктәбендә физкультура укытучылары Дофак Фәттахов, Рәис Назаров, математика укытучысы Фаил Ягудин, җыр-музыка укытучысы Фәнис Гыйльметдинов, пионервожатый Әзһәт Баһауовлар белән еш аралашабыз. Өйләнмәгән, ялгыз чак, фатир да юк. Садовая урамында Әминә апаларда Әзһәт белән торып алдык. Аннары шул ук урамда яшәүче Рафаэль Әхмәтовларда Фәнис белән яшәдек.

Рафаэль белән клубта таныштык. Ул да җырга мөкиббән иде. Концертларда бергә җырлыйбыз.

Клубта эшләүче Котдус Хөснуллин, Гаяз Абзаловлар белән дә дуслашып киттем. Котдус миңа күптән таныш. Ташлыяр мәктәбендә эшләгәндә, мин аны 7нче класста укыткан идем. Алабуга культура-агарту училищесын тәмамлап, хәзер ул да Мөслимгә эшкә кайткан. Гаязның профессиональ белеме юк. Ләкин Ходай аңа илаһи табигый сәләт биргән. Музыкаль һәм вокал гыйлеменә белгечләр кул астында тәрбияләнсә, аннан, һичшиксез, олы җырчы чыгар иде.

Аралашкан кешеләр болар гына түгел әле. Район газетасында эшләүче Рафис Измайлов, район комсомол комитетының беренче секретаре Марсель Вәлитов, икенче секретарь Данил Хиялиев, район "Сельхозтехника"сы инженеры Минтимер Шәймиев, район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары Павел Иванов, күршедәге сигезьеллык мәктәп директоры Азат Ганиевләр белән еш очрашабыз. Клубка бергә чыгабыз, бәйрәмнәрне бергә уздырабыз. Боларны инде чын дуслар, диярга була.

Марсель армия хезмәтенә беренче булып китте. Аны озатыр алдыннан җыелып чәйләп алдык. Шулай чәй эчеп утырганда, беребез әйтеп куйды:

– Мондый көнне бераз "тотып" куйсаң да ярар иде дә, берәрегезнең запасы юкмы соң?

Беребезнең дә запасы юк иде шул. Авыл халкын тәрбияләү чарасы булдымы, әллә башка сәбәбе булдымы, вакыт-вакыт авыл кибетләрендә эчемлек сатуны туктатып тору гадәте бар иде хөкүмәтнең. Шунда минем башка бер уй килде. Физика кабинетына, тәҗрибәләр ясау өчен, спирт урынына динатурат кайтаралар иде. Спиртовкага салып тәҗрибәләр ясаганда шуны яндырабыз. Мәктәпнең завхозы Антипов физика кабинеты лаборанты Рәйсә апа кырына кергәләп йөри, шкаф артында гына Рәйсә апа тегенә динатурат салып бирә. Антиповка бик ошый.

Бу турыда мин иптәшләргә әйттем.... "Әллә шуны тотып карыйк микән? Антиповка берни дә булганы юк," – дидем. Риза булдылар. Рафис белән тиз генә мәктәпкә барып кайттык. Шәмәхә төстәге бу сыеклыкны эчеп карарга беребезнең дә йөрәге җитми. Мамык аркылы уздырып чистартырга кирәк моны, дигән тәкъдим керде. Мамык аша да, күмер аша да уздырып карадык, төсе үзгәрмәде теге әйбернең. Миңа ул нәрсәне яңадан физика кабинетына илтеп куярга туры килде.

Марсельгә, бер ел хезмәт иткәч, 10 көнлек ял бирделәр. Ул Мөслимгә кайтты. Аның белән матур гына йөрибез. Минем туган көн якынлаша, март ае. Иптәшләрнең шушы уңайдан бергә җыелып утырып аласы килә. Бу фикерне фатир хуҗасы Миңнежамал апага да әйттек. Ул каршы килмәде. Ләкин болай диде: "Безнең бу бүлмә бик тар инде, иркенләп утыра алмассыз. Утын тапсагыз, теге олы якны җылытыр идем. Анда теләгәнчә утырыр идегез."

Без торган йортның олы бүлмәсе, утын экономияләү максатыннан, кыш көне ябып куела иде. Авыл укытучысы буларак миңа бирелгән бер машина утын фатирның кечкенә бүлмәсен җылытырга да җитәр-җитмәс кенә була иде.

Утын табу турында уйлап йөри башладым. Яз башында урманга барып утын кисәргә барырга теләүче күренми.

Беркөнне Марсель белән кинодан соң урамда йөрибез. Урамыбызда бездән ерак түгел генә милиция идарәсе йорты бар. Идарә каршында күп итеп каен бүрәнәләре өеп куелган. Марсельнең күзе шул бүрәнәләргә төште.

– Син әллә кайлардан утын эзләп йөрисең, әнә бит синең өчен утынны кайтарып өйгәннәр, – диде ул.

Утын өеме янына киттек. Бүрәнәнең ике башыннан тотып, күтәреп карыйбыз. Чи каен җиңел түгел, тырышсаң, күтәрергә була. Ләкин бүрәнәне күтәреп йөгерү турында сүз дә булырга мөмкин түгел, әкрен генә кайта алсаң да ярый әле. Безнең фатирга кадәр 100 метрдан артык ара бар. Бүрәнәне күтәреп барганда милиционер килеп чыкса, яки урамда берәрсе очрап: "Каян алдыгыз бу бүрәнәне?" – дип сораса, нишләрбез?! Тотсалар, район комсомол комитетының элеккеге беренче секретаре белән Мөслим урта мәктәбенең физика укытучысы милициянең утынын урлаганда тотылганнар, дигән сүз китә инде.

"Бу ниятне ташлыйк инде без", – дидек тә, китеп бардык. Туган көнне кечкенә бүлмәдә уздырдык.

Марсель Галиәкбәр улы шактый еллар инде Профсоюзларның Үзәк комитетында, җаваплы урында эшли. Мәскәүгә барган саен, шушы вакыйганы искә төшереп көлешәбез...

Хәләф Шәмсетдинов

Чыгышы белән Метрәй авылыннан ул. Озак еллар Мөслим партия райкомының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире булып эшләде. Кайвакыт кеше хезмәт урынындагы вазифасы-

на туры килми. Ул кешенең йә шул урында эшләрлек шәхси сыйфатлары яки профессиональ әзерлеге житми; яки бу хезмәткә аның күңеле ятмый, эшен исә үзен мәҗбүриләп кенә башкара.

Хәләф Мөхетдинович үз урынындагы кеше иде. Ул – югары белемле педагог. Хезмәт юлын география укытучысы булып башлаган, аннары партия райкомы инструкторы һәм райкомның бүлек мөдире булган. Эшен бик белеп һәм теләп башкара иде. Ул – кече күңелле, ярдәмчел. Мактануны, массаюны белми. Кызык сүзләр, анекдотлар сөйләргә дә ярата. Анекдотларны, ишеткән берсен, блокнотына язып бара һәм мөмкинлек булган саен аларны кешеләргә сөйләргә тырыша. Һаман сөйли торгач, ул аның күңеленә дә кереп кала.

Хәләф Мөхетдинович оста оештыручы да иде. Аның бу сыйфаты, Мөслим районын бетереп, Сарман районына кушкач аеруча сизелде. Район үзәгендә күпләгән оешмалар бетерелде, парткабинет кына калды.

Аның мөдире – Х.М.Шәмсетдинов, ә хезмәткәрләре А.Н. Оленин белән Т.М. Галиев булды.

Х.М. Шәмсетдинов элекке район үзәгендә агитация-пропаганда эшен бөтен тулылыгы белән алып барды, торле темаларга лекцияләр, концертлар, спектакльләр оештырды.

Сарманга да концертлар белән бара идек. Бер концерттан соң әйткән сүзләре истә калган: "Концерт әйбәт чыкты, булдырдыгыз, сарманлыларга юньле концерт куеп күрсәттегез, рәхмәт барыгызга да! Сез кунып кайтырсыз инде, мин районны Чухнинга гына калдырып килгән идем, мин кайтып китәм, минсез тарала күрмәсен район!" – диде ул. Бу сүзләрдә уенычыны бергә иде. Ә Чухнин элекке районның җир бүлеге хезмәткәре иде.

Мөслимдә билгеле кеше булгач, Хәләфнең һәр әйткән сүзе халык арасында тарала иде. Беркөнне универмагка килеп керә бу. Карый, галстук саталар. Галстугы да гадәти түгел, синтетик җепләрдән үрелгән. Аласы килә моның бу галстукны. Сатучыдан сорый:

– Тәүхидә апа, миңа да бер галстук бир әле!

– Галстук күкәйгә бит, Хәләф Мөхетдинович!

– И, булмады инде болай булгач. Миңа муенга иде ул, күкәйгә түгел!..

Безнең якта "тавык йомыркасы" дип түгел, "күкәй" дип сөйләшү гадәткә кергән. Сатучы белән Хәләф арасында сөйләшүне дә магазиндагы халык ике мәгънәдә аңлаган.

1965 нче елның 1 нче гыйнварыннан Мөслим районы яңадан торгызылды. Районнарны кушу, эреләндерү политикасының хата булуына төшенделәр. Бу идеянең уңай яклары да булгандыр. Әйтик, һәр райондагы күп санлы һәм төрле дәрәҗәдәге оешмаларда йөзләгән җитәкчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең кыскаруы. Болар бюджет чыгымнарын экономияләргә булышкандыр. Әмма бу елларда мондый берләшү өчен шартлар тудырылмаган иде әле. Юллар мәсьәләсен генә алыйк. Асфальт юллар турында сөйлисе дә юк, шоссе юллар да бик сирәк урыннарда гына. Сарманга берәр йомыш белән яки җыелышка барырга туры килсә (ә мондый вакытлар һәрвакыт булып тора), ерак урнашкан авыллардан трактор белән Мөслимгә килергә бер көн кирәк. Мөслимдә төн үткәреп, ул икенче көнне Сарманга барып куна. Өченче көнне җыелышта була. Тагын Сарманда куна. Шулай итеп, ул авылына 5 көннән соң гына кайтып җитә. Ә 5 көндә бу кешенең күпме эше кала...

Районнарны кире кайтарганда бу факторны да истә тотканнардыр.

Районның яңадан кайтуы халыкның күңелен күтәреп җибәрде. Хәләф Мөхетдинович та җиң сызганып эшкә керешге. Клуб, оешма йортлары яңача бизәлде. Бу эштә Х.М. Шәмсетдинов район художнигы Кузьма Иванов иҗатыннан уңышлы файдаланды. Яңача дизайн эшләренә дә сәләте булган әлеге рәссам, нәрсә генә ясаса да, башкарган һәр эше көлеп тора иде.

Урамнар эчтәлеге белән дә, башкарылу стиле белән дә яңача булган плакатлар белән бизәлде. Плакатлар дигәннән, бер көнне Мөслимдә гарасат купты. Зур тизлек белән үткән давыл агачларны сындырды, түбәләрне куптарды. “Давыл май заводының түбәсен алып аткан!” – дигән хәбәр таралды. Бу хәбәрне Хәләфкә дә җиткерәләр. Ул: “Май заводының түбәсен ябучы булыр, менә минем плакатлар нишләде икән?!” – дип, үтә борчылып әйткән, имеш.

Шулай әйтергә урыны да бар. Аның кул астында физик эш башкарырлык бер генә хезмәткәр дә юк бит.

Бервакыт Хәләф Мөхетдинович эш белән Казанга китә. Киткәндә хатыны Альбинага әйтә: “Казанга китәм, 3 көнлек семинарга чакыралар”. Альбина больницада медицина сестрасы булып эшли. Бергә эшләгән медсестра кызны кич утырырга чакыра. Эштән соң килә бу кыз кич утырырга. Альбинага әйтә:

– Альбина апа, мин монда булганны Хариска да әйттем. Ул да килеп чыгарга мөмкин әле...

– Килсен, килсен! Баянын да алып килсә, бигрәк әйбәт булыр. Җырлашып утырырбыз! – дип, Альбина иптәш кызының сүзен куәтли.

Хәзерге вакытта республикада күренекле баянист, халык уен кораллары ансамбле җитәкчесе Харис Нигъмәтҗанов, музыкаль училище тәмамлагач, эшкә Мөслимгә билгеләнде. Мөслимдә балаларны баянда уйнарга өйрәтте ул.

Икс медсестра, сөйләшә-сөйләшә, кич утыралар. "Вакыт соңарды инде, Харис та килмәде", – дип, йокларга әзерләнәләр. Шулвакыт тыштан ишекне кагалар. Альбина:

– Харис, килдеңме? – дип сорый.

Мондый каршылауны көтмәгән өй хуҗасы саллы-саллы сүзләр белән хатынына ташлана. "Мин командировкага киткәч, син менә кемне көтеп утырасың икән?" – янәсе.

Бу тавышка өйдән медсестра кыз йөгереп чыгып кына, хәлне җайлый...

Хәләф Мөхетдинович анекдотлар, кызык сүзләр сөйләргә ярата, дигән идем. Вакыт-вакыт үзе турында да шаяртып кына мактау сүзләрен әйткәли иде ул. "Карагыз әле миңа, райкомда минем кебек киенүче юк, карагыз әле, минем бу костюмны", – дия иде. Чыннан да, аның кигән киеме үзенә килешеп тора иде. Спортчыларга хас җыйнак гәүдәле, төз буйлы иде ул!.

Беркөнне ул үзенең пальтосы белән мактанырга уйлый. Яңа пальто, дигәннән, ул елларда үзең теләгән киемне магазиннан гына барып алу – мөмкин булмаган эш. Кайтмый иде ул, юньле товар кайтса да, райсоюз складыннан чыкмый. Югары урыннарда утыручылар яки сәүдә эшендәгеләрнең якын танышлары дефицит товарны складтан гына алып китәләр иде. Хәләфкә дә пальто шундый юл белән эләгә. Альбина алып кайтып бирүгә, ул аны киеп, райкомга кереп китә. Әлбәттә, пальто шәп, үзенә үлчәп теккән диярсең, килмәгән җире юк!

Беренче булып ул райкомның икенче секретаре янына керә: "Карагыз, Фәрит Фазлыевич, пальто менә шулай була ул!" Әмма пальтога уңай бәя бирелми, аның бәясе бөтенләй көтелмәгәнчә: "Кая әле, карыйк әле пальтоңны! Тәк, тәк, бу бит әйләндерелгән пальто! Иске пальтоңны гына әйләндереп кигәнсең бит. Мин синең бу эшеңне бер дә хупламыйм!"

Хәләф бу сүзләргә ышанырга да, ышанмаска да белми. Райкомның өченче секретаре Әкъсән Әмирович Шәриповка юнәлә. Тормышка һәрвакыт аек караучы өлкән кеше буларак, ул аннан гадел бәя көтә.

Әкъсән Әмирович бу пальтога нинди бәя бирер иде икән, әйтеп булмый, ләкин аның бүлмәсенә кереп житкәнче Фәрит Фазлыевич телефоннан шалтыратып өлгерә. Пальтога ничек бәя куярга кирәклеген әйтеп куя. Шәриповның Хәләфкә жавабы әзер:

– Хәләф Мөхетдинович, син райкомда күптән эшлисең инде, район халкы арасында дәрәжәң дә зур. Болай йөрмә инде син! Мондый түбәнлеккә төшмә. Рядовой колхозчы да хәзер ун ел кигән пальтосын яңадан әйләндереп кими. Килешми бу сиңа, сал син моны!

Пальтоның әле генә магазиннан алып кайтылганын, биркасының да исән булуын аңлатырга тырышып карый Хәләф.

Ләкин жавап кискен бирелә:

– Бусы инде, Хәләф, сиңа бөтенләй килешми. Иске пальтога биркалар юнәтеп йөрүеңне кеше ишетә күрмәсен!

“Болар юньле товарны аңлый торган кешеләр булмады. Исполкомга керим әле, алар – дөнья күргән кешеләр!” – дип уйлап, ул шунда юнәлә. Башта район партия контроле бүлеге мөдире З.Ф.Хәбибуллинга, аннары райбашкарма комитеты урынбасары Р.М.Зиннәтулинга керә. Алар инде телефоннан кисәтелгән, жаваплар әзерләнеп куелган һәм алар үз рольләрен оста башкаралар.

Һәрбер намуслы кешедә була торган ышанучанлык сыйфаты көчле иде Хәләф Мөхетдиновичта. Ул пальтоның яңа түгеллегенә, әйләндерелгәнлегенә ышана. Альбинага пальтоны илтеп бирергә куша.

Пальтога чират торучылар аны шунда ук складтан алып китә. Исполком секретаренең ире – “Маяк” колхозы председателе – бу пальтоны озак еллар буе яратып киде...

Хәләф Мөхетдиновичның икенче баласы булып малай туды. Шул вакыйгадан соң, уенын-чынын бергә кушып, симпозиум уздырырга теләве турында белдерде ул.

– Нәрсә турында сөйләшәсез инде ул симпозиумда? – дип сорадылар аннан.

– Минем малай туды! Малай булдыру серләре турында тәжрибә уртаклашам, – диде ул.

– Кемнәрне чакырасыз инде анда? – дип тә сорадылар.

– Бездә малай ясый алмаучылар күп бит ул. Врачлардан И.А. Хәбибуллин, А.С.Салахов, Л.Ф.Фәйзрахманов, РОНОдан Ә.Ә.Салихов, исполкомнан Р.М.Зиннәтуллин, райкомнан Ә.Ә.Шәрипов...

Бу турыда Әкъсән Әмировичка житкерәләр:

– Әкъсән Әмирович, симпозиумга чакыру алдыгызмы әле?

– Нинди симпозиум ул? Кем уздыра аны?

– Хәләф Мөхетдиновичның малае туган бит! Симпозиум җыеп, тәҗрибә уртаклашам, дигән иде ул. Сезне дә чакырам, дигән иде.

– Чакырып тормасын инде ул. Болай да билгеле бит инде: үзең генә тырышсаң, кыз туа, күршеләрең дә булышса, малай туа бит ул!

Авыл җирендә кеше сүзе тиз йөри бит ул. Бу сөйләшү Хәләф Мөхетдиновичка да ишетелә.

Симпозиум, никтер, булмый кала. Терәлеп торган күршесе Әкъсән Әмировичның әйткән сүзләре дә тәэсир итми калмагандыр.

Малай үсә, инде көлә дә башлый. Беркөнне кызы әтисен чакыра:

– Әти, әти, кил әле! Айратның көлүен күр әле? Шулкадәр охшаса да охшар икән, көлгәндә дә бит очлары чокыраюына кадәр гел Әкъсән Әмировичныкы инде!

Хактырмы, юктырмы, шушы сөйләшүдән соң, ике күрше шактый вакыт бер-берсе белән исәнләшми йөрде, дип сөйләделәр.

Хәләф Мөхетдинович юморлы кеше иде. Аның бу сыйфатына мисалларны күп китерә алам мин. Шуның берсенә генә тукталыйк әле.

...Бервакыт райком ишек төбендә берничә кеше сөйләшеп торабыз. Арабызда Х.М. Шәмсетдинов та бар. Хатыны Альфира белән безнең янга Равил Шамилевич та килеп туктады. Ул – республикабыздагы иң күренекле хирургларыбызның берсе! Алар Казаннан, ялга чыгып, Мөслимгә, элек эшләп киткән җиргә кайтканнар. Аларны Мөслим халкы әйбәт белә. Равил Шамилевичның өстендә сыйфатлы гына яңа костюм. Хәләф Мөхетдинович сүз башлады:

– Равил Шамилевич, әллә эчүне ташладыңмы?

– Нигә алай дисең?

– Эчүгә дә, мондый кыйммәтле костюмга да акча җиткереп булмыйдыр ул. Безнең хезмәт хаклары әллә ни түгел бит!

Юмор белән әйтелгәнне аңлап, без кычкырып көлдек. Хәләфнең юморын Альфира аңламаган. Райком кырыннан киткәч, ул Равилне битәрләп ташлады.

– Әллә Мөслимдә сине эчкече дип беләләрме? – диде ул.

– Ни сөйлисең син? Хәләф шаяртты гына бит ул! – дип Равил Альфираны тынычландырырга тырышты.

Равилгә өстәп, мин дә, Хәләфнең шаяруын аңлаткач кына Альфираның фикерен үзгәртә алдык.

Әйбәт кеше иде Хәләф Мөхетдинович. Мөслим халкының хәтерендә калырлык яхшы эшләр башкарды. Кызганычка каршы, яман чир аны иртәрәк алып китте...

Фриль Әхмәтов

Аның белән без – якташлар. Фриль Мирзанурович – Минзәлә районыннан. Аның туган авылы – Кызыл Төбәк – безнең Мөслим районына терәлеп тора. Үткән юлларыбыз да охшаш. Урта профессиональ белемне дә бер уку йортында – Минзәлә педагогия училищесында алганбыз. Шуңа күрә, күрешкән вакытта сүзебез яшь вакытлар, Минзәлә педагогия училищесы, анда безне тәрбияләгән укытучылар, аларның үз эшләрен җиренә җиткереп башкаруы, бездән чын укытучы ясау өчен, барлык белемнәрен биреп, намуслы хезмәт куюлары турындагы истәлекләребездән башлана.

Әле соңгы күрешүебез вакытында да Фриль сүзне безнең укытучылардан башлады: “Педучилищеда безне арифметикадан укыткан укытучыбыз Ясәви абый Хадыев Казанда яши икән бит. Ул хәзер 100 яшькә якыная торгандыр, хәлен белергә барыйк әле!”

Шундый ул минем яшь дустым Фриль Мирзанурович! Ул – кешелекле, кече күңелле, ярдәмчел, юмарт, эшлекле, тынгысыз һәм эшчән. Югары белемне ул техник вузда алган. Ул – төзүче-инженер. Мондый профессия кешеләре, гадәттә, коры, кырысрак, әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә игътибарсызрак булалар. Фриль Мирзанурович бу темаларга рәхәтләнеп сөйләшә, кызып-кызып бәхәсләшә дә. Бу – аның педучилищеда алган тәрбиясеннән башланып, аның белемен һаман тулыландырып торуыннан, иҗади эзләнүеннән киләдер.

Чаллы шәһәре мэрының төзелеш эшләре буенча ярдәмчесе, Татарстан Республикасының төзелеш эшләре министры урынбасары, Югары Совет депутаты буларак эшләгәндә дә, төрле мәсьәләләр буенча безнең очрашулардан мин һәрвакыт канәгать кала идем.

Ә безнең беренче очрашулар Сабантуйларыннан башланды. “Очрашу” дигән сүз, бәлки, бик урынлы да түгелдер. “Минем аны белә башлавым” дисәм, дөресрәк булыр. Көрәшкә мин гомер буе мөкиббән кеше. Студент елларында, Казанның данлыклы тренеры Морящичев җитәкчелегендә, классик көрәш

белән дә шөгыльләнергә туры килде. Шуңа күрәдер, мин Сабантуйларында, республикада оештырылган төрле дәрәҗәдәге ярышларда көрәшне башыннан ахырына кадәр күзәтәм. Бу — миңа, бик көчле куелган спектакль яки концертлар карагандай, ләззәт бирә. Күренекле көрәшчеләр Илдус, Әсхәт, Раббаниларның, минеке кебек, Гайфуллин фамилиясендә булулары да миңа горурлык хисләре өсти.

Фрильне Сабантуенда беренче тапкыр күргән идем, дидем бит. Шуңа кайтыйк әле. 1978 нче елның Сабантуен без Минзәләдә карадык. Минзәлә — минем өчен бик якын шәһәр. Яшьлек елларым, инде әйткәнемчә, шунда үтте.

Кояшлы җылы көн. Сабантуй түгәрәген әйләндереп алган тамашачыларның бөтен игътибары — көрәшчеләрдә. Көрәшчеләрнең берсе башкалардан аерылып тора. Зәңгәр спорт костюмыннан, аякларында кроссовкалар; физик әзерлеге һәр адымыннан сизелә, җыйнак гәүдәле. Көрәш берничә үлчәү категориясе буенча алып барыла. Бу егет — җиңел үлчәү категориясендә. Димәк, ул 60 килограммга кадәр авырлыктагылар белән көч сынаша. 70 һәм 80 кг авырлыктагылар — югарырак категориядә.

Көрәш башланды. Минем игътибарны җәлеп иткән көрәшчегә дә чират җитте. Ул егетне: "Фриль Әхмәтов!" — диделәр. Үз авырлыгындагы көрәшчеләрне (ә алар егермедән артык иде) ул бөтен шартларын туры китереп, җиңеп бара!

Хәзерге татар көрәшендә алымнар бик күп. Шул алымнар җыелмасын урынлы файдаланган көрәшчедә көрәш техникасы бар, диләр. Фрильдә, чыннан да, шул вакытта ук югары дәрәҗәдә көрәш техникасы булган.

Көрәшчеләр телендә тагын "тактика" дигән термин бар. Бусы инде — аерым көрәшчеләр белән бил алышканда үзеңне ничек тотарга кирәклекне дөрес сайлау, дигән сүз. Кайберәүләр, сөлгеләр аркага салынуга, актив һөҗүмгә күчә. Алдын-артын уйламыйча башланган мондый активлык күп вакыт көрәшче файдасына булмый. Ипташенә асылынып, "берәр җай чыгар әле" дип, вакыт сузучы көрәшчеләр дә була. Мондыйлар, гадәттә, судья тарафыннан кисәтү алалар, исәп аның көндәше файдасына бара башлый.

Мин күп Сабантуйлары күрдем. Ләкин көрәшне сәнгать дәрәҗәсенә җиткереп көрәшүчеләр бик сирәк. Фрильдә тактика, осталык, техника һәм физик әзерлек шул дәрәҗәдә тиешенчә файдаланыла ки, көндәшләре аркалары белән барып төшүне сизми дә калалар. Халык, исе китеп, карап тора. Бер

тамашачының бәясе истә калган: “Хәрәмләшмичә көрәшә, яман да көчле көрәшә бу егет!” — диде ул Фрильгә ихластан соклап.

Фриль, чыннан да, “яман шәп” көрәште бу көнне. Җиңел үлчәүдәге егермедән артык көрәшче арасында ул җиңүче булды, батыр калды! Аңа келәм тапшырдылар...

Әле көрәшнең кызыклары алда торган икән. Өч үлчәү категориясендә дә җиңүчеләр ачыклангач, алар арасыннан баш батырны билгеләргә кирәк булды. Сабан туеның олы бүләге — тәкә дә аңа тиеш. Җирәбә салынды. Башта урта һәм җиңел үлчәүдәге батырлар көрәшергә тиешләр... Ике батыр бил алыша башлады. Фриль көндәшенең билен тартып карый, әмма сөлге җилкәгә шуа да китә, шуа да китә. Менә бервакыт теге егет Фрильне күтәргән кебек хәлгә китерде, әйләндереп салырга теләде, ләкин Фриль аякларында басып калды. Фриль шунда судьяга мөрәҗәгать итте: “Минем белән көрәшүченең өстендә эчтән ефәк майка, тыштан ефәк күлмәк, бу — тигезлек түгел! — Әйдәгез, икебез дә күлмәкләрне һәм майкаларны салып көрәшик!” Шулай иттерделәр дә...

Озак та үтмәде, Фриль, көндәшенең сизгерлеген югалтып, бер алым ясады, аны җирдән суырып алып, аркасына салды.

Хәзер инде ике генә батыр калды. Берсе — әлеге дә баягы Фриль, ә икенчесе — авыр үлчәүдәгесе — күп мәртәбәләр Россия һәм Татарстан чемпионы Раббани Гайфуллин. Соңгы елларда Раббанины җиңүче булмагандыр?! Мәйдандагы тамашачы да шулай уйлады. Шулай уйламыйча мөмкин дә түгел. Фрильнең авырлыгы 60 кг нан аз гына артык. Озынлыгы ике метрга житкән Раббаниның авырлыгы 120 кг га якын. Көрәшчеләр арасында Раббаниның исеме “Минзәлә Карахмәте” иде! Чыннан да, мәһабәт гәүдәсе, төс-кыяфәте, каралыгы, көчлелеге белән ул Габдулла Тукай поэмасындагы Карахмәткә шактый охшаш иде.

Пәһлеваннар очрашуын халык исе китеп карап тора. Раббани, зур гәүдәле кешеләргә хас булганча, борчылуын күрсәтми. Аңа борчылырга урын да юк. Аның күзләре, гүя: “Энекәш, акылың бармы синең, кем белән көрәшкә чыкканыңны чамалыйсыңмы, әрәм буласың бит!” — дия иде.

Фриль житдиләнде. Көндәшенең кем икәнен яхшы белә! Бу вакытта ул үзен күп еллар көрәш серләренә өйрәткән остазының сүзләрен исенә төшергәндер. Бәлки, ул Бөекбританиянең атаклы премьеры Уинстон Черчильнең китабындагы сүзләрне хәтерләгәндер. Әлеге китапка Фриль еш мөрәҗәгать

итә. Шул китабында Черчиль болай дип яза: "Беркем алдында да һәм бервакытта да куркып калмагыз. Бу таләп бөек эшләргә дә, көндәлек вак-төякләргә дә кагыла... Дошманның көче күп мәртәбәләр артык булса да, бирешмәгез!"

Көрәшә башладылар. Раббани, бу малайны җиңел генә күтәреп алам да болгап атам, дип уйлагандыр. Ул Фрильнең билен тартып карагандай итте. Әлбәттә, Фрильнең алымга эләгәсе килми. Ул Раббаниның аяклары арасына кереп чумды. Шул мизгелдә Фриль, бөтен көчен җыйнап, Раббанины күтәреп, аякларын җирдән аерды һәм пәһлеванны, үзенә генә хас алым белән, әйләндереп тә салды!..

Бу тамашаны карап торучы халык "ах!" итте. Фриль Сабантуеның иң мактаулы бүләгенә лаек булды!..

Батырның җилкәсенә үзеннән дә зуррак тәкә китереп салдылар. Бу мизгел минем күңелдә Сабантуеның иң онытылмаслык хатирәсе булып уелып калды!..

Яшьтәшем Ранас

Минзәлә педагогия училищесын тәмамлагач, Сәвия апаны эшкә Мухан сигезьеллык мәктәбенә билгеләделәр. Шунда ул кияүгә чыкты, Мухан авылы аның өчен гомерлеккә үз авылына әйләнде. Утырган урыны, табигате белән бу авыл – Мөслим районының иң күркәм авылларының берседер. Бормаланып аккан Ык елгасының култыгына авыл җәйләп кына кереп урнашкан. Яр буйларындагы комлыклар махсус ясалган кебек. Ерак илләргә ял итәргә йөрисе дә юк. Комлыгында кызынакызына, чиста Ык суында теләгән кадәр су коенырга, йөзәргә була. Теләсәң, кармак салып утыр, бушка булмас, ухалык яки берничә табалык тәмле балык тотып кайтырсың.

Башкортстанның Бакалы районы ягына карап чакрым ярымлап барсаң, Г. Тукай шигырьләрендәгечә, матур урманнар китә. Мондагы чикләвек, миләш, җир җиләге, кура җиләге, каен җиләге кебек нигъмәтләрне җыеп кына бетерә торган түгел!

Җизнинең энеләре, сеңелләре бик күп. Шуларның берсе – Ранас. Ул минем белән яшьтәш. Шуңадыр, без аның белән бик тиз дуслашып киттек. Безнең яшьтәшләр бу авылда шактый икән. Алар белән дә дустанә мөнәсәбәт урнашты.

Ранас армиядә хезмәт иткәндә, без хат алышып тордык. Хезмәтен тутырып армиядән кайтканда, ул Казанга кагылды. Минем студент вакыт. Пединститутның Зур Кызыл урамын-

дагы тулай торагында Ранас та бер атна торып китте. Шул кыска гына вакыт эчендә Ранас тулай торакның үз кешесе булып бетте. Кызлар бүлмәләрендә дә, егетләрнекендә дә ул – сөйләшер сүз таба, әңгәмәләр тиз генә бетми. Тулай торакта һәркөн диярлек берәр чара уздырыла. Монда инде Ранас бу чараны әзерләүчеләрнең берсенә әйләнә. Соңыннан Ранас җитәкчелегендә авылча кичке уеннар башлана. Ялгыз да, икеле, өчле, дүртле, алтылы, сигезле биюләр дә башкарыла. Студент халкы бу кичәләргә күнегеп китте. Ранас Мөслимгә кайтып киткәч тә, Ранасны сораштырып йөрүче кызлар булгалады әле.

Үз авыллары Муханга кайтып ике генә кич куна да, Ранас безнең авылга – Югары Табынга кунакка килә. Гадәте буенча безнең авыл клубында да активлыгын ташламый. Авылның матур кызы Рая белән дуслаша. Аларның өйләренә барып йөри, әтиәнисе белән таныша. Авылда сугым сую вакыты була. Сугым суйган хуҗаның аш мәҗлесе уздыру гадәте бар авылда. Раяның әти-әнисе дә мәҗлес җыя. Кунакларны күп чакырганда җитмәгән савыт-сабаны, өстәл-урындыкларны күрше-тирәдән сорап торалар. Бу эшләрне дә бик теләп башкара Ранас. "Әби, бабай, кунакларның кайсысын кайда утыртыйм?" – дип үзенең алдагы эшен дә тәгаенләп куя. Шулай килештереп йөри кунак егете.

– Бу егет безнең кызга өйләнергә йөри, ахры! – дип, кызның әтисе, туй кирәк-яраклары алыр өчен, Ижау шәһәренә чыгып чаба.

Бераз кунак булгач, Ранас үз авылларына кайтып китә. Кайтканда, Метрәй авылына кагыла. Ерак туганнарында берничә көн кунак була. Гадәте буенча, Метрәй кызы Асия белән дуслаша.

Үз авылларына кайткач, әти-әнисенә мәсьәләне "кабыргасы" белән куя Ранас:

– Әти, әни, табын әзерләгез – мин өйләнәм, бүген кичкә Метрәй кызын алып кайтам!

Көтелмәгән бу яңалык Ранасның әти-әнисен борчуга сала.

– Нинди өйләнү ди әле ул, армиядән кайтып җитмәс борын! Безнең туй уздырырлык әзерлегебез дә юк! – өлкәннәрнең җавабы шундый була. Ранас та мәсьәләне коры тота:

– Әзерлегегез булмаса-булмас, безнең эш беткән инде! – Шулай ди дә, кичке мәҗлескә кунаклар чакырырга чыгып китә.

"Безнең эш беткән инде" дигән сүзләрнең тәэсире зур була. "Кеше алдында хур була күрмик!" – дип, кичке мәҗлескә нык-лап әзерләнә башлыйлар.

Шулай итеп, Ранас Асия белән тормыш корып җибәрде...

Дөреслек дулкынында

“Тыңлагыз, Казан сөйли!”

*“Татарстан” радиосының өлкән мөхәррире, күренекле шагыйрь һәм публицист – Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм республикабыз язучылары оешмасының Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Әхмәт Рәшитов**ның Татарстан Халык мәгарифе министры **Васил Гайфуллин** белән әңгәмәсе. (Әңгәмә “Кызыклы очрашулар” программасында 1995 нче елның мартында оештырылды).*

Әхмәт Рәшитов. Васил Габдуллович, Сез матур табигате җырларда җырланган Мөслим районында туып-үсеп, республикабызда иң мәртәбәле булган Халык мәгарифе министрлыгының төп хуҗасы дәрәҗәсенә ирешкәнсез. Хөкүмәт әгъзасы югарылыгындагы җитәкче булуның сәбәпләре, серләре бардыр. Моңа, бәлки, Сезнең камил профессиональлек, бәлки, туган Мөслим районының үзенчәлеге, андагы милли җанлы кешеләр, оста белгечләр сәбәпледер?! Бу турыда уйлап караганыгыз бармы?

Васил Гайфуллин. Минем язмышыма туган як, туган авылымның тәэсире булмый калмагандыр. Югары Табын дигән авылда туганмын. Авылны башлап җибәрүчеләр акыллы кешеләр булганнар. Авылның бер ягында инеш агып ята. Инешне җәй көне буып куялар. Зур гына буа барлыкка килә. Бала-чагалар, олыраклар да шунда җәй буе су коена.

Мул сулы Ык елгасы да бездән ерак түгел, 1,5 чакрым гына. Ык тирәләрен әрәмәлекләр каплый, анда җиләк-җимешнең ниндие генә юк! Аннан калын урман башлана. Ул Шуран авылына кадәр дәвам итә.

Авылның икенче башында да урман бар, Атлас урманы! Безнең авылдагы башлангыч мәктәп укытучылары табигатьнең мондый күркәм урыннарына укучыларның экскурсияләрен еш оештыралар иде.

Әхмәт Рәшитов. Мин Мөслим районын бераз беләм. Мондый матур табигатьле районнардан күренекле шәхесләр: язучылар, шагыйрьләр, музыкантлар, рәссамнар, җырчылар күбрәк чыга. Сорауны биргәндә мин шуларны да истә тоткан идем.

Васил Гайфуллин. Анысы шулай. Монда икенче факторны да истән чыгарырга ярамый. Бу – авылдагы мәктәп һәм андагы укытучылар. Безнең авылда башлангыч мәктәп бар иде. Укытучыбыз Хөршидә апа Галиева бик әйбәт укытты. Аның осталыгы, тырышлыгы аркасында, укырга, язарга, тәртипкә, максат куеп, үзлегемнән эшләргә өйрәндем. Үзебезнең авылның башлангыч мәктәбеннән соң, күрше Түбән Табын авылындагы җидееллык мәктәпкә баргач, анда инде яхшы укучылардан саналдым. Биредәге укытучылар да үз эшләренең чын осталары иде. Мәктәп директоры Ә.Г. Гәрәев, татар теле укытучылары Р.Ш. Шәяхмәтов, Л.И. Измайлова, математика укытучысы Р.Янбухтина, немец теле укытучысы Ф.Г. Хаков, тарих укытучысы Х.Ә.Әхмәтовлар безгә тирән белемнәр бирделәр.

Класс җитәкчебез һәм рус теле укытучысы Гали Сәетович Камаловны мин һәрвакыт олы рәхмәт хисләре белән искә алам. “Укытучы нинди булырга тиеш?” – дигән сорау куелса, мин: “Укытучыбыз Гали Камалов кебек булырга тиеш!” – дип җавап бирер идем. Ул дәресләрне барлык укучыларны да җәлеп итәрлек итеп оештыра белде. Авыр үзләштерүчеләр өчен өстәмә дәресләр уздыра, ата-аналар белән һәрвакыт тыгыз бәйләнештә була иде. Ул матур итеп яза, пөхтә киенә, күп укый, күп белә. Аның турникта ясаган күнегүләрен без авызны ачып карап тора идек. Үрнәк алырлык сыйфатлары күп иде Гали абыйның.

Җидееллык мәктәпне “5”ле билгеләренә генә тәмамлап, Минзәлә педагогика училищесына укырга киттем. Үзебезнең укытучыларыбыз кебек, минем дә укытучы буласым килде.

Педучилищедан соң бер ел үзебезнең районның Ташлыяр җидееллык мәктәбендә укытучы булып эшләдем. Аннары – Казан дәүләт педагогия институты; Мөслим урта мәктәбендә – укытучы, завуч, район мәгариф бүлеге мөдире; Ленинград пединститутында – аспирантура, фәнни эшләр; Казан дәүләт педагогия институтында – укытучы, аннары доцент, профессор, кафедра мөдире, декан булдым.

Әхмәт Рәшитов. Сез физика-математика факультетын тәмамлагансыз. Моның сәбәбе нәрсәдә? Ә башка фәннәргә карашыгыз ничек?

Васил Гайфуллин. Физика-математика факультетына баруымны болайрак аңлатам. Педучилищедан соң бер ел эшләп

алдым. Бу 1955-1956 нчы уку еллары иде. Бөек Ватан сугышының кайтавазы әле һаман дәвам иткән чор. Мәктәпләргә килүче балалар саны кимеп барган еллар. Шуңа карап, класслар саны кими. Укытучылар штаты кыскара. Педагогия уку йортларын тәмамлаучыларга эш юк. Педучилищены кызыл дипломга тәмамлаучы буларак, миңа эш таптылар, анысы. Армия срогын тәмамлап, Алабуга пединститутының физматын тәмамлаган туганым Нурулла абый кайтып төште. Район мәгариф бүлеге аны Михайловка мәктәбенә физика-математика укытучысы итеп билгеләде. Михайловка авылы Ташлыяр кырыенда гына. Нурулла абый белән бер фатирда торабыз. Эш турында, минем киләчәк турында сөйләшәбез. Алдагы елда минем институтка китү теләген Нурулла абый инде белә иде.

– Физматка кер син! Һәрвакыт эш белән тәэмин ителгән булырсың. Физматның да математика бүлегенә бар, физика бүлегенә барма. Физика, математикага караганда, катлаулырак ул. Аннары физиканы укытуы да авыр. Һәр дәрескә тәжрибә ясап, жаның чыга. Математикадан бер кагыйдәгә 15-20шәр дәрес мисал эшлисең, барысын да бер калыпка салып, – ди бу миңа.

Мин аның сүзен тотып, физматка киттем. Ләкин физика бүлегенә. Моңа Минзәлә педагогия училищесында безне физикадан укыткан Гыйззәт Рәхмәтуллович Галиев сәбәпче булгандыр, дип уйлыйм. Физиканың шактый катлаулы темаларын, тормыш мисаллары китереп, гади генә аңлата алуы барыбызга да ошый иде. Мин дә аңарга охшарга теләгәнмендер, күрәсең.

Башка фәннәргә караш мәсьәләсе болай. Мин башлангыч, жидееллык мәктәпләрне дә, педучилище һәм пединститутны да гел “5”легә тәмамладым. “Бу фән миңа кирәк, бусы кирәкми”, – дигән караш миндә булмады. Ул “бишле”ләрне дә бинибая зур тырышлык нәтижәсе дип әйтмәс идем. Фәннәрне өйрәнү миңа авыр бирелмәде. Укытучының аңлатканын тыңлау яки дәреслекне бер кабат карап чыгу миңа югары белем алу өчен житә иде.

Әхмәт Рәшитов. Физикларны бик коры, артык конкрет итеп, лирикларга диаметраль каршы кую очраклары бар. Ә менә Сездә мондый каршылыклар сизелми. Сез физика-математикага да, әдәбиятка, музыкага, жырга тигез карыйсыз кебек. Моны ничек аңлатасыз?

Васил Гайфуллин. Мин моны тулысы белән Минзәлә педагогия училищесында укуым белән аңлатыр идем. Физика укытучысы булырга теләвемнең сәбәбен әйткән идем инде.

Физиклар һәм лириклар турындагы бәхәскә килгәндә, мин моны ясалма рәвештә тудырылган, дияр идем. Физиклар да күктән төшкән түгел, гадәти кеше. Педучилищеда безне рәсем ясарга, лозунг язарга, җырларга, музыкага өйрәттеләр. Зур гына хорыбыз, музыкаль инструментлар оркестры бар иде. Икесендә дә актив катнаштым.

Тальян, хромка гармуннарында, баянда, пианинода, скрипкада, домрада уйнарга өйрәндем.

Укытучы булып эшләгәндә, миңа боларның ярдәме нык тиде. Класс бүлмәсен бизәгәндә, стена газетасы чыгарганда, концертлар, спектакльләр куйганда читтән ярдәм сорап тормый идек.

Әхмәт Рәшитов. Безнең радиокомитет фондында Сезнең музыкаль язмаларыгыз бар икән. Шуларны тапшыруны сорап, безгә еш кына хатлар килә. Әлеге язмаларның тарихы турында да сөйләсәгез иде.

Васил Гайфуллин. Пединститутта укыган елларымны уйлыйм да хәйран калам. Мин – үзем укый торган студентлар төркеменең старостасы, институтның комсомол комитеты члены, тулай торакта студсовет председателе, мәктәптә берничә сәгать дәрес укытам, Татарстан укытучылар йортының эстрада төркеменә, Горький исемендәге клубның Сара Садыйкова оештырган хорына, "Мехкомбинат" клубында Хәким Сәлимҗанов оештырган халык театрына йөрим, еш кына концертлар, спектакльләр куябыз. Барысына да житешелә.

Безнең бер концертны композитор Исмай Шәмсетдинов тыңлаган. Ул мине радиога чакырды.

– Җырларыңны тыңладым. Тавышың матур! Моңың, башкару осталыгың бар. Кил әле, язып алыйк әле. Үзешчәннәр концертында бирербез. Халыкны яңа тавыш белән сөендерик әле! – диде ул.

Шул елларда башланды ул музыкаль язмалар. Алар шактый җыелды. Хәзер дә 6-7се вакыт-вакыт яңгырап алалар.

Бу уңайдан ул елларда музыкаль язмаларны булдыручы композитор Исмай Шәмсетдинов турында җылы фикерләремне әйтәсем килә. Булса да була икән шул дәрәҗәдә кешеләрне ярату, ярдәмчеллек, кече күңелллелек, кешене санлау! Кабинетына килеп керүгә, сикереп торып, кочаклап ала, чәй тәкъдим итә, нинди яңа җыр алып килүең белән кызыксына, аккомпаниаторың булмаса, музыкант эзли башлый. Рәхәт була иде андый кеше белән эшләве!

Әхмәт Рәшитов. Музыкага кагылганбыз икән, тагын бер нәрсәне ачыклыйк әле. Җырларны гына алыйк... Аның опера юнәлешендәгеләре, халык җырлары, "шлягер" дигәннәре яңгырый.

Сезне нинди юнәлештәге җырлар кызыксындыра?

Васил Гайфуллин. Табигатем шундыймы – миңа озын, моңлы халык җырлары ошый. Аларда – халкыбызның тарихы, аның үткәне, кичерешләре, уй-теләкләре.

"Тәфтиләү", "Эскадрон", "Уел", "Сандугач", "Әллүки", "Хәмдия", "Мәрфуга", "Хафизәләм, иркәм" һ.б. татар халык көйләренең моңы һәм сүзләре шулкадәр бер-берсенә тәңгәл килә, аларны җырлап кына торасы килә. Солтан Габәши, Виноградов һәм Әлмөхәммәтовлар тудырган "Эшче" операсыннан Нигъмәт җыры, З.Исмәгыйловның "Салават" операсыннан Салават ариясе дә халыкчанлыгы белән аерылып тора. Ул җырларны башкару миңа Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия конкурсларында җиңү китерде.

Хәзерге җырлардан минем күңелгә Сара апа Садыйкова һәм Рөстәм Яхин җырлары якын. Ә бүгенге яшьләр җырлый торган такмаклар, ритмикага гына корылган җырларны мин кабул итә алмыйм. Җитмәсә, аларның сүзләрендә дә мин мәгънә күрмим. Анда рифмалашкан сүзләр җыелмасы гына. Концертларда дистәләгән җырчы (аларны хәзер "йолдыз" диләр) чыга. Концерт ахырына ул җырларның көе дә, сүзләре дә истә калмый.

Әхмәт Рәшитов. Элекке композиторлар җырның сүзләренә бик таләпчән иде. Хәзер сүз текстына игътибар кимеде кебек. Сезгә дә шулай булып тоелмыймы?

Васил Гайфуллин. Талантлы автор тарафыннан язылган мәгънәле шигырь булса, композиторга җырның көен язу бермә-бер җиңелдер. Җырның башта сүзләре истә кала бит. Гомәр Бәширов сүзләренә Сара апа язган "Җидегән чишмә" җырын яки Гарифҗан Мөхәммәтшин сүзләренә Рөстәм Яхинның "Керим әле урманнарга..." җырын гына мисалга алу да җитә. Ә мәгънәсез сүз тезмәләренә нинди генә композитор көй язса да, уңышка ирешмәячәк.

Әхмәт әфәнде, тагын бер мисал китерим әле. 60 нчы елларда Сезнең "Беренче мәхәббәт" исемле шигырегезгә Сара апа язган көйне барлык кеше күтәреп алды. Ул җырны яше дә, карты да җырлады. Матур хисләрнең мәгънәле сүзләргә төренүе, музыканың шул эчтәлеккә сыланып кына торуы бу җырны мәңгелек итте. Ул җыр алдагы гасырда да яңгыраячак!

Әхмәт Рәшитов. Рәхмәт Сезгә!.. Әйтегез әле, үзешчән сәнгатьтә актив катнашкан еллардагы җырчыларның репертуарларын хәзерге җырчыларныкы белән чагыштырып караганыгыз бармы?

Васил Гайфуллин. Әле күптән түгел генә җырчы Рөстәм Маликов концертын тыңладым. Күп җырлар арасында татар һәм башкорт халык җырлары да бар иде. Рөстәмнең матур тембрлы тавышы ул җырларны тагын да баетты.

Онытылып, ләззәт белән тыңладык. Рөстәмнең олы җырчы булуына ышандык. Элеккерәк вакытларны, халык җырларының дәрәҗәле елларын искә төшердек. Мондый мисалларны Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Хәйдәр Бигичев, Мирсәет Сөнгатуллин, Фердинанд Сәлахов, Шамил Әхмәтҗанов концертларыннан да китерер идем. Безнең җыр традицияләрен саклау буенча алар хәзерге яшь җырчыларга (җырлаучылар, дисәк, дөресрәктер дә әле) үрнәк булырлык.

Әхмәт Рәшитов. Сез – министр кеше. Эшегез сәнгатьтән ерак торган кебек. Ләкин Сез бу өлкәне дә якын итәсез, концерт-спектакльләрне калдырмыйсыз.

Васил Гайфуллин. Министрның эше катлаулы һәм авыр. Мин бигрәк тә катлаулы чорга туры килдем, дип уйлыйм. Демократияләшү, яңарыш чоры, мәгариф системасындагы элекке принциплар урынын яңалары алыштыра. Хата ясамыйча, яңача үсүне тәэмин итәргә кирәк. Финанс кыенлыклары, укытучыларга вакытында хезмәт хакы түләмәү остәмә мәшәкатьләр китереп чыгара. Эш сәгате ахырында үзеңнең рухи халәтең буенча да, физик халәтең буенча да бик нык арыганыңны сизәсең, нервылар да ахыр чиккә җитә. Әгәр дә эштән соң берәр төрле культура чарасына – концерткамы, спектакльгәме барсаң, яки спорт ярышын карарга вакыт тапсаң, монда инде чын мәгънәсендә ял итәсең. Киләсе эш көнендә синең арыганнарыңның эзе дә калмый, ул көнге мәшәкатьләр, борчылулар онытыла.

Әхмәт Рәшитов. Сез безнең Татар дәүләт академия театрының барлык премьераларын да карап барасыз, дип беләм. Аның репертуары Сездә нинди фикер уята?

Васил Гайфуллин. Безнең Татар дәүләт академия театры үзенең режиссерлар составы, артистлар коллективы белән, безнең республикада гына түгел, барлык милли театрлар арасында иң көчлесеседер, дип уйлыйм мин. Кемнәр генә уйнамаган анда?! Элегрәк Хәлил Әбҗәлилов, Таҗи Гыйззәт, Кәрим Тинчурин, Зәйни Солтанов, Хөсәен Уразиков, Хәким Сәлимҗанов,

Фоат Халитов, Габдулла Шамуков, Фатыйма Ильская, Гөлсем Болгарская һәм Гөлсем Камскаялар. Хәзергеләре – Шәүкәт Биктимеров, Вера Минкина, Наил Әюпов, Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәләлов, Ирек Баһманов, Әзһәр Шакиров, Ренат Таҗетдинов һ.б. артистлар, сәләтләре буенча да, осталыклары буенча да бик югары дәрәҗәдә, дияр идем. Ләкин соңгы вакытта анда куелган спектакльләрнең кайберләре – эчтәлеге, күтәргән проблемалары, куелышы белән – тамашачы буларак, мине тулысынча канәгатьләндерми. Репертуар сайлауда талымсызланыбрак китмәделәр микән, дигән фикер туа. Театрда Галиәсгар Камалның, Нәкый Исәнбәтнең классик әсәрләре, Туфан Миңнуллинның бер дигән пьесалары куела. Ләкин, кызганычка каршы, урынсыз көлүгә, буш эффектка корылган спектакльләр дә очрый. Аларның тирән фәлсәфи проблемалары да булмый. Карап утырганда кызык кебек күренсә дә, фикер уятмый, уйландырмый. Мондый күренешләрдән арыну олы театрыбызны сәламәтләндерер генә иде.

Әхмәт Рәшитов. Васил әфәнде, Сез гармониягә омтыласыз. Мәгариф министры буларак, үзегезнең кул астыгызда эшләгән йөзләгән-меңләгән педагоглардан да шуны таләп итәсезме?

Васил Гайфуллин. Безнең мәгариф системасында эшләүчеләр бихисап күп санны тәшкил итә. Укытучылар гына да 60 меңгә якын. Ә балалар бакчаларында, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә, идарә органнарында эшләүчеләрне дә кушып санасак, 120 меңнән артык кеше эшли бездә. Укытучыларны, тәрбиячеләрне педагогия уку йортлары әзерли. Педагогия училищеларының уку планы уңышлы төзелгән. Педучилищены тәмамлап килгән белгеч укытучы булырга тулысынча әзер. Аңа читтән ярдәм кирәкми дә. Бәлки, аны мәктәптәге үзенчәлекле яңа алымнар белән таныштыру кирәктер, ләкин ул дәрес уздыру, класстан тыш чаралар уздыру буенча педучилищеда тулы әзерлек алып чыккан була. Шуның өстенә аның педучилищеда махсус программа буенча алган җыр, музыка, рәсем, матур язу буенча җитәрлек күләмдә күнекмәләре дә бар.

Югары профессиональ белем бирүче педагогия уку йортларында мондый әзерлек алып барылмый. Әмма теләк булганда, мондый әзерлекне студент үзлегеннән алырга мөмкин. Без укыган елларда Казан шәһәренең мөмкинлекләре зур иде. Алардан мин 5 ел уку дәвамында тулысынча файдаландым. Анда йөреп бию хәрәкәтләренә, вокаль осталыкка, халык алдында

чыгыш ясау күнекмәләренә өйрәндем. Минем алдагы хезмәт юлымда боларның файдасы күп тиде.

Ә пединститутның уку планы буенча гына әзерлек үтеп чыгучы белгечтә бу күнекмәләрнең байтагы булмаска мөмкин бит.

Әхмәт Рәшитов. Мәгариф тарихыннан билгеле булганча, безнең элекке гимназияләрне тәмамлап чыгучылар берничә телне, музыканы, риториканы өйрәнеп чыкканнар. Шул гимназияләр белән бүгенге мәктәпне чагыштырганда аерма күпме?

Васил Гайфуллин. Гимназияләр алар күп санда булмаган. Аларга сәләтле балалар гына сайлап алынган. Уку йортлары да бертөрле генә булмаган. Шулай тиеш тә. Балалар да бит бертөрле генә түгел. Аларның кайберсе – физика-математикага, икенчеләре – гуманитар фәннәргә, өченчеләре – техникага, дүртенчеләре физкультура-спортка сәләтле. Һәрбер укучының да мәктәпнең уку планындагы барлык фәннәрне дә уңышлы үзләштерүе мөмкин түгел. Ә безнең илдә барлык мәктәпләр дә бертөрле иде. Шуңа күрә дә, без бу бертөрлелектән китәргә булдык. Хәзер гимназияләр, лицейлар, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнә торган махсус мәктәпләр оештырабыз.

Бүгенге көндә аерым юнәлешләр буенча эшли торган махсус мәктәпләрнең саны гына да 200дән артып китте. Шуларның 80 нән артыгы – татар гимназиясе.

Аларның уку планнарында без телләрне өйрәнүгә игътибар итәбез. Күбесендә өч тел өйрәнү мәҗбүри куелган. Дүрт тел өйрәнгәннәре дә бар. Безнең республика уку йортларын тәмамлаучылар, ким дигәндә, өч тел белергә тиеш дигән принцип белән эшлибез без. Мәгариф министрлыгының таләбе шундый.

Әхмәт Рәшитов. Димәк, элитар мәктәпләрнең булуы аклана?

Васил Гайфуллин. Элитар мәктәпләр булырга тиеш. Цивилизацияле илләрнең барысында да элитар мәктәпләр бар. Җәмгыятьнең һәр әгъзасына да бертигез урта яки югары белем бирергә, дигән таләп кую дөрес түгел.

Әхмәт Рәшитов. Элегрәк безнең Казанда ир балалар һәм кыз балаларны аерым укыту практикасы бар иде. Сез моны кирәк дип табасызмы?

Васил Гайфуллин. Хәзерге көндә дә мондый практика бар. Мәсәлән, Казанның Горки дип аталган районында яңа төзелгән бина ике өлештән тора. Монда, яңа уку елыннан башлап, кызлар һәм малайлар аерым-аерым укыйлар. Казанның 6 нчы сан-

лы лицее, дип атала ул. Лицейның бер корпусында – 800ләп кыз, икенчесендә шуның кадәр малай укый. Казанның үзендә, Тукай урамында кыз балалар өчен махсус гимназия ачтык. Хәзер без бу тәҗрибәне төрле яктан өйрәнәбез. Өстенлекләре ачыкланса, бәлки, мондый уку йортларын күбәйтербез. Казанда шулай ук кызлар өчен махсус ачылган төрек-татар лицее эшли.

Моннан тыш, республикада 7 татар-төрек лицее эшли. Алары – малайлар өчен.

Мондый уку йортларын булдыру идеясе миндә Төркия республикасына командировка вакытында туды. Бу илдә булуның файдасы зур булды, дияр идем. Беренчедән, шунда баргач, Татарстан Халык мәгарифе министрлыгы белән Төркия Республикасы Мәгариф министрлыгы арасында килешүгә кул куелды. Бу килешү буенча без Төркия вузларына студентлар һәм аспирантлар җибәрә башладык. Безнең вузларга да төрек яшьләре килделәр. Иң әһәмиятлесе шул булды: Төркия Мәгариф министрлыгы безнең республикада оешачак махсус лицейларга фәнни-методик һәм материал ярдәм күрсәтергә риза булды.

Төркиядә булу вакытында Төрек дөньясын өйрәнү институты (җитәкчесе – профессор Туран Язган) һәм Эртугрул Гази исемендәге белем-тәрбия ширкәте белән турыдан-туры танышырга мөмкинлек туды. Истанбул, Иске шәһәр, Измир шәһәрләрендә булып, алардагы лицейларда укыту-тәрбия эшенең торышы белән таныштык. Шуннан соң инде, бер дә шикләнмичә, үзебезнең республикада төрек-татар лицейлары ача башладык. Һәм хәзер зур ышаныч белән әйтә алабыз – монда укыган егетләр-кызлар арасыннан республикабызның, халкыбызның киләчәген тәэмин итәрлек тәрбияле белгечләр, һичшиксез, чыгачак.

Әхмәт Рәшитов. Тагын бер нәрсәне ачыклап китик әле. Безнең мәктәпләрдә төрле милләт балалары бергә укыйлар. Ә һәр милләтнең үзенә генә хас менталитеты була, диннәре дә төрле. Соңгы вакытларда мәктәпләргә дин әһелләре дә йөри башлады. Мондый очракларда урталыкны ничек табарга?

Васил Гайфуллин. Шәһәр мәктәпләрендәге уку рус телендә алып барылган классларда төрле милләт балалары бергә укыйлар. Бу – бездә гадәти күренеш. Мәктәпләргә дин әһелләренең килүе мәсьәләсенә килгәндә, безнең илдә, Конституциядә язылганча, мәктәп диннән аерылган. Безнең уку планнарында дин дәресләре юк. Диннәр тарихы, дигән факультатив уку предметы гына бар. Бу предметны махсус әзерлеге булган мөгал-

лим укытырга тиеш. Монда инде бер генә дин – йә ислам, йә христиан, йә яһүд дине генә өйрәнелми. Монда диннәрнең нигезе, нинди принциплар белән эш итүе турында сөйләнелә. Балалар һәм ата-аналар, үзләре теләгән очракта, мәктәптәге дәресләргә зыян китермичә, мәчетләргә яки чиркәүләргә йөри алалар. Без аларның ниятләренә каршы килмибез.

Әхмәт Рәшитов. Хәзер шәһәр мәктәпләре укытучылары укучыларының тәртипләреннән зарланалар.

Васил Гайфуллин. Тәрбия процессы ул – гаять катлаулы процесс. Элек безнең еллар буена килгән тәрбия принциплары бар иде. Хәзер ул принциплар бетеп бара. Хәзерге чор өчен яңа тәрбия концепциясе эшләнә. Элек яшәп килгән октябрятлар, пионерлар, комсомоллар һәм башка укучылар оешмалары коллективизм принцибына таянып эшләде. Хәзерге шартларда идеология үзгәрде. Ләкин балаларны бушлыкта калдыра алмыйбыз. Милли үзаңны булдыру, кешелеклелек сыйфатларын тәрбияләү мөһим. Халык педагогикасы принципларына таянып, тәрбиянең яңа системасын булдырырга кирәк. Бүгенге көндә мәктәпләрдә "Татарстан варислары" дип аталган оешма, табигатьне саклаучы, техника белән кызыксынучы балалар оешмалары эшли. Мәктәпләрдә укучылар комитетларының эшләре җанланып китте. Менә шундый чаралар ярдәмендә тәрбия процессын йомшартмаска тырышабыз.

Кызганычка каршы, заман үзгәрү укучы яшьләрнең дә холкына үзгәреш кертә, тәртипсезлекләр китереп чыгара. Һәртөрле начарлыкларга иярүдән аларны саклап калу безгә өстәмә бурычлар йөкли.

Әмма шунысын да әйтеп китәргә кирәк. Казанда хәзер 20гә якын татар гимназиясе һәм өч татар-төрек лицее эшли. Шуларның берсендә дә милиция органнарында теркәлерлек тәртип бозу яки җинаять эше билгеле түгел. Бу инде – безнең тәүге уңышларыбызның берсе!

Әхмәт Рәшитов. Татар халкы гомер-гомергә милли мәгариф булдыру турында сүз алып барды. Әлегә бу мәсьәлә кайсы урында тора?

Васил Гайфуллин. Мәгариф министрлыгына эшкә килгән көннән башлап, милли мәгарифне торгынлыктан чыгару юлларын эзли башладым. Әлбәттә, беренче чиратта, татар баласының беренче класстан ук татарча укый башлавына ирешергә кирәк иде. Бу яктан хәлләр бик мөшкел иде. Республиканың барлык шәһәрләрендә диярлек бер генә татар мәктәбе дә юк. Чаллы һәм Казан шәһәрләрендә берәр татар мәктәбе эшли.

Мөслим, Актаныш, Балтач, Әтнә, Сарман кебек чын татар районнарының район үзәкләрендә дә татар класслары бетеп бара. Республика җитәкчеләрен дә бу хәл борчымый. Киресенчә, Мәскәү алып барган политика безнең республикада бик уңышлы үтәлә дип, канәгатьләнү хисләре кичергәннәрдер кебек тоела.

Ата-аналар да шушы тәртипкә күнегеп беткәннәр.

Бу вәзгыятьне үзгәртү кирәк иде. Ләкин моны ничек эшләргә? Күп уйладык һәм шундый фикергә килдек: татар мәгарифе концепциясе булдырырга һәм шул нигездә татар мәгарифен үстерү программасын төзергә. Шулай эшләдек тә. 1991 нче елның августында концепцияне Татарстан Халык мәгарифе министрлыгы коллегиясендә кабул иттек.

Концепция буенча, милли мәгарифнең буыннары булып, гаилә тәрбиясе, башлангыч, төп, урта мәктәпләр, югары мәктәп, аспирантура, белем күтәрү уку йортлары эшләргә тиеш. Боларны тормышка ашыру программасы да булырга тиеш.

Бераздан программабыз да әзер булды. Программа буенча татар мәгарифен үстерү берничә юнәлештә бара:

1) Һәр районда, һәр шәһәрдә татар мәктәпләре ачыла. Яңа төзелгән мәктәп бинасы яңа ачылачак татар мәктәбенә бирелә. Шушы юл белән күп кенә шәһәрләрдә һәм районнарда татар мәктәпләре ачылды.

2) Күп еллар буе татар мәктәбенә уңай булмаган караш ата-аналарга да тәэсир итми калмады. Алар да балаларын татар мәктәбенә теләп бирмәделәр. Без тагын бер юлны сайладык – татар гимназияләре ача башладык. Уку планнарына үзгәрешләр кертелгән, белем стандартлары яңартылган әлеге уку йортларына ата-аналарның да игътибары артты. Шулай итеп, гимназияләр саны елдан-ел күбәя барды.

3) Район үзәкләрендә һәм шәһәр җирләрендә татар мәктәбе өчен аерым бина табып булмаганда, беренче класс укучылары өчен махсус татар классы ачу. Казанның үзендә генә дә мондый татар-рус мәктәпләренең саны берничә дистәгә җитте.

4) Республика шәһәрләрендә татар-төрек гимназияләре булдыру...

Мин Мәгариф министрлыгына эшкә килгәндә, Казандагы татар балаларының 0,4%ы гына үз ана телендә белем ала иде. Быел, безнең тарафтан күрелгән чаралар нәтиҗәсендә, бу процент – 40ка якын, Түбән Камада – 25 тирәсе. Моны, бер дә кыенсынмыйча, милли мәгарифнең үсеше, дип атый алабыз. Татар телендә эшләүче мәктәпләр саны да бүген 1200дән ар-

тып китә. Республикада быел татар балаларының 48%ы ана телендә белем ала. Ләкин бу саннар безгә җиңел генә бирелмәде. Һәр көнне диярлек министрлыкта милли мәгарифкә багышланган аппарат җыелышлары оештырдык. Бу җыелышта эшләнгән эшкә йомгак ясала, алдагы көннәргә бурычлар билгеләнә. Милли мәгариф буенча министр ярдәмчесе Г.Г. Садриевка, министрлыкның милли бүлек мөдире һәм аның хезмәткәрләре Ә.Н. Хуҗиәхмәтов, Р.А. Зарипов, Г.Ә. Гайнетдинова иптәшләргә һәм башка хезмәткәрләргә конкрет бурычлар йөкләнә, республика буенча командировкалар оештырыла. Һәр районда ел саен район Советы сессиясе утырышы милли мәгарифкә багышлана. Ул сессияләрдә катнашу вазифасын, гадәттә, үз өстемә алам.

Район, шәһәр хакимиятләре дә бу эшне аңлап эш итә башладылар. Күпчелек чаралар районнарда планлаштырылган срокта үтәлә иде. Ләкин ата-аналар белән аңлату эшләрен күп эшләргә кирәк иде. Бер генә мисал китерәм. Казанның Азино районында менә дигән мәктәп бинасы төзелеп бетте. Чишмәле урамындагы 149 нчы мәктәп иде бу. Район хуҗаларын бу мәктәпне татар мәктәбе итеп ачарга ризалаштырдык. Микрорайонда ата-аналар белән күп кенә эшләр башкардык. Әмма бу районда яшәүчеләрнең күбесе татар булса да, мәктәпне татар мәктәбе итеп ачып булмады, татар-рус мәктәбе итәргә туры килде. Шунысы кызганыч, күп кенә ата-ананың үз балаларын татар мәктәбендә укытырга һәм милли тәрбия бирергә теләмәве ачыкланды.

Әхмәт Рәшитов. Кадрлар мәсьәләсе ничек?

Васил Гайфуллин. Бу мәсьәлә әлегә тулысынча хәл ителмәгән, бигрәк тә милли мәгариф өчен. Бу аңлашыла да, чөнки бер генә педагогия югары уку йорты да моңа кадәр ана телендә укыту өчен укытучы әзерләмәде. Беренче эш итеп, безнең министрлыкка буйсынган 10 педагогия училищесында да татар бүлекләре булдырдык. Аннары Казанда махсус педагогия колледжы ачтык. Бу колледжда бүген 500ләп бала укый. Минзәлә, Чаллы, Арча, Казанның 1 нче педучилищеларын колледж итеп үзгәрттек. Бу колледжларның барысында да татар теле укытучылары әзерли торган төркемнәр булдырдык. Бу бүлекләргә урта белемле яшьләрне алып, өч ел эчендә тәмамланмаган югары белемле белгечләр әзерләп чыгара башладык. Болар, татар теле укытучылары булып, мәктәпләргә килделәр. Алга таба укуларын дәвам итәргә алар педуниверситетларда читтән торып укыячаклар.

Параллель рәвештә педагогик вузлар белән эшләдек. Чаллы, Алабуга, Казан педагогия институтларында татар төркемнәрен ачтыруга ирештек.

Шушы чаралар якындагы берничә ел эчендә яңа ачылган татар мәктәпләрендә, гимназияләрендә, балалар бакчаларында кадрлар мәсьәләсен тулысынча хәл итәчәк.

Әхмәт Рәшитов. Васил әфәнде, Сез бит министр гына түгел – гаилә башлыгы да! Гаиләгез турында да берничә сүз әйтсәгез иде.

Васил Гайфуллин. Гаиләбез турында шуны әйтә алам. Хатыным Тихния белән беренче тапышуым Минзәлә педагогия училищесында булды. Педучилищеда без дүрт ел буе бер төркемдә укыдык. Аннары юллар аерылды. Мин – Казан педагогия институтына, ул Алабуганыкына китте. Институтларны тәмамлап, икебез дә Мөслимдә эшли башладык. Шунда инде якынаеп киттек, гаилә кордык. Аның әти-әниләре дә, минекеләр дә – колхозчылар. Тәрбияләребез, үткән юлларыбыз бер булгач, безгә бер-беребезгә ияләшү авыр булмады. Конфликтларсыз гына (аларын булдырырга тырышмыйбыз), матур итеп яшәп ятабыз.

Һөнәре буенча Тихния – татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Үз эшенә чын күңелдән бирелгән һәм сәләтле укытучы буларак, аны укучылары да, коллегалары да, ата-аналар да хөрмәт итте. "Татарстанның атказанган укытучысы" дигән мактаулы исемгә дә лаек булды. Ул тәрбияләгән укучыларның бик күбесе укытучылык һөнәре буенча китте, кайберләре журналистлар булдылар, шагыйрь яки язучы булганнары да шактый.

Балаларыбыз турында да мактау сүзләрен генә әйтә алам. Кызыбыз Лилия дә, улыбыз Айрат та урта мәктәпне алтын медальгә, югары уку йортларын исә кызыл дипломга тәмамладылар. Кызыбыз бүгенге көндә балалар врачы булып эшли. Тәлгать исемле егет белән гаилә кордылар. Ул да безнең гаилә әгъзасы булып китте – эшлекле һәм тәртипле егет! Аның әти-әниләре – кода һәм кодагый да – чыгышлары белән авыл кешеләре, безнең кебек! Гел аралашып торабыз. Ике оныгыбыз бар. Буш вакытларыбызда шулар белән күңел ачабыз.

Улыбыз Казан дәүләт университетының юридик факультетын тәмамлады. Хәзер шунда ук аспирантурада укый, бер үк вакытта Татарстан Югары Советында консультант булып эшли. Әлегә өйләнмәгән...

Әхмәт Рәшитов. Педагоглар гаиләсенә ял вакытлары сирәк эләгәдер. Ул вакытларны Сез ничек уздырасыз?

Васил Гайфуллин. Ял вакытлары бик күп эләкми инде ул. Шулай да, төп эштән бушаганда, үземнең галим кеше булуымны искә төшерәм. Берәр фәнни конференциягә – доклад, журналга – мәкалә, монография яки уку әсбабы – дәреслекләр язу белән дә шөгыльләнәм.

Һәр атнага кимендә 20 сәгать вакытны фәнгә багышларга дигән ниятем бар. Шул ниятне җиренә җиткерергә тырышам.

Башны ял иттергән вакытларда вакытлы матбугат белән танышам, әдәби китаплар укыйм. Мөхәммәт Мәһдиев, Фоат Садриев, Миргазиян Юныс, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Тәлгат Галиуллин әсәрләрен укырга яратам. “Казан утлары”, “Идел” журналларын укымыйча калдырмыйм.

Студент елларында көрәш, ату спорты, шахмат белән шөгыльләнә идем. Шахмат белән хәзер дә, вакыт тигәндә, мавыгып алам. Милләттәшебез Гата Камскийның уңышларына сөенәм. Ул катнашкан ярышларда аның партияләрен күзәтәм.

Әхмәт Рәшитов. Васил Габдуллович, безнең редакциягә килеп, әңгәмәгә катнашырга риза булганыгыз өчен, Сезгә ихлас күңелдән олуг рәхмәт! Җаваплы хезмәтегездә зур уңышлар телим, эшләрегез гел уң булсын, милләтебез өчен файдалы гамәлләрегез алга таба да артып торсын, сәламәт булыгыз!

Васил Гайфуллин. Матур теләкләрегез кабул булсын!

Яңа ректор сайлау мажаралары

"Язмыш борылышлары" дип аталган китабымда мин Татар дәүләт гуманитар институтын университетка әйләндерү өчен куйган тырышлыклар турында язган идем. Республикабыз җитәкчеләренең Татарстан бюджетыннан югары уку йорты тотасылары килмәде. Бу институт Казан дәүләт педагогика университетына кушылды. Ике уку йортының исемнәрен кушып, яңа университет булдырылды. Университет исемендәге баштагы өч сүз безнең институтныкыннан калды.

Шулай итеп, мин элек эшләгән җиремә кире кайттым. Мине физика факультетының деканы, физика теориясе һәм методикасы кафедрасының профессоры итеп сайлап куйдылар. Бу эшнең минем өчен яңалыгы юк иде. Ләкин һәр заманның үз мәшәкатьләре туып тора икән. Университетның күп җитәкчеләре алышынган, факультетлар саны арткан, күбесендә – яңа кешеләр, үзгәрәк тәртипләр...

2007-2008 нче уку елы катлаулы шартларда башланып китте. Укытучылар-профессорлар составы кебек, университет ректоры да биш елдан биш елга сайланып куела. Әлегә ректор вазифасын башкаручы Җәмил Газизович Нигъмәтовның да ректорлык срогы 2008нче ел башында тула икән. Югары мәктәп турындагы Россия Федерациясе законы нигезендә, университет ректоры булып эшләргә 70 яшькә кадәр генә рөхсәт ителә. Шуңа күрә, гамәлдәге ректорның вәкаләтләре февраль аенда бетә һәм ул яңа срокка сайлана алмый. Димәк, алдагы ректор сайлауларында хәзер эшләп торган ректор үзенең кандидатурасын күрсәтә алмый – безнең университетның ректоры яңа кеше булачак!..

Менә шушы яңалык бөтен университет коллективының тынычлыгын алды. Ректорат әгъзалары – проректорлар янында, факультетларда, кафедраларда. Аерым-аерым да, төркемнәргә җыелып та сөйләшүләр ешайды. Сөйләшүләрнең темасы, әлбәттә, бер мәсьәләгә килеп төртелә: "Яңа ректор кем булыр?!"

Яңа ректорны сайлау 2008 нче елның февраль аенда гына булачак. Әле ул көнгә кадәр берничә ай вакыт бар. Университетның киләчәгенә битараф булмаган һәр кеше шушы вакыт эчендә нәрсәдер башкарып чыгарга тырыша.

Әлегә ректор вазифасында булган Җ.Г. Нигъмәтов университет уставына төзәтмәләр кертү буенча бик актив эшчәнлек җәелдерде. Ректор өчен яңа уставта төзәтмәнең иң мөһиме – университетта яңа эш урыны булдыру. Мондый урыннар Казан вузларының кайберләрендә (финанс-экономика институтында һәм авиация университетында) булдырылган икән инде. Озак еллар бу вузларның ректорлары булып эшләгән Н.Г. Хәйруллин һәм Г.Л. Дегтярев, вакытлары җиткәч, шушы вазифага керешкәннәр.

Вазифаның исеме дә кызыктырырлык — “университетның президенты” дип атала. Уставта президентка конкрет хезмәт вазифалары күрсәтелмәсә дә, яшәү өчен уңай шартлар иркен күрсәтелгән. Барысы да ректор булган вакыттагы кебек: хезмәт хакы, җиһазлы, телефонлы кабинет, секретарь, ярдәмче, транспорт, бушлай ял итү мөмкинлекләре һ.б.

Әкренләп ректор вазифасына кандидатлар да күренә башлады. Аларның беренчесе психология факультеты деканы профессор Р.А. Вәлиева иде. Бераздан: “Нигъмәтов кыстаганга гына ректор булып сайланырга ризалыгын биргән булган, хәзер ул уеннан кире кайткан, кандидатурасын кире алган”, – дигән хәбәр ишетелде.

Кандидатларның башкалары барлыкка килде. Күп кенә факультетлар (шулар арасыннан – физика факультеты да) проректор Р.Р. Җамалетдинов кандидатурасын күрсәттеләр. Рәдиф Рифкатович реаль кандидатура иде. Ул – үзебезнең элеккеге студент, аспирантурада укыды. Укытучы, декан ярдәмчесе, декан вазифаларын уңышлы үтте, докторлык диссертациясен бик яхшы яклады, профессор булды. Укыту эшләре проректоры буларак, ул университетта бу эшнең тулысынча хуҗасына әйләнде. Ректор буларак та, университетны җитәкләргә ул җитлегеп беткән иде инде. Шуңа күрә дә, факультетларның барысы да диярлек бу кандидатураны хуплады.

Тора-бара, ректор постына кандидатлар булып, беренче проректор Ф.Г. Әхмәдиев, физик тәрбия факультетыннан кафедра мөдире И.Х. Вахитов, көнчыгыш телләре факультеты деканы В.Н. Хисамова, математика факультетынын информатика кафедрасы мөдире Р.Х. Минһаҗев теркәлде. Боларга мәгарифне үстерү институты (ИРО) ректоры Р.Ф. Шәйхелисламов та килеп кушылды.

Бу иптәшләр миңа яхшы таныш, якын кешеләр. Минһаҗев белән Шәйхелисламов – минем якташларым, Мөслим егетләре. Хисамова да, ун елга якын, Татар дәүләт гуманитар институтында минем белән эшләде, чит телләр факультетын җитәкләде, үзен уңай яктан гына күрсәтте. Ф.Г. Әхмәдиев белән дә соңгы елларда еш аралаштык. ТДГИ ректоры буларак, эшем төшеп, мин аңа гел керә идем. Казан шәһәре башкарма комитеты председателенең социаль мәсьәләләр буенча ярдәмчесе буларак, ул һәрвакыт хезмәтем буенча булган сорауларны хәл итүдә гел ярдәм итеп килде.

Кандидатлар арасында миңа И.Х.Вахитов кына таныш түгел иде. Ул моңа кадәр физик тәрбия факультетында кафедра мөдире булып эшләгән, аның белән очрашырга туры килмәде.

Кандидатларның барысы да теоретик әзерлекләре буенча ректор булырга лаек – фән докторлары, профессорлар. Моңа кадәр башкарган хезмәт юллары тел-теш тидерерлек түгел. Мисал өчен, математика факультетының кафедра мөдире Р.Х.Минһаҗевны алыйк. Ул безнең институтның физика-математика факультетын тәмамлады, Мөслим районында укытучы, завуч булып эшләде. Аспирантура тәмамлагач, үзе укыган факультетта эшләде, фән белән нәтиҗәле шөгыльләнде, докторлык диссертациясен әйбәт яклады. Татар дәүләт гуманитар институтында кафедра мөдире, проректор вазифаларын уңышлы башкарды. Информацион технологияләрне, беренчеләрдән булып, ул үзләштерде.

Профессор Р.Ф. Шәйхелисламовны да яхшы беләм мин. Ул да кайчандыр минем укучым иде. Мәктәптә бик яхшы укыды. Мәктәпнең генә түгел, Мөслим районының көчле спортчысы – җиңел атлетика, волейбол, баскетбол буенча перспективасы зур иде. Математика укытучысы, мәктәп директоры булып үзен уңай яктан күрсәтте. Чаллы шәһәренең мәгариф идарәсе мөдире буларак, мин аның эшенә югары бәя бирәм. Мәгариф министры булып эшләгәндә, Р.Ф. Шәйхелисламов җитәкләгән Чаллы мәгариф идарәсенең алдынгы тәҗрибәсе белән уртаклашу өчен, районнарның мәгариф бүлекләре мөдирләрен мин күп тапкырлар Чаллыга алып бардым, Чаллы мәгариф учреждениеләре бу чорда Татарстан Мәгариф министрлыгының эксперименталь базасына әйләнде, дисәк тә дөрес булыр. Милли мәгарифне үстерүдә алар аеруча уңышлы эшләделәр. Мактаулы татар мәктәпләре, гимназияләре барлыкка килде. Рус балаларына татар телен өйрәтү Чаллы мәктәпләрендә уңышлырак барды.

Әмма ни гаҗәп, Р.Ф. Шәйхелисламов Татарстан Мәгариф министрлыгында эшләгәндә, милли мәгарифкә игътибар кимеде. Мин бу хәлне берничек тә аңлата алмыйм. Югарыдагылар, өстән шулай куштылармы, әллә булыр-булмас киңәшчеләр министрның башын әйләндерделәрме — аның бу чордагы эшчәнлеге милләт файдасына булмады диярлек.

Башка факультет деканнары нинди халәттә булгандыр, әйтә алмыйм. Бу көннәрдә минем хәл җиңелдән түгел иде. Деканнар белән сөйләшкәндә, мин Рәдиф Рифкатович кандидатурасын яклавымны белдердем. Бу вакытта әле Әхмәдиев һәм Шәйхелисламовлар "горизонт"та юк иде. Рәдиф Рифкатович белән бер күрешкәндә, ул әйтте: "Әхмәдиев үзенең кандидатурасын күрсәтми, мине якларга булды, үзенең эш урынында беренче проректор булып калу теләге бар," — диде. Шулай әйтсә дә, беркөнне Әхмәдиев минем бүлмәгә килеп керде. "Якын кешем дип, сиңа килдем. Мине үзегезнең факультеттан ректорлыкка кандидат итеп күрсәтегез әле," — ди. Миңа нишләргә? Ничек бар, шуны әйттем. "Без инде бер кандидат күрсәттек, син соңга калгансың, мондый ниятең булгач, иртәрәк кыймылдарга иде," — дидем. Әхмәдиев тә кызык, Рәдифкә бертөрле сөйли, үзе икенче төрле хәрәкәт итә. Соңрак беленде, аның башын ректор Нигъмәтов әйләндерә икән. Җамалетдиновны ректор иттермәскә, аңа каршы көчле кандидатура куярга, моны булдырсаң, син генә булдыра аласың, янәсе.

Көчле кандидатура, дигәннән, Нигъмәтов тагын бер "көчле"не тапкан – республикабыздагы мәгарифне үстерү институты ректоры Шәйхелисламовны "кодалый" башлаган.

Шәйхелисламов та килеп җитте минем бүлмәгә. Соравы шул ук: ректор булып сайланырга миннән ярдәм кирәк! Әхмәдиевка әйткән сүзләрне аңа да әйтергә туры килде.

Шәйхелисламовка да бу идеяне Нигъмәтов биргән булып чыкты. Нигъмәтовның бу көннәрдәге тәртибен аңлый торган түгел. Кемне генә үгетләмәде инде ректор булырга: кем булса да ярый, тик Җамалетдинов кына булмасын! Аның ни өчен тырышканын аңларга була. Алда олы максат тора — ректорлык срогы бетүгә, ТДГПУның президенты булып сайланырга! Аның фикеренчә, ректор Рәдиф булса, бу максат барып чыкмаячак. Шуңа күрә, төрле планнар корыла, Рәдифне яклаучыларга каршы яңа "блок" оеша.

Сайлау чорында "блок"та катнашучыларның бурычларын тәгаенләү өчен, берничә киңәшмә уздырыла. Киңәшмәләр ИРО бинасында, аның ректоры Шәйхелисламов бүлмәсендә уза.

Үзебезнең университет бинасыннан читкә китеп, сер чыкмаслык итеп "конспирация" оештырсалар да, анда сөйләгән сүзләр, ничектер, барыбер мәгълүм була иде.

Вакыт уза торды. Кандидатларның сайлаучылар белән очрашу вакыты килеп җитте. Бу вакытта инде кандидатлар саны өчкә генә калган иде. Тәртип буенча, кандидатлар исемлеген башта безнең республика җитәкчелеге тикшерә. Аннан исемлек Мәскәүгә китә. Алты кандидатның өчесе Мәскәүдә Мәгариф һәм фән министрлыгында сызып ташлана. Калган өчесе –Җамалетдинов, Әхмәдиев, Шәйхелисламов сайлауларда катнашса ярый дип, кире университетка җибәрелә.

Факультетларда, университетның башка тармакларында сайлау алды җыелышлары бара. Һәр кандидат үз платформасы буенча чыгыш ясый, университетны алга җибәрү турында вәгъдәләр бирә.

Кандидатлар итеп күрсәтелгән Әхмәдиев һәм Шәйхелисламовлардан очрашуда катнашучыларның канәгать булмаулары билгеле булды. Әлбәттә, моның объектив сәбәпләре дә бар. Беренче проректор буларак, Ф.Г. Әхмәдиев университетта активлык күрсәтә алмады. Бу эш шулай махсус оештырылды кебек, аңа йөкләнгән вазифалар артык тыйнак булды. Халык аның ни белән шөгыльләнгәнен белми дә иде. Ә Фаил Габделбәровичның эшләргә сәләте бар иде. Казан шәһәре хакимияте җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча ярдәмчесе булганда, ул актив эшләде. Мәгариф министры һәм ТДГИ ректоры булып эшләгәндә, мин аның белән шактый файдалы эшләр башкардым.

Ә Р.Ф. Шәйхелисламовны безнең университет хезмәткәрләре бик аз белә иде. Җитмәсә, аның әле министр вазифасыннан яңа гына алынган вакыты. Аның министрлыктан китү сәбәбен тегеләй дә, болай да гаманладылар. Алар Шәйхелисламов файдасына түгел иде. Очрашулардан канәгатьсезлек шуннан да килгәндер...

Җ.Г. Нигъмәтов безне бу чорда тагын бер кат гаҗәпләндерде.

Аның кушуы буенча, Әхмәдиев белән Шәйхелисламов үзләренең кандидатураларын кире алдылар, киләчәктә ректор сайлауларында катнашудан баш тарттылар. Ректор булып сайланырга бер генә кандидат – Р.Р. Җамалетдинов кына калды.

Нигъмәтов һәм аның тарафдарлары фикеренчә, бу хәлдә ректор сайлаулары уздырылырга тиеш түгел. Ректорны сайлау, берничә кандидат булганда, альтернатив тәртиптә генә уз-

дырылырга тиешлелеге турында документ барлыгын алар белми түгел.

Мәсьәләне ачыклау өчен, ректорны сайлау буенча университет комиссиясе рәисе, университетның кадрлар бүлеге начальнигы Н.А. Гончаров, консультация сорап, Мәскәүгә мөрәҗәгать итә. Россия Мәгариф һәм фән министрлыгыннан җавапны язмача бирергә ышандыралар. Җавап ректор исеменә җибәрелә. Нигъмәтов әлегә ректор вазифасында. Җавапта ачык әйтелә: сайлау кампаниясе вакытында ректор сайлауларында алты кеше катнашкан, альтернатива булган. Россия Мәгариф министрлыгында болардан өчесенә ризалык бирелгән. Алар сайлау кампаниясендә катнашканнар. Альтернатив тәртип бозылмаган. Ике кандидатның соңгы вакытта гына сайлау "марофон"ыннан чыгуы ректор сайлау кампаниясен туктата алмый. Сайлау комиссиясе билгеләгән вакытта сайлау процессын башкарып чыгарга тиеш.

Җ.Г. Нигъмәтовка бу җавап ошамый. Җавап хаты яшерелә. Яңа план корыла: ректорны сайлау процессын булдырмаска, альтернатива юклыкны сәбәп итеп алырга! Ректорның вәкаләтләре беткәч (2008 нче елның 14 нче февралендә), ректор вазифасын Әхмәдиевкә, беренче проректор вазифасын Шәйхелисламовка тапшырырга планлаштырыла. Университетның президенты булып Нигъмәтов сайланачак. Әкренләп ректор сайлауга әзерлек башланачак. Ректор сайлауга әзерлек комиссиясен Әхмәдиев җитәкләргә тиеш. Яңа сайланган ректор Шәйхелисламов булыр, дип планлаштырыла.

Шул арада Нигъмәтов ашыгыч кына ректорат утырышын җыя. Ректор белән рәттән таныш түгел кеше утыра. Ул Юстиция министры урынбасары икән. Нигъмәтов соравы буенча, аңа безнең коллективны ректор сайлавын уздырмаска күндерү бурычы йөкләнгән. Янәсе, альтернатива булмаган тәкъдирдә безнең сайлау легитим булмый. Безгә университетның гыйльми советын җыярга һәм ректор сайлау буенча конференцияне булдырмау турында карар чыгарырга куша.

Деканнар советы председателе — физик тәрбия факультеты деканы Абзалов, Юстиция министрлыгы кешесенә каршы килеп, кискен генә чыгыш ясады. Абзалов утырыш алдыннан гына Россия Мәгариф министрлыгы белән сөйләшкән булган. Министрлык вәкиле ректор сайлау буенча конференция уздырырга бернинди дә киртә булмавын, сайлау билгеләнгән вакытында уздырылырга тиешлеген тагын бер кат раслаган булган. Ринат Абзалович халыкка бу турыда да җиткерде. Нигъмәтов-

ның Мәскәүдән килгән җавапны яшереп куюы фаш ителде. Сайлауны туктату нияте өзелде, ләкин бу киңәшмәдән соң конференцияне булдырмый калуның икенче варианты буенча эш башланды. Конференциягә сайланган делегатлар инде билгеле. Нигъмәтов "блогы" активистлары аларның өйләренә юнәлә. Делегатлар икенең берсен сайларга тиеш: яки конференциягә килмәскә, яки Җамалетдиновка каршы тавыш бирергә! Бу шартлар үтәлгәндә сайлау яки бөтенләй булмый, яки кире нәтиҗә була.

Әмма конференция билгеләнгән вакытта узды. Конференция делегатлары барысы да килделәр. Профессор З.З. Мифтахов, авыруы сәбәпле, килә алмаган иде, ул өендә сайлады.

Конференциядә сайланачак ректор кандидатурасын хуплап, өч делегат чыгыш ясады: профессор Ф.Ф. Харисов, мин һәм университетка кабул итү комиссиясенең җаваплы секретаре Р.Р. Миңнәхмәтов.

Р.Р. Җамалетдиновны күптәннән беләм. 90нчы еллар башында, мин Татарстан Мәгариф министрлыгында эшләгәндә, милли мәгарифне торгызу, аякка бастыру буенча күп эш башкарылды. Татар мәктәпләре, гимназияләре, лицейлары, балалар бакчалары күпләп ачылды. Болар өчен методик ярдәмлекләр, дәреслекләр юк дәрәҗәсендә иде. Программаларга һәм уку планнарына кертелгән милли-төбәк компонентлы дәресләре өчен дә (рус балаларына татар теле, Татарстан, татар халкы тарихы, географиясе, экологиясе, экономикасы һ. б.) методик кулланмалар, дәреслекләр юк иде. Министрлыкта шушыларны булдыру буенча эшләүче фәнни үзәк оештырырга ниятләдек һәм оештырдык та. Бу үзәккә кадрлар тупладык. Җамалетдинов фамилияле бер яшь егет шулар арасында иде. Ул вакытта әле ул пединститутның татар теле факультеты студенты гына булган.

Еллар үтә торды. Мәгариф министрлыгыннан мин Татар дәүләт гуманитар институтына күчтем. Факультетларның яңа уку планнары белән шөгыльләнәбез. Татар филологиясе факультетының уку планнарын эшләгәндә, пединститутка мөрәҗәгать иттем. Рәдиф Рифкатович анда декан булып эшли иде. Биредә инде яңа уку планнары төзелгән. Алар үрнәге безнең эшне шактый җиңеләйтте.

Бераздан Рәдиф Рифкатович Җамалетдинов ТР Министрлар Кабинетының Татарстан халыкларының телләрен үстерү бүлегендә эшли башлады. Югары уку йортларында татарча укыту буенча кайбер финанс чыгымнарын шушы бүлек ярдәмендә ала идек. Безнең институтка аның ярдәме күп тиде. Шул

ярдәм белән без студентлар өчен күп кенә дәреслекләр, методик ярдәмлекләр бастырып чыгардык.

Бераздан мин дә ТДГПУның физика факультетында декан булып эшли башладым. Беренче проректор булып эшләүче Рәдиф Рифкатович янында көн саен диярлек булам. Күп кенә мәсьәләләр аның ярдәме белән хәл ителә. Нинди генә консультация кирәк булса да, аңа мөрәҗәгать итәбез. Бу эштә ул кирәкле тәҗрибә туплаган. Мәсьәләләр вакытында, тиешенчә хәл ителә.

Ректор вазифасына керешсә дә, Рәдиф Рифкатович бу мөһим эшне тиешенчә башкара алачак. Аның үткән юлы, туплаган белемнәре, практикада алган күнекмәләре алда торган бурычларны профессиональ дәрәҗәдә хәл итүдә ныклы нигез булачак. Безнең университетның ректоры булырга ул инде әзер. Бүгенге көндә аның башкарган фидакарь хезмәте дә ректор дәрәҗәсенә торырлык!..

Мин үземнең чыгышымда шул хакта сөйләдем...

Сайлаулар ябык тавыш бирү тәртибендә барды. Нәтиҗәсе Р.Р. Җамалетдинов файдасына булды. Конференциядә катнашучыларның 73%ы аны яклап тавыш биргән булып чыкты. Ләкин 70тән артык сайлаучы Җамалетдиновка каршы тавыш биргән. Димәк, Нигъмәтов "блогы" тик ятмаган, конференция делегатларының шактыен үз ягына аудара алган. Ләкин бу сан сайлау нәтиҗәсен үзгәртә алмады. Конференция Рәдиф Рифкать улын ректор булып сайлануы белән котлады. Сайлау комиссиясе беркетмәсе Мәскәүгә китте. Аннан Р.Р. Җамалетдиновның ректор булып сайлануы турында приказ килде. Шуннан соң университет җитәкчелегендә һәм факультетлар тормышында кайбер үзгәрешләр башланды...

Минзәлә педагогия училищесы укучылары Васил Гайфуллин, Нургаян Җәмилев.

Тулай торакта күңел өзгәләнгән минутларда...

Мөслим урта мәктәбендә үз классым укучылары янәшәсендә.

Кызыбыз Лилиягә – бер яшь!

Рус теле укытучысы – Түбән Табын җидееллык мәктәбендә класс җитәкчем булган Гали Сәетович Камалов оныгы белән.

Казанның М. Горький исемендәге клубында, концерт алдыннан, баянчы Кәрим Сафин белән.

Кызыбыз Лилия һәм киявебез Тәлгать белән ЗАГСтан соң. 1987 нче ел.

Минзәлә педучилищесын тәмамлаучылар – Казан дәүләт педагогия институты студентлары. Беренче рәттә (уңнан сулга): Илгиз Минһажев, Люция Кәримова, Динә Сөләйманова, Васил Миннәхмәтов; икенче рәттә: Роберт Сәрвәров, Васил Сәрвәров, Тәзкирә Ханова, Васил Гайфуллин, Илдар Галәветдинов; өченче рәттә: Илгизәр Гыйззәтуллин, Карл Бикмәтов, Карл Әхмәтов. 1959 нчы ел

Минзәләдә узган фәнни-практик конференциядә Мөслим районы делегациясе. 1965 нче ел.

КДПИның физмат факультеты деканы – Мөслим егете Илгиз Низамовбелән әңгәмә вакытында.

“Варзи-Ятчи” курортында Әсхәт Хәбибуллин белән. 1967 нче ел.

Чиләбе шәһәрендә яшәүче туганнарыбыз Кәшбетдин абый, Гөлфәния, Гөлбану, Рамил, Дамир Гыйльметдиновлар, 1976 нчы ел.

Дустыбыз Сәгыйть Шәйхрамов.
Мәскәү, 1986 нчы ел.

А. И. Герцен исемендәге Ленинград пединститутында – Г. Ш. Әхмәтҗанов, С. Г. Габдуллина, Т. М. Гайфуллина, В. Г. Гайфуллин. 1974 нче ел.

Туганыбыз Әсләхетдин Гыйльметдинов.
Чиләбе, 1970 нче ел

Сәвия апабыз Галимҗан җизни Әхмәтҗанов белән...

Талибулла абый Гайфуллин.
1944 нче ел.

Туганыбыз Кәшбетдин абый армия хезмәтендә. 1953 нче ел.

Туганнарыбыз Фәһия, Энже, Рәис, Расих, Разиф Гайфуллиннар.

Рафаэль Гарипов армия хезмәтендә.
1958 нче ел.

Вәзир абый Гайфуллин.
1953 нче ел.

Сеңлебез Фәһия Гайфуллина.

Сәвия апаның кызлары Гөлүзә, Әлфия, Гөлшат Әхмәтҗановалар.

Хатыным Тихния ханым янәшәсендә. Мөслим. 1970 нче ел.

Мөслим районында Укытучылар көне бәйрәме. Мәгариф бүлеге мөдире жырлый. Баянда – Фаил Ханов, арткы планда Күбәк мәктәбе завучы К. М. Әхмәтов һәм партия райкомының бүлек мөдире Х. М. Шәмсетдинов.

Тихния Гайфуллина –
Татарстанның атказанган укытучысы.
1986 нчы ел.



Авылдашларым Рәҗәп Ханов һәм Рафаэль Нуретдинов. Мөслим, 1958 нче ел.

Физика кафедрасы мөдире З. И. Усманов белән доцент В. Г. Гайфуллин конференция программасы төзиләр. КДПИ, 1978 нче ел.

Мәктәп җитәкчеләренең белемен күтәрү факультетында яңа килүчеләрне каршы алырга хәзерләнәбез.

Ленинград истәлеге. 1971 нче ел.

Мәскәүдә белем күтәрү курсларында. 1983 нче ел.

Татарстан һәм Мари-Эл республикаларының мәгариф эшендәге хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул кую мизгеле. Министрлар Г. М. Мустаев, В. Г. Гайфуллин, урынбасарлар В. А. Боговарова, Г. Г. Садрыев. Казан. 1993 нче ел.

Мамадыш районы хакимияте җитәкчеләре Татарстан Мәгариф министрын ипи-тоз белән каршы алалар. 1992 нче ел.

Гроссмейстер Гата Камский һәм Мәгариф министры Васил Гайфуллин шахмат тактасында көч сынашыр алдыннан.
Казан, 1994 нчы ел.

Мөслим районы укытучыларының шахмат беренчелеге. Д. Г. Галиев һәм В. Г. Гайфуллин партиясен Ф. Л. Ханов күзәтә. 1969 нчы ел.

Аксубай районында.
Ихлас дуслар белән үзара
аңлашып яшәү – үзе бер
җан рәхәте!..

Балык Бистәсе районында “Укытучылар Сабантус”нда.

Төркия Мәгариф министрлыгы белән килешү төзү вакыты. Анкара, 1991 нче ел.

Төрек лицеенда укучыларның кул эшләре белән танышу. Истамбул, 1992 нче ел.

Төркиянең балалар бакчасында. Анкара, 1993 нче ел.

Истамбул шәһәренең мәгариф идарәсендә. Төркия, 2002 нче ел.

Татарстан һәм Һинстан хөкүмәтләре арасында мәгариф һәм фән өлкәсендәге килешүгә кул кую мизгелләре. Дели шәһәре, 1996 нчы ел.

ТР Премьер-министры Ф.Х. Мөхәммәтшин ЮНЕСКО вәкиле В.А. Бацын һәм ТР Мәгариф министры В.Г. Гайфуллин белән әңгәмә вакытында. Казан, 1996 нчы ел.

Министрны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ренат Харис котлый.
1997 нче ел.

"Россия Федерациясенең атказанган укытучысы" билгесен һәм дипломын В.Г. Гайфуллинга В.В. Кириенко тапшыра. Пермь шәһәре, 2004 нче ел.

Татарстан Республикасының Беренче Президенты М.Ш. Шәймиев бүлмәсендә.
Казан, Кремль. 1991 нче ел.

Президент Минтимер Шәрипович белән мәктәп балалары янәшәсендә.

Укытучыларның август конференциясендә. Алабуга шәһәре, 2004 нче ел.

Татарстанның данлыклы мәгариф бүлекләре мөдирләре И.Х. Гыйльфанов (Апас), В.М. Зәкиев (Балтач), Ш.З. Зиннуров (Саба), И.Г. Шакиров (Кайбыч) белән. Казан, 1995 нче ел

Татарстан Республикасының Премьер-министры – хәзерге Президентыбыз Р.Н. Миннеханов бәйрәм белән котлый.

Дуслар-рухташлар җыелган җирдә. Сулдан уңга: Т.К. Сәгыйтов, Р.Ш. Шәймәрданов, В.Г. Гайфуллин, И.Г. Әхмәтҗанов, М.М. Хаснуллин, М.М. Таишев, Р.М. Галимов. Казан, 2007 ел.

Кырым-татар индустриаль-педагогика университеты проректоры Рәмзи Рәфикович Дәүләтов белән әңгәмә. ТДГИ, 2004 нче ел.

Бүләкләнүчеләр "Укытучылар көне" бәйрәмендә.

Питрәч районында яңа мәктәп ачу тантанасы. 1994 нче ел.

Мәгариф мөдирләре киңәшмәсендә. Азнакай, 1995 нче ел.

Академиклар Т.Н. Галиуллин, В.Г. Гайфуллин, Х.Й. Миннегулов.
Казан, 2004 нче ел.

Минзәлә педучилищесы юбилеенда. Уңнан сулга: Рафаэль Галявов, Хәнәфи Гәрәев, Васил Сәрвәров, Васил Гайфуллин, Мәрьям Абдуллина, Наиб Ләисов.
2007 нче ел.

Физика факультеты деканы
В. Г. Гайфуллин.

30 ел элек физмат факультетын тәмамлаучыларны тәбрикләү. Уннан сулга: математика факультеты деканы М. З. Хөснетдинов, физика теориясе һәм методикасы кафедрасы мөдире Ә. С. Габидуллин, физика факультеты деканы В. Г. Гайфуллин, декан ярдәмчесе Н. Г. Гафуров.

Арча педагогия колледжы җитәкчесе И. А. Сәгъдиев белән әңгәмә һәрвакыт мәгънәле дә, күңелле дә! Арча, 2000 нче ел.

Кафедра мөдире, профессор Р.Х. Минһаҗев белән дәрес тыңлаганда. 2006 нчы ел.

ТДГИ ны тәмамлау турындагы дипломны ректор яшь белгеч Илнурга тапшыра.
ТДГИ, 1998 нче ел.

Татар дәүләт гуманитар институты студентлары диплом алгач. 1998 нче ел.

Ректорның студентлар белән әңгәмәсе. ТДГИ, 2002 нче ел.

ТДГИ проректоры Т.М. Талманова, ректор В.Г. Гайфуллин, бүлек мөдире Р.Ф. Мельникова. 2003 нче ел.

ТДГИ студентларының «Ягымлы яз» фестивалендә. 1999 нчы ел.

Гроссмейстер Сандугач Шәйдуллина белән көч сынашу мизгелләре.

Казан каласының Бауман урамында Республика көнен бәйрәм иткән мизгелләр. Дусларыбыз Римма һәм Карл Әхмәтовлар белән.
30 нчы август, 1996 нчы ел.

Житмеш яшем тулган көн! Янәшәмдә – гомерлек дустым Р.Ш. Шәймәрданов.
23 нче март, 2007 нче ел.

Кисловодскида ял иткән чаклар.

Мөслим район Советы Башкарма комитеты рәисе Г.Х. Хафизов белән
В.Г. Гайфуллин Железноводск шәһәрендә ял вакытында.

“Казан шәһәренең Ел укытучысы”
Тихния Гайфуллина. 1992 нче ел.

Академик М. И. Мәхмүтов КДПИда
мәктәп җитәкчеләренең белемен
күтәрү факультетында.

Аксубай районы хакимияте башлыгы М. Ш. Халитов белән хәл ителәсе
мәсьәләләр турында сөйләшкән мизгелләр. 1994 нче ел.

Бертуганнар – унганнар!..

Гомернең бәхетле мизгелләре



Оныкларга яңа әкият сөйләгәндә. 2004 нче ел.

Тихния һәм Васил Гайфуллиннар балалары Лилия, Айрат һәм гаилә дусты Равил Шәймәрданов белән. Казан каласы, 2005 нче ел.

Туганнарыбыз Флера Шәйдуллина һәм Рәис Гайфуллин белән.

Без дә ашны тәмле пешерә беләбез!..

Якыннар белән Табигать-Ана кочагында.

Туганнар бергә җыелгач, бигрәк тә күңелле, рәхәт була икән!.. Сулдан уңга: Сәвия апа, мин, Фәүзия Фатыйхова (Тихния ханымның сеңлесе), хатыным Тихния, ирле-хатынлы Вәзир һәм Хәерлевәрә Гайфуллиннар, сеңлебез Фәһия Гайфуллина, Сәвия апаның кызы Әлфия, сеңлебез Һәдия Гайфуллина.
24 нче март, 2007 нче ел.



Нәсел шәҗәрәсен Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Нәҗип Нәккаш** эшләде

Өзлексез педагогик белем – көн таләбе

Кешелек дөньясы XXI гасырга чыкты. Бу гасырны: "Мәгълүматлылык гасыры булыр", – дип гоманлыйлар. Хәзер үк инде күпләп яңа технологияле җитештерү тармаклары, яңа белгечлекләр барлыкка килә.

Үз чиратында, бу яңалыклар мәгариф системасы алдына яңа таләпләр куя. Дөньяның күп кенә илләре үзләренең мәгариф системаларын яңача кора башладылар, аңа өстенлекле тармак итеп карыйлар.

АКШ, Япония, Германия, Англия кебек илләрдә яшьләрнең 80-90%ы тулы урта белемгә ия. Шуның белән беррәттән, күп кенә илләрдә бу сан әлегә бик түбән. Япония һәм АКШта урта мәктәпне тәмамлаган яшьләрнең 70% тан артыгы югары уку йортларына керә. Бу илләрдә һәр кешегә гомуми мәҗбүри югары белем бирү турындагы закон көн тәртибенә куелырга тора.

Узган гасырда ук инде прогрессив илләрдә өзлексез уку идеясе хөкем сөрде. Идеянең максаты – белемнәрне һәрвакыт яңартып тору, кешенең гомере буе белемнәрне тулыландырып, камилләштереп торуына ирешү. Мондый илләрнең экономикасы да һәрвакыт үсештә. Мисал өчен, Америка Кушма Штатларын алыйк. Бу илдә 1995 елда югары уку йортларында 12 млн. кеше укыган. Аларның 7 миллионы – гадәти студентлар, ә 5 миллионы – өлкән яшьтәге өзлексез укучылар. Соңгы елларда бу илдә 25 яшькә кадәр студентлар саны – 15% ка, өлкән яшьтәгеләр саны 114% ка арткан. Көнбатыш илләрендә эшкә кабул иткәндә: "Эшләргә теләсәң, даими рәвештә укы, белемеңне күтәр!" – дигән таләп куела.

Шулай итеп, югары технологияләр кулланып эшләүче җәмгыять яңа белемнәр үзләштерергә сәләтле белгечләр әзерли, һәр кешегә өзлексез уку өчен, шартлар тудыра.

Күп кенә илләрдә өзлексез укуны тәэмин итү өчен, программалар төзелә. Моңа компьютер технологияләрен үзләштерү дә, экономика, мәгълүмати чараларны өйрәнү дә, яңа техника, технология белән танышу да, гомуми грамоталылыкны камилләштерү дә керә.

Шуны да әйтергә кирәк. Әлегә өзлексез белем эстәү теориясе эшләнмәгән, ләкин бу эшнең концепциясе, моделе, аның компонентлары, звенолары турындагы документлар эшләнеп ята. Моңа омтылыш безнең республикада да башланды инде. Шунсыз мөмкин дә түгел, чөнки бездә яшәп килгән күп кенә кимчелекләрнең булуы – күп кенә тармакларда камил белемле белгечләрнең җитмәве аркасында бит?! Кайсы гына тармакны алсак та – мәгарифнеме, мәдәниятнымы, сәламәтлек саклаунымы, сәүдә, тышкы бәйләнешләрнеме, җитәкчелекнең түбән яки югары буыннарынмы – компетентлы, югары квалификацияле белгечләрнең җитмәве сизелә.

Илне чолгап алган кризисның сәбәбен дә җаваплы урыннарда хезмәт итүчеләрнең белемнәре, грамоталыгы, профессиональлеге һәм культура дәрәҗәсе җитешмәүдән эзләргә кирәк.

Экономика, авыл хуҗалыгы, мәгариф, сәламәтлек саклау, көнкүреш хезмәте тармакларында башланган реформалар да шуплыктан аксый.

Хәзерге шартларда камил дәрәҗәдә әзерләнгән профессионал, дип, тирән һәм күпкырлы белемнәргә ия булган, шул белемнәрне иҗади кулланып җәмгыять өчен дә, үзенең гаиләсе өчен дә югары нәтиҗәләргә ирешүче белгечне әйтергә була. Фәнни-техник һәм социаль прогресс шәхеснең күпкырлы, универсал булуын таләп итә. Белгечләрне әзерләгәндә бу таләп тә үтәлергә тиеш.

Өзлексез белем концепциясе нигезендә, һәр кешенең – аның нинди яшьтә һәм уку йортында алган белгечлегенең нинди һәм кайда, кем булып эшләвенә карамастан, системалы рәвештә үз белемен һәм квалификациясен күтәрергә мөмкинлек бирелә. Шуның өстенә, һәр кешенең бу эшкә теләге һәм әзерлеге булырга тиеш. Кешенең бу сыйфатлары һәм мөстәкыйльлеге урта мәктәптә, аннары профессиональ белем бирү уку йортында, соңрак, белем күтәрү уку йортларында тәрбияләнә.

Шулай итеп, гомуми урта белем бирүче мәктәп – өзлексез белем бирү системасының башлангыч звеносы. Мәктәптә фән нигезләре өйрәнелә, профессияләр турында мәгълүмат бирелә, күнекмәләр булдырыла, мөстәкыйльлелек, белемнәрне үзле-

геннән өйрәнү күнекмәләре бирелә һәм укучының сәләте ачыла, шәхес тәрбияләнә.

Бу бурычларны мәктәптә укытучы башкара. Аның үзенең дә бу эшне башкарырга теләге дә, сәләте дә булырга тиеш. Бәхетебезгә, безнең мәктәпләрдә мондый укытучылар аз түгел! Алар дәресләргә тырышып әзерләнәләр, тәрбия эшләрендә катнашалар, күп вакытларын мәктәптә уздыралар – балалар янында булалар. Шундый укытучыларның булуы аркасында, мәктәп тормышына иҗади эшләү алымнары, фәнни тикшеренүләр, педагогик тәҗрибәләр алып бару, яңа технологияләр килеп керде.

Барлык мәктәпләрдә бертөрле генә уку планы белән, бердәй таләпләргә буйсынып эшләү заманы үтеп бара. Һәр мәктәп үзенең "йөзен" күрсәтергә тырыша. Яңа типтагы уку йортлары барлыкка килә. Лицейлар, колледжлар, гимназияләр, физика-математика, гуманитар фәннәр, экология, экономика, физкультура-спорт, музыка, чит телләрне тирәнтен өйрәнү мәктәпләре һәм башка юнәлештәге мәктәпләр эшли.

Кызганычка каршы, новаторлар янәшәсендә яңалыкларны кабул итмәүче, нәтиҗәле алымнар белән эшләүдән мәхрүм, элек өйрәнгәннәр белән генә эшләүчеләр дә бар. Аларның саны да аз түгел. Әлбәттә, мондыйлар укучыларга хәзерге таләпләр югарылыгында белем бирә алмыйлар.

Моның сәбәбе, көн кебек, ачык: болар кайчандыр педагогия уку йортларында алган белемнәренә һәм күнекмәләренә генә таяналар, белемнәрен камилләштерү өстендә системалы эшләмиләр. Күренекле педагог К.Д. Ушинскийның: "Укытучы даими укып торганда гына укытучы була ала", – дигән сүзләре бүгенге көндә дә аксиома булып тора.

Республикада эшләүче укытучыларның 95% ка якыны югары белемле булса да, тормыш тукталып тормый, заман таләп иткән белемнәр өстәлә, яңалыклар барлыкка килә...

"Өзлексез педагогик белем нәрсә соң ул?" – дигән сорау туа. Моңа җавап шул: өзлексез педагогик белем – укытучының даими рәвештә гомуми мәдәни, социаль-әхлакый һәм профессиональ юнәлештәге белемнәрен тулыландырып торуы.

Өзлексез педагогик белемнең системасы булырга тиеш, һәм ул берничә этаптан тора.

Беренче этап: гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларга профессиональ юнәлеш бирү, педагогик эшкә сәләтле укучыларны табу, аларны педагогия уку йортларына керергә әзерләү.

Икенче этап: педагогия уку йортларында профессионал укытучы әзерләү.

Өченче этап: дипломлы укытучының үз белемен күтәрү буенча даими эшләве, белем күтәрү курсларында булу.

Өзлексез педагогик белем системасында бу этапларның һәрберсенең үзенчәлекле роле бар. Мисал өчен, **беренче этапка** күз салыйк. Педагогия уку йортларында укытып кына, теләсә кемне чын педагог итеп тәрбияләү бик авыр. Мәктәп елларында ук аерым укучыларның сәләтләрен ачу-өйрәнү, сәләтле балалар белән аерым шөгыльләнү, аларга укучылар белән эшләү өчен вазифалар тапшыру кебек эшләр булырга тиеш. Мәктәпне тәмамлаганда инде, бу укучының укытучылык эшенә сәләте барлыгы турында нәтиҗә ясарга мөмкин. Профессионал уку йортында мондый абитуриентлардан чын белгеч әзерләргә була.

Профессиональ юнәлеш бирү эшенең әһәмиятен тирән аңлап, Көнбатыш илләре мәктәпләрендә бу юнәлештә махсус белгечләр эшли. Алар укучыларны өйрәнәләр, алар белән даими эшлиләр, консультацияләр, аерым белгечлекләр буенча курслар уздыралар, укучылар һәм ата-аналар өчен профессияләр турында ярдәмлекләр әзерлиләр. Шушындый әзерлектән соң, педагогия уку йортларына кабул ителүчеләр арасында очраклы кешеләр булмый.

Кызганычка каршы, безнең ил уку йортларында бу практиканы куллану әлегәчә юк. Бездә кабул итү имтиханнарын тапшырган һәр кеше укытучы була ала, дип уйлыйлар.

Профессиональ юнәлеш бирүне урта һәм югары педагогия уку йортлары да башкара. Бу эш ачык ишекләр көне уздыру, укучыларны педучилищеларга, пединститутларга чакыру формасында бара. Аерым эпизодлардан торган мондый очрашулар көтелгән нәтиҗәне бирми. Мәктәп һәм педагогия уку йортлары коллективлары бергәләп даими эшләгәндә нәтиҗә күпкә уңай булыр иде.

Элегрәк елларда мәктәпләрдә педагогик класслар педагогия уку йортларына абитуриентлар әзерләү буенча зур эш башкаралар иде.

Казан шәһәренең 11нче, 30нчы, 52нче мәктәпләрендә, Чаллы шәһәренең 27нче, 35нче, Зеленодольскиның – 10нчы, Кукмара районының – Зур Сәрдек, Лаеш районының Никольский мәктәпләрендә бу класслар шактый уңышлы эшләделәр. Педагогия уку йортларына бу класслардан күпләп әзерлекле абитуриентлар килә иде. Югарыда саналган мәктәпләрдә булачак педагоглар әзерләү эше гөрләп бара иде. Ул укучыларга педагогика һәм психологиядән махсус дәресләр керде, укучылар класс җитәкчеләренең ярдәмчеләре булдылар, укучылар белән тәрбия

чаралары уздырдылар, түбән класс укучыларына дәрес биреп карадылар. Кызганычка каршы, бу чаралар соңгы елларда сүлпәнләнеп бара.

Урта мәктәп һәм югары мәктәп коллективлары бергәләп эшләгәндә, педагогия уку йортына килүчеләрнең сыйфатын яхшырту мөмкинчелеге зур. Югары мәктәпнең һәр факультеты, һәр кафедрасы мәктәпләрдә үзенең педагогик классын булдыра ала. ТДГПУның физика факультеты, мәсәлән, 2008-2009 нчы уку елында мәктәпләр белән килешү төзеп, түбәндәге мәктәпләрдә педагогик класслар ачты: физика теориясе һәм методикасы кафедрасы – Теләче районының Алан урта мәктәбендә һәм Актаныш районының 2нче номерлы урта мәктәбендә; теоретик физика кафедрасы – Казан шәһәренең 51нче һәм Буа районының академик Р.З. Сәгъдиев исемендәге мәктәбендә; гомуми һәм эксперименталь физика кафедрасы – Буа шәһәренең махсус гимназиясендә һәм Казан шәһәренең 18нче татар гимназиясендә; математика һәм информатика кафедрасы – Балтач районы һәм Зеленодольск районы мәктәпләрендә.

Килешү нигезендә, кафедралар мәктәпләр өчен физика, математика, информатика фәннәреннән уку программаларын камилләштерәләр, дәреслекләр белән тәэмин итүдә булышалар, югарыда күрсәтелгән фәннәрдән методик ярдәмлекләр язалар, укучылар белән дәресләр уздыралар, программаларның авыр темалары буенча консультацияләр ясыйлар, БДИ буенча биремнәрне чишәргә өйрәтәләр, укытучылар белән методик семинарлар оештыралар. Бу чаралар физика факультетына укырга килүчеләрнең теоретик һәм практик әзерлеген яхшырту өчен уздырыла.

Икенче этап – педагог әзерләүнең төп этабы. Белгечләр әзерләүче башка югары профессиональ уку йортларыннан югары педагогия уку йортлары аерылып тора. Аларга катлаулы бурычлар йөкләнгән. Техника юнәлешендәге югары уку йорты техникага кагылышлы фәннәрне белүче инженерлар әзерләп чыгарса, ул үзенең бурычын тулысынча үтәгән була. Педагогия уку йортының бурычы катлаулырак. Беренчедән, ул үз фәнен яхшы белүче укытучы әзерли. Икенчедән, ул әзерләгән белгечләр яшь буынның дөньяга карашын тәрбияләргә, күпьяклы үсешен булдырырга тиеш. Тагын шунысы да бар: мәктәп практикасы күп кенә очракларда педагогика фәненнән алда бара. Укытучылар әзерләгәндә бу яңалыклар да исәпкә алынырга тиеш...

Хәзерге укытучының нинди булырга тиешлеге аның профессиограммасында билгеләнгән. Профессиограмма – укытучы нинди белемнәргә һәм нинди шәхси сыйфатларга ия булырга тиешлеген раслаган фәнни документ. Укытучының нинди белемнәргә ия булырга тиешлеге белгечлеге буенча квалификация характеристикасында күрсәтелгән. Ә укытучының нинди сыйфатларга ия булырга тиешлеген гомумиләштереп әйтсәк, укытучыга югары культуралылык, интеллигентлык, югары әхлаклылык, фидакарьлек, намуслылык, яңалыкка тартылу, алга карап эш итә белү, яшь буынны киләчәк тормышка әзерли белү, һәр эшкә иҗади якын килү, иҗтимагый активлык, таләпчәнлек, ярдәмчеллек, кеше хәленә керә белү, белемнәрен даими күтәрә белү кебек сыйфатлар хас.

Яңа белемнәрнең көннән-көн арта баруын исәпкә алып, укытучы әзерләгәндә студентның мөстәкыйльлегенә, үзлегеннән фәннәрне өйрәнүгә, фәннәрнең бер-берсе белән бәйләнешенә, фундаментальлелеккә игътибар ителә.

Уку йортларының төрлелеген исәпкә алып, лицейда, гимназиядә, фәннәрне тирәнтен өйрәнүче һәм профильле мәктәпләрдә эшләү өчен, укытучыларны махсус әзерләү дә көн тәртибендә булырга тиеш. Моны тормышка ашыру максатында һәр факультетның югары курсларында яхшы өлгерүче студентлардан махсус төркемнәр туплана.

Югары уку йортларындагы кебек, гомуми белем бирү мәктәпләрендә һәм профессиональ-техник училищеларда да хәзерге вакытта фәнни-тикшеренү эшләре киң таралды. Безнең республикада гына бүгенге көндә мәктәпләрдә 40тан артык темага тәҗрибәләр уздырыла.

Югары уку йортларында студентларны фәнни-тикшеренү эшләренә тарту белән, бер яктан, эзләнүчән һәм иҗади эшләүче профессионал-педагог әзерләү максатын күздә тотса; икенче яктан, югары мәктәптә галимнәр җитәкчелегендә алган фәнни-тикшеренү эшләрендә катнашу аларны бу эш белән мәктәпләрдә мөстәкыйль шөгыльләнерлек итеп әзерли.

Шуңа күрә дә, студентларны – булачак укытучыларны югары уку йортында укыган елларда фәнни-тикшеренү эшләренең күптөрле чараларында катнаштыру мөһим бурычларның берсе.

Яңа эшли торган күп сандагы уку йортлары өчен педагогик вузларда аерым төркемнәр булдырып, укытучы-тикшеренүчеләр әзерли башларга да вакыт җиткәндер.

Өзлексез педагогик белем алуның **өченче этабы** белгеч диплом алганнан соң башлана. Дөньяның барлык илләрендә дә белгечләрне яңадан әзерләү, аларның белемен күтәрү курслары бар. Укытучылар да системалы рәвештә мондый курсларда укыйлар. Ләкин белем күтәрү бу курслар белән генә чикләнми – укытучы үзлегеннән гомер буе укырга тиеш! Өзлексез педагогик белем идеясенең нигезе дә шунда. Гомере буе профессиональ осталыгын камилләштергән, белемнәрен тирәнәйткән, яңалыкларны күрә, аңлый белгән һәм аларның уңай якларын эшендә куллана белгән укытучы гына югары дәрәҗәләргә, исемнәргә ирешә.

Укытучыларның белемнәрен күтәрү аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерүне, профессиональ осталыкны арттыруны һәм, шулар нигезендә, укыту һәм тәрбия эшен хәзерге заман таләпләренә туры килерлек итеп башкаруны күздә тота. Бу эш белән мәктәп җитәкчеләре, методик берләшмәләре, районнар һәм шәһәрләрнең методик кабинетлары җитәкчелек итә. Республика күләмендә бу эшләрнең фәнни-методик һәм җитәкче үзәге булып Мәгарифне үстерү институты (МҮИ) тора.

Һәр педагог 5 ел саен махсус комиссия тарафыннан аттестация үтә. Моның өчен, аның белем күтәрү курсларында укуы шарт итеп куела.

Бу курсларның нәтиҗәле узуы өчен, төрле категориядәге педагогларга яңа белемнәр күләме, лекторлар, методистлар составы, фронталь, төркемләп һәм индивидуаль эш формалары алдан уйланырга тиеш.

Белем күтәрү курсларында МҮИ хезмәткәрләреннән тыш, республиканың иҗат һәм фәнни оешмаларының потенциалын куллану мөһим.

Педагогик вузлар бу эштә беренчеләрдән булып катнашырга тиеш. Мондый бәйләнеш курслар үтүче укытучылар өчен генә түгел, югары мәктәп галимнәре өчен дә кирәк. Аралашулар вакытында алар бер-берсен баетачаклар. Бу курсларда эшләп, югары мәктәп галимнәре мәктәп тормышы турында мәгълүматлар алалар.

Шулай итеп, балачактан башланган уку педагогның мәңгелек юлдашына, тормышының мәгънәсенә әверелә. Гомер буе уку – өзлексез педагогик белемнең нигезе! Бу нигезне республикабыз педагогик коллективларының девизы дияргә мөмкин...

Каюм Насыйри һәм хәзерге татар милли мәгарифе

Редакциядән: *2004 нче елда Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы мәртәбәле Каюм Насыйри премиясенә Васил Габдулла улы Гайфуллин кандидатурасын күрсәтте. Бу аның милли мәгарифнең аякка бастыру өлкәсендәге күпьеллык нәтиҗәле хезмәтен, шулай ук республикабыз мәгариф җәмәгатьчелегенең күп санлы тәкъдимнәрен искә алып эшләнде.*

Олуг галимнең шәхесенә, бинһаят киң юнәлешле хезмәтләренә Васил Габдулла улы гомере буе ихтирамлы булды. Түбәндә аның Каюм Насыйрига багышланган язмасын тәкъдим итәбез. Ул иң элек Татар дәүләт гуманитар институтының "Гыйльми язмалар"ында (2003 нче ел, 11 нче чыгарылыш) басылып чыккан иде.

...Бүгенге татар мәгърифәте алдында торган иң зур бурычларның берсе – халык хәтерен яңарту, шуның белән бергә, татар халкының бөек шәхесләрен өйрәнү, халыкның гореф-гадәтләрен, милли көнкүрешен, җыр-бию-ләрен кире кайтару. Һәм иң мөһиме – һәр татар күңелендә үзенең милләте белән горурлану хисе уяту, аны тәрбияләү. Әлеге бурыч, максатлар турында сүз алып барганда, без татар милли мәгърифәтенең башында торган, аның төп юнәлешләрен, үсеш юлын билгеләгән күренекле шәхесләребез – мәгърифәтче галимнәр, язучылар, җәмәгать эшлеклеләрен искә алабыз.

Халкыбызның әнә шундый фидакарьләреннән берсе булган Габделкаюм Габделнасыйр улының исеме, күренекле мәгърифәтчеләребез Габделнасыйр Курсави, Галиәсгар Гафуров-Чыгтай, Закир Һади, Заһир Бигиев, Ибраһим Хәлфин, Мәхүбҗамал Акчурина, Мифтахетдин Акмулла, Мөхәммәтгали Мәхмүдов, Ризаэддин Фәхретдинов, Утыз Имәни Эл-Болгари, Фатих Хәлиди, Фатих Кәрими, Шиһабетдин Мәрҗәни, Хөсәен Фәезханов, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Садри Максудилар белән беррәттән, лаеклы урын алып тора.

Ярты гасыр дәвамында тырыш һәм гаять нәтиҗәле эшчәнлек күрсәткән галим, язучы, педагог Каюм Насыйри татар мәгърифәтчеләренең күренекле вәкиле булды. Мәшһүр галим матур әдәбият, халык авыз иҗаты, филология, педагогика, физика, математика, тарих, география, биология, астрономия һ.б. фәннәр турында кырыктан артык хезмәт иҗат итә. Ул бөтен тормышын һәм талантын халыкка хезмәт итүгә, татар халкы-

ның аң-белемен, мәдәниятын күтәрүгә багышлады. Аның бүгенге татар мәгърифәте өчен зур әһәмияткә ия булган титаник хезмәтләре татар халкының иҗтимагый уяну тарихында мактаулы урын ала. Әдәби, тарихи, гыйльми хезмәтләр язуы, татар халкының телен гыйльми калыпларга салуы, русча укытуга керешүе, кагылу-сүгелүләргә карамыйча, олы максатларына баруы К. Насыйрины фидакарь галим, энциклопедист-мәгърифәтче итеп таныта. Аның Ватанга мәхәббәт, халыклар арасындагы дуслык, туганлык турында әйтелгән сүзләре, бүген тагын да тирән мәгънә алып, яңача яңгырый.

Каюм Насыйри алдынгы иҗтимагый хәрәкәт өчен көрәштә ялгыз булмады. Г. Ибраһимов билгеләп үткәнчә: "Насыйри белән бергә, бер үк иҗтимагый кыйблага карап көрәшүче Мәрҗәниләр, Фәезхановлар, Акъегетзадәләр, Заһир Бигиевләр <...> болардан башка, ләкин болар кебек шөһрәткә ирешмәгән, исеме тарихка керә алмаган, күзгә күренмәгән бөтен буын кешеләр шул мәгълүм бер хәрәкәт эчендә мөһим бер элемент буларак эшләп, көрәшеп үттеләр. Ул тарихи баскычта эшләүчеләрнең яшәгән җирләре, алга куелган мәсьәләләре, калдырган мираслары, тышкы калып буенча бер-берсеннән аерылып торса да, тарихи ераклыктан карап үлчәгәндә, үзләренең үсеп чыккан туфраклары, аларның күзәткән ерак кыйблалары бер иде. Болар төрле җирдән, төрле юл белән бер кәгъбәгә барырга чыккан юлчылар иде..." Әйткәнебезчә, Каюм Насыйри – шушы демократик юнәлеш вәкилләренең иң зурларыннан берсе.

Габделкаюм Габделнасыйр улы 1825 елның 14 февралендә элеккеге Казан губернасы, Зөя өязе (хәзерге Яшел Үзән районы) Югары Шырдан авылында туа. Ата-бабалары ул заманның шактый танылган, укымышлы кешеләре була. Каюм Насыйри үзенең гыйльми хезмәтләрендә Югары Шырданның тарихы, ата-бабалары, аларның эшләре турында киң мәгълүмат бирә. "Габделнасыйр мулла үзенең заманында гайяр үткен вә бик зирәк адәм булгандыр... Бик галим кеше, хәтта заманының галләмәсе (иң зур галиме) дип атасак та садыйк (дөрес) булыр. Гәрчә указной мулла булмаса да, тирә-якта Насыйр мулла иң мәшһүр иде, язуга бик оста иде. Хәзер дә, егерме бишләп, үз кулыннан чыккан китаплары бар. Фарсы һәм гарәби язуга маһир иде. Хосусан, ахыр көннәрендә күп китап язды..." – дип, Каюм Насыйри әтисен хөрмәтләп искә ала.

Үзенең хезмәт юлын Духовное училищеда татар теле укытучысы булып башлап җибәргән К. Насыйри укытучылык

эшенә бик житди карый. Аның шәкертләре арасыннан татар теленең белгечс булып житешкән галимнәр чыга (мәсәлән, П.П. Масловский). Укытучы Насыйри, ана теле белән беррәттән, балаларга урыс телен өйрәтүнең никадәр әһәмиятле булуын аңлый. Шул рәвешчә, барлык авырлыкларны җиңеп, ул татар балаларын урысча укыта башлауны оештыручы була. Казан шәһәрендә татар балаларына урыс теле өйрәтер өчен, рәсми мәктәп оештыру авырлыкларын да үз җилкәсендә күтәрә, балаларга төрле юллар белән ярдәм итеп, 24 ел балаларга аңбелем, тәрбия бирү белән шөгыльләнә. Калган гомерен язучылык эшенә, фәнгә багышлый. Аның зур күләмле фәнни һәм әдәби хезмәтләре шул вакытларда туа. Ул үзенең барлык көчен китап һәм дәреслекләр язуга, кулына кергән акчасын аларны бастыруга сарыф итә. Билгеле, К. Насыйрига иҗат итү һәм хезмәтләрен дөньяга чыгару бик авыр була. Аның кыю эшчәнлеге, гыйльми һәм әдәби әсәрләренең басылып чыга башлавы консерватор байларның, руханиларның, Казан мещаннарының аңа карата дошманлыкларын көчәйтә. Ләкин заманының алдынгы кешеләре арасында галимнең хезмәтләрен танучылар да күп була. Укучы яшьләр, урыс галимнәре, тюркологлар К.Насыйриның хезмәтләрен үз вакытында ук тәкъдир итәләр. Галим Казан университеты янындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең әгъзасы булып сайлана һәм рәсми яктан дә фән кешесе булып таныла.

Каюм Насыйри үзенең гомерен, бөтенләй дип әйтерлек, Казанда уздыра. Әмма фәнни максатлар белән бик еш авылларга йөреп, гади халык белән якыннан аралаша, аның җанлы телен, гореф-гадәтләрен өйрәнә, тарихи истәлекләр һәм фольклор материаллары җыя. Әдипнең язучылык эше, аның беренче әсәре "Мәҗмәгыль әхбар"дән ("Хәбәрләр җыентыгы") башлана.

Телләр өйрәнүгә зур әһәмият биреп, К. Насыйри "Русча өйрәнүче мөселман егетләре өчен, вә һәм татарча өйрәнүче рус егетләре өчен, тәсниф кылдым" дип үзенең махсус "Нәхү китабы"н ("Татар теленең кыскача грамматикасы" – "Краткая татарская грамматика") бастырып чыгара. Балалар һәм башлангыч белем алучылар өчен табигать күренешләреннән кыскача мәгълүмат биргән күңелле һәм популяр телдә язылган "Буш вакыт" исемле әсәре дә шул ук елны дөнья күрә. Бу – 12 биттән торган, татар телендә язылган әдәби-фәнни популяр әсәрләрнең беренчесе, соңыннан 87 биткә житеп, үз вакытында зур әһәмияткә ия була, һәм бу китап – татар балалар әдәбиятын нигезләү буенча башлангыч әсәрләрнең беренчесе.

К.Насыйриның иҗади эшчәнлеге киңкырлы. Шуның бер дәлиле – аның 24 ел буена ярым журнал рәвешендә чыгып килгән өстәл календарьлары. Аларны төзегәндә, әдипнең халык соравын, аның ни дәрәҗәдә кызыксынуын искә алып эшләгән булуы мәгълүм. К.Насыйри татар телендә газета чыгарырга ниятләп, аны "Таң йолдызы" дип исемләргә тели. Ләкин патша хөкүмәтеннән рөхсәт ала алмау сәбәпле, бу омтылышын тормышка ашыра алмый һәм теләгенең бер өлешен еллык календарьлар бастырып үти, ул календарьларында төрле темаларга фәнни һәм әдәби мәкаләләр урнаштыра.

Каюм Насыйри – XIX йөз татар мәгърифәтчеләре арасында иң алдынгысы һәм эшлеклесе. Ул – киң колачлы универсаль галим һәм күренекле педагог та. Фәннәрне өйрәнүдәге бүгенге уңышларыбыз аның исеме белән тыгыз бәйләнгән. Ул – төрле фәннәрнең нигезләре белән татар халкын ана телендә беренче буларак таныштыручы да. К. Насыйри хезмәтләреннән математика фәне буенча "Хисаплык", "Истыйляхате гыйльме һәндәсә", "Гыйльме һәндәсә" (геометрия); географиядән "Истыйляхате җәгърафия" (география терминнары), "Ысулы җәгърафияи кәбир" (зур күләмле география китабы), табигать белеменнән "Буш вакыт", ботаникадан "Гөлзар вә чәмәнзар", игенчелеккә карата "Гыйльме зирагать" (иген игү һәм бакча эше турында кулланма) исемле дәреслекләр һәм китаплар бүгенге фәнебезнең олы мирасы булып тора. Галим календарендә системалы рәвештә географиягә караган мәкаләләрен, үзе сызган карталарын бастырып тора. К. Насыйри теге яки бу фән хакында мәгълүмат биргәндә, аның тормышта файдалану якларына да нык игътибар итә. Календарендә технологиягә карата һәм химик үзгәртүләр юлы белән төрле нәрсәләр ясау мөмкинлеге хакында киңәшләр биреп бара. "Санаигъ голфания" (ювелирлык һәм слесарьлек эше) исемле китабында электрдан файдаланып, металлны эшкәртү, никельләү юлларын өйрәтеп яза.

Күпьяклы фәнни хезмәтләре белән заманында тормыш, яшәү өчен һава шикелле кирәк булган фән нигезләрен өйрәтә башлавы үзе генә дә К. Насыйри эшчәнлегенең тарихи әһәмиятен билгели.

Галимнең иң зур хезмәтләреннән берсе – аның тел өлкәсендә эшчәнлеге. Телче буларак, ул күпьяклы хезмәтләр башкарды: татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын, шуна хакы һәм сәләте барлыгын исбат итте. Аны практик һәм фәнни камилләү юлында гаять кыю һәм зур эшчәнлек күрсәтте. К.Насыйри тел гыйлеме һәм сүзлекләр төзү буенча шулкадәр

катлаулы һәм кирәкле эшләрне башкарды ки, бу өлкәдә ул кагылмаган, хезмәт күрсәтмәгән бер генә тармак та юк. Татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге ("Ләһҗәи татари"), урысча-татарча һәм татарча-урысча сүзлекләр, математика, георграфия һәм табигать фәннәре буенча киң массага аңлаешлы терминнар, дөрес һәм матур язу кагыйдәләрен күрсәткән кулланма ("Кавагыйде китабәте"), татар теленең фәнни грамматикасы ("Әнмүзәҗ") галимнең олы мирасының бер өлешен тәшкил итәләр. Чөнки бу хезмәтләр үз вакытында ук тел галимнәренең югары бәясен ала. Атаклы тюрколог Н.Ф. Катанов Каюм Насыйрины "Казан татар галиме мәшһүр К. Насыйри" дип атап, аның сүзлек-китабын русчага тәрҗемә итәргә кирәклеге һәм тюркологлар өчен бик файдалы булуы турында яза.

Бу хезмәтләр хәзер дә тарихи әһәмиятләрен һәм фәнни кыйммәтләрен югалтмыйча, бүгенге тел белеме үсешендә нигез булып торалар. Бер үк вакытта, К. Насыйри урыс телен үзләштерү өчен уку китаплары ("Кыйраәте рус") урыс теленең грамматикасын ("Нәмүнә, яки әнмүзәҗ") төзеп, бастырып тарата. Ул урыс һәм татар грамматикасында булган яңалыкларны, аермалыкларны, үзенчәлекләрне өйрәнеп, бер телне икенче тел белән чагыштыру методын кулланды. Галимебез керткән бу яңалык бүген дә тел өйрәтүдә укытучыларыбыз тарафыннан уңышлы файдаланыла.

Каюм Насыйриның тел турындагы карашларына бөек урыс галиме М. Ломоносов хезмәтләренең йогынтысы булуын да әйтеп китү кирәктер.

Үз чорында татар теленә карата булган реакцион карашларга каршы чыгып, К. Насыйри телебез турында бүген дә кыйммәтен җуймаган изге фикерләр әйтә: "*Без – татарлар, телебез – татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул*".

К. Насыйри – хәзерге татар әдәби теленең беренче байракчысы һәм нигез салучысы булды. Ләкин әдәби тел төзү бер кешенең эше белән генә тәмамланмый, аны заманнар эшли, берничә буын талантлы язучылар чарлап камилләштерә. Насыйри бу юлда үзенең кулыннан килгәннәрнең барын да эшләгән, ишекләрен ябып китмәгән. Үзеннән соңгыларга тикшерү, эзләнү һәм камилләштерү өчен юллар сызган, хәзинәләр калдырган. "Һәрбер нәрсә әүвәл чыкканда бәгъзе җирләре җитешмәгән кебек булса да, бара-бара төзелә, яхшыга әйләнә, елдан-ел арттыралар, төзетәләр... өмет бер – табылмасмы икән йокысын кызганмаган егетләр?! Бездән тик бары юл күрсәтү булсын...",

дип яза Каюм Насыйри үзенең 1871 нче елда эшләгән календарендә.

Татар халкының, татар теленең үсеш юнәлешен Каюм Насыйри дөрес билгеләде һәм аның өметләре бушка булмады. Ул калдырган мирас бөек шәхесләребез Г. Тукай, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал, Ф.Әмирхан кебек атаклы язучылар, Мөхетдин Корбангалиев, Гыймаз Нугайбәк, Гыйбад Алпар кебек тел галимнәренең иҗатында үсеш тапты, баеды.

Шулай ук матур әдәбият өлкәсендә дә Каюм Насыйриның тарихи әһәмиятле һәм универсаль хезмәтләре күп. Ул тәрҗемәче, оригиналь әсәрләр тудыручы һәм бер үк вакытта, фольклор җыеп, аны гыйльми нигездә эшләп бастыручы! Үзенә кадәр иҗат иткән татар шагыйрьләренең һәм галимнәренең әсәрләрен тикшерүче галим дә.

Язучы буларак, Каюм Насыйри үзенең "Кырык вәзир кыйссасы" исемле мәшһүр әсәре белән халык арасында дан казана. Бу әсәр гаделлеккә, намуслылыкка, батырлыкка өйрәткән экиятләр җыентыгыннан тора. Дөньяның күп телләренә тәрҗемә итеп, укучыларның игътибарын җәлеп итә. Әсәр аның мәгърифәтчелек теләкләренә, фәнни карашларын киңәйтергә омтылуына җавап бирә.

1879 нчы елда әдип зур күләмле әсәре "Фәвакиһел җөләса фил әдәбият" ("Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше") китабын язарга керешә һәм, озакламый, аның кыскартылган вариантын "Кырык бакча" исеме белән аерым китап итеп бастырып чыгара. Бу әсәрдә өйрәнелергә һәм сакланырга тиешле гадәтләр турында сөйләнелә, гыйбрәтле мисаллар китерелә. Аларның бер өлеше заманның социаль җитешсезлекләрен тәнкыйть итүгә, укучыларның аңын һәм культурасын күтәрүгә юнәлтелгән. "Кырык бакча" китабында мәңгелек бай фикерләр, хикмәтле сүзләр күп: "Кеше үз-үзен таныса, камил акыл шуннан беленер". "Әгәр берәүгә гыйлем үгрәтергә теләсәң, әүвәл үз-үзеңне үгрәт". "Олуглык акыл белән, әдәп белән, әмма нәсел белән, нәсәп белән түгелдер".

Каюм Насыйри татар халык авыз иҗатын, этнографиясен җыю һәм эшкәртү буенча гаять зур эш алып бара. Ул халык авыз иҗатының барлык жанрларын өйрәнә һәм бастырып чыгара, бу өлкәдә теоретик карашларын да әйтә бара. Аларны үз вакытында ук Катанов кебек тюркологлар югары бәяләгән. Бу галим үзенең "Исторические песни казанских татар" дигән китабында бәетләрне К.Насыйридан алганлыгын әйтә.

Халыкның алдынгы үсеш юлына басуы өчен, фән һәм мәдәният өлкәсендә башка халыклар ирешкән казанышлар белән танышу һәм, киресенчә, үз халкы казанышларын күрсәтү кирәклеген Каюм Насыйри бүгенгедәй тирән аңлаган. Шул максаттан чыгып, ул үзе җыйган материаллар белән рус галимнәрен дә таныштырып бара. "Татарның тормышын ачыклауда рус кешеләренә <...> күп еллар бу тормышны тикшерү һәм күзәтү өстендә эшләвемнең нәтиҗәләрен матбугатта алар белән уртаклашуны үземнең изге бурычым дип саныйм", ди ул.

Халык иҗаты һәм язма әдәбиятларның үзара йогынты ясавын күзәтү буенча да галим башлангыч хезмәтләрен бирә. Ул үзе җыеп алган 11 татар әкиятен урыс һәм татар телләрендә бастырып чыгара һәм аларда башка халыклар белән уртаклык булуына игътибар итә. Аның бу хезмәте "Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халык әкиятләре белән чагыштыру" дигән исем белән басыла.

Каюм Насыйриның күп кенә хезмәтләрендә тарих язу өчен материаллар бирелә. Мифологиягә һәм этнографиягә караган хезмәтләренә, тарихны язучылар тарафыннан кузгатылмаган, тикшерелмәгән материалларны табып, фән дөньясына тапшыруны бурыч итеп куя һәм аларның тарих битләренә кереп калуына нык игътибар бирә.

Шундый хезмәтләреннән – "Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары", "Татар этнографиясе материаллары" Казан һәм анын тирәсендәге татарлардан алынган һәм этнография фәнендә кабул ителгән системага салып төзелгән.

Галим, гомумән, тарих материаллары җыю белән беррәттән, аерым авылларның да тарихын яза. Татар халкының бабалары VIII–XIII йөзләрдә Урта Идел һәм Кама буйларында аерым бер дәүләт булып яшәгән Болгар иленә бәйле. Шуңа ул "Безнең Болгар йорты" дип сөйли. К. Насыйриның тарихка кергән хезмәте югарыда әйтелгәннәр белән генә чикләнми. Татар халкын үз ана телендә Ватан тарихы, Россия тарихы белән таныштыручыларның да берсе Насыйри була. Аның рус телендәге тарих китапларыннан файдаланып язылган "Зөбдәт мин тәварихи әр-Руси" дигән китабы – бу юлда беренче башлангыч хезмәте.

Кыска эчтәлекле һәм конспект рәвешендә язылган бу китап үз чоры өчен зур әһәмияткә ия була.

Каюм Насыйри илаһият гыйлеменә турыдан-туры кагылышлы хезмәтләр калдырмаган. Ул шулай ук, ислам тарафда-

ры һәм дөньяны барлыкка китерүче көч буларак, Аллаһыны таный. Дөньядагы вакыйгаларның барышы Аллаһы тарафыннан билгеләнсә дә, ул вакыйгалар сәбәпчелек принцибы нигезендә баралар, дип саный.

Каюм Насыйриның язма мирасы белән якыннан танышкач, аның адәм баласына туганнан алып соңгы юлына (вафатына) кадәр киңәш, уй-фикерләр җиткерүче олуг остаз икәнен аңлыйсың. "Бала тумак", "Гакыйга корбаны", "Сөннәткә утыртмак" кебек бүлекләрендә халкыбызның борынгыдан килгән гореф-гадәтләре, йолалары чагылган, аларда әле без халыкка, укучыларыбызга җиткерәсе күпме фикер бар, күбесен яңача, фән ачышларына нигезләп аңлатасы бар.

Халык педагогикасының иң мөһим идеяләре әдипнең хезмәтләрендә киң урын алган. Бу биеклеккә К.Насыйри күп еллар укытучы булып эшләп, шуннан алган бай тәҗрибәсе ярдәмендә ирешкән. Мәгърифәтче галим мәгариф эшен кайнар яклый, татар халкының аң-белемен, мәдәниятен алга җибәрү уе белән яна. Бабаларыбызны сәләтле, белемле, югары әхлаклы шәхесләр итеп тәрбияләргә тели.

К.Насыйриның мәгариф мәсьәләсендәге төп идеалы – татарлар өчен гимназия һәм башка урыс мәктәпләре тибындагы уку йортлары булдырудан тора. Шул максат белән 1872 елда ул башлангыч мәктәп оештыра һәм шатланып: "Хәзер дә мәдрәсәнең сыйфаты гимназия классларыннан бер дә ким түгел", – дип язып үтә. К. Насыйри үзенең өендә татар балаларын гимназиягә керергә әзерли.

Аның кулъязмалары арасында 1871 елгы календарьга кертү өчен әзерләнгән "татарча язылган гимназия программасы" саклана.

1876 елда, Казанда башка уку йортларыннан шактый аерылып торган, "Татар укытучылар мәктәбе" ачыла. Анда татар теле һәм башка иҗтимагый фәннәр, табигать фәннәре укытуга билгеле урын бирелә. К. Насыйри бу мәктәпнең башлангыч классларын оештыруда актив катнаша, анда байтак вакытлар зур тырышлык белән укыта. Галим тәрбия сүзенең эчтәлеген түбәндәгечә билгели: "Тәрбия кыйлмак вә тәрбия итмәк, диган сүз фәкать ашатып-эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, бәлки, ашатып-эчертеп үстермәк, вә баланың холкын, фигылен ислах кыйлмак вә тәзәтмәк, вә хайванидан чыгарып, инсаният дәрәҗәсенә китермәк, вә тәгълим бирмәк, вә үгрәтмәк, вә укытмак, вә әдәп нигезе бирмәк мәгънәсендәдер". Һәм шунда

ук гаилә һәм иҗтимагый тәрбияләрнең үз вакытында һәм тиешенчә кирәк булуына басым ясый. Ата-анадан, укытучылардын балаларга яшьтән үк актив тәрбия бирү эшләрен оештыруларын таләп итә. "Баланың иң кыйммәтле гомере, үзен-үзе белерлек булып, үзе ашый башлаган вакыттан мәдрәсәгә йөреп, сабак тәмам кылганчыга чаклы вакыт буладыр. Әнә шул вакытларда баланы яхшы тәрбия кылып, тәртипкә вә тәрбиягә төшендермәк лазимдер, ди Каюм Насыйри.

Бүгенге көндә һәр педагогның киңәшчесенә әверелгән "Китабәт-тәрбия" әсәренең республикабыз укытучылары, тәрбиячеләре, ата-аналар өчен кыйммәтле бер хәзинә булуына аеруча басым ясап әйтмичә мөмкин түгел. Китап, 113 тәрбия бүлегеннән торып, бүгенге мәгариф концепциясенең укучыларда шәфкатьлелек, миһербанлык, югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләү максатларына хезмәт итүче мәшһүр әсәр. "Әхлак рисаләсе", "Тәрбия китабы"нда К. Насыйри балаларның үзләренә дә күп киңәшләр биреп яза. Бер генә минутка да үзенең педагог булуын хәтереннән чыгармый, барлык иҗади хезмәтләрен шуңа буйсындырып алып бара.

Танылган педагог бәхәсле булган бер генә сорауга да битараф калмый. Ул яшәгән елларда татарларда музыка сәнгатенә игътибар ителми. Насыйри бу өлкәне дә читтә калдырмый, әдәби хезмәтләрендә күп дәлилләр китереп, җырның, музыканың күңелгә шатлык, хәрәкәткә батырлык бирүе турында сөйли. "Фәвакиһел җөләса"ның 30 нчы равзасы музыканың әһәмиятен аңлатуга багышланган. "Хәкимнәр әйтмешләрдер ки, гөннә (көй, матур тавыш) рухның азыгыдыр. Фәһемне саф кылыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, җебенне (куркакны) баһадирландырыр, саранны юмартландырыр, димешләрдер", дип тәмамлый әдип музыканың тәэсир итү көче турында.

К. Насыйри – татар халкының фидакарь улы. Ул халыкның авыр тормышына битараф була алмый, борчылып, кайгырып яши. Бу турыда аның әдәби хезмәтләреннән тыш, шәхси хатлары да сөйли. Үзенең абыйсы Габделхәйгә Казан халкының авыр тормышы турында: "...Халык бик ябык, зарланмаган кеше юк", – дип яза.

Халкының матур киләчәге турында хыялланган әдип, бернинди авырлыкларга бирешмичә, иҗат итә, киләчәктә үз эшен дәвам итәчәкләренә тирән ышана. Дөрестән дә, гасырлар буенча тупланган бу хәзинә югалмады, киресенчә, баетылып, бүген-

ге галимнәребез – Мансур Хәсәнов, Хатыйп Госманов, Якуб Ханбиков, Мирфатыйх Зәкиев, Диләрә Тумашева, Вахит Хаков, Гомәр Саттаров, Хатыйп Миңнегулов, Рузәл Юсупов, Җәмил Нигъмәтов кебек шәхесләрнең хезмәтләрендә чагылыш тапты.

К. Насыйри әдәби-тарихи, иҗтимагый һәм педагогик эшчәнлегенә татар, урыс һ.б. халыклар җәмәгатьчелеге тарафыннан югары бәя бирелә, аның гүзәл образын яктыртучы матур әдәбият әсәрләре, рәсемнәр иҗат ителә.

Мөхәммәт Гали һәм Хосәен Уразиковлар язган "Каюм Насыйри" пьесасы нигезендә эшләнгән спектакль дистә еллар буена Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәләрендә куелды. Равил Бухараев пьесасына нигезләнеп, К. Насыйрига багышланган телевизион фильм эшләнде. Мөхәммәт Галинең "Каюмның балачагы" дигән әсәре укучылар тарафыннан яратып укыла. Танылган татар рәссамнары Бакый Урманче, Садри Ахун, Байназар Альменев, Эрот Зариповлар бөек фикер иясенең портретларын, бюстларын эшләделәр. Мансур Рәхимов "Мәгърифәтче-галим Каюм Насыйри – үзенең туган авылы Югары Шырдан кешеләре арасында" дигән картинасын иҗат итте.

1987 нче елның 23 нче апрелендә Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы алдынгы педагогик коллективларга, укытучыларга, тәрбиячеләргә, югары һәм махсус урта уку йортлары галимнәренә һәм белгечләренә Каюм Насыйри премиясе бирү турындагы карар кабул итте. Шул вакыттан башлап, республика буенча педагогик коллективларга һәм аерым шәхесләргә лауреат исеме һәм акчалата бүләкләр бирелеп килә. Алар арасында – Арча педагогия көллияте укытучылары Сәләй Гата улы Вагыйзов, Рәмзия Гыйлаҗ кызы Вәлитова, Казан шәһәренең 103 нче урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәдинә Хәниф кызы Абылганиева, Актаныш районы, Әтәс урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Зәкия Ибраһим кызы Ибраһимова, Арча районының Ташкичү урта мәктәбе директоры Равил Габдерәүф улы Габдерәүпов, Казан дәүләт педагогика университеты профессорлары Габделхан Габдулла улы Габдуллин, Фираз Фәхраз улы Харисов, Казан дәүләт университеты галимнәре Флера Садри кызы Сафиуллина, Альберт Гата улы Яхин, Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин, Кукмара районының Зур Сәрдек урта мәктәбе, Яшел Үзән районының Ачасыр урта мәктәбе, Тукай районының Суыксу урта мәктәбе, Әгерже районының Иж-Буби мәктәбе коллективы.

Каюм Насыйри премиясе лауреатларыннан Сәләй Гата улы Вәгыйзов һәм Рәмзия Гыйлаҗ кызы Вәлитованың педагогик эшчәнлеге аеруча олы хөрмәткә лаек. Бу ике педагог – республикабыз мәктәпләренә меңнәрчә укытучылар тәрбияләп озатучылар, "Әлифба", башка дәреслекләр һәм методик кулланмалар авторлары. Менә күпме еллар инде татар баласы шушы ике олы зат тарафыннан тудырылган гүзәл әлифбалар аркылы белем дөньясына юл ала. Икенче лауреат – Казан шәһәрендәге 103 нче урта мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мәдинә Хәниф кызы Абылганиева – Каюм Насыйри бүләген бөек мәгърифәтченең васыяте итеп кабул итте. Моннан 100-120 еллар элек яшәгән Каюм Насыйри татар балаларына урыс телен өйрәтүнең кирәген билгеләп үткән булса, бүгенге көндә шәһәр шартларында татар балаларына татар телен тиешле дәрәҗәдә укыту житди проблемаларның берсе булып тора. Һәм бу өлкәдә Мәдинә Хәниф кызының ирешкән уңышлары игътибарга лаек.

Кыскасы, Каюм Насыйри исеме – мәңгелек! Хәзерге татар мәгарифенең кайсы гына тармагын алсаң да, аның тамырлары олуг шәхес Каюм Насыйри хезмәтләренә барып тоташа. Рус халык мәгърифәте тарихында Михаил Ломоносов нинди урын биләсә, татар милли мәгърифәте үсешендә Каюм Насыйриның хезмәте, тоткан урыны да шундый ук бәягә лаек!

Мәгарифле халык – иркле халык

Мәгарифебезнең күп гасырлык тарихы бар. Безнең бабаларыбыз – борынгы төркиләр – VI гасырда ук укый-яза белгәннәр. Татарларда шул чорда ук мәгърифәтчелек хәрәкәте көчәеп китә.

Болгар дәүләтендә IX гасырда ук милли мәктәп-мәдрәсәләр саны арта бара. Һәр мәчет каршында мәктәп булган, дип исәпләсәк, 1742 нче елда аларның саны 536га житә. 1858 нче елда Казан губернасында – 430, Ырынбур губернасында 418 татар мәктәбе эшләгән. Аларда грамоталылык югары дәрәҗәдә булган. Болар хакында татар телендәге һәм башка телләрдәге архив документлары бик ачык сөйли. Шул вакытта татар язуы төрки халыклар арасында аралашу чарасы булып хезмәт иткән. XVIII гасырның ахырында рус уку йортларының 20сендә татар теле өйрәтелгән. Татарча китапларны күчереп язу, кулдан язылган сочинениеләрне бизәү һәм төпләү эше дә әйбәт куелган.

1759 нчы елда Казанда гимназия ачыла. Ул Казан татарларының мәдәни үсешенә билгеле бер уңай йогынты ясаган. 1769 нчы елда монда татар теле классы ачылган. Күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре Хәлфиннәр династиясенең башында торучы Сәгыйть Хәлфин анда татар теле укыткан.

Әлеге күренекле мөгаллим 1778 нче елда "Татар теле әлифбасы"н нәшер иткән. Ул башка уку йортларында һәм татарлар арасында киң таратылган. Сәгыйть Хәлфин татар теленең ике томлык сүзлеген һәм кыскача татар грамматикасын төзи. Алар алга таба камилләштерелгән грамматикалар һәм сүзлекләр чыгару өчен нигез булып тора. Ул басмалар XIX гасырда Казан университетында бастырылып чыгарыла.

XIX гасырның башында Казанда татар китапларын нәшер итү башлана. 1807–1855 нче елларда Казанда гарәп графикасында 577 исемдә китап чыгарыла. Аларның һәрберсенең тиражы 2400–4200 данә. Татар китабының һәм аны бастырып чыгаруның зур әһәмияткә ия булуы Октябрьгә чаклы яшәгән һәм Совет чоры галимнәре тарафыннан югары бәяләнде. Татар әдәбиятының да үзенчәлекле үсеше күзгә күренеп тора. Мәдрәсәләрне тәмамлаган шәкертләр арасыннан Батырша, Утыз Имәни, Габди, Локман, Габдулла кебек шагыйрьләр һәм язучылар үсеп чыга. XIX гасырда әдәби әсәрләр саны арта һәм бу гасырның II яртысында татар әдәбияты эпик әсәрләр тудыру дәрәҗәсенә ирешә. Беренче татар романын язучылар Көнбатыш мәдәнияте белән якыннан таныш була.

Татар халкы мәгарифен үстерүгә мәктәп-мәдрәсәләр керткән зур өлеш турында да әйтеп үтәргә кирәк.

Бөек татар мәгърифәтчеләре, җәмәгать эшлеклеләре, тарихчылар, язучылар Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Х. Фәезханов, Ш. Көлтәси, С. Кукляшев, М. Акмулла, Г.Мәхмүтов, Г. Ильяси, Р. Фәхретдинов, Г. Баруди, Ф. Кәрими, Г. Ибраһимов мәдрәсәләрдә укыганнар. Г. Исхакый, Г. Камал, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, М. Гафури, Ш. Камал һ.б. да гыйлем алуны мәдрәсәләрдән башлаганнар.

1905 нче елда Казан губернасында 845 татар мәктәбе һәм мәдрәсәсе булган. Аларда 54549 укучы белем алган. 1907 нче елда милли уку йортлары саны – 877 булса, 1913 нче елда ул сан 967гә җитә.

Милли белем үсеше Октябрь инкыйлабыннан соң да дәвам итә. Әмма бу процесс озакка сузылмый. Татарстанның автономияле республика итеп калдырылуы, Мәскәүдә Милли мәк-

тәпләр идарәсе бетерелүе милли мәгариф үсешен туктатуга сәбәп булды...

Мәгариф ул гомумкешелек культурасының бер тармагы гына түгел. Югары дәрәҗәдәге мәгариф системасы (тирән белемнәр стандарты, тиешле матди-техник база, сәләтле һәм тотрыклы кадрлар, алдынгы педагогик технология һ.б.) булган илнең икътисады да югары, халыкның тормыш, культура-әхлак дәрәҗәсе дә тиешенчә, милләтләр дә тату.

Мәгариф системасы башкарган чараларда җәмгатьтәге икътисади бәйләнешләр да, сәяси интеграцияләү процесслары да, мәдәни үсеш юнәлешләре дә, фокуста җыелган кебек, очрашалар. Шуларны истә тотып, уку йортлары яшьләргә дөрес хезмәт тәрбиясе, тирән белемнәр бирергә, төрле халыклар арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырырга, башка халыклар мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләргә тиеш.

Россия Федерациясе – күпмилләтле дәүләт. Аның мәгариф системасы да унитар принципта корыла алмый, һәр халыкның үзенең мәгариф системасы була. Анда халыкның милли үзенчәлекләре, тарихи үткән юлы һәм гореф-гадәтләре дә, этнопедагогик һәм этнопсихологик үзенчәлекләре дә исәпкә алынырга тиеш. Мәгариф үсешен тәэмин итү өчен төзелгән концепциядә болар искә алына.

“Халык” сүзе инглиз һәм немец телләрендә “милли” төшенчәсе белән аваздаш. Ул мәктәптә белем һәм тәрбия бирүдә укучының милли туган теле һәм мәдәнияте өстенлек иткәндә генә, уңышка ирешеп булачагына ишарәли. Көнбатыш Европа мәктәбе, шуңа күрә дә, милли башлангычларга таянып үсеш алган. Үз акылында булган бер генә тәрбияче дә баланы милли мирастан аерым тәрбияләргә омтылмаган.

Хәзерге педагогиканың атасы – чех галиме Я.А.Коменский халык мәктәбен “туган тел мәктәбе”нә тиңләп караган. Немец халкы мәктәбенә нигез салучы М.Лютер, бер үк вакытта, бүгенге немец телен торгызучы да булып исәпләнә. Шул нәүбәттән, татар мәктәбе “халык мәктәбе” рәвешен алырга тели икән, ул цивилизацияле дөнья белән бәрабәр рәвештә үзенә милли мәктәп йөкләмәләрен дә алырга тиеш.

Халык мәктәбе исә, гасырлар дәвамында яшәргә хокуклы икәнен раслап килде. Халык уку-укыту эшләрен мөгаллимнәргә ышанып тапшырды. Бу җәһәттән, халык мәктәбе генә тулы гыйлем бирүне тәэмин итә ала. Бары ул гына халыкларны гафиллек баткагыннан өстерәп чыгара ала. Югары катламнарда байлык һәм гыйлем, түбән катламнарда наданлык һәм хәер-

челек хөкем сөргән очракта иҗтимагый каршылыкларның яшәве көн кебек ачык.

Югары катлам үзенә берничә дистә укытучының хезмәт хакы күләмендә "оклад" билгеләгәндә, демократия турында сүз алып бару урынсыз булыр иде.

Шул рәвешле, укымышлы халык кына үзенең ирегеп саклый ала. Ул гына иректән дөрес файдалана ала. Бер милләттә мең кешегә – биш йөз югары белемле кеше, икенче милләттә, әйтик, 60 кына кеше туры килә икән, демократиянең җиңүе турында сафсата сату үзе үк гөнаһ булыр иде.

Халык мәктәбе бурычларын башкару юнәлешендә татар мәктәбе алга киткән илләрдән күпкә калыша әле. Мәсәлән, немец мәктәбе барлык фәннәрне дә туган телендә укыту мәсьәләсен инде 1915нче елда ук күтәреп чыккан иде.

Халык мәктәбе табигатьне өйрәнүгә яраклаштырылган. Халык мәктәбендә "теләсә нәрсәгә түгел, нәкъ менә табигать турындагы мәгълүматларны бирүгә" корылган немец галиме Дистервег принцибы сакланырга тиеш. Бу очракта швецарияле Песталоццининың: "Күргәзмәлек – барлык белемнәрнең дә абсолют нигезе", – дигән сүзләрен дә онытмаска кирәк. И.В. Поликовскийның 128 битле немец теле дәреслегендә (Киев, 1928), мәсәлән, табигать турында 100дән артык текст һәм 253 табигать сурәте урнаштырылган. Шушындый китаплар гына балаларның табигатенә туры килә, дигән авторлар күп мәртәбә хаклы, әлбәттә.

Халык мәктәбе өчен язылган әлеге китаплар һәм күргәзмә әсбаплар абстракт төшенчәләрне аңлатуга корылган хәзерге дәреслекләрдән күпкә аерылып тора.

Педагогика тарихын игътибар белән өйрәнгәндә, болай дип нәтиҗә ясарга була: халык мәктәбе үрнәкләре белем һәм тәрбия бирүдә үзенең үзенчәлекләре булуга карамастан, бүгенге заманда да яшәргә хокуклы. Бу нәүбәттән "мәктәпне тәмамлап чыгу өчен түгел, тормыш итү өчен белем алабыз" дигән гыйбарәдә мәңгелек хакыйкать бар. Чынлап та: "Мәктәбе булган халыкның гына туган Ватаны бар", – дип әйтә алабыз. Татар халкының мәдәнияте, шәрыкъ һәм мөселман мәдәниятенең бер тармагы буларак, кешеләрне кече яшьтән алып картлыкка кадәр тәрбияләүдә зур урын алып тора. Шул рәвешле, татар халкы педагогикасының традицияләре бик күп әхлакый сыйфатларга ия. Шуларның берсе – кешенең эчке дөньясына игътибар итү, рухи байлыкны саклау, туган җиреңә, туган халкыңа хөрмәт тәрбияләү. Алдагы буыннарга, өлкәннәргә, туган-тумачага һәм

якыннарга изге хисләр тәрбияләү дә халыкның иң яхшы сыйфатларыннан санала.

Социологлар билгеләгәнчә, шәхси мәнфәгатьләрне милли башлангычларга каршы кую, ахыр чиктә, кешенең рухи үсешенә кире йогынты ясый. Һәрьяклы тәрбия алган кешегә һәм шәхси һәм милли мәнфәгатьләр дә ят нәрсә түгел. К.Д.Ушинский сүзләре белән әйтсәк, һәр халыкның үзенә генә хас тәрбия системасы булырга тиеш. Аны башка халыктан алу мөмкин түгел.

Безнең илдәге мәгариф системасының хәзерге торышын тотрыксыз, эчке каршылыклы һәм стратегик яктан билгесезлектә дияргә була. Югары кимәлдәге мәгарифе булган илдәге халыкның культурасы саклана һәм иҗаты үсә. Цивилизацияле илләр мисалында без моны ачык күрәбез.

Россия Федерациясе кебек күпмилләтле илдә милли мәгарифнең фәнни нигезләнгән концепциясе булырга тиеш. Мәгариф системасына реформа башланган 1990нчы елларда милли идеологиягә нигезләнгән мәгарифне үстерү концепциясе булмау бу эшне катлауландырды. Демократияләшү юнәлешендә барган үзгәрешләр милли мәктәпнең теоретик-методологик нигезләрен эшләүне көн тәртибенә куйды. Бу чорга Россия Федерациясендә дә, Татарстанда да мәгариф үсешенә юнәлеш бирерлек концепция юк иде. Заман таләбе нигезендә бу документлар булдырылды. Хәзер шул процессның этапларын карап китик.

...Күпмилләтле Россия Федерациясе 89 административ берәмлектән тора. Аларның 32се милли-административ берәмлеккә керә: Адыгей, Алтай, Башкортстан, Бурятия, Дагыстан, Ингушетия, Кабарда-Балкар, Калмыкия, Хальм-Тангч, Карачай-Черкес, Карелия, Коми, Мари-Эл, Мордовия, Саха-Якутия, Төньяк Осетия, Татарстан, Тыва, Удмуртия, Хакасия, Чечня, Чувашия; автономияле Еврей өлкәсе һәм автономияле 10 округ.

Совет дәүләтенең милли мәктәпләрне мөстәкыйль типтагы мәгариф учреждениеләре итеп раслаган норматив документлары 1918 нче елның октябрендә барлыкка килде. Ул документларда милли мәктәпкә түбәндәгечә билгеләмә бирелде: аз санлы халыклар өчен ачылган һәм уку ана телендә алып барыла торган мәктәп, дип атала. Туган телне өйрәнү белән беррәттән, ул халыкның әдәбияты һәм тарихы өйрәнелә. Милли мәктәпләрдә бу территориядә күпчелекне тәшкил иткән халыкның телен өйрәнү мәҗбүри. Совет властеның беренче 15 елында мәдәният һәм мәгариф өлкәләрендәге сәясәт милли мәктәпләрне үстерү юнәлешендә барды. Моңа кадәр үз телендә укый-яза белмәгән 40 этноска әлифба булдырылды, барлык

миллэтлэр өчен башлангыч мэктэплэр эшлэде, милли укытучы кадрлар әзерләү оештырылды.

1927 нче елда чыккан РСФСР Мәгариф министрлыгы күрсәтмәләрендә ачык әйтелде: милли мәктәпләр ана телендә эшләүгә күчкәндә, барлык аңлату һәм тәрбия эшләре ана телендә алып барылырга тиеш. Бу – Совет властеның милли политикасы һәм педагогика, психология фәннәренең таләбе.

Укытучы һәм тәрбиянең туган телдә алып барылу принцибына басым ясап, бу документларда әдәби телнең роле дә күрсәтелде: туган тел, дигәннән, сүз аерым өлкәләрдә яшәгән халык төркемнәренең диалектлары һәм сөйләмнәре турында түгел, ә халыкның әдәби теле турында бара.

1929 нчы елда Россия Федерациясендәге 85 педучилищеда һәм 8 пединститутта милли кадрлар әзерләнде. Моннан тыш, тагын 24 пединститутта милли мәктәпләр өчен укытучылар әзерли торган аерым төркемнәр эшләде.

Утызынчы елларның икенче яртысыннан илдә шактый үзгәрешләр башланды. Индустриаль үзәкләр барлыкка килү, шәһәрләрнең үсүе, авыл халкының промышленность үзәкләренә күчүе, армиядәге реформа, андагы команда теленең рус телендә генә алып барылуы һ.б. сәбәпләр рус теленең кулланылу сферасын киңәйтте. Бу хәлләр милли мәктәпләргә дә үзгәрешләр кертте. 1938 иче елның 13 нче мартында СССР хөкүмәтенең “Милли республикалар һәм өлкәләр мәктәпләрендә рус телен мәҗбүри укытуны кертү” турындагы карары чыкты. Карар СССРдагы рус булмаган 71 миллион халыкка кагылды.

Бу карарны хөкүмәтнең мәгариф өлкәсендәге яңа идеологик доктринасы башлану, дип әйтергә була. Аның төп максаты алга таба илдә милли беришле (бертөрле) җәмгыять төзү иде.

1958 нче елда чыккан мәктәп турындагы закон милли мәктәпләр тормышын тамырдан үзгәрткән хәлиткеч документларның берсе булды. Бу вакытта СССРда милли мәктәпләрдә 94,7 миллион укучы белем ала иде. Закон нигезендә, ата-аналарга, балаларын укыту өчен, мәктәпне үзләренә сайлап алырга хокук бирелде. Рус теленең кулланылу сферасының көннән-көн үсүен күреп торган ата-аналар, әлбәттә, үзләренең балаларын рус мәктәпләренә бирә башладылар. Милли мәктәпләр әкренләп кимеде, аларның күбесе ана теле укытыла торган рус мәктәпләренә әйләнде. Төмән, Чиләбе, Свердловск, Пермь, Ульяновск, Куйбышев һ.б. өлкәләрдәге йөзләгән татар мәктәпләре шушындый язмышка дучар булды.

Закондагы үзгәрешләрне коммунизм төзүдәге алда торган яңа бурычлар белән аңлатырга тырыштылар, ләкин прагматик максат ачык билгеләнде: милли үзенчәлекләре булмаган җәмгыять төзү. Бу максат 1960 нчы елларда тагын да конкретлапты: яңа җәмгыять күп милләтлелектән котыла, яңа җәмгыятьтә бер генә милләт – "совет халкы" гына булачак, алар социалистик идеологиягә буйсыначак, рус телендә сөйләшәчәк.

1966нчы елда Союз күләмендә Мәгариф министрлыгы оеша. Ул үзенең эшен милли мәктәпләрне кысрыклаудан һәм мәгариф системасын руслаштырудан башлый. 1968 нче елдан 1980 нче елга кадәр, КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Министрлар Советының дүрт карары чыга. Болар барысы да милли мәктәпләрдә рус теленең ролен киңәйтүгә юнәлдерелгән иде. Югары уку йортларында ана телендә белем бирү кискен тәнкыйтьләнде. Мәгарифнең барлык буыннарында унитар система хакимлеге башлапа.

Казан дәүләт педагогия институтында 1950–1960 нчы елларда белем алган кешеләр хәтерлиләрдер, ул елларда һәр факультетта параллель ике бүлек эшләде: рус бүлеге һәм татар төркемнәре. Физика-математика факультетында ул елларда саф татар телендә безгә белем һәм тәрбия биргән укытучыларыбыз хәзер дә күз алдында: математиклардан – профессор М.Әлмөхәммәтов, доцентлар К.Йосыпов, К.Юнысов, Б.Газизов, физиклардан – фән кандидатлары, доцентлар Г.Кудашев, Ш.Таҗетдинов, М.Галиев, С.Зиннәтов һ.б. Әлеге укытучылар әзерләгән белгечләр СССРның бик күп өлкәләренә эшкә китәләр иде. Алга таба пединститутта татар бүлекләре ябылдылар.

1950 нче еллар ахырыннан башлап, милли мәктәпләр миллилек сыйфатын бетерә башлады. Югары классларда, аннан 5-8 классларда, алга таба башлангыч мәктәпләрдә дә укыту рус теленә күчте, ана теле, укыту теленнән, уку предметы гына булып калды. Рус теле, милләтләр арасындагы аралашу теленнән, икенче ана теле статусына күчте. 1974–1975 нче уку елында милли мәктәпләрнең уку планында ана теле һәм әдәбиятына атнага – 39 сәгать, ә рус теле һәм әдәбиятына 70 сәгать вакыт бирелгән иде. Милли мәктәпләрдә рус теле һәм әдәбиятын укытканда, класстагы укучылар 15 кешедән артмый торган төркемнәргә бүленде, укытучыларның хезмәт хакларына 15% өстәмә түләнде.

СССРның барлык регионнарында да мәктәптә укытыла торган фәннәр бер үк программа нигезендә укытылды. Фән-

нәрнең эчтәлеге сыйнфый һәм пролетар кыйммәтләр идеологиясе белән сугарылган иде.

1958 нче елда мәктәп турындагы закон кабул ителгәнче, Россия Федерациясе мәктәпләрендә укулар 46 телдә алып барылды. 80нче еллар уртасына бу сан 18гә генә калды. Татар һәм башкорт мәктәпләре тулы урта белемне ана телендә бирсәләр, тува һәм якут мәктәпләрендә ана телендә уку – 7-8 класска кадәр, чуаш, мари мәктәпләре – башлангыч классларда гына, ә калган 12 телдәге милли мәктәпләрдә ана телендә уку ике-өч елдан артмады.

Ана телендә укытыла торган милли мәктәп рус телендә укытыла торган милли мәктәпкә әйләнде. Гадәти рус мәктәбеннән аермасы шунда гына – мондый мәктәпләрдә атнага берничә сәгать ана теле дәресе керә. Татарстан мәктәпләре өчен дә бу бик табигый күренешкә әйләнде. Казанда гына да, мәсәлән, бу чорда утыздан артык татар мәктәбе ябылды, милли мәктәпләрдән 2 генә мәктәп калды: Бауман районының – 35нче һәм Совет районының 106 нчы мәктәбе. Аларда барлык фәннәр дә рус телендә укытылды, татар теле дәресе генә булып калды. Мәктәпләрнең исемнәре "рус телендә укытыла торган милли татар мәктәбе"нә әйләнде. "Кызыграк" яңгырый, әлбәттә.

Мәгариф эшендәге мондый юнәлеш үзенең нәтиҗәләрен дә бирде: берничә буын мәктәп баласы туган теленнән һәм мәдәниятеннән, милли традицияләреннән читләштерелде, чит телдә тәрбияләнде. Милләтләрнең ана теле кысрыкланды, җәмгыятьтә кулланылышта бер генә тел калды.

Милли республикаларда милли мәктәпләр кимегәннән-кими барды. Ул республикаларда яшәүче руслар андагы җирле халыкның телен өйрәнүдән "котылдылар". Җирле халыкның теле кухняда гына файдаланырга ярый торган тел булып калды.

Марксистик идеология буенча милләтләр, ахыр чиктә берләшеп, бер генә төрле халыкка әверелергә тиеш. Ләкин, классиклар фикеренчә, билгеле бер шартта гына: милләтләрнең экономикасы һәм мәдәнияте чәчәк аткан очракта. КПСС идеологлары бу чорны көтеп тормаска булдылар, бердәм совет халкын төзүне ашыктырдылар. Ләкин бу кешелек җәмгыятенең үсеш законнарына тулысынча каршы килә. Табигать тудырган үсемлекләр һәм хайваннар дөньясында һәрбер җан иясе – табигатьнең күпьеллык иҗат нәтиҗәсе. Шуңа күрә дә, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясындагы һәр генетик төрне саклау өчен, күп

көч куела, законнар чыгарыла. Шуның кебек үк, һәр халыкның кечкенә генә этносның да теле, мәдәнияте, үзаңы, менталитеты кешелек дөньясының иҗаты, байлыгы, дип саналырга хаклы. Аерым этнос-халыкның мәдәнияте – ул бөтен халык байлыгы. Бу байлыкны сакларга, үстерергә кирәк. Моны аңламыйча, күпмилләтле дәүләт төзеп булмый.

СССРның таркалуы, тоталитар партия-совет системасының җимерелүе демократияләшү элементларына юл ачты, халыкларның үзаңы уянуга ярдәм итте. Милли мәгарифнең кирәклеге көн тәртибенә килеп басты: милли мәгариф системасы унитар дәүләт таләпләрен генә түгел, ә халыкларның, милләтләрнең теләкләрен дә канәгатьләндерергә тиеш, милли мәктәпләр яңадан торгызылырга, уку ана телендә алып барылырга, белемнәр эчтәлегендә милли мәдәният, тарихи мәгълүмат тиешенчә урын алырга тиеш.

Таләпләр урынлы булса да, кызганычка каршы, бу чорда милли мәгарифне үстерүнең фәнни яңартуның төпле концепциясе һәм Россия хөкүмәтенең моны эшләргә теләге дә булмады. Кайбер инициатив төркемнәрнең Россия Федерациясендә милли мәгарифне җайга салуны күз алдында тоткан программалар һ.б. төр документлар тәкъдим итүен күрсәтеп үтәргә кирәк. Шуларның берничәсенә тукталыйк.

1. РСФСР Мәгариф министрлыгы 1990 нчы елның 22нче февралендә "РСФСРның милли (рус булмаган) уку йортлары программасын" кабул итте. Ул 1990–1995 нче елларга исәпләнгән иде. Ләкин программа милли мәктәпләрнең яңадан тууы һәм үсүе өчен берниндн дә чаралар тәкъдим итми, милли мәктәпләргә яңа шартларда "косметик ремонт" үткәрүне генә күздә тота. Милли мәктәпнең статусы элеккечә кала бирә: уку рус телендә алып барыла торган милли мәктәп.

2. СССР Педагогия фәннәре академиясенең авторлар группасы милли мәктәпләрнең яңа моделен тәкъдим итте. Авторлар мәгариф системасында белем стандарты инвариант һәм вариантлы өлешләрдән торырга тиеш, дип исәпли. Инвариант өлеше барлык типтагы гомуми урта белем бирүче уку йортлары өчен дә мәҗбүри. Ул белем стандартының гомумсоюз компоненты, дип атала. Вариантлы өлешләргә аерым республикалар һәм мәктәп компонентлары керә. Авторлар фикере буенча, аерым республикаларда (мәсәлән, Татарстанда) уку йортлары өчен уку планы төзегәндә, болар исәпкә алынырга тиеш. Татарстанда милли мәгарифне үстерү концепциясен һәм про-

граммасын әзерләгәндә, без моны исәпкә алдык. Уку планнарында "Татарстан һәм татар халкы тарихы", "Татарстан географиясе", "Татарстанның экономикасы", "Татарстанның экологиясе" һ.б. үзенчәлекле уку предметлары кертелде. Бердәм уку планы урынына күп төрле уку планнары барлыкка килде. Һәр мәктәпкә үзенә туры килгән уку планын сайлап алырга мөмкинлек бирелде.

Милли мәктәпнең бу моделен тәкъдим итүче авторлар укыту-тәрбия процессында милли традицияләрнең этнопедагогика һәм этнопсихологиянең дә роленә игътибар бирергә тәкъдим иттеләр.

3. 1989 нчы елда СССР Фәннәр академиясе "Мәктәп" исемле Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү коллективы оештырган иде. Алар да милли мәктәпне үстерүнең яңа вариантын тәкъдим иттеләр. Авторлар фикеренчә, мәгариф системасында төп буын булып, башлангыч мәктәп тора. Башлангыч классларда һәр милләт үз баласын үз ана телендә укыта ала, тәрбиядә милли мәдәният исәпкә алына, аннары укыту һәм тәрбия гомум Россия җирлегенә һәм дөнья культурасы дәрәҗәсенә күтәрелә.

Милли мәгарифне үстерү юлында өч принцип тормышка ашырыла:

– Милли мәктәп милли мәдәнияткә таяна, укучыда милли үзаң формалаштыра;

– Милли мәдәният башка халыкларның мәдәнияте белән баетыла;

– Милли мәктәпнең белем стандарты цивилизацияле илләрнең белем стандарты белән тәңгәлләштерелә.

Бу концепциянең милли мәктәпләр өчен уңай яклары күп иде. Шуңа күрә ул РСФСР Мәгариф министрлыгының коллегиясендә (1991нче елның марты) уңай бәя алды. Ләкин концепциянең җитешсезлеге дә бар иде. Күрсәтелгән принципларга нигезләнгән программалар, технологияләр булмау бу концепцияне тиешенчә тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәде.

Татарстанда да 90нчы еллар башында милли мәгарифне торгызуга омтылыш зур иде. Ләкин бу эшне башлап җибәрергә теоретик белемнәребез юк дәрәҗәсендә булды. Татар мәктәбен яңадан торгызу-үстерүнең теоретик-методологик проблемаларын тирәнтен өйрәнергә, аның концепциясен яңадан тудырырга туры килде.

Татар мәгарифен үстерү концепциясе 1991 нче елда Татарстан Мәгариф министрлыгы коллегиясендә кабул ителде. Кон-

цепциядә татар мәгарифенең күп баскычлы тәрбия системасы булуы, аның милли традицияләргә, дөнья педагогикасының алдынгы тәҗрибәсенә таянуы ассызыклана, укыту һәм тәрбиядә ана теленең роленә, дөнья мәдәниятен өйрәнүдә рус теленең әһәмиятенә басым ясала ("Концепция развития татарского просвещения" // "Панорама", №8, 1991.).

Татар милли мәгарифен үстерү принциплары, укыту һәм тәрбия процессы төрки халыклар, Көнчыгыш һәм Ислам культурасына таяна, шуның белән беррәттән, дөнья илләренең, беренче чиратта, Көнбатыш дәүләтләренең алдынгы педагогик тәҗрибәсенә таяна.

Безнең концепциянең шушы принцибы Россия Федерациясенең мәгариф концепциясе төзү идеологларына ошап бетмәде. Ничек инде ул Татарстандагы татар мәктәбендә, христиан дине кануннарына түгел, ислам кыйммәтләренә табыналар?! Ләкин татар мәгарифен үстерү концепциясен бу нигездә төзүнең сәбәпләре һәркемгә ачык. Тоталитар дәүләт системасының унитар мәгариф системасы эчтәлеге белән дә, милләтләрне рухи канәгатьләндерү ягыннан да гамәлгә яраксыз иде. Милли мәктәпне яңа шартларда торгызу һәм үстерү өчен икенче идеология кирәк булды. Татар халкының борынгыдан килгән тәрбия кануннары бар. Төрки халыкларның үзләренә генә хас үзенчәлекле традицияләре бар. Көнчыгыш һәм Ислам культурасы күп гасырлар буе укыту һәм тәрбия эшендә уңышлы файдаланылган.

Югарыда күрсәтелгән принцип татар милли мәгарифен үстерү концепциясенең нигезен тәшкил итәргә тиешлеге аңлашыла булса кирәк. Татар мәгарифен үстерү концепциясе Татарстаннан читтә яшәүче татарларны да күздә тотып төзелде.

Концепциянең безнең Республикада киң фронт белән гамәлгә ашырылуының сәбәбе шунда, бу эш концепция төзү белән генә тукталмады, ә концепцияне тормышка ашыруның конкрет программасы булдырылды һәм аның үтәлеше Мәгариф министрлыгы, район һәм шәһәр мәгариф бүлекләре тарафыннан даими контрольдә булды.

Татар мәгарифен үстерү программасындагы кайбер чараларны искә төшерү урынлы булыр. Иң беренче чиратта, татар теленең дәрәҗәсен, ролен күтәрү чаралары күрелде, аның иң үтемле һәм нәтиҗәле юлы итеп, балалар бакчасында тәрбияләнгән балалардан алып, урта мәктәпләрдә укучы һәр сыйныф баласына да татар теле һәм әдәбияты мәҗбүри дәрес итеп кертелде. 1991 нче елның 1 нче сентябреннән бу эш гамәлгә керде.

Балаларны татар мәктәбендә ана телендә укытуга күчерү чаралары түбәндәгеләр иде:

а) татар гимназияләре, лицейлары ачу. Махсус уку планы буенча белем бирә торган бу тип уку йортларының гадәти урта мәктәпләрдән өстенлекләре күп иде. Шуңа күрә гимназияләрдә укырга теләүчеләр дә күп булды. Шәһәрләрдә, район үзәкләрендә шактый санда лицей һәм гимназияләр ачылды;

б) лицей һәм гимназияләрдә укырга барлык балаларның да әзерлекләре җитмәскә мөмкин. Мондый очракта алар татар мәктәпләрендә укый алалар;

в) тулысынча татар мәктәбе оештыру мөмкинлеге булмаганда, рус мәктәбендә I класстан башлап татар класслары ачу;

г) рус мәктәпләрен татар мәктәбенә әйләндерүнең тагын бер юлы тәкъдим ителде. Бу шәһәр шартларында микрорайоннарда балаларны бер мәктәптән икенчесенә күчерү уңайсыз булган очракта эшләнде. Рус мәктәбенең I классына татар балалары гына алына, башка классларда укулар рус телендә дәвам итә. Киләсе елга тагын I класска татар балалары алына. Шулай итеп, 10 елдан рус мәктәбе татар мәктәбенә әйләндерелә.

Республикада барлык балаларга да татар теле керү һәм татарча укыта торган уку йортларының саны арту укытучы кадрларны күпләп әзерләү кирәклеген китереп чыгарды. Шул уңайдан, яңа шартларда эшләүче педагогик кадрларны әзерләүнең яңа концепциясе төзелде.

Программаны үтәүнең конкрет чараларыннан районнардагы һәм шәһәрләрдәге мәгариф бүлекләре мөдирләренең милли мәгариф буенча ярдәмчеләре, урта мәктәп директорларының милли мәгариф буенча ярдәмчеләрен билгеләүне дә санарга кирәк. Программаны үтәүдә дә аларның файдасы күп булды.

Милли мәктәпнең күтәрелеше халыкның этнос буларак үсүенә китерде. Чыннан да, этник күтәрелеш белән милли мәктәп арасында турыдан-туры бәйләнеш бар. Беренчедән, этник культура элементлары милли мәктәп үсешенең нигезен тәшкил итте. Икенчедән, милли мәктәп халыкның этник үсешен тормышка ашыручы магистраль юл ул.

Милли мәктәп этносның милли культурасын формалаштыра, дидек. Ләкин милли мәктәпнең максаты бу гына түгел әле. Милли мәктәп этносны соңгы елларда дөньяда барган цивилизацияле үсешкә, мәдәни-социаль-демографик үзгәрешләргә дә әзерләргә тиеш. Ә моның өчен, милли мәктәпләрдәге укытуның эчтәлеген, уку планнарын бу үзгәрешләргә яраклаштырып, камилләштереп торырга кирәк.

Милли мәктәпләрдә хезмәт тәрбиясенең әһәмияте зур. Укучыларны тормышка әзерләү – иң мөһим проблемаларның берсе. Этносның хезмәткә әзерләү традицияләре исәпкә алынырга тиеш. Гомер-гомергә татар халкында агач эшкәртү, агач материалы белән корылмаларны бизәү, алтын, көмеш белән, тире белән эшләү, чигү һ.б. юнәлешләрдә эшләү алга киткән булган. Болар милли мәктәптә үз урынын алырга тиеш. Чөнки онытылып баралар иде. Бу уңайдан Ерак Көнчыгыш һәм төньяктагы аз санлы халыкларның балаларын хезмәткә әзерләүдә җибәрелгән хаталар гыйбрәтле. Унитар мәктәп системасы тәртипләре буенча, ул балаларны шәһәрләрдә укыталар, интернатта тоталар, аларны хезмәткә әзерләү дә шәһәр шартларына яраклаштырыла иде. Мәктәпне тәмамлап өйләренә кайткан бу балалар эшкә керешергә тиеш. Ул җирлектә халыкның төп шөгыле болан асрау һәм аучылыктан гыйбарәт. Ә балалар әлеге хезмәткә өйрәтелмәгән. Мондый хәл килеп чыкмасын өчен, милли мәктәпләр укучыларны хезмәткә әзерләүне көчәйтергә тиеш. Шуның белән беррәттән, хезмәткә хәзерге заман икътисадына яраклаштыру да мөһим чараларның берсе. Милли мәктәпләрдә укучыларны тормыш өчен түбән квалификацияле эшче кадрлар итеп кенә әзерләү, дип аңламаска кирәк, цивилизацияле җәмгыять нинди кадрларга мохтаҗ, шуңа әзерләнергә кирәк. Хәзерге көндә Япония дәүләте тормышның барлык юнәлешләрендә гүзәл уңышларга ирешкән икән – моның сәбәбе – мәктәптә. Япония мәктәпләрендә укучыларга тирән белемнәр дә бирелә, тиешенчә хезмәткә әзерлек тә булдырыла.

Милли мәгарифне тиешенчә үстерүдә объектив һәм субъектив кыенлыклар да бар: федераль һәм милли-региональ дәрәҗәдә милли мәктәпләрнең максаты һәм укучыларга биреләсе белемнәр эчтәлеген килештерүдә каршылыклар бар, күп сандагы уку планнарыннан кирәклесен сайлап алу өчен нигезле рекомендацияләр юк дәрәҗәсендә, белем стандартының милли региональ компоненты тиешенчә эшләнмәгән һ.б.

Алга таба эшләнергә тиешле чараларга тагын түбәндәгеләрне өстәр идем:

– бүгенге көн һәм алдагы еллар өчен, милли мәктәпнең укыту эчтәлеге буенча гомуми теориясен булдыру;

– белем стандартының федераль һәм милли компонентларында милли культура, күршеләр культурасы һәм дөнья культурасы кыйммәтләренең оптималь бәйләнешен булдыру;

– милли мәктәпләрнең матди-техник базасын ныгыту, аларда эшләү өчен, әзерлекле кадрлар булдыру.

Бу шартларны үтәгәндә, милли мәктәпләрнең алда торган бурычларны үтәп чыгуына шикләнмәскә мөмкин.

Милли мәгариф өлкәсенә караган программа, концепциядә, дәүләт документларында Татарстаннан читтә яшәүче татарларның мәгарифен, мәдәниятен үстерү, яңарту мәсьәләләренә зур урын бирелә. Мондый мөһим эшләрне гамәлгә ашыру урыны булып, Татарстан тора. Башка өлкә-республикаларның мәгариф белән идарә итү органнары белән бергә гомуми бурычлар билгеләгәндә генә, Милли (татар) мәгариф системасын торгызырга, яңартырга мөмкин. Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев Беренче Бөтендөнья татар конгрессында мондый эшчәнлекнең гаять дәрәҗәдә мөһим булуы турында билгеләп үткән иде. Без республикабыздан читтә яшәүче миллионнарча татарларның язмышы турында онытырга тиеш түгел. Шуңа күрә, Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы бу юнәлештә төгәл максатлар билгеләде. Мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек итү турында Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Россиянең 18 төбәге белән килешү төзелде. Мәскәү, Ленинград, Рязань, Тамбов, Томск, Пенза, Кемерово, Волгоград, Киров, Ульяновск, Әстерхан, Чиләбе өлкәләренә, Абхазия Республикасына, Ханты-Мансийск округына килешү проектлары җибәрелде.

Хәзерге вакытта Мәгариф министрлыгы әлеге килешүләрне гамәлгә ашыру буенча сизелерлек эш башкара. Бу эшнең төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтында һәр елны татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен курслар оештырыла;

– республика-өлкәләрнең үтенечен искә алып, безнең методистлар, галимнәр, шул төбәкләргә барып, укытучылар өчен махсус занятиеләр, очрашулар үткәрәләр;

– чуваш, мари, мордва, удмурт телләре мөгаллимнәре милли республикаларның укытучылар белемен күтәрү институтларында оештырыла торган өлкәара курсларда укыйлар;

– Удмуртия, Мари Эл, Чувашия республикалары, Түбән Новгород, Ленинград өлкәсе укытучылары һәм мәгариф хезмәткәрләре белән бергә, фәнни-гамәли конференцияләр, семинар-киңәшмәләр уздырылды;

– координация советлары утырышлары бергәләп оештырылды (Мари Эл, Санкт-Петербург);

– башка төбәкләргә методик кулланмалар, ял көне мәктәпләре программасы, татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадалар

уздыру өчен материаллар, татар халкы бәйрәмнәре, дәрес эшкәртмәләре җибәрелде;

– татар иҗтимагый оешмалары белән элемтәләр урнаштырылды.

Соңгы ике елда Мәгариф министрлыгы башка төбәк укучыларын татар теле һәм әдәбияты олимпиадасына чакыру мөмкинлеген тапты.

Узган уку елында уздырылган шундый олимпиадада Башкортстан, Удмуртия, Мордовия, Мари Эл республикалары, Төмән, Ырынбур, Түбән Новгород, Самара, Ульяновск, Пермь, Саратов өлкәләре укучылары катнашты.

Без, иң беренче чиратта, татар мәктәпләре күбрәк эшли торган төбәкләргә игътибар итәбез. Шундыйларга Башкортстан (1037 мәктәп). Төмән өлкәсе (119), Пенза (77), Ырынбур (73), Ульяновск (49), Түбән Новгород (29), Самара (23), Свердловск өлкәсе (23 мәктәп) керә.

Төмән өлкәсендә соңгы 3 елда татар мәктәпләре саны 93тән 119га җитте. 1991 елга чаклы бу өлкәдә мәктәпкәчә балалар учреждениеләре юк иде. Хәзер монда 15 татар ясле-бакчасы эшли. Карагандада, Нижневартовскида, Санкт-Петербургта, Сыктывкарда да татар телендә эшләүче ял көне мәктәпләре ачылды.

Татарстан Мәгариф министрлыгы татарлар яши торган төбәкләрдә эшләүче татар мәктәпләрен кадрлар белән тәэмин итү өчен, килешү нигезендә, Татарстан дәүләт гуманитар институтында татар теле һәм әдәбияты укытучыларын максатчан әзерләүне оештырырга тәкъдим итә.

Мари Эл, Чувашстан, Удмуртия мәгариф органнары белән әлеге республикаларның югары уку йортларында мари, чуваш, удмурт телләре укытучыларын максатчан әзерләү турында өстәмә килешүләр төзелә. Ә без исә, бу республикалардагы татар мәктәпләрен тәмамлаучыларны Казан педагогия университетының һәм Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлекләренә кабул итәбез.

Башка төбәкләрдә яшәүче татар мәктәпләре татарча дәреслекләргә, күрсәтмә әсбапларга, укыту программаларына мохтаҗ. Хәзер аларның барысы да республика, өлкә Мәгариф министрлыклары алдан биргән заказ буенча гына җибәрелә. 1995–1996 нчы уку елына 22 төбәк 600 мең данә дәреслеккә һәм методик әдәбиятка заказ юллаган иде. 1996–1997 нче уку елы-

на 17 төбәктән заказ кабул ителде. "Мәгариф" нәшрияты дәреслекләргә һ.б. кулланмаларга мәктәпләрнең үзләреннән дә заказлар кабул итә. Тик моның өчен нәшрият белән алдан ук килешү төзергә кирәк.

Безнең алда күп кенә мәсьәләләрне хәл итү бурычы тора. Шуларның иң беренчесе: яңа ачылган татар мәктәпләренең, мәктәп-гимназияләрнең укыту-матди базасын ныгытырга кирәк. Бу мәсьәләдә без хөкүмәтебез ярдәменә таянабыз. Башка төбәкләрдәге татар мәктәпләренә дә тиешенчә булыша алмавыбызга да нык борчылабыз.

Латин графикасына күчүне дә өлгергән мәсьәлә, дип карыйбыз. Моның белән бәйләнешле рәвештә, тиешле дәреслекләр, кулланмалар нәшер итәргә кирәк булачак.

Этнопсихологияне һәм этногеографияне өйрәнүгә дә игътибарны көчәйтергә уйлыйбыз. Татар телендә югары белем алу мәсьәләләрен дә гамәлгә ашыру сорала.

Башка республика-өлкәләр алдында да милли мәгарифне үстерү буенча зур бурычлар тора. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– милли кадрлар әзерләү өчен, төбәкләрдә махсус урта һәм югары уку йортлары ачу, булганнарында нәтиҗәле эш оештыру;

– мәгариф өлкәсенә караган программалар, педагогик технологияләр, укыту-методик эшкәртмәләр, фәнни тикшеренү нәтиҗәләре белән алмашу;

– милли мәгариф мәсьәләләре буенча сөйләшүләр, конференцияләр үткәрү;

– өлкә, республика мәгариф учреждениеләре белән турыдан-туры эшлекле элемтәләр урнаштыру;

– һәр өлкә, республикада татар мәгарифе бурычлары белән шөгыльләнүче белгеч булуына ирешү;

– фәннәрне татар, удмурт, чуваш телләрендә тирәнтен өйрәтү максатында, милли мәктәпләр һәм яңа төр уку йортлары өчен белем стандарты төзү;

– өлкә-республикалар белән бергәләп, татар теле һәм әдәбияты укыту программалары, язучылар, композиторлар, рәссамнар, артистлар иҗаты буенча аудио-видеокассеталар әзерләүнең төрле вариантларын булдыру;

– өлкә, республика педагогик югары уку йортларында һәм педучилищеларда милли (татар, чуваш, удмурт, мари һ.б.) мәктәпләргә укытучылар әзерләү өчен махсус бүлекләр ачу.

Хәл итәсе мәсьәләләр булуга карамастан, мәктәп фәннәр нигезе булды һәм ул шулай булып кала да. Нәкъ менә анда кеше тәрбияләнә, аңа белем бирелә, шәхескә әхлаклылык нигезе салына. Заман таләпләренә җавап бирә торган мәгариф системасын булдырган милләт кенә ирекле була ала!..

Физика дәресенең максатын планлаштыру

Укытуның нәтиҗәлелеген күтәрү юллары күптөрле. Түбәндә без шуларның берсенә – физика дәресләренең максатын планлаштыруга гына тукталабыз.

Дәреснең максаты социаль-экономик һәм педагогик бурычлардан, программаларда куелган таләпләрдән чыгып билгеләнелә. Конкрет дәрес өчен максатның төгәл куелуы мөһим. Дәрескә әзерләнгәндә укытучы балаларга яңа белемнәр бирү турында да, тәрбияне тормышка ашыру чаралары, укучы шәхесен формалаштыру, акыл үсешен камилләштерү хакында да уйларга тиеш. Педагогик һәм методик матбугатта моны дәреснең максатларын комплекслы планлаштыру, диләр.

Дәреснең максатларын дөрес кую өчен, аның эчтәлеген, нәтиҗәсен алдан күрә белергә кирәк. Күзәтүләр күрсәткәнчә, күп кенә укытучылар нәкъ әнә шуны күз алдына китерә алмый. Дәрес планнарында конкрет булмаган гомуми бурычлар языла. Мәсәлән: "үзиндукция күренеше турында сөйләргә", "укучыларда дөньяга фәнни караш тәрбияләргә", "укучыларның акыл сәләтен үстерергә". Мондый бурычлар конкрет максатка ирешергә ярдәм итә алмый. Белем һәм тәрбия бирүнең һәр дәрес өчен конкрет бурычлары була.

Хәзер шул максатларга тукталыйк.

1. Дәреснең белем бирү яки укыту-өйрәтү максатлары. Боларга түбәндәгеләр керә: яңа фактлар, физик күренешләр, төшенчәләр турында мәгълүматлар бирү; яңа физик күренешләрне, законнарны өйрәтү; күзәтүләр оештыру; электр чылбыры төзү, графиклар сыза, китап белән эш итә, тәҗрибәләр ясый белү һ.б.; физик төшенчәләрнең яңа билгеләрен, яңа бәйләнешләрен ачу; мәгълүм фактлар, законнар, төшенчәләр турындагы мәгълүматларны киңәйтү, тирәнәйтү; үзләштерелгән белемнәрне куллану, механизмнарның, җайланмаларның, физик приборларның төзелеше һәм эшләү принцибы белән танышу; белемнәрне гомумиләштерү, системага китерү һ.б.

Күренгәнчә, дәрес максатының бу төре яңа белемнәр үзләштерүне, укучыларда күнекмәләр, таныпбелү алымнары формалаштыруны күздә тота. Шуны да искә төшерик, укыту процессының нәтиҗәлелеге соңгы елларда берничә дәрәҗә белән күрсәтелә башлады. Шуңа күрә максатны да шул дәрәҗәләр өчен конкретлаштыру зарур. Беренче дәрәҗә: материалны аңлау һәм хәтердә калдыру; икенчесе: укучыларның белгәннәрен үз сүзләре белән аңлата белүе; өченчесе: белемнәрне билгесез ситуацияләрдә куллана алу.

Дәреснең белем бирү яки укыту-өйрәтү максаты шулардан чыгып билгеләнелә. Бер мисал китерик:

"Алмаш электр чылбырында резонанс күренеше" темасын өйрәнгәндә (X класс), түбәндәге максатлар куела: көчәнеш резонансы вакытында физик күренешләрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, мәсьәләләр чишкәндә әлеге күренеш закончалыкларыннан файдалана белү, резонансның практикада кулланылуын күрсәтү һәм укучыларның политехник карашын киңәйтү, радиотехникага кагылышлы профессияләр турында мәгълүмат бирү.

2. Дәреснең тәрбияви максаты укучыларда әхлакый сыйфатлар булдыруны күздә тота. Ләкин моңа аерым дәрестә генә ирешү мөмкин түгел. Бу – дәвамлы процесс. Аерым дәресләрдә исә түбәндәге тәрбияви максатларны куярга була: идея инанганлыгы; хезмәтне ярату, аны теләп башкару, җәмгыятькә файдалы хезмәткә әзер булу; илебездәге бөек төзелешләр белән горурлану, патриотизм хисе; физика фәнен, техниканы үстерүдә зур хезмәт куйган галимнәргә, производствода югары күрсәткечләргә ирешкән хезмәт кешеләренә мәхәббәт; табигатьне саклау, Туган илне сакларга әзер булу; интернационализм (башка халыкларның фән, культура һ.б. өлкәләрдәге эшчәнлегенә ихтирам); коллективизм, гуманизм (шәфкатьлелек, башкалар турында кайгырту, өлкәннәрне хөрмәтләү; кешелексезлек күренешләренә түзеп тормау); эстетик, атеистик тәрбия бирү һ.б.

"Егәрлек" темасын (VII класс) өйрәнү дәресенә түбәндәге тәрбияви максатларны куярга була: совет энергетикасының дөньякүләм уңышларын үсеш перспективасын аңлату юлы белән идея-патриотик тәрбия бирү; хезмәт житештерүчәнлеген күтәрүдә егәрлекнең ролен күрсәтү, эшче профессияләренә хөрмәт, хезмәткә уңай караш тәрбияләү.

3. Укучыларның фикерләү сәләтен, акыл үсешен камилләштерү максаты: физик зурлыкларның, күренешләрнең төп билгеләрен аерып күрсәтү, аналитик фикер йөртә белү, гомумиләш-

терү, физик күренешләрдәге гомуми билгеләрне ачыклау; интуитив, индуктив һәм дедуктив фикерләү юлы белән нәтиҗәләр ясарга; гипотезалар әйтергә, аны дәлилләргә, проблемаларны хәл итәргә өйрәтү.

"Газларда электр тогы" темасын (X класс) өйрәнгәндә, мәсәлән, укучыларның акыл үсешен тәэмин итү өчен, түбәндәге максатлар куюю урынлы: физик күренешләрнең бер-берсенә бәйле булуын (электр чыбыкына тоташтырылган газлы пыяла көпшәдә көчәнешнең кимүе яки артуы һәм газ молекулаларының хәрәкәт тизлеге үзгәрү), сан үзгәрешләренең сыйфат үзгәрешләренә китерүен (корылган кисәкчекләрнең энергиясе арту, газ молекулаларының таркалуы, газ эчендә электр үткәргеч тирәлек хасил булу) ачыклау юлы белән укучыларда диалектик фикерләүне үстерү; күренешләрне чагыштырырга, нәтиҗә ясарга; аналогия, эксперимент кебек фәнни методлар ярдәмендә физик күренешләрне, диалектик категорияләрне анализларга өйрәтү.

Инде дәреснең максатын комплекслы планлаштыруга мисаллар китерик.

Тема. Газларда, сыеклыкларда һәм каты җисемнәрдә диффузия күренеше (VII класс).

1. *Дәреснең укыту-өйрәтү максаты.* Молекула һәм атомнарның туктаусыз хәрәкәте, диффузия күренеше турында төшенчә бирү, төрле җисемнәрдә бу күренешнең характерын һәм аерымлыкларын укучыларның төшенүенә һәм конкрет мисаллар ярдәмендә аңлата белүенә ирешү.

2. *Тәрбияви максат.* Материалның бер өлеше булган матдә кисәкчекләренең мәңгелек хәрәкәте үрнәгендә укучыларда диалектик-материалистик караш тәрбияләү; диффузия күренешенең авыл хуҗалыгы культуралары, үсемлекләр өчен әһәмиятен, авыл хуҗалыгы продуктларын эшкәртү (яшелчә тозлау һ.б.), тирә-юнь мохитнең, сулыкларның чисталыгын тәэмин итүдәге (буа, елга-күлләрнең пычрануы су эченә кислород керүне тоткарлый, балыклар өчен яшәү шартлары кыенлаша) ролен билгеләп үтү.

3. *Укучыларның фикерләү сәләтен камилләштерү максаты.* Диффузия күренешенең төрле җисемнәрдә төрлечә булырга тиешлеген матдә төзелеше һәм матдә кисәкчекләренең хәрәкәтендәге аерымлыкларны чагыштыру ярдәмендә исбат итәргә, проблемалы ситуацияне анализларга, проблема куярга, гипотезалар әйтергә, аны дәлилләргә, нәтиҗә ясарга өйрәтү.

"Сыеклыкларның кайнавы. Чагыштырма пар ясалу җылылыгы" темасы (VIII класс).

Дәреслекнең укыту-өйрәтү максаты. Укучыларда “сыеклыкның кайнавы”, “кайнау температурасы”, “чагыштырма пар ясалу җылылыгы” төшенчәләрен формалаштыру; кайнау процессының физик эчтәлеген аңлатырга өйрәтү; кайнау процессын графикта күрсәтә, кайнау процессын өй шартларында күзәтә белү, таблица куллану, конспект төзү, мәсьәләләр чишү күнекмәләрен ныгыту.

Тәрбияви максат. Кайнау күренешенең материянең сыйфат үзгәрешләренә китерүенә басым ясау – дөньяга диалектик-материалистик караш тәрбияләүне дәвам иттерү; температура үзгәрү, сыеклыкның кайнавы мисалында сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; илебездә, республикада җылылык энергетикасының үсешен күрсәтү юлы белән патриотик тәрбия бирү; промышленностьта, медицина һәм авыл хуҗалыгында пар ясалу күренешеннән файдалану, нормаль һәм түбән температураларда кайнауга тәҗрибәләр күрсәтү ярдәмендә укучыларның хисләренә тәэсир итү; физикага кызыксыну тәрбияләү.

Укучыларның фикерләү сәләтен, акыл үсешен камилләштерү максаты.

Физик күренешләрне чагыштыра белергә өйрәтүне дәвам иттерү; кайнау һәм парга әйләнү процессларындагы уртаклыкны һәм аерымлыкны билгеләү; кайнау процессының молекуляр-кинетик нигезләре турында эзлекле сөйләү.

“Эчке энергия. Термодинамикада эш” темасы (X класс). Эчке энергия, эш төшенчәләре, механик эшнең формуласы укучыларга таныш инде. Дәреснең максатын билгеләгәндә аңа шул белемнәрне тирәнәйтү, кайбер өстәмә мәгълүматлар бирү күздә тотылырга тиеш.

Дәреснең белем бирү максаты. Эчке энергия турында укучыларның белемнәрен актуальләштерү һәм тирәнәйтү; термодинамик параметрлар: басым (P), күләм (V), абсолют температура (T) төшенчәләре нигезендә термодинамикада эш төшенчәсен формалаштыру, эшнең эчке энергиясе үзгәрү зурлыгын конкрет очраклар өчен аңлата белергә, мәсьәләләр чишәргә өйрәтү.

Тәрбияви максат. Табигатьтәге үзгәрешләрнең физик эчтәлеген ачыклау, энергия чыганакларына, табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.

Фикерләү сәләтен үстерү, күнекмәләр булдыру максаты. Гипотезалар әйтү, проблемалар хәл итү юлы белән мөстәкыйль

фикер йөртү алымнарына өйрәтү, өстәмә материал белән эшләү күнекмәләре булдыру.

Дәреснең максатын комплекслы планлаштырмыйча гына, дәрестә төп бурычларны уңышлы хәл итәргә мөмкин түгелме соң? Тәҗрибәле укытучылар моңа билгеле бер дәрәҗәдә ирешә, әлбәттә. Ләкин, психология фәне өйрәткәнчә һәм тәҗрибә күрсәткәнчә, башкарылачак эшнең уңышы планлаштыруга бәйле.

Куелган максатларга ирешүдә дәрестә башкарыласы эшнең зарурлыгына укучының инануы да мөһим. Әйтик, укучы дәрестә өйрәнгән материалның төп положениеләренә карата тормыштан мисаллар китерергә кирәк булачагына ышанса, бу күнекмәләрне ул, күп көч куймыйча, теләп башкара.

Аннары, дәреснең максатларын билгеләгәндә, укытучының һәм укучыларның эш алымнары һәм методларын да күз алдына китерергә кирәк. Укучыларда активлык, мөстәкыйльлек тәрбияләргә уйлыйбыз икән, материалны лекция яки сөйләп аңлату юлы белән өйрәнү максатка ярашлы булмас. Бу очракта проблемалы укыту методлары: проблемалы ситуация китереп чыгару, гипотезалар әйтү, проблема кую, укучылар эшчәнлеген аны хәл итәргә юнәлдерү, мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәләр ясарга өйрәтү, закон һәм закончалыклар ачу һ.б. кулайрак.

Бер үк алым яки метод ярдәмендә берничә бурычны хәл итү мөмкинлеген дә истә тотарга кирәк. Мәсәлән, дәрестә мәсьәлә чишү күздә тотыла икән, математик исәпләүләр күнекмәсе булдыруны гына максат итеп куярга ярамый. Алдынгы укытучылар мәсьәләләр чишү юлы белән укучыларның белемнәрен актуальләштерәләр. Бу исә яңа материалны өйрәнгәндә аларның активлыгын арттыра. Аннары мәсьәләләр чишү – яңа белемнәр үзләштерү чарасы да. Әйтик, "Архимед көче" темасы өйрәнелә, ди. Укытучы класска мәсьәлә тәкъдим итә: сулы савытка җепкә бәйләп куб төшерелгән. Аның өске һәм аскы өслекләре су эчендә h_1 һәм h_2 биеклегендә. Кубка басым ясаучы көчләрнең бердәй тәэсир итүчесен табарга кирәк.

Аны чишү нәтиҗәсендә укучылар мөстәкыйль рәвештә дәреснең төп нәтиҗәсен ясыйлар: сыеклыкка батырылган җисемгә шул җисем күләмендәге су авырлыгы кадәр көч астан өскә таба тәэсир итә.

Кайчак теоретик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен дә мәсьәлә чишү юлы белән тикшерергә мөмкин. Мәсәлән, X класста, Кулон законын өйрәнгәч, шундый мәсьәлә тәкъдим итәргә була: ике кечкенә металл шарчык бер-берсеннән 20 см ерак-

лыкта. Алар башта бер үк исемдәге корылма белән, ә аннары шул ук микъдардагы капма-каршы исемдәге корылма белән корыла. Икенче очракта шарчыкларның бер-берсенә тәэсире зуррак була. Бу күренешне ничек аңлатыр идегез?

Бер исемдәге корылма белән корганда, шарлар бер-берсеннән этелә, корылмалар аларның капма-каршы өслекләренә тупланa. Шарчыкларның күләме бар. Шуңа күрә корылмалар арасындагы ара арта, ә Кулон законы – ноктадай корылмалар өчен генә. Теманың аңлап үзләштерелгән булуын ачыклау өчен, мәсьәләнең асылын укучыларның әнә шулай бәян итүе җитә.

Дәрескә күп төрле укыту-тәрбия бурычлары билгеләү читен эш түгел. Ә дәрес материалының эчтәлегеннән чыгып, шушы дәрес өчен конкрет максат кую – шактый катлаулы эш. Монда өйрәнеләсе белемнәрнең күләме дә, күнекмәләрнең сыйфаты да, класстагы укучыларның белем дәрәҗәсе, физика кабинетының мөмкинлекләре дә истә тотыла.

Тагын шуны да әйтик: билгеләнгән максатлар укучыларның игътибарын төп фикердән читкә юнәлтергә тиеш түгел. Әйтик, VI класста "Тоташкан савытлар" темасы өйрәнелә, ди. Укытучы дәрестә рәсемнәр дә, диафильмнар да, шлюз модельләре дә куллана, кино да күрсәтә, бездә һәм чит илләрдә төзелгән шлюзлар турында да сөйли. Ләкин төп фикергә, материалның физик асылына – тоташкан савытларда сыеклыкның бер тигезлектә булуына басым ясамый. Сыеклык молекулаларының хәрәкәтчән булуы, җир тарту көче тәэсирендә сыеклык молекулаларының үзләреннән астарак урнашкан молекулаларга басым ясавы да игътибардан читтә кала. Дәреснең белем бирү максатлары тиешенчә үтәлми...

Кыскасы, дәреснең максатларын дөрес планлаштыру һәм аны тулысынча тормышка ашыру укытуның нәтиҗәлелеген күтәрергә ярдәм итәчәк!..

("Совет мәктәбе" журналы, № 9 – 1985 нче ел)

Глобальләшү процессы һәм мәгариф системасы

XX гасырның соңгы еллары һәм XXI гасырның башында сәяси, икътисади һәм социаль факторларның тоташ бер бәйләме кешелек цивилизациясенең үсешенә куәтле сулыш бирде, бөтен дөнья иҗтимагый фикерен гуманизм һәм демократия юлына юнәлтте.

Дөньяда бара торган глобальләшү процессын да шуның белән аңлатырга кирәктер. Бу процесс дөнья илләренең мәга-

риф системаларының интеграцияләнүенә дә уңай йогынты ясый. Европаның алга киткән илләренең Италиядәге Болонья шәһәрендә мәгарифнең киләчәге турында килешү төзүе – шуның ачык мисалы.

Бу килешүне процесс яки конвенция, дип тә атыйлар. Ул 1999 нчы елда төзелде. Конвенциянең максатлары: төрле илләрдәге профессиональ уку йортларының белем стандартын һәм күнекмәләрен тәңгәлләштерү, белгечләр алган квалификацияне һәм дипломнарны тану һәм гамәлгә кую, дөнья илләрендә конкурентлык сәләтен үстерү. Болонья процессының төп принципларының берсе – белем бирүнең сыйфатын яхшырту. Моңа ирешүдә сыйфат өчен көрәшнең бердәй идарә итү технологиясен эшләү зарур.

Болонья документларында бу максатларга ирешү юллары да күрсәтелгән: югары уку йортларының ике баскычлы (бакалавр, магистр) булуы, зачет берәмлекләре нигезендә кредит системасы кертү, уку йортларын лицензияләү, аттестацияләү һәм аккредитацияләүдә бердәм таләпләр булдыру. Европадагыча, бердәм белем бирү пространствосы дөньяда әйдәп баручы һәм иң нәтиҗәле булырга тиеш.

Дөнья практикасында укыту программаларының эчтәлеген зачет берәмлекләре системасы, дип атыйлар. Бер зачет берәмлегенә программа материалыннан күпме сәгать бирелә, гомуми вакытның ничә сәгате лекциягә, күпмесе гамәли эшләргә яки семинарларга бирелергә тиешлеген конвенциядә катнашучы илләр үзара килештерергә тиеш.

Болонья процессына 2003 нче елдан Россия дә кушылды.

Процесста катнашучы буларак, Россия белем сыйфатын билгеләүче критерийларны эшләүгә керешне дә инде. Бу эштә мөһим бурычларның берсе – уку йортларында бирелә торган белемнәрнең сыйфатын яхшырту. Демократияләшү чорының шартлары буенча, ул эш шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен эшләнергә тиеш.

Уку йортларының укыту-тәрбия процессы алдына куелган таләп элегрәк (үзгәртеп кору процессына кадәр) гади генә иде – укучыны хезмәткә әзерләү. Хәзер мәгарифтәге үзгәрешләр шәхес, җәмгыять һәм дәүләт өчен эшләнә. Шәхес тәрбияләүдә дә төп бурыч хезмәткә әзерләү генә түгел, ә хезмәткә һәм тормышка әзерләү.

СССР таркалган елларда реформаторлар шәхесне үстерүче, гуманлы һәм гуманитар юнәлешле яңа мәгариф системасы тәкъдим итте. Базар икътисадына керә башлагач, бурыч үзгәрде –

базар икътисады шартларына яраклаша белүче, конкуренция көрәшендә җиңәргә сәләтле буын әзерләү максаты куелды.

Болонья конвенциясе таләпләре буенча, безнең илдәге унитар мәгариф системасы үзгәрешләр кичерә, төрле типтагы уку йортлары системасы барлыкка килә.

Болонья процессында катнашучы ил буларак, безгә әле ул илләргә тиңдәш булу өчен күп нәрсәләр эшләргә, яңалыклар кертергә кирәк.

Укыту-тәрбия, белем бирү процессында яңалыклар (инновацияләр) үзеннән-үзе генә түгел, ә, бәлки, теоретик эзләнүләр һәм эксперименталь тикшеренүләр нәтиҗәсендә барлыкка килә. Бу яңалыклар өч өлештән тора: яңа фәнни-теоретик мәгълүматлар, шулардан чыгып тәкъдим ителгән конкрет методик күрсәтмәләр һәм яңа белемнәр нигезендә эшләнгән педагогик технология.

Белем эчтәлеге булдырганда да, укучыларга яңа белем биргәндә дә, тәрбия чаралары уздырганда да, педагогик процесста катнашучылар эшчәнлегенең нәтиҗәле структурасы һәм педагогик чараларның яңа системасын булдыру өчен дә инновацион технологияләр кулланыла. Дистанцион укыту технологиясе соңгысына мисал булып тора.

Дистанцион укытуны читтән торып укытуның яңа формасы, дип уйлаучылар да бар. Ләкин болай уйлау дөрес булып бетмәс. Ул – укытуның үзенчәлекле яңа технологиясе. Бу технологияне читтән торып укучылар өчен дә, уку йортларында даими укучылар өчен дә файдаланып була. Күп кенә чит ил уку йортлары, бигрәк тә хезмәткәрләрнең белемен күтәрү белән шөгыльләнүче уку йортлары, бу технологияне күптән кулланалар инде.

Дистанцион укыту (distant learning) – укучыларның һәм укытучыларның вакыт һәм пространствода яңача бәйләнешләрен, хезмәттәшлеген тәэмин итүче укыту төре. Хәзер дистанцион укыту технологиясенең берничә варианты файдаланыла:

а) кейс технологиясе. Кейска (инглиз сүзе, портфель мәгънәсен белдерә) укыту фәненнән укыту-методик ярдәмлекләр салына, сораулар, биремнәр күрсәтелә һәм укучыга җибәрелә. Укучы кейсны ала, ярдәмлекләр белән таныша, биремнәрне үти, мөстәкыйль эшләрне башкара.

Урта һәм югары һөнәри уку йортларында читтән торып укучылар һәм югары уку йортларына әзерлек төркемендә укучылар өчен бу технология безнең илдә күптән кулланыла. Укучыны мөстәкыйль эшләргә өйрәтү ягыннан бу бик уңай

алым. Ләкин тискәре яклары да бар: биремнәрне үтәгәндә укытучы белән бәйләнеш булмау укучыда авырлыклар китереп чыгарырга мөмкин. Һәр укучы өчен уку ярдәмлекләре, биремнәр комплексын эшләү дә уку йортларына өстәмә мәшәкатьләр тудыра;

б) хәзер күп кенә югары уку йортларының (башкаладан читтә) вәкиллекләре оешты. Уку планнары, дәреслекләр, укытучы кадрлар белән вәкиллекләрне югары уку йорты тәэмин итә, югары уку йортында укучылар өчен торган урыныннан читкә китмичә генә белем алу мөмкинлеге тудырыла. Вәкиллек белән югары уку йорты арасындагы ераклыкны (дистанция) искә алып, белем бирүнең мондый формасын да дистанцион укытуга кертәләр;

в) телевизион технологияләр. Дистанцион укытуның бу төре читтән торып укучылар өчен лекцияләр циклы оештырганда, консультацияләр уздырганда, семинарларга, контроль эшләргә әзерләнгәндә бик уңайлы һәм нәтиҗәле. Моның өчен, уку йорты телевизион канал программасы белән махсус килешү төзи, тапшыруларның вакыты билгеләнә һәм укучыларга тапшырулар расписаниесе җиткерелә. Оештыру мәсьәләләре уңай хәл ителгән очракта, укучылар өчен мондый лекцияләр, консультацияләрнең файдасы күп.

Кайбер югары уку йортлары бу технологияне кейс-технологиягә өстәмә итеп тә файдаланалар. Бу очракта, әлбәттә, нәтиҗәлелек бик күпкә арта;

г) компьютерлы технологияләр. Монда белем бирүнең төп юлы буларак, компьютер программалары киң кулланыла, компьютер ярдәмендә эшләү өчен укучыларда электрон дәреслекләр һәм өйрәтүче программалар булдырыла. Күп эшләр Интернет аша башкарыла. Укучыларның белеме дә электрон мәгълүмат чаралары аша исәпкә алына.

Студент Интернет-сервер аша укытучы белән бәйләнешкә керергә, тестлар ярдәмендә белемен тикшереп карарга һәм имтихан тапшырырга да мөмкин.

Укучыларның сәламәтлеге турында кайгырту да дөньякүләм җитди проблемага әйләнеп бара. Болонья процессында мона аеруча игътибар ителә.

Мәктәп баласының сәламәтлеген өйрәнүче галимнәр фикеренчә, балалар сәламәтлеге, беренче чиратта, гаиләдә тиешле шартлар булдыруга бәйле. Икенче сәбәп – мәктәптә уку планнарының, программаларның катлауълануы. Шуның нәтиҗәсендә

укучы мәктәптән арып кайта. Күп вакытын дәрес әзерләүгә сарыф итүгә мәҗбүр, аның ял итәргә, сәламәтлеген ныгытырга, спорт белән шөгыльләнергә вакыты калмый. Дәрес тукланмау, экологик шартларның начарая баруы да сәламәтлеккә зыян китерә, әлбәттә.

РФ Мәгариф министрлыгының бүлек мөдире В.Ф.Сауткин күрсәткәнчә ("Народное образование" журналы, №6 – 2001, 16 б.), фәннәрне тирәнтен өйрәнү классларында барлык балаларның 18% тан артыгы укый, ә ул классларда укырга сәләтле балалар – 10% тан, өстәмә педагогик ярдәм күрсәтү өчен ачылган классларда укучы балалар саны 4% тан артмый, ә мондый классларда укырга мохтаҗ балаларның саны барлык балаларның 40%ыннан артып китә. Боларны да исәпкә алырга кирәк булачак.

Хәзер инновацион мәктәп, лицей, гимназия һ.б. типтагы уку йортлары турында күп сөйләнелә. Ләкин ул уку йортларына фәнни билгеләмә бирелми. Чит илләрдәге яки революциягә кадәр бездә киң таралмаган махсус уку йортларына ишарә ясала. Хәзерге вакыттагы альтернатив-вариатив үсеш максатларын күздә тоткан билгеләмәләр юк. Мәгълүм булганча, бүгенге гимназия һәм лицейларның төп максаты билгеле. Ул – укучыларны югары уку йортларына керергә әзерләү.

"Элиталы мәктәп" төшенчәсе белән дә шундый ук хәл. Гадәттә, элиталы уку йорты, дигәндә, түләүле мәктәп, гимназия, лицей, югары уку йортын күздә тоталар.

Элиталы мәктәпләр уку планнарына күптөрле өстәмә фәннәрне – икенче, өченче чит телне, валеология, йөзү, хореография, этиканы һ.б. өстиләр. Директорга яки кайбер ата-анага нәрсә ошый – шуны булдыралар. Кайвакытта "экзотик-фән" укытырлык белгеч табалар. Бай ата-аналар мәктәп иданнәрен, бүлмәләрен келәмнәр белән тутыра, мәктәпләрдә милиционерлардан, ата-аналардан даими дежур тору оештырыла.

Мондый мәктәп элиталы мәктәп була аламы соң? Сүзлекләрне ачып карасак, "элита" сүзе "җәмгыятьнең иң яхшы өлеше", "сайлап алынган иң яхшы токым" (терлек), "үсемлекнең яхшы төре" төшенчәләрен аңлата.

Югарыда сөйләгән уку йортын берничек тә элиталы, дип атап булмый, чөнки анда тәрбияләнгән балалар җәмгыятьнең иң яхшы өлеше була алмаячак. Җәмгыятьнең, илнең икътисадын, халыкның тормыш-көнкүреш дәрәҗәсен күтәрүне югары белемле, тәрбияле, тырыш, эшчән, кешеләрне, илен яраткан кадр-

лар гына хәл итә ала. Ә андый тәрбия бирә торган йортны, чыннан да, элиталы уку йорты дип атарга була.

Уку йортларының төре турында да ачык кына фикер юк. Мәгълүм тикшеренүче фикеренчә, "Россиядә гомумбелем бирү мәктәпләре ике төрле: аларның беренчесе – элиталы мәктәпләр. Анда хәлле кеше балалары һәм сәләтле балалар укый. Икенчесе – киң таралган гадәти мәктәпләр. Аларда башка балалар укый" (Даринский А.В: Нужна ли элитарная школа? // "Педагогика" № 7 – 2002, 21 б.). Мәктәпләрнең мондый бүленешен гадел бүленеш дип атап буламы соң? Хәлле кеше балаларын фәкыйрьләрнекеннән аерып, гадел, демократик һәм гуманлы җәмгыять төзи алырбыз микән?!

Безнең фикеребезчә, элиталы мәктәпләр күп төрле юнәлештә – физика-математикадан, техника, табигать фәннәре, гуманитар фәннәр, сәнгать, физкультура-спорттан һ.б. белем һәм күнекмә бирү юнәлешендә эшләргә, шундый мәктәпләрне тәмамлаган иң сәләтле балалар элиталы югары уку йортына алынырга тиеш. Элиталы уку йортының дәрәҗәсен һәм популярлыгын аның статусы билгеләми, ул күп нәрсәләргә бәйле. Бу уңайдан үзебезнең җирле шартларга тукталып үтик әле.

Республикабыз оештыру, матди-техник һәм фәнни потенциалдан белеп файдалану нәтиҗәсендә, зур югалтуларга дучар булмыйча, җәмгыятьне демократия һәм базар мөнәсәбәтләре принципларында үзгәртеп коруның катлаулы чорын узды. Ләкин бүген яңа инициативалар, яңа башлангычлар, озак вакытка исәпләнгән һәм алга таба үсешкә юнәлтелгән яңа стратегия кирәк. Шушындый мөһим дәүләт мәсьәләсен хәл итүнең төп шартларыннан берсе – Татарстанда югары һөнәри белем бирү системасын камилләштерү. Төп максат – республикада социаль-икътисади үсеш стратегиясен эшләргә һәм гамәлгә ашырырга сәләтле элиталы белгечләр әзерләп чыгару. Белгечләр Татарстанның җирле шартларын, фәнни һәм җитештерү потенциалын төгәл белүләре, хәзерге мәгълүмати технологияләрне камил үзләштерүләре белән хәзерге вакытта барлык югары уку йортларындагы бер типтагы уку-укыту программалары нигезендә әзерләнүче белгечләрдән аерылып торырга тиеш. Димәк, җирле шартларны искә алып, яңача эшләргә сәләтле элиталы милли югары уку йорты кирәклеге көн тәртибенә килеп баса.

Цивилизацияле илләр тәҗрибәсе ана телендә югары һөнәри белем алу һәм югары уку йортын тәмамлагач, белемне ана

телендә камилләштерүнең мәгариф системасының югары этабы булуын күптән исбат итте инде.

Элиталы уку йорты башкалардан нәрсәләр белән аерыла?

Беренче чиратта, студентлары белән. Алар махсус сайланып алынырга тиеш. Югары уку йорты мәктәпләр белән хезмәттәшлек булдыра, әзерлек төркемнәре, олимпиадалар, конкурслар оештыра. Анда җиңүчеләр югары уку йортына беренче чиратта алына. Мәктәпләрдә тәрбияләнгән максатчанлык, тырышлык, түземлелек – югары уку йортында уку өчен иң кирәкле сыйфатлар.

Илнең киләчәге элиталы кадрлар кулында. Бөекбританиядә, мәсәлән, илнең югары җитәкчеләренең 80% тан артыгы элиталы Кембридж һәм Оксфорд университетларын тәмамлаган.

Мондый уку йортларында эшләүче укытучылар үз эшенә чын күңелдән бирелгән сәләтле педагог һәм күренекле галим булырга тиеш. Мөгаллимнәр белгеч әзерләүгә бөтен көчен бирәләр, студентларның мөстәкыйль эшләрен оештыралар, фәнни түгәрәкләр алып баралар.

Студентларның күпьяклы үсеше өчен барлык шартлар тудырыла: яхшы җиһазланган китапханә, компьютерлар, интернет, спорт җиһазлары, күпсанлы үзешчән сәнгать түгәрәкләре һ.б. гөрләп эшләп тора. Телләр өйрәнүгә җитди игътибар ителә.

Җәмәгать эшлеклеләре, дәүләт хезмәткәрләре, галимнәр, күренекле шәхесләр белән очрашулар үткәрелә, чыгыш ясау күнекмәләре бирелә, лидерлык сыйфатлары камилләштерелә.

(“Мәгариф” журналы, № 10 – 2004 нче ел)

Мәгариф реформалары һәм модернизациясе

Гомумдәүләт реформалары кебек, мәгариф реформалары да, чор таләпләрен истә тотып, билгеле бер максатка ирешүне бурыч итеп куя.

1917 елгы борылыштан соң, дәүләт мәгариф өлкәсендә торган бурычларның иң мөһиме итеп, мәгариф учреждениеләрен тәртипкә салу һәм халыкның грамоталылыгын билгеле бер дәрәҗәгә җиткерү бурычын куйды. Бу максат уңышлы гына тормышка ашырылды. Гомуми урта белем бирә торган бердәм структуралы урта мәктәпләр булдырылды. I–IV класслары булган мәктәпләр – башлангыч мәктәп дип, V–VII класслары булганнары – тулы булмаган урта, ә VIII–X класслары да булганнары урта мәктәп дип аталды. Бу елларда укытуның эчтәле-

генә кертелгән үзгәрешләрне игътибарга лаеклы үзгәрешләрнең берсе, дип атарга кирәк. Укыту процессы ул чорда тормыш мисаллары белән баетылды, дәресләрдә производство мисаллары киң кулланылды, укучыларга "Физика һәм производство", "Химия һәм производство" кебек дәреслекләр тәкъдим ителде.

Укыту формаларын һәм методларын кулланганда, Европа һәм АКШ мәктәпләре тәҗрибәсе үрнәк итеп алынды. Бу чорда ул илләрдә укытуның эзләнүле-тикшеренүле методы, иҗади эшне, мөстәкыйльлекне таләп итә торган алымнар, дәресләрне оештыруның бригадалы-лаборатор, Дальтон-план, проектлар белән эшләү формалары киң кулланылышта булды. Болар безнең мәктәпләрдә уңышлы кулланылды, дип әйтеп булмый. Сәбәпләре күптөрле. Иң мөһиме: эзләнүне-тикшеренүне таләп итә торган укыту методларын киң куллануга безнең укытучылар да, укучылар да әзер түгел иде әле. Педагогика, психология фәннәренең торышы бу яңалыкка рекомендацияләрен бирә алмады, аерым фәннәрне укыту методикалары да бу яңалыклардан артта калган иде. Боларга өстәп, мәктәпләрнең укыту-матди базасының да түбән дәрәҗәдә булуын әйтергә кирәк.

30 нчы еллар башыннан мәгариф системасы алдына яңа бурычлар куелды, мәгарифтә яңа реформа башланды. Барлык укучы балага да гомуми мәҗбүри башлангыч белем бирү законлаштырылды, педагогика тарихында үзен аклаган укыту методларының тулы арсеналы укыту практикасына кайтарылды, белем стандарты камилләштерелде, фәнни-теоретик дәрәҗәсе югарырак булган яңа дәреслекләр булдырылды.

Бу елларда ирешелгән уңышлар совет мәктәбен дөньядагы иң алдынгылар дәрәҗәсенә күтәрде. Физика, математика, химия, биология фәннәренең үсеше, югары квалификацияле инженерлар әзерләү, аерым фәннәр буенча укучылар арасында уздырылган дөнья олимпиадаларында җиңүләр – шуның ачык мисалы.

1937 нче елда – шәһәрләрдә, ә 1952 нче елдан авыл мәктәпләрендә дә гомуми мәҗбүри 7 еллык укыту кертелде.

1958 нче елда мәктәп турында яңа закон чыкты. Бу вакыйганы яңа реформаның башлануы, дип атарга була. Реформа куйган яңа бурычлар: барлык яшьләргә гомуми мәҗбүри сигезьеллык белем бирү, укытуны тормышка, производствога бәйләп алып бару, укучыларны хезмәткә әзерләүне яхшырту, житештерүчән хезмәткә әзерләү һ.б. Бу реформаның уңай һәм тискәре яклары күп булды. Укучыларны хезмәткә әзерләү, бигрәк тә

авыл мәктәпләрен тәмамлап чыгучыларның тракторчы, комбайнчы, терлекче, төзүче, балта остасы, электромонтер һ.б. һөнәрләр алуы начар күренеш түгел. Әмма яңа законның тискәре ягын да күрсәтми булмый. Милли мәктәпләрнең әкренләп кими баруы менә шушы реформадан башлана да инде. Ата-аналар балаларын үзе теләгән мәктәпкә бирә ала, диелгән иде анда. Бу законны язучылар балалар укуларын ана телендә башларга тиешлеген беләләр иде, әлбәттә. Ләкин максат икенче иде шул: киләчәктә укулар бер генә телдә – рус телендә генә барырга тиеш иде.

Мәгариф системасында 1964 нче елдан башлап, 10 ел буе, яңа реформа уздырылды. Бу елларда яңа белем стандарты булдырылды, барлык фәннәр буенча яңа программалар, яңа дәреслекләр эшләнде, укыту технологияләрендә шактый гына үзгәрешләр булды. Бу үзгәрешләр белемнәрнең эчтәлеген дөнья стандартына тәңгәлләштерүдә хәлиткеч адым иде.

КПСС ҮКның һәм СССР Министрлар Советының мәгариф системасының алга таба эшчәнлеге турындагы 1984 нче елгы 5 нче карары мәгариф эшенә әллә ни үзгәреш кертә алмады. Фәнни-теоретик яктан тиешенчә нигезләнмәгән һәм матди-техник, финанс ягыннан төгәл чыгымнары исәпкә алынмаган бу карарлар кәгазьдә генә калды, дисәк тә дөрес булыр.

90нчы еллар башында илдә барган демократик үзгәрешләрнең мәгариф системасына да йогынтысы зур булды.

Халык мәгарифендә бу реформаның элеккеләреннән аермасы шактый.

Беренче аермасы шул: элекке реформалар партия һәм хөкүмәт карары нигезендә, өстән төшерелә, һәм түбәнгә таба карарны тормышка ашыру буенча эш башлана иде. Соңгы реформа түбәннән башланды: укытучылар, мәктәп коллективлары уку планына аерым үзгәрешләр тәкъдим иттеләр, укыту методларына яңалыклар керттеләр, укыту-тәрбия процессын камилләштерү максатында педагогик тәҗрибәләр үткәрә башладылар, яңа уку фәннәре тәкъдим иттеләр. Гомуми белем мәктәпләренең яңа типлары: аерым фәннәрне (яки берничә фәнне) тирәнтен өйрәнү мәктәпләре, экология, икътисад, сәнгать, физкультура-спорт, табигать фәннәре, гуманитар фәннәр юнәлешендәге мәктәп, гимназия, лицей, укыту-тәрбия комплекслары һ.б. барлыкка килде.

Бу чордагы демократик үзгәрешләр уңаеннан халыкның милли үзаңы уянуы һәм үсүе – реформаның икенче аермасы. Ә ул, үз чиратында, милли мәгарифне үлеп яткан җиреннән

торгызырга ярдәм итте, татар мәктәпләре, гимназия, лицей, татар балалар бакчалары булдырылды, рус телендә эшли торган мәктәпләрдә татар класслары ачылды; республика мәктәпләрендә укучы барлык милләт балаларына да татар теле укытыла башлады, белем стандартының милли-региональ компоненты булдырылды, мәктәп рописаниесендә Татарстан һәм татар халкы тарихы, Татарстан географиясе, экологиясе, икътисады һ.б. фәннәр лаеклы урын алды.

Дөньяда бара торган үзгәрешләр безнең тормышны да читләтеп үтми: әхлакый нормалар җимерелә, тәрбия принциплары таркала, гомер буе яшәп килгән кешелеклелек кыйммәтләре алышына, байлар һәм ярлылар арасында аерма артканнан-арта бара.

Кешеләрнең тамагын гына туйдырырга кирәк. Бу тискәре күренешләр үзеннән-үзе җайланыр, дип уйлый кайберәүләр. Кызганыч, алай гына түгел шул.

Адәм баласында дөньяга дөрес караш формалаштыру – гаять катлаулы процесс. Кешелеклелекнең гүзәл сыйфатларын саклап калу өчен, яшь буында түземле рәвештә инанганлык, матурлыкны таный белү, табигатьне ярату һәм саклый, мәдәниятне, тарихны аңлый белү, халыкны, аның телен, традицияләрен, хезмәтне ярату, халыклар арасында дуслык булдыру, аларның тормыш шартларын яхшырту, яшәешне камилләштерү кебек сыйфатларны булдыруда мәгариф системасының әһәмияте гадәттән тыш зур, җәмгыятьнең кайсы юнәлештә үсүе укыту һәм тәрбиянең нәтиҗәлелегенә бәйле. Шулай итеп, мәгариф системасы илнең икътисадын, әхлакый, рухи көчен үстерүгә җирлек тудыра.

Мәгариф өлкәсе киләчәктә мондый катлаулы бурычларны үтәргә әзерме соң? Алга таба ул ничек үсәр? Стратегиясе ничек үзгәрер? Нинди юнәлешләрдә үсәр? Мәгариф системасы функцияләрендә үзгәрешләр булырмы? Мәгариф реформалары концепциясендә бу сорауларга җавап бирелергә тиеш.

Алга киткән илләрдә хөкүмәт сәясәтенең нигезендә халыкка, беренче чиратта, белем һәм тәрбия бирү ята. Мәсьәләгә икенче төрле карауучылар да бар. Алар фикеренчә, илдәге халыкның тормыш дәрәҗәсе икътисади күрсәткечләргә (предприятиеләрнең уңышлы эшләвенә, газ, нефть, ташкүмер һ.б. табигый байлыкларны күбрәк җитештерүгә) бәйле. Бу очракта мәгариф һәм мәдәният хөкүмәтнең башкарылачак мөһим эшләре арасында соңгы буынны тәшкил итә.

Мондый сәясәтнең дөрес түгеллеген Япония мисалы бик ачык күрсәтте. Бу илдә табигый байлыклардан газ да, нефть тә, урман да юк дәрәҗәсендә, ә мәгариф системасының дөрес куелуы, илнең иң югары җитәкчеләренең аңа әһәмият бирүе югары квалификацияле, белемле, югары әхлакый сыйфатларга ия булган кадрлар, үз илләренең патриотларын тәрбияләргә ярдәм итә.

2000 нче елның гыйнварында мәгариф хезмәткәрләренең Бөтенроссия киңәшмәсендә ясаган чыгышында В.В.Путин хөкүмәт сәясәтенең мөһим юнәлешләрен билгеләде. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: ничек кенә булса да, хәерчелекне бетерү, базар икътисадына күчү, гражданнарны шәхес буларак яклау, нәтиҗәле тышкы сәясәт, барлык тармакларда да ныклы контроль булдыру. Дәүләт көчле булса, барлык проблемалар да җиңелрәк хәл ителәчәк.

Көчле дәүләтнең социаль-икътисади проблемаларны уңышлы чишү мөмкинлеге бар, әлбәттә. Ләкин бер шарт үтәлгән очракта гына: хөкүмәт политикасында халык мәгарифе өстенлекле тармак булырга тиеш. Киресенчә булганда, ягъни халык хуҗалыгындагы барлык тармакларга кирәкле акчаны бүлеп бетергәннән соң, калганын гына мәгарифкә бирү планлаштырылса, бу юнәлешнең уңышлы баруы шикле.

2001 нче елның 25нче октябрендә Россия Федерациясе хөкүмәте утырышында мәгариф реформасының яңа варианты тикшерелде һәм кабул ителде. Бу документ хәзер икенче төрле атала инде: Россия мәгарифен модернизацияләү. 90нчы елларда мәгариф системасында булырга тиеш һәм бара торган үзгәрешләр реформа, дип аталса, 2000 нче ел башына бу үзгәрешләр "Мәгарифне үстерү доктринасы" дип аталды. Ниһаять, 2001 нче ел ахырына бу документка яңа исем өстәлде: "Россия мәгарифен 2010 нчы елга кадәр модернизацияләү концепциясе".

Элеккеләреннән кай ягы белән аерыла соң бу концепция? Сорауга җавап бирү өчен, әлеге концепцияләрнең төп положениеләренә игътибар итик.

"Мәгариф системасын реформалау концепциясе" (ул "Учительская газета"ның 1997 нче елгы 51нче нче санында басылды) һәм "Россия мәгарифен үстерүнең милли доктринасы" (2000 нче елның 15нче гыйнварында кабул ителде) бер үк максатны күздә тоталар; шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең тотрыклы үсешен тәэмин итәрлек югары сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү белән шөгыльләнүче мәгариф системасы булдыру.

Реформа түбәндәге принципларга нигезләнә:

а) Халык мәгарифе – өстенлекле тармак. Россиянең беренче Президенты Б.Ельцинның 1 нче Указында да бу шулай язылган иде. Ләкин аңа карап үзгәрешләр булмады. Мәктәп һәм балалар бакчаларында да, мәгариф системасы өчен кадрлар әзерләү учреждениеләрендә дә, мәгарифнең укыту-матди базасын ныгытуда да, мәгариф хезмәткәрләренең көнкүрешен яхшыртуда да уңай үзгәрешләр сизелмәде диярлек;

а) укыту һәм тәрбиянең шәхесне үстерүгә юнәлтелгән булуы;

б) планлаштырылган үзгәрешләрнең гамәли юнәлештә булуы;

в) үсешнең тотрыклы булырга тиешлеге; федераль, региональ һәм җирле идарә органнарының бергә эшләвен координацияләү;

г) яңалыкларны тәҗрибәдә тикшерелгәннән соң гына тормышка ашыруы;

д) элекке яхшы традицияләрне саклау;

е) реформа чараларының матбугатта вакытында яктыртылып баруы.

Концепциядә мәгариф системасының икътисади механизмын реформалауга нык игътибар ителә. Икътисади механизмны реформалау финанс чыгымнарының 3 төрле юнәлешенә нигезләнә:

а) бюджет финанславы; б) предприятиеләр чыгымнары; в) түләргә сәләтле гаиләләр чыгымнары.

Элекке елларда бюджет чыгымнары турында гына сүз барса, хәзер белем һәм тәрбия чараларын финанслауга аерым гражданнарның яки гаиләләрнең чыгымнары законлаштырыла. Шуңа бәйле рәвештә профессиональ уку йортларына кадрлар әзерләү буенча заказ бирү тәртибе дә үзгәртелә. Моңа кадәр кадрлар әзерләү буенча профессиональ уку йортларына дәүләт заказы гына бирелә иде. Яңа реформа концепциясе нигезендә уку йортлары контрактлар (заказлар) буенча эшләүгә күчә, һәм финанслау да 5 төрле юнәлештә була: 1) федераль дәүләт заказы; 2) республика дәүләт заказы; 3) җирле муниципаль заказ; 4) предприятие, учреждениеләр заказы; 5) аерым гражданнар заказы.

Финанслауның икътисадын механизмын реформалауда төп яңалык – статьялап финанслаудан норматив финанслауга күчү. Цивилизацияле илләрдә мәгариф системасы күптәннән шушы алым белән финанслана. Ягъни, мәгариф учреждениесенә укыту-тәрбия процессын нормаль алып бару өчен күпме чыгым

кирәк булса, аңа бу чыгымнар тиешенчә бирелә. Ә бездә ул алай булмады. Хәрби чыгымнарга, космик очышларга, промышленность һ.б. тармакларга финанс чыгымнарын бүлеп биргәч, бюджетның калган өлеше генә социаль сферага бирелә иде, һәм мәгариф системасы “калдык” принцибы белән финансланып килгенде. Норматив финанслауга күчүне уңай күренеш булыр, дип уйларга кирәк.

Белем эчтәлеген реформалауда төп яңалык булып, 12 еллык гомуми урта белемгә күчү тора. Яңа белем стандарты моңа яраклаштырып эшләнергә тиеш. Бу юнәлештә 90нчы еллардан ук гамәлгә кереп килгән белемнең милли-региональ компонентын булдыруга игътибар кочәергә тиеш. Ягъни милли республикаларда белем стандарты ике өлештән, федераль компоненттан һәм милли-региональ компоненттан торачак. Укыту-тәрбия процессын компьютерлаштыру һәм дистанцион укытуны гамәлгә кертү кебек юнәлешләр дә концепциядә урын алган.

Концепциянең кадрлар әзерләү бүлегендә укучыларның атналык укыту нагрузкасының яңа нормативын булдыру, педагогик кадрларны аттестацияләүнең яңа положениесен эшләү, белем күтәрү системасын үзгәртү, эштән аерылмыйча дистанцион укытуга күчү, укытучыларга методик ярдәм оештыруның яңа үтемле чараларын табу һ.б. каралган.

Болардан тыш, концепциядә мәгариф учреждениеләренең структурасы, мәгариф системасы белән идарә итүдәге булачак үзгәрешләр, мәгариф работниклары өчен социаль гарантияләр һ.б. күрсәтелгән.

2000нче елның 15нче гыйнварында кабул ителгән Россия Федерациясе мәгарифенең милли доктринасы бу реформа концепциясенең төп положениеләрен тулысынча раслады.

Реформада күрсәтелгән чараларны шушы документлар нигезендә тормышка ашырырга мөмкин иде. Ләкин мәгариф системасын камилләштерү буенча тагын бер концепция барлыкка килде. Ул “2010 нче елга кадәр Россия мәгарифен модернизацияләү концепциясе” дип атала. Бу концепция 2001 нче елның 25нче октябрендә Россия Федерациясе хөкүмәте утырышында тикшерелеп расланды.

Концепциянең авторлары фикеренчә, реформа ул билгеле бер планлаштырылган чараларны озакка сузмыйча, тиз генә хәл итүне таләп итә. Җәмгыятьтәге бүгенге көндә бара торган вазгыять реформа уздыруга әзер түгел. Шуңа күрә мәгариф системасын модернизацияләргә генә кирәк, диделәр хөкүмәт утырышында. Модернизация төшенчәсе салмак бара торган

иҗтимагый процессны аңлата. Бу процесста максатчан идарә итү юлы белән әкренләп уңай нәтиҗәләргә ирешү күз алдында тотыла. Илдә бара торган социаль-икътисади һәм сәяси үзгәрешләргә яшәп килә торган мәгариф системасын яраклаштыру максатыннан эшләнә инде бу салмак үзгәрешләр.

Безнең уйлавыбызча, модернизация концепциясе кайбер үзгәрешләрнең планын билгеләп чыгу гына түгел, ә укыту-тәрбия процессының яңа идеологиясе булырга, нинди яңа бурычлар куелырга тиешлеген ачыкларга, кешелеклелек кыйммәтләренең ниндиләрен нинди чаралар ярдәмендә булдырырга тиешлеген дә күрсәтү зарур.

Яңа концепцияниләр тәкъдим итә соң? Модернизация яңалыкларны тәҗрибәләрдә сынаганнан соң гына гамәли кулланырга тәкъдим итә. Тәҗрибәнең иң масштаблысы – 12 еллык урта белем бирүгә күчү. Ул 6 ел дәвам итәргә тиеш. Аннары "Урта белем алуның вакытын 12 ел итәргәме, әллә 11 ел белән чикләнергәме?" дигән сорауга ачык җавап биреләчәк. Тәҗрибәнең нәтиҗәсен фаразлавы авыр, чөнки әлеге укучыларның кайберләре урта белемне – 11 елда, кайберләре 10 елда (III классны тәмамлагач, V класска күчә) ала. Аннары 12 елга исәпләнгән белем стандарты да әлегә эшләнмәгән, аның кайчан буласы да билгеле түгел.

Тәҗрибәләрнең икенчесе югары уку йортларына керүчеләр өчен бердәм дәүләт имтиханы булдыру белән бәйле. Россиянең кайбер төбәкләрендә бу тәҗрибәне үткән ел уздырдылар инде. Безнең күрше Чувашия һәм Мари Элда да бу тәҗрибә уздырылды. Ул тагын 2 ел дәвам итәргә тиеш. Югары уку йортларына кабул итүдә чит илләрнең күбесе шушы юлны куллана. Безнең илдә моңа карата әлегә бердәм фикер юк.

Модернизация концепциясендә тагын бер тәҗрибә планлаштырылган. Ул хөкүмәтнең, югары белем алу өчен, гражданнарга исемле финанс бирү йөкләмәсе. Моның безнең илдә булганы юк иде әле. Бу тәҗрибә югары уку йортларына кергәндә абитуриентларга билгеле бер күләмдә дәүләттән акча бирүне күздә тота. Укып бетереп эшли башлагач, ул аны күпмедер вакыт эчендә кайтарып бирергә тиеш. Белгеч, укып бетереп, эшкә кирәкле урынга билгеләнсә һәм шунда эшләсә, ул бу акчаны кире кайтармаска да мөмкин.

Мәгариф системасын модернизацияләүнең төп юнәлешләре:

1. Муниципаль мәгариф учреждениеләренә дәүләт учреждениесе статусы бирү һәм ул уку йортларын җирле финанслауга күчерү.

2. Белем эчтәлеген яңарту. Укучылар белеменең сыйфатын тикшерү процессын камилләштерү. Өлкән классларда профильле укытуны кертү. Мәгарифнең идарә итү органнарына бәйсез булган мәгариф учреждениеләрен аттестацияли һәм аларның эшенә контроль ясый торган оешма булдыру.

3. Уку йортларының структурасын һәм аларны финанслауны яхшырту. Этаплап, норматив финанслауга күчү.

4. Мәгариф системасының социаль юнәлешен көчәйтү. Тәртипсез, җинаять юлына баскан яшьләргә карата кискен чаралар күрү. Күп балалы һәм мохтаҗ гаиләләргә адреслы ярдәм күрсәтү. Мәктәпкәчә тәрбиягә игътибарны көчәйтү. Сыйфатлы белем алу өчен барлык укучыларга да мөмкинлек тудыру.

5. Авыл һәм поселок мәктәпләренә ярдәм итү юлларын билгеләү.

6. Профессиональ белем бирү уку йортларын базар икътисады таләпләренә яраклаштыру. Күп баскычлы һәм күп профильле башлангыч һәм урта профессиональ уку йортлары булдыру. Югары профессиональ белемнең беренче баскычы функциясен үтәүче колледжлар санын арттыру. Профессиональ белемнәрне камилләштерү һәм белем күтәрү курслары оештыручы уку йортларының нәтиҗәле эшләвенә ирешү.

7. Уку йортларының икътисади мөстәкыйльлегенә ирешү.

8. Мәгариф хезмәткәрләренең социаль статусын күтәрү. Яшәү минимумыннан ким булмаган минималь хезмәт хакы булдыру. Нәтиҗәле һәм озак еллар эшләгән өчен, мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакына өстәмә түләү кертү. Хезмәт хакы түләүдә бердәм тариф челтәрен бетерү, мәгариф хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүнең яңа тәртибен булдыру, пенсия түләүнең яңа системасын эшләү. Мәгариф системасында эшләүче белгечләрне хәрби хезмәткә алуны кичектерү.

9. Мәгариф хезмәткәрләренә фәнни-методик ярдәм күрсәтүне яңача оештыру. Алдынгы педагогик тәҗрибәне хуплау. Педагогика фәненең практикадан аерылуына һәм артка калуына юл куймау.

10. Модернизация таләпләрен искә алып, мәгариф системасының хокукый-норматив документларын билгеле бер тәртипкә китерү.

Башка илләрнең мәгариф системаларында да реформалар булып тора. Аларда нинди үзгәрешләр көтелә соң? Мисалга АКШ мәгарифен алыйк. Буш хөкүмәтенең мәгариф реформасына карашы болай: реформа чорында уку йортларына тулы мөстәкыйльлек бирергә кирәк. Мөстәкыйльлек аларга җавап-

лылыкны да үстәячәк. Реформа чараларының үтәлеше өчен алар тулысынча җавап бирәчәк. Мәгариф учреждениеләрен тулысынча финанслауны мәктәп округлары һәм штатлар үз кулларына алырга тиеш. АКШта мәктәп реформасы нигезендә 4 бурыч үтәлә:

1. Укыту-тәрбия процессының уңышы өчен мәктәп округлары һәм штатларның җаваплылыгын арттыру.

2. Үзгәртеп корулар вакытында нәтиҗәлелеге исбатланган чараларны гына куллану.

3. Реформа чараларын, аның нәтиҗәләрен халыкка җиткереп тору, бюрократияне бетерү.

4. Ата-аналарга балаларын начар эшләгән мәктәптән яхшы эшләүче мәктәпкә күчерергә мөмкинлек бирү.

Болардан тыш, уңай нәтиҗә бирмәгән штатларда административ персоналны тотуга каралган финанс чыгымнарын киметү мөмкинлеге каралган. Яхшы нәтиҗәләргә ирешкән мәктәпләр һәрьяклы ярдәм алачак. Тикшерү нәтиҗәләре буенча еллар буе начар күрсәткечләргә ирешкән мәктәпләр ябылырга да мөмкин.

Мәгариф эшен камилләштерү өчен эшләнгән документлар – концепцияләр, доктриналар, модернизация программалары белем бирүнең эчтәлегенә дә, технологиясенә дә, финанс мәсьәләләренә дә кагылырга тиеш. Ләкин болар гына җитми әле. Ни өчен уздырабыз соң без бу реформаны? Реформа ярдәмендә укучыда нинди кешелеклелек сыйфатларын булдырырга омтылабыз? Яшәештә, җәмгыятьтә кешеләр эшчәнлегенең рухи һәм әхлакый сыйфатларының нинди якларына нинди юллар белән тәэсир итәргә тырышабыз?

Мәгариф реформасының яңа концепциясе (1997), Россия Федерациясе мәгарифенең милли доктринасы (2000) һәм Россия мәгарифен модернизацияләү концепциясе (2001) бу сорауларга җавап бирәме?

Мәгариф, фән, мәдәният һәрвакыт җәмгыятьне алга әйдәүче һәм юнәлтүче көч булган. Югары әхлак сыйфатларына игътибарсыз булып, җиңел генә хәзерге чорның әдәпсезлек, акчага табыну кебек күренешләренә һ.б. ияреп китсә, мәгариф системасы үзенең җәмгыятьне әйдәп баручы функциясен югалтачак.

Яңа концепция яки программаларда мәдәният һәм әхлак мәсьәләләре турында язылган урыннарны табып була. Ләкин һәр кешедә шундый сыйфатлар булырга тиешлеген раслап кую әле мәсьәлә хәл ителде, дигән сүз түгел. Нинди чаралар ярдә-

мендә бу сыйфатларны тәрбияләргә, тәрбиянең нәтиҗәлелеген нинди критерийлар белән билгеләргә? Менә шунысы мөһим. Билгеле, гуманлы шәхес тәрбияләү концепцияләрендә коллективизм, кешелеклелек тәрбияләү идеяләре өстенлек итәргә тиеш.

("Мәгариф" журналы, № 11 – 2002 нче ел).

Бердәм дәүләт имтиханы: тәҗрибә һәм уйланулар

Россия мәгариф системасын модернизацияләү концепциясендә әйтелгәнчә, укучыларга югары сыйфатлы белем бирү – иң мөһим бурычларның берсе. Белемнең сыйфатын күтәрү – дәүләт күләмендәге әһәмиятле эш. Ләкин җәмгыять зур үзгәрешләр кичерә. Базар икътисадына кереп барабыз. Хәзерге кырыс таләпләр шартларында яшь буынга нинди белем бирелергә, гомуми урта белем уку йортларын тәмамлаучылар хәзер нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

Белемнең сыйфаты дигән сүз укыту нәтиҗәләре куелган максатларга туры килергә тиешлекне белдерә. Ләкин бу бик үк дөрес туры килмәскә мөмкин. Беренчедән, максат һәрвакытта да дөрес куелмый. Һәр фән буенча укыту программаларында укучыларга бирелергә тиешле белемнәр мәктәп тәмамлаучыларга алдагы тормышларында кирәк буламы? Икенчедән, укытучы һәм укучылар тарафыннан бик күп көч куеп үзләштерелгән белемнәр тормыштагы гамәли мәсьәләләрне чишкәндә ярдәм итәме? Укучы мәктәптән тормышта очраган күптөрле проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә әзер булып чыгамы?

Мәктәптә алынган белемнәрнең сыйфатын тикшергәндә бу сораулар игътибар үзәгендә булырга тиеш. Ни кызганыч, әлегә мәктәп тәмамлаучыларның югары һөнәри уку йортына керергә әзер булу-булмавы гына тикшерелә. Базар икътисады шартларында яшәүче демократик җәмгыятьтә күп кенә мәсьәләне кеше үзе хәл итәргә тиеш. Элек болар турында кеше үзе түгел, хөкүмәт кайгырта иде. Хәзер инде бу тормышта ул әлеге проблемалар белән турыдан-туры очраша.

Менә шуңа күрә дә соңгы елларда мәгарифнең социаль функцияләрендә шактый гына үзгәрешләр булды. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– мәгариф учреждениесе илдә булган бердәнбер идеологик юнәлешне тормышка ашыру функциясеннән җәмгыятьтәге

дөньяга караш һәм төрле политик позицияләрнең бердәмлеген тәэмин итү функциясенә күчә;

– мәгариф учреждениесе, билгеле кагыйдәләр һәм мәҗбүри үзләштерелергә тиешле тәртип нормаларын өйрәтүдән тыш, укучыларда хезмәтнең төрле юнәлешләрендә мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итәрлек шәхес сыйфатлары тәрбияләргә тиеш;

– укучыны коллектив әгъзасы итеп кенә түгел, ә, бәлки, аны үзенә генә хас үзенчәлекләре булган шәхес итеп күзаллау.

Модернизация программасы белем стандартларын яңартуны, профильле укытуга күчүне, мәгариф учреждениеләренең яңа структурасын булдыруны, уку йортларына уку планнарын сайлауда мөстәкыйльлек бирүне, мәктәп тәмамлаучыларның белемнәрен бәяләүдә бәйсез дәүләт структурасы булдыруны, мәгариф учреждениеләрен яңача норматив финанслауга күчүне һ.б. юнәлешләрне үз эченә ала.

Яңа белем стандарты хәзерге шартларда укучыларга бирелергә тиешле белемнәрнең эчтәлеген һәм күләмен, шулай ук мәктәп тәмамлаганда укучыларга нинди таләпләр куелуын ачыкларга тиеш. Хәзерге стандартларның элеккеләреннән өстенлеге шунда: яңа белем стандартларында җәмгыятьнең демократияләшүе һәм тоталитар системаның бетүе киң чагылыш таба. Ул белем стандартларындагы үзгәрешләрдә дә ачык чагыла. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Урта мәктәпнең югары классларында белем эчтәлегенә “гомуми белем” һәм “профиль” компонентлары кертелүе.

2. Белем стандартларында федераль компонентны өйрәнүгә бирелгән вакытның бераз кыскартылуы, шуның исәбенә милли-төбәк һәм мәктәп компонентларын өйрәнүгә вакытның күбрәк бирелүе.

3. Федераль компонентның инвариатив һәм вариатив элементларга бүленүе.

4. Укучыга федераль компонентта тәкъдим ителгән мәгълүматларның ике өлештән – өйрәнү өчен һәм танышу өчен бирелгән мәгълүматлардан торуы.

5. Мәҗбүри өйрәнү өчен тәкъдим ителгән мәгълүматлар минимумында гомуми белем максатлары өчен әһәмияте булмаган элементларның төшереп калдырылуы.

Бердәм дәүләт имтиханы – яңа шартларда укучыларның белемнәрен тикшерүнең яңа формасы. Укучыларны югары уку йортына әзерләү – соңгы елларда мәктәп алдына куелган таләпләрнең иң мөһиме. Шулай итеп, бердәм дәүләт имтиханы (БДИ) ике максатны – укучыларның белем дәрәҗәсенә бәя

бирүнс һәм мәктәп тәмамлаучыларны ике тапкыр имтихан бирүдән коткаруны күздә тота. Шулай итеп, югары уку йортына кабул итү имтиханын БДИ алыштыра.

БДИ һәм ДИФЙ (дәүләтнең исемле финанс йөкләмәсе – урта мәктәпне тәмамлаучыларга, югары уку йортында уку өчен, дәүләттән акчалата ярдәм биреп тору тәртибе) илдә бара торган мәгариф реформасының нигез ташлары булып санала. Болар модернизация юнәлешләрен хәл итәргә тиешле түбәндәге өч механизм ролен үтәргә тиеш:

– югары сыйфатлы белем алу мөмкинлеген арттыру;

– белем дәрәҗәсен күтәрү;

– бюджет средстволарын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру.

Бу чараларны уңышлы кулланганда зур шәһәрләрдән ерак авылларда яшәүче укучыларга, конституцион хокуклардан файдаланып, югары уку йортына керү мөмкинлеге; дәүләт уку йортларында нормага кереп бара торган түләүле укудан; төрле югары уку йортларының үзләре уйлап тапкан кырыс таләпләреннән котылу мөмкинлеге туар иде.

БДИ нәтиҗәсендә алынган урта белем турындагы аттестатның да дәрәҗәсе күтәреләчәк. Бу инде аерым бер мәктәп биргән аттестат кына түгел, ә гомуми дәүләти аттестат булачак.

Россия Федерациясендә БДИ тәҗрибә рәвешендә дүрт ел үткәрелә инде. Беренче елларда бу экспериментта берничә төбәк кенә катнашса, 2004/2005 нче уку елында 65 төбәк катнаша. 821184 укучы, ягъни урта мәктәпне тәмамлаучыларның 68,3% ы, махсус тестлар ярдәмендә дәүләт имтиханы тапшырды инде.

Чит илләрдә укучыларның белемен БДИ ярдәмендә бәяләү күптән кертелгән. Безнең өчен ул – яңалык. Ил белән ил арасында аерма бик зур. Ул мәгариф системаларындагы традицияләрдә бигрәк тә ачык чагыла. Бу аермаларны искә алмыйча, чит ил тәҗрибәсен турыдан-туры күчерү уңай нәтиҗәләр бирмәскә дә мөмкин. Мәгълүмат чараларында басылган мәкаләләрдә БДИгә төрлечә караш белдерелә.

Безнең республика бу тәҗрибәдә шушы уку елында катнашырга ниятли. Шуңа күрә БДИ турындагы кайбер фикерләрне искә алу зыянлы булмас.

Фикерләрнең уңайлары да, тискәреләре дә бар. Берәүләр БДИны хуплый, икенчеләре аңа уңай карашта түгел. Хәзер шушы фикерләр белән танышып узыйк:

1. БДИ өчен әзерләнгән тестларның сыйфаты начар.

2. Укучыларның белем дәрәҗәсе төрле төбәктә төрлечә (Ярославль, Саратов, Киров, Белгород, Карачаево-Черкесск, Ульяновск өлкәләрендә – түбән, Мари Эл, Чувашия, Якутия республикаларында, Чиләбе, Самара, Псков өлкәләрендә – югары).

3. Компьютер белән тестлар ярдәмендә имтихан алуга караганда, имтиханны "күзгә-күз" карап алу уңышлырак. Турыдан-туры имтихан алганда, укытучы укучының белем күләмен генә түгел, аның логик фикерләү дәрәҗәсен дә, мөстәкыйль уйлау сыйфатын да ачыклый. Тестлар абитуриент потенциалының 20-25% ын гына бәяли ала. Уйлый белүче, перспективалы студентны кабул итү мөмкинлеге югала.

4. БДИ баллары буенча кабул ителгән студент югары уку йортының үзенчәлекләрен белми. Мондыйлар, гадәттә, таныш булмаган уку йортын ташлап, икенчесенә күчә. Үзенә дә, уку йортына да зыян килә.

5. БДИ тестларының җавапларын бәяләүдә зур шәһәрләрдә һәм авылларда эшләүче педагогларның критерийлары бер-берсеннән нык аерыла. Моннан укучы зыян күрә.

6. Компьютер һәм интернет заманында БДИ тестларындагы биремнәрне төрле төбәкләргә тарату мөмкинлеге зур. БДИның объективлыгы югала. Имтиханны һәр җирдә дә бер үк вакытта уздыру зарур. Ләкин монда техник чаралар һәм кадрлар белән тәэмин итүдә кыенлыклар барлыкка килә. Бу каршылыкны ничек чишәргә?

7. БДИ нәтиҗәләре буенча укырга кабул иткәндә, җәмгыять өчен кирәкле, ләкин халык арасында популяр булмаган белгечләр әзерләүче институтларга бик аз кеше укырга керергә мөмкин.

8. БДИ баллары буенча берничә вузга кабул ителгән абитуриентлар югары уку йортына студентлар туплауда кыенлыклар тудыра. Планлаштырылган студентлар уку йортына килми. Буш урыннарга студент туплау проблемасы килеп чыга.

9. Абитуриентлар БДИ сертификатларын почта аша җибәрәчәк. Почта эшендәге җитешсезлекләр бу мөһим эшне вакытында башкарырга комачауламасмы?

10. БДИ схемасы буенча укучы 5 имтихан тапшырырга тиеш. Математика һәм рус теле белән әдәбияттан имтихан бирү мәҗбүри итеп куела, калган 3 имтиханны укучы үз ихтыяры белән сайлап тапшыра. Соңгы вакытта бер мәҗбүри имтихан (математикадан) калдырып, дүртесен сайлап тапшыру мөмкинлеге турында да сүз бара. Ләкин монда бер тискәре күренеш шәйләнә: укучы вузга БДИ нәтиҗәсе белән кабул ителгәндә, мәктәптәге уку фәннәре "кирәкле" һәм "кирәксез"гә әйлән-

мәсме? Профильле укытуга күчкәч, бу тенденция тагын да көчәймәсме? Болар мәктәпнең тәрбияви максатларын үтәүгә комачауламасмы?

11. БДИ нәтиҗәләре күп кенә төбәк авыл мәктәпләрендә программа материалының тулысынча үтәлмәве кебек тискәре күренешләрне дә күрсәтә. Укучыларның 20% ының математикадан имтиханны "2"легә тапшыруы, "5" леләрнең бик сирәк кенә булуы – шуның ачык мисалы...

Мәгариф хезмәткәрләренең һәм галимнәрнең БДИ турындагы фикеренә анализ ясап, түбәндәгеләрне әйтергә була: БДИ, һичшиксез, кирәкле чара. Бердәм белем пространствосы булдыруда, мәгарифнең регионнардагы торышы турында объектив мәгълүмат туплауда аның әһәмияте зур. БДИ ярдәмендә ата-аналарның акчасы янга кала, югары уку йортына кабул итү имтиханнарын яңадан бирмәү – абитуриентта стресс булдырмый, югары уку йортына кабул ителүчеләр арасында авыл мәктәпләре балалары саны арта.

Ләкин бу мәсьәләдә хәл ителмәгән проблемалар да шактый. Әлегә республика олимпиадаларында җиңүчеләр югары уку йортына имтихансыз кабул ителә иде. Алга таба да бу шулай дәвам итәрме? Республиканың ректорлар советы абитуриентлар кабул итүдә күп вариантлы форманы калдырырга тәкъдим итә. Бәлки, шулай кирәктер дә. "БДИ нәрсә тикшерергә тиеш соң?" – дигән сорау да урынлы кебек. Әлегә бу эштә катнашучыларның фикере уңай түгел: БДИ ярдәмендә укучыларның уйлау сәләте, акыл үсеше дәрәҗәсе түгел, ә, бәлки, алар ятлаган фактлар һәм саннар гына тикшерелә. Укытучылар, тәрбиячеләр, сәнгать белгечләрен әзерләүче уку йортлары булачак белгечләрнең бу эшкә сәләтлеме, юкмы икәнен тестка биргән җаваплар нигезендә генә ачыклый алырмы икән?

2005 нче елда БДИ Россиянең 75 төбәгендә (шул исәптән, Татарстан Республикасында да) уздырыла. Димәк, Яңа елдан чыгарылыш класс укучыларының 83% ы БДИда катнашачак. 2005 нче ел бюджетында бу эшкә шактый зур суммада акча каралган.

Югары уку йортына керү баллы конкурс нигезендә билгеләнәчәк. Быел бу тәҗрибәгә Татарстанның барлык дәүләти югары уку йортлары да кушыла.

Әмма әлегә бу белгечлекләрнең яртысына гына кагыла. Яртысына аттестат нигезендә кабул итү мөмкинлеге булачак. Мәктәптә бердәм имтихан тапшырмаучыларга да аптырарга кирәкми. Әгәр сайлаган белгечлеккә бары тик бердәм имтихан нәтиҗәләре нигезендә генә кабул итсәләр, алар аны вузда бирә ала.

Татар мәктәбен тәмамлаучылар имтиханны татар телендә тапшыра алачак.

Демографик процесслар белән бәйле рәвештә, профессиональ уку йортлары алдында тагын бер проблема тора. 2005 нче елдан башлап, якындагы 10 елда гомуми белем урта мәктәпләрен тәмамлаучылар 30% ка кимиячәк. 2001 нче елда Россия Федерациясендә урта мәктәпләрне 2,7 млн. укучы тәмамласа, 2007 нче елда аларның саны 1,5 млн. гына булачак. Югары уку йортларына керергә теләүчеләр арасында конкурс та кимиячәк. Уку йортларына кабул итү тәртибе дә җитди үзгәрешләр кичерә. Әле аның нинди буласы билгеле түгел. Мин шушындый юлны тәкъдим итәр идем: югары уку йортына укырга теләүче барлык яшьләрне дә кабул итәргә, әмма беренче семестр нәтиҗәләре буенча өлгермәгән (яки укырга теләмәгән) студентларны уку йортыннан чыгарырга.

50 нче елларда урта һөнәри уку йортларына кабул итүдә мондый тәртип бар иде. Минзәлә педагогия училищесына, мәсәлән, башта һәр төркемгә 45-50 шәр укучы алалар иде. Уку башлангач, өч фәннән (татар теле, рус теле, математикадан) контроль эш уздырыла. Шуларны үти алмаганнар кайтып китә, ә калганнарыннан менә дигән укытучы әзерләнә иде.

БДИ белән алга таба нәрсә булыр? Оештыру, идарә итү мәсьәләләре буенча гына нәтиҗәләр ясалырмы, әллә "авыруларны дәваларбызмы?"

Эзләнү, тәҗрибәләрне дәвам итү урынлы, аларның нәтиҗәләре мәктәпләргә дә, югары уку йортларына да файдалы, укучыларның белем дәрәҗәләрендә дә алга китеш булыр иде.

БДИга әзерлекне дә, аны уздыруны да камилләштерү зарур. Эшнең сыйфатын контрольдә тотучы профессионал орган булдыру да мәслихәт. Бу орган тикшерү сыйфаты белән дә һәм, иң мөһиме, укучыларның белем сыйфатына һәм әзерлегенә дә бәя бирер иде.

("Мәгариф" журналы, № 2 – 2005 нче ел)

Педагогикада технологияләр

Соңгы елларда педагогика фәне башка тармаклардан кергән күп кенә фәнни төшенчәләр белән баетылды. "Педагогик технологияләр" төшенчәсе дә шундыйларга керә.

Технология – грек сүзе, "сәнгать" дигән сүз. Техникада, промышленностьта, авыл хуҗалыгында технология дигәннән, ул ниндидер конкрет продукт җитештерүнең алдан уйланыл-

ган эзлекле башкару процессы кагыйдәләре тупланмасы буларак аңлашыла. Мәсәлән, корыч кою, бәрәңге, чөгендер үстерү, костюм, аяк киеме тегү технологияләре. Монда технологиягә кергән һәр этап, процесс, һәр хәрәкәт, һәр адым программалаштырыла, башкару элементы үз урынын ала. Программадагы бер элемент кына төшеп калса, яки үтәлмәсә, продукциянең планлаштырылган сыйфаты бозыла.

Педагогикада технологияләр төшенчәсенә әлегә күнегеп кенә киләбез. Галимнәр һәм мәгариф системасында эшләүче практиклар өчен монда әле хәл итәсе мәсьәләләр шактый. Ул мәсьәләләр теоретик эзләнүләргә дә, табылган нәтиҗәләрдән чыгып методик ярдәмлекләр язучыларга да, аларны тормышка ашыручы мәктәп җитәкчеләренә һәм укытучыларга да кагыла.

Укыту-тәрбия процессын технологияләштерү һәм аны тормышка ашыру турында безнең илдә һәм чит илләрдә язылган күп санлы әдәбият һәм гыйльми язмалардан чыгып, түбәндәге нәтиҗәне ясый алабыз: педагогикада технологияләр куллану идеясе фәнни-техник прогрессның үсүе һәм аның казанышларының теория һәм практиканың күп кенә өлкәләренә таралуы белән бәйле.

Педагогика фәнендә һәм уку йортлары практикасында педагогик технологияләр төшенчәсе формалашуның билгеле бер эзлеклелеген күрсәтергә мөмкин: уку-укыту процессында техник чаралардан файдалану, программалаштырылган укыту, уку-укыту процессында алгоритмик кагыйдәләр куллану, мәктәп тормышында укытучы һәм укучылар өчен хезмәтне фәнни оештыру таләпләрен кертү, укыту-тәрбия процессын интенсивлаштыру һәм оптимальләштерү, дидактик технологияләр, информацион технологияләр, модульле укыту, педагогик технологияләр...

Педагогик технологияләрне уку йортларында куллана башлау 60 нчы елларга туры килә. Тикшеренүчеләр күрсәткәнчә, бу Америка Кушма Штатлары мәктәпләрендәге, ә соңрак Европа илләре мәктәпләрендәге реформалар белән бәйле.

Чит ил галимнәреннән Дж.Кэрролл, Б.Блум, Г.Гейс, П.Митчелл, В.Коскарелли һ.б. педагогик технологияләр турында күп кенә хезмәтләр язып чыгардылар.

Педагогикада технологияләр теориясен һәм практикасын булдыруда безнең ил галимнәреннән П.Я.Гальперин, Н.Ф.Талызина, А.Г.Ривин, Л.Н.Ланда, Ю.К.Бабанский, П.М.Эрдниев, И.П.Раченко, Л.Я.Зорина, М.В.Кларин, М.И.Мәхмүтов, Т.И.Шамова һ.б. галимнәрнең хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин.

Хәзерге вакытта педагогик технологияләр фәндә шактый киң таралды. Кеше турындагы фәннәрнең аерым бер тармагы буларак, ул гомуми психология, социаль психология, дидактика, кибернетика, идарә итү, менеджмент һәм фәннәрнең башка тармакларына таяна.

Педагогик технологияләр үзләреннән-үзләре генә барлыкка килмәде. Аның барлыкка килүенең сәбәпләре күп төрле. Беренчедән, педагогика фәне үсешендә фәннең башка тармакларында ирешелгән нәтиҗәләр уңышлы файдаланыла. Боларга бәйле рәвештә укыту-тәрбия эшчәнлегендә дә системалы эшчәнлек принцибы киң кулланыш тапты. Ә бу, үз чиратында, технологияләр чылбыры эшләүгә этәреш бирде.

Икенчедән, традицион укыту системасы укучыларга белемнәрне укытучының сөйләве ярдәмендә бирүгә корылган. Укучы игътибар белән тыңларга, информацияне хәтерендә калдырырга тиеш. Ләкин психология фәненең соңгы тикшеренүләре шәхеснең (шулай ук мәктәп баласының да) яңа информацияләрне үзләштерүенең 65%ы күрү ярдәмендә башкарылуын ачыклады. Бу процесста укучының тыңлап утыруы гына түгел, ә төрле эшчәнлектә, хәрәкәтләрдә катнашуы бик мөһим. Шуңа күрә, педагогик технологияләр игътибарны укучыларның күрү ярдәмендәге эшчәнлек төрләренә юнәлтәләр дә инде.

Укытучы һәм укучылар эшчәнлеген оештыруның барлык нечкәлекләрен алдан уйлап, укытучылар башкарырга тиешле эшләрне системага салып кую укыту-тәрбия процессының уңышын гарантияли. Бу әзер технология белән тәҗрибәсе (яки квалификациясе) зур булмаган укытучы да уңышка ирешергә тиеш. Бу инде технологияләр барлыкка килүнең өченче сәбәбе.

Педагогикада технологияләр куллану идеясе А.С.Макаренкодан килә. 1933 нче елда ул болай дип язган иде: “Безнең педагогик производство бервакытта да технологик логика буенча корылмады, күбесенчә ул сүз белән аңлату яки әхлакый кануннар юлы белән барды. Шуңа күрәдер, бездә җитештерү сферасында була торган күп кенә тармаклар юк. Боларга технологик процесс, эшләнәсе операцияләрнең исәбен алу, конструкторлык эше, җайланмалар куллану, эш нормаларын билгеләү, эш процессын тикшереп күзәтеп тору, эш нәтиҗәсен бәяләү критерийларын эшләү һ.б. керә” (9).

Педагогик технологиянең асылын тирәнрәк аңлау өчен, аның фәндәге билгеләмәләренә игътибар итик.

Инглиз галиме П.Митчелл фикере буенча: “Педагогик технология ул мәгариф системасында теоретик һәм практик тик-

шеренүләрнең бер тармагы. Ул педагогик системаның барлык тармакларын да эченә ала һәм укыту-тәрбия эшендә нәтиҗәлелекне тәэмин итә" (6).

1986 нчы елда ЮНЕСКО педагогик технологиягә түбәндәге билгеләмәне бирде: "Педагогик технология ул – белем бирү һәм белемнәрне үзләштерүнең оптималь формасын табу өчен планлаштыру һәм бәяләүнең методологиясе нигезендә техника һәм кеше ресурслары эшчәнлеген бер-берсенә бәйләп алып бару процессы" (8). Педагогик энциклопедия билгеләмәсендә педагогик технология практикада аерым укучыларга һәм коллективка уңышлы эшләү шартлары тудыру өчен методлар сайлаганда белемнәр һәм күнекмәләр күләме күпме булырга тиеш дигәнне аңлата (7).

Академик М.И.Мәхмүтов фикеренчә: "Алга куелган бурычларны уңышлы үтәү өчен, укытучы һәм укучыларның алдан планлаштырылган үзара бәйле эшчәнлеген технология дип атыйлар" (5).

Бу билгеләмәләрдән чыгып, педагогик технологияне алдан планлаштырылган, һәр этабы конкретлаштырылган укыту-тәрбия процессын башкару кагыйдәләре, дип әйтә алабыз.

Педагогик технология дидактика да (укыту теориясе), методика да (аерым фәннәрне укыту теориясе) түгел. Практикада расланган дидактик теорияләр һәм методик концепцияләр педагогик технология эшләү өчен нигез булып хезмәт итәләр. Бу яктан караганда педагогик технология дидактик-методик системага охшаш.

Күп кенә авторлар педагогик технологиянең үзәнчәлекле сыйфатлары итеп түбәндәгеләрне күрсәтәләр: технологияләрнең эзлекле операцияләр системасын тәшкил итүе, күрсәтмәләр, кагыйдәләр җыелмасы булу, башкарыласы эшләрне алдан күрү һәм ул эшчәнлек белән идарә итү, бәяләү мөмкинлеге (1; 2; 3; 5; 8).

Бу сыйфатлар күпмедер дәрәҗәдә методик системаларга да хас. Ләкин методика фәне күбрәк өйрәнә торган фәннең методологиясенә, ул фәннең эчтәлегенә һәм өйрәнү методларына бәйле.

Педагогик технологиядә аерым фәннең эчтәлегенә зур игътибар бирелми. Ләкин анда укучылар һәм укытучыларның эш процессы, аның этаплары конкрет күрсәтелә. Шуңа күрә дә бер үк технология белән күп төрле фәннәрне укытучы мөгаллимнәр дә файдаланырга мөмкин.

Педагогик технология барлыкка килүне түбәндәге этапларга бүләргә мөмкин:

1. Технологиянең нигезендә билгеле бер методологик, философик идея ята. Шуңа күрә, технология төзү өчен, башта концептуаль фикер алына. Ул педагогик, психологик, философик теорияләргә нигезләнә. Мәсәлән, укучыларның акыл үсешен тәэмин итүче проблемалы дәрес технологиясе, укучыларны мөстәкыйльлеккә өйрәтү, күнекмәләр булдыру технологиясе, программалаштырылган укыту технологияләре шундыйларга керә.

Шунысын да әйтеп китү урынлы булыр:педагогик теорияләрнең, методикаларның барысын да технологиягә яраклаштырып булмый. Ягъни барлык теорияләрне дә эзлекле алгоритмик процедуралар, операцияләр рәвешендә кулланып булмый. Технология булдыру өчен, теориянең бер-берсенә логик бәйләнеп бара торган эзлекле этаплары да булырга тиеш. Мәсәлән, программалаштырылган укыту яки проблемалы дәрес технологиясен уңышлы тәкъдим итәргә була, ә дифференцияле яки индивидуаль якын килеп укыту теориясен бердәй педагогик технология итеп тәкъдим итүе авыр.

2. Көтелгән нәтиҗә фаразлана һәм шуның буенча укучыларның һәм укытучының эшчәнлеген исәпкә алган конкрет технологик чылбыр төзелә.

3. Алгоритмик процессларның этаплары билгеләнә.

4. Диагностик процедураларны исәпкә алып, эшнең нәтиҗәлелегенә бәя бирү критерийләре күрсәтелә.

Максатлары буенча педагогик технологияләр берничә төрле булырга мөмкин. Аларның бертөрлеләре теоретик материалны өйрәнү дәресе өчен төзелә, икенчеләре укучыларда практик күнекмәләр бирү, осталыкны арттыру һ.б. өчен, өченчеләре фикерләү сәләтен үстерү өчен эшләнә.

Педагогик технологияләр турында сүз чыккан баштагы чорда аны укыту процессында техника куллану дип аңладылар. Педагогик технологиянең практикада иң беренче кулланганнарыннан берсе программалаштырылган укыту булды. Шуның белән бәйле рәвештә дәресләрдә перфокарталар, калькуляторлар, алгоритмик программалар кулланыла башлады.

Алга таба педагогик технология төшенчәсенең эчтәлеге киңәйтелде. Педагогик технологияне укыту процессында техник чаралар, компьютер куллану дип кенә түгел, ә укытуның нәтиҗәлелеген күтәрү өчен күптөрле методик алымнарны куллануның билгеле бер системасын булдыру, укытуның нәтиҗәсен алдан билгели белү, бәя бирә, прогноз ясый белү кебек чаралар җыелмасы, дип аңлый башладылар.

Укыту-тәрбия процессын оештыруның төп формасы булып дәрес тора. Шуңа күрәдер, дәрес технологиясен эшләүгә күп кенә галимнәр тарафыннан зур игътибар бирелә. Дәрес технологиясен эшләгәндә, аның һәр этабында укучылар һәм укытучының бер-берсенә бәйле рәвештә алып барылган эшчәнлеге күз алдында тотыла.

Дәреснең максатлары аны тотрыклы система итеп саклый. Ул максатлар өчәү: белем һәм күнекмәләр бирү, укучылар белән тәрбия чаралары уздыру, шәхес буларак үстерү һәм аларның фикерләү сәләтен, акыл үсешен булдыру.

Дәрес теориясен һәм технологиясен эшләгәндә ике әйбергә игътибар ителә: дәреснең эчтәлеге һәм эшчәнлек процедуралары.

Дәреснең эчтәлеген уку материалы – өйрәнеләсе кагыйдәләр, законнар, төшенчәләр һәм күнегүләр тәшкил итә.

Дәрес технологиясенең процессуаль ягын – укытучы һәм укучыларның эшчәнлек төрләрен сайлаганда, нигез итеп укыту методлары алына. Укучылар һәм укытучының максатка ирешү өчен башкарылган бер-берсенә бәйле эшчәнлек төрләрен укыту методлары, диләр. Укыту методларына бәйле рәвештә өйрәнелгән материалның эчтәлеге дә ачыла, шәхес буларак, укытучы һәм укучыларның эшчәнлек стиле дә формалаша. Димәк, технологиядә укучыларның таныш-белү эшчәнлеге, яңа материалны өйрәнүдәге мөстәкыйльлеге, фикерләү юнәлешләре конкрет күрсәтелергә тиеш.

Дәреснең төп максаты – укучыларга билгеле күләмдә белемнәр һәм күнекмәләр бирү. Методика фәне бу процессның нәтиҗәлелегенә ирешү юлларын күрсәтергә тиеш. Һәр фәнне өйрәнүнең үзенең методикасы була. Ул фәннең методологиясе, эчтәлеге, үзенчәлекләреннән чыгып, методика, психология, дидактика, философия, физиология, логика һ.б. фәннәрнең казанышларына таянып, әлеге фәнне өйрәнүнең уңышлы юлларын билгели.

Соңгы елларда методикада шәхесне үстерү мөмкинлеген булдыручы укыту алымнарына игътибар көчәйде; мондый укытуны тормышка ашыру методларына һәм оештыру формаларына багышланган хезмәтләр күп языла. Үстерешле укыту теориясен булдыруда П.Я.Гальперин, Н.Ф.Талызина, И.Я.Лернер, М.И.Мәхмүтов, Д.В.Вилькеев һ.б. галимнәрнең хезмәтләре игътибарга лаек.

Шул хезмәтләргә нигезләнеп, шәхесне үстерүне тәэмин итүче проблемалы дәрес технологиясе эшләнде. Ул берничә этаптан тора. Шуларны карап китик.

I этап. Белемнәрне актуальләштерү. Проблемалы дәреснең башка дәресләрдән аермасы булып, анда махсус рәвештә проблемалы ситуация тудыру тора. Ләкин үзләштереләчәк яңа материалга турыдан-туры бәйле булган, элегрәк өйрәнелгән белемнәр группасын искә төшермичә (актуальләштермичә) уку-укыту проблемасын куярга ярамый. Укытучы моны исендә тотарга тиеш. Болай булмаганда, проблема аңлашылмаячак яки аны укучылар кабул итмәячәк, проблема үзенең функциясен үтәмәячәк. Шулай итеп, дәреснең үткәннәрне искә төшерү этабында, укытучы яңа материалны өйрәткәндә, укучыларны проблемаларны хәл итәргә әзерли. Шулай ук бу этапта укучыларның фикер эшчәнлеге активлаштырыла, проблемалы ситуацияләр тууга җирлек тудырыла.

II этап. Проблемалы ситуация тудыру. Материалның эчтәлегенә һәм классның үзенчәлегенә карап, проблемалы ситуация тудыру юлы сайлана һәм билгеле бер алым белән (кызыклы тормыш мисаллары, тарихи фактлар, кызыклы тәҗрибәләр, гаҗәеп вакыйгалар ярдәмендә) класс алдында проблемалы ситуация тудырыла. Аннары укытучы җитәкчелегендә укучылар барлыкка килгән ситуацияне анализлыйлар. Барлыкка килгән ситуациядән дәреснең төп проблемасы – кичектергесез хәл ителәсе мәсьәлә килеп чыга.

III этап. Укучыларның проблеманың җавабын фараз итүләре, гипотезалар әйтү. Бу этапта проблеманы хәл итү юллары тикшерелә. Үткән материалларга таянып, укучылар проблеманы хәл итү вариантларын тәкъдим итәләр.

Укучыларның гипотезалар тәкъдим итүен, яңа гипотезалар барлыкка килүен укытучы куәтләп, укучыларга ярдәм итеп торырга тиеш. Бу вакытта укучыларга бер-берсе белән фикер алышырга да рөхсәт ителә. Укытучының укучылар тәкъдим иткән гипотезаларны тыңлый белүе бик мөһим. Аларны шунда ук расларга да, кире кагарга да кирәк түгел. Укытучы гипотезаларны дөрес яки дөрес түгеллеге турында әйтсә яки, ым кагып, укучыларга белдерсә, проблема проблема булудан туктый, фикер эшчәнлеге пассивлаша, билгесез шунда ук билгеле була, эзләнү процессы юкка чыга. Бу уңайдан, укытучының укучылар белән булган һәрбер әңгәмәсе укучылардан гипотезалар әйтүне таләп итә, дигән карашның дөрес була алмаганын да ачыкларга кирәк. Проблемалылык төп максат булмаган (традицион) дәресләрдә әңгәмә вакытында укучыларның җаваплары дәлилләнми, еш кына, укучылардан дөрес җавап алыну белән, укытучы фикернең дөреслеген раслый. Дөрес булмаган фикерләрнең хаталары ачылмый кала. Шулай итеп, мондый әңгәмә

укучыларны бераз активлаштырудан узмый, укучыларның логик фикерләвенә, гипотезалар тәкъдим итүгә, аларны дәлилләүгә этәргеч тудырмый.

IV этап. Проблеманы хәл итү. Гипотезаларны анализлап, дәреснең төп проблемасы ачыклангач, укучылар проблеманы чишүгә керешәләр. Укытучы укучыларның фикер йөртү, эзләнү процессына юнәлеш бирә, рациональ юл белән нәтиҗә чыгарырга булыша.

V этап. Табылган нәтиҗәләрне тикшерү, эзләнүләргә йомгак ясау. Проблеманы хәл итү нәтиҗәсендә укучылар яңа төшенчәләргә, кагыйдәләргә, закончалыкларга килергә тиеш. Укучылар чыгарган нәтиҗәгә укытучы тарафыннан фәнни аңлатма бирелә, өйрәнелгән яңа белемнең элек өйрәнгәннәр белән бәйләнеше ачыклана.

VI этап. Хәл ителгән проблеманы яңа ситуацияләрдә тикшерү, күнегүләр, мәсьәләләр эшләү. Бу этапта укучылар логик фикерләп, өйрәнелгәннәрне яңа ситуацияләрдә куллана белергә тиешләр.

VII этап. Өйгә эш бирү. Бу этапта укучыларга өйдә эшләнеләчәк эшләрнең максаты, эчтәлеге аңлатыла. Дәреслектәге теоретик материал һәм мәсьәлә, күнегүләрдән тыш, укытучы өй эше итеп тирән уйлануны, мөстәкыйльлекне, иҗади эшне таләп иткән биремнәр һәм сораулар да бирергә тиеш.

Дәреснең мондый структурасы укучыларның фикерләү дәрәҗәсен үстерә, мөстәкыйльлеген арттыра. Дәреснең һәр этабы бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән. Бер элементның төшеп калуы икенчесенә кимчелек китерә. Әйтик, актуализация этабын тиешенчә үтәмәсәк, проблемалы ситуацияне анализлау процессы авыр бара, проблемалы ситуация тудырылмаса, дәрестә укучыларның активлыгы кирәгенчә булмый.

Педагогик технологияләрне мәктәп практикасына кертүдә һәм аларны тормышка ашыруда мәктәп җитәкчеләре күп эш башкара. Әлбәттә, моның өчен аларга психология, педагогика, методика фәннәре казанышларын системалы өйрәнеп барырга, төрле юллар белән үзләренең квалификациясен күтәрергә кирәк.

Мәктәп җитәкчесенең төп вазифаларыннан берсе – укытучыларның дәресләренә һәм тәрбия чараларына анализ бирү. Бу анализны һәрвакытта да билгеле бер кануннар кысаларында гына башкаруы авыр. Өйрәнеләсе материалның, фәннең, дәрес төренең, аның максатларының үзенчәлегеннән чыгып, дәрескә анализ да төрлечә ясалырга мөмкин. Ләкин тәҗрибәле мәктәп

житәкчеләренең эш практикасыннан чыгып, дәрескә анализ ясау технологиясен тәкъдим итәргә мөмкин.

Идарә итү фәне теориясе һәрбер уздырылган чарага (дәрес, тәрбияви чаралар) башта гомуми бәя бирүне таләп итә. Аннары дәрескә куелган максатларның дөрес куелуына бәя бирелә. Дәреснең өч максатының да формулировкасы төгәл булырга тиеш. Яңа белемнәр нинди күләмдә бирелә? Укучылар нинди яңа күнекмәләр алырга яки нindиләрен ныгытырга тиеш? Шәхеснең нинди сыйфатларын үстерү яки тәрбияләү кирәк?. Анализда аларны тормышка ашыру юлларының уңышлылыгы бәяләнә.

Аннары дәреснең һәр этабының оештырылуы, аның эчтәлеге, укытучы һәм укучыларның эшчәнлек формаларына бәя бирелә, дәреснең уңышлы яки кимчелекле яклары, топ максатларга ирешүнең яки ирешмәүнең сәбәпләре ачыклана.

Соңыннан укытучыга алга таба камилләшү өчен юллар күрсәтелә, киңәшләр, тәкъдимнәр әйтелә.

Психология, педагогика, идарә итү фәннәре буенча күп сандагы тикшеренүләр нәтиҗәләренә нигезләп, 80 нче елларда күренекле педагог Ю.П.Бабанский укыту-тәрбия процессын оптимальләштерү технологиясен эшләде. Аның технологиясе түбәндәгеләрне эченә ала: укыту-тәрбия процессын конкрет планлаштыру, бу процесста катнашучыларның функцияләрен рациональ билгеләү, дәрестә укытучы һәм укучыларның хезмәтенә контрольлек итү, анализ ясау, укучылар һәм укытучы мөмкинлекләреннән һәм дәрес материалы үзенчәлекләреннән чыгып, уку-укыту методлары, максатлар һәм җиһазлар сайлау, вакытка һәм уку-укыту процессында катнашучыларның энергия сарыф итүенә экономия ясау һ.б.

Укытучының сүзен, күргәзмәлекне, укыту темпын һәм дәрес материалының катлаулылыгы, дидактик принципларның урынлы кулланылуы мәсьәләләрен теориядә һәм тәҗрибәләрдә күп еллар өйрәнеп, профессор Л.В.Занков кече яшьтәге мәктәп балаларын үстерешле укыту технологиясен эшләде.

Берничә дистә ел инде Донецк шәһәре укытучысы В.Ф.Шаталов тәҗрибәсе турында күп сөйләнелә. Аның технологиясе нигезендә акыл культурасын камилләштерү идеясе ята: укытучының аңлатуын игътибар белән тыңлау, информацияне тыңлап хәтердә калдыру, информацияне язып хәтердә калдыру, сөйләү ярдәмендә материалны истә калдыру, күнегүләр эшләү, иҗади биремнәр үтәү һ.б.

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, технология эшчәнлеккә системалы якын килү принцибына таяна, аның нигезендә

педагогик-психологик теория яки методик концепция ята. Технология, алгоритмик кагыйдәләр ярдәмендә, хезмәтне фәнни оештыруга булыша, куелган максатка ирешкәндә, кеше энергиясен һәм материал чыгымнарны экономияләргә ярдәм итә.

Бу уңайдан тагын бер юнәлешкә тукталыйк. Соңгы елларда педагогикада яки мәктәп тормышындагы барлык яңалыкларны да педагогик технология дип атау модага әйләнде. Мәсәлән, Монтессори, Френе, Вальдорф мәктәпләре технологияләре һ.б. турында сөйлиләр. Бу, чыннан да, шулаймы соң? Берничә мисал китерик. Әйтик, Френе системасы өчен нәрсә характерлы?

Селестен Френе (1896–1966) – француз педагогы – "Яңа мәктәпне яклаучыларның Халыкара Федерациясе"н оештыручы. Ул мәктәпнең төп максаты – укучыларда мөстәкыйльлелек тәрбияләү. Балалар беләп оештырылган барлык эшләрнең үзәгендә мәктәп типографиясе тора. Төрле темаларга иншa язып, балалар шуны типографиядә бастыралар.

Мәктәп эшендә төп принциплар: язышу, газеталар чыгару ярдәмендә укучы шәхесен үстерү, сөйләм телен, укуны камилләштерү, рәсем, театр, кино, техника белән шөгыльләнү, хаталардан эшли-эшли арыну методын куллану, балалар арасында хезмәттәшлекне киң җәелдерү, конкуренцияне бетерү.

Башлангыч классларда дәреслекләр куллануга Френе каршы чыга. Дәреслекләр балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен инкарь итә, дип саный ул. Дәреслекләр урынына ул уку материаллары язылган карточкалар тәкъдим итә. Укучылар, укытучы ярдәмендә, атналык эш өчен карточкалар сайлап алалар.

Френе тәрбия эшендә сөйләү методларына каршы чыга. Шәхес үзен үзе эш белән тәрбияләргә тиеш, дип саный ул. Эшләү өчен, укучыларга "мәктәп кооперативы" оештырыла. Укучының үз-үзенә хезмәт күрсәтүенә дә, хуҗалык эшчәнлегенә дә "кооператив" җитәкчелек итә.

Френе концепциясендә күп кенә уңай якларны санарга мөмкин. Болар: укучыларда мөстәкыйльлелек тәрбияләргә тырышу, укучы белән өлкәннәрнең дустанә мөгамәләсе, хезмәткә өйрәтү, техник чаралардан файдалану һ.б. Шуның белән беррәттән, Френе мәктәбендә тискәре якларны да күрергә була: белем бирүдә системалылык принцибын танымау, тәрбиянең берьяклылыгы яки фрагментарлыгы һ.б.

Бу тәҗрибәне педагогик технология дип атап буламы соң? Юк, әлбәттә. Моны педагогик система дисәк, дөресрәк булыр.

Монтессори мәктәбе тәҗрибәсе турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Мария Монтессори (1870–1952) – Италия педагогы һәм врачы. Аның педагогик системасының нигезен ирекле тәрбия принцибы тәшкил итә. “Һәр эшне дә үзең башкар, үзеңне үзең камилләштер, чыныктыр!” принцибы нигезендә укучы язарга, укырга, түкмичә кувшинга су салырга, кадак кагарга, музыка тыңларга һ.б. эшләргә өйрәнә. Автор концепциясе фаразлаганча, бу система белән эшләгәндә, укучылардан мөстәкыйль шәхес тәрбияләнергә тиеш.

Шәхесне үстерүгә юнәлтелгән укыту принципларыннан чыгып карағанда, укучылар да, укытучы да – кабатланмас шәхес. Аларның һәрберсенең үзенә генә хас фикер йөртү үзенчәлеге, иҗади мөмкинлекләре, практик сәләте бар. Педагогик технологияләр боларны исәпкә алып тормый. Бу яктан караганда, педагогик технологияләр шәхесне үстерүгә юнәлтелгән укыту принципларына каршы килә.

Тагын шуны да искәртик, укытуны технологияләштерү элементлары күптәннән килә. Һәрвакытта да технологияләр методика фәненең үсеше дәрәҗәсенә бәйле булды. Максатларны һәм аңа ирешү юлларын ачык күрсәтеп, тематик планнар төзү, материалны үзләштерүне тикшерүче контроль эш текстлары (тестлар) төзү – технология элементлары. Методика фәне үсә барган саен, технологияләр дә камилләште.

Шуңа күрә, педагогик технологиягә укыту-тәрбия процессының барлык проблемаларын да хәл итүнең бердәнбер чарасы итеп карау дөрес булмас, ә аңа яңа модага караган кебек карау – бөтенләй хата.

Педагогик технологияләрне тормышка ашыруның объектив кыенлыклары да бар:

1. Психология, педагогика, методика фәннәренең соңгы казанышларын файдаланып төзелгән педагогик технологияләр, практик эшләүче укытучылар өчен, рекомендацияләр рәвешендә мәктәпләргә вакытында килеп җитми. Технологияләрне новатор укытучылар үзләре эшләгән очракта, алар матбугатта яктыртылганчы шактый вакыт үтә.

2. Күп кенә авторлар технологияләр, укыту-тәрбия модельләре ясаганда, төп игътибарны укытуның эчтәлегенә, теориягә юнәлтәләр, процессуаль якка игътибар җитми. Шуңа күрә ул хезмәтләр практикага авыррак керә.

3. Башлангыч класслар өчен эшләнгән оригинал педагогик технологияләр югары класслар өчен дәвам итми.

4. Мәгариф системасының һәм уку йортлары җитәкчеләренең консервативлыгы да алдынгы технологияләрнең киң җәелдерелүенә комачаулый.

Объектив кыенлыкларны һәм субъектив сәбәпләрне бетергәндә, теориядә һәм практикада сыналган алдынгы технологияләр укыту-тәрбия эшендәге алда торган бурычларны уңышлы хәл итәчәк.

Искәрмәләр

1. *В.П. Беспалько.* Слагаемые педагогической технологии. – М.: Педагогика, 1989.

2. *М.С. Каган.* Человеческая деятельность. – М., 1974.

3. *М.В. Кларин.* Педагогическая технология в учебном процессе. – М.: Знание, 1989.

4. *М.И. Махмутов.* Современный урок. – М.: Педагогика, 1985.

5. *М.И. Махмутов, Г.И. Ибрагимов, М.А. Чошанов.* Педагогические технологии развития мышления учащихся. Казань, тип. ГЖИ, 1993.

6. *П.Митчелл.* Энциклопедия педагогических средств, коммуникаций и технологии. Лондон, 1978.

7. Педагогическая энциклопедия. – М., изд. "Сов.энц.", 1968. Т.4.

8. *Т.И. Шамова и др.* Педагогические технологии: что это такое и как их использовать в школе. Москва-Тюмень, 1994.

9. *А.С. Макаренко.* Педагогическая поэма. М. Учпедгиз., 1948.

Мирасыбызны, шәхесләребезне барлыйбыз

Хәерле көн, Васил Габдуллович һәм Тихния Миргалимовна!

Сезгә ямьле Мөслим якларыннан күп итеп кайнар сәламнәр җибәрергә рөхсәт итегез.

Үзем турында әйтеп китәм. Мин, Зарипов Рафаэль Зиннур улы (педстаж – 25 ел), Түбән Табын урта мәктәбендә физика һәм информатика укытам, хатыным Филия Тимергази кызы рус теле һәм әдәбиятыннан дәресләр бирә. Айсылу исемле бер кыз үстерәбез. 4 нче сыйныфта укый.

Түбән Табын урта гомумбелем бирү мәктәбе педколлективы менә инде ун елдан артык халык педагогикасы алымнарын укытуда һәм тәрбия чараларында куллану буенча уңышлы гына эшләп килә. Тәҗрибәбез дә бар. Безгә килеп өйрәнеп тә китәләр.

Хәзерге вакытта даими эшли торган проблемабыз: **"Халкыбызның мирасын һәм үткәнен барлау аша укучыларда патриотизм, мираска хөрмәт, белемгә омтылыш тәрбияләү"**. Без, укучылар белән, җирлегебездә туып, халыкка зур хезмәт куйган шәхесләребезне барлыйбыз, аларның тормыш юлын, иҗатын, эшчәнлеген өйрәнәбез. Аларга багышланган альбомнар, стендлар, сценарийлар төзибез, видеофильмнар төшереп, төрле кичәләрдә, дәресләр вакытында кулланабыз. Мәсәлән, атаклы спортчыларыбыз Фәиз Хуҗин, Маргарита Ахунова, табибыбыз Рафис Хәбибуллин, артистыбыз Зөфәр Харисов, галимебез – профессор Васил Гайфуллин – әнә шундыйлардан. Бу исемлекне тагын да дәвам итәргә мөмкин.

Туган өен белмәгән
Туган җирен белерме?
Туган телен белмәгән
Туган халкын белерме?

Ә туган халкын белмәгән, аның мирасын өйрәнмәгән кешенең, гомумән, милләтнең киләчәге бармы? Юк! Һәм тагын бер мәртәбә юк!

Хөрмәтле Васил ага Гайфуллин! Мин сезгә бер язмамны җибәрәм. Бу язманы әзерләгәндә Муханда яшәп ятучы Сәвия апагыз янына барып та киңәшләштек, сөйләштек. Бик күңелле, ачык йөзле апа булып чыкты ул. Быел 25–26 февральдә "Каюм Насыйри укулары"на чыгыш ясарга ике укучыбызны Казанга алып бардым. Аларның чыгыш ясау темасы Сезнең хакта иде. Укучылар әйбәт кенә чыгыш ясадылар. Сездән, Васил Габдуллович, рөхсәт сорамыйча эшләдем инде – гафу итәрсез дип ышанам.

Васил Габдуллович! Минем Сезгә бер үтенечем дә бар иде. "Укырга, укырга һәм укырга!" – дигән бит Ленин бабабыз. Шуңа микән, әллә башка сәбәптәндерме – укыйсы килә! Авыл укытучысы фән кандидаты булырга хыяллана ала микән? Мине халык педагогикасы кызыксындыра. Әгәр хыяллана алса, аның шартлары нинди микән? Бәлки, аның хакында башка берәр җирдән белергәдер? Менә шул." Апаем, тыпырчынма, барыбер тешең үтмәс", – дисәгез, шул сүз җитә.

Сезгә ихтирам белән: *Рафаэль Зарипов*. 09.04.05.

P.S. Минем адрес: 423977. Мөслим районы, Тегермәнлек авылы. Хәзер исә Сезгә багышланган язмабыз белән танышыгыз!

Казаныбызның 1000 еллыгына багышлана

Якташыбыз белән горурланабыз

> Кайсы туфрак биргән ул даһига
> "Эврика"лы зирәк акылны?..
>
> ...Югары Табында туган чын егет
> Сокландырды газиз халкымны!

Мөслим районы Татарстан Республикасының иң көнчыгыш өлешендә, искиткеч матур урынында урнашкан. Әлеге районның калын урманы да, киң болыны да, биек таулары да һәм балыкка бай мул сулы Ык елгасы да булган урында Югары Табын авылы урнашкан. Васил Габдулла улы Гайфуллин менә шушы авылда, колхозчы Габдулла абзый белән Тәгъзимә апа

гаиләсендә, 1937нче елның 23 мартында, гаиләдә өченче бала булып, дөньяга килә.

Бәләкәй чагыннан ук бик тырыш була ул. Белемгә омтылышы, укуга аңлы карашы, татар халкының "тырышкан табар, ташка кадак кагар" дигән мәкален яхшы аңлавы аңа алдагы гомерендә ныклы терәк була.

Васил абыйның апасы Сәвия апа сөйли: "Әгәр чәй алып килсәң, укырга алабыз (чәй бик дефицит була), – дигәч, ул, әбинең чәен, киштәдән уклау белән алып, мәктәпкә илтеп бирә. Билгеле, бу хакта укытучы шаяртып кына әйткән була. Мәктәпкә алырга Васил әле бик яшь була".

Менә шушы уку теләге аның тормышында зур роль уйный, гомере буе аңа юлдаш була һәм халкына хезмәт итүче көчле шәхес итеп тәрбияли.

Мәктәптә белем-тәрбия биргән укытучыларның да ярдәме зурдан була. "Башлангыч мәктәптә Хөршидә апа Галиева укытты. Ул тырыш булырга өйрәтте. Җидееллыкта – класс җитәкчесе һәм рус теле укытучысы Гали ага Камалов, татар теле укытучысы Разия апа Шәяхмәтова күңелемдә аеруча тирән эз калдырдылар", – дип искә ала Васил абый. Ул Түбән Табын авылының җидееллык мәктәбен "бик яхшы" билгеләренә генә тәмамлый. Яшьтән үк күп белергә, өйрәнергә тырышуы нәтиҗәсендә, Васил үзе эшләп тапкан акчага гармун сатып ала һәм анда уйнарга өйрәнә.

Билгеле бу чорда тормыш итү шома гына, җиңел генә бармаган. Бу еллар халкыбыз тарихына рәхимсез репрессия, авыр сугыш, аның белән бәйле ачлык, ялангачлык еллары булып кереп калган.

"...Биш бала янына бозау белән сарык бәрәннәрен дә сыйдырган сәкеле авыл өендә үстем. Әйе, чабаталы малай чагым – үзәкләргә үткән ачлык белән суыкны өстерәп, күрше авылга мәктәпкә чабудан гыйбарәт. Учком әгъзасы буларак, арттa калучыларга булышу өчен дәресләр беткәч тә кала идем", – ди ул үзенең бер мәкаләсендә. ("Ватаным Татарстан" – 17нче апрель, 2004 нче ел).

1951 нче елда Васил Гайфуллин Минзәлә педагогия училищесына укырга керә һәм 1955нче елда аны "бик яхшы" билгеләренә генә тәмамлый. "Тормышымда иң матур еллар педучилищеда узды дип саныйм. Уку йортлары нинди булырга тиеш дисәгез, нәкъ менә педучилищелар кебек, дияр идем. Анда тирән белем бирәләр, тәрбия эше дә шәп куелган, кешенең сәламәтлеген ныгыту, сәләтен ачу өчен дә тиешле шартлар бар.

Педагог, тәрбияче булып җитлегү өчен дә мөмкинлекләр җитәрлек. Һәм эзләнүче-фәнни тикшеренүче, галим булып үсеп китү өчен дә беренче оеткыны шунда салалар. Класс җитәкчесе һәм педагогика укытучысы Сания апа Гобәйдуллина, физик Гыйззәт ага Галиев укытучылык эшенә нык юнәлеш бирделәр", – диеп искә ала соңрак Васил ага. Педучилищеда укыганнан соң, Васил Гайфуллин Мөслим районының Ташлыяр мәктәбендә физика фәне укыта. Укуны дәвам итәргә кирәклеге аны Казан пединститутына алып килә.

1956–1961 нче елларда Васил Габдулла улы – Казан педагогия институтының физика-математика факультеты студенты. Сәләтле егетне шундук күреп алалар, ул башы-аягы белән җәмәгать эшләренә чума. Группа старостасы да ул, студсовет әгъзасы да, соңрак – профсоюз, комсомол активисты. Үзешчән сәнгать коллективының җаны, студентлар хорында башлап җырлаучы. Укытучылар йорты каршында эшләүче төрле түгәрәкләрнең үзәгендә дә ул!..

Студент елларының иң зур авырлыгы тулай торак белән бәйледер. Ул утын белән җылытыла. Ә утынны елга портыннан алып кайтасы, кистертәсе, ваклатасы, ташыттырасы – боларны оештыру барысы да В.Гайфуллин өстендә. Бер бүлмәдә 14 егет тора. Ашау коры-сары гына, ярты буханка ипине кайнаган су белән кәне буена җиткерәсең, ә көрәш түгәрәгеннән соңрак кайтсаң – ипидән дә җилләр искән була.

Колхозчы әти-әни ерак, алардан ярдәм көтеп тормый Васил: бер мәктәпкә лаборант булып эшкә урнаша.

Студент елларында аны физика методикасы укытучысы Мөхәммәт Салихович Галиев, физика укытучысы Камил Әхмәтович Вәлиев (хәзер атаклы академик) фән юлыннан кереп китәргә нык әзерлиләр.

1961 нче елда институтны "кызыл" дипломга тәмамлаган Василны ул чактагы кафедра мөдире Камил Вәлиев аспирантурада калдырырга омтыла, кат-кат ректорга керә. Әмма Халык мәгарифе министры Мирза Мәхмүтов җавабын кыска тота: "Мөслим районына физика укытучылары җитми, шунда кайтасың!"

Ыклы Мөслим, таңда чыклы Мөслим,
Тере утлы ныклы Ватаным!
Кайсы якка гына юл тотсам да,
Мин бит һаман сиңа атладым!

Васил Мөслим мәктәбенә физика укытырга кайта һәм завуч булып эшли. Эшкә мөнәсәбәтенә карап, 27 яшьлек егетне Мөслимнең мәгариф бүлеге мөдире итеп куялар. 1965–1971нче елларда районда мәгарифне күтәрү, аны алдынгы урыннарга чыгару өстендә тырышып эшли ул. Мәсәлән, кичкс мәктәпләрнең эшен оештыру, район мәктәпләренең яңа уку елына әзерлеге буенча 1970–1971нче елларда республикада да, РСФСР буенча да 1–2нче урыннар яулапа. 1971 елда аспирантурага конкурста җиңеп чыга һәм 1974 елга хәтле Ленинград пединституты аспирантурасында укый. Монда Петр Знаменский, Евгения Савелева кебек профессорлар аның остазлары була.

Васил Гайфуллин 1974–1990нчы елларда КДПИ да эшли. Ул ассистенттан кафедра мөдире, факультет деканы дәрәҗәсенә күтәрелә. Шушы елларда аның фәнгә сәләте ачыла да инде. Ул физика фәнен үстерү, аны укыту методикасын камилләштерү, проблемалы ситуацияләр, укыту технологияләре турында бик күп фәнни мәкаләләр яза башлый.

1990–1997нче елларда Васил Гайфуллин Мәгариф министры була. Бу елларда татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү, икетеллелекне тормышка ашыру буенча бик күп эшләр эшләнә. Тарихыбызда безнең милли мәгариф системасы булган. Кызганыч, төрле сәбәпләр аркасында, ул сүнеп бара иде. 90 нчы елларда авылларда да, шәһәр җирлегендә дә гел бер генә төрле урта мәктәпләр булса, хәзерге вакытта республикабыздагы барлык балалар да балалар бакчасыннан һәм 1 класстан башлап, уку йортын тәмамлап чыкканчы, татар телен һәм әдәбиятын өйрәнә. Васил аганың зур тырышлыгы нәтиҗәсендә, татар телендә укыта торган мәктәпләр, яңа гимназияләр, лицейлар барлыкка килә, халык педагогикасына игътибар арта.

Министр буларак, Васил Габдуллович үзен мәгариф өлкәсенең әйдәп баручы эшлеклесе, тирән белемле аналитик һәм зур оештыру сәләтенә ия җитәкче итеп танытты. Шулар җөмләсенә гражданнарның белем алуга хокукын гарантияләячәк законнарны һәм яңа педагогик технологияләрне эшләү, гамәлгә кертү дә; мәгариф учреждениеләренең югары уку йортлары, шулай ук чит илләр белән бәйләнешен ныгыту да; 300 дән артык яңа типтагы уку йортларын оештыру да; милли мәгарифне торгызу һәм үстерү дә керә. Болар барысы да – олы хезмәт, заманыбызның үсеш закончалыкларын алдан күрә белү, мәгарифнең гаять катлаулы мәсьәләләрен стратегик планда дөрес хәл итү нәтиҗәсе.

Милли мәгарифне торгызуның тагын бер буыны булып милли институт тора. Васил аганың зур хезмәте нәтиҗәсендә

бу эш тә уңышлы тормышка ашырыла. Менә нәрсәләр сөйли ул үзе бу хакта: "Узган гасырның 90 нчы еллары башында дөньяның айкалган-чайкалган бер чоры булып алды. Милләт каһарманнары мәйдан җыеннарына җыелып: "Үздәүләт!" – дип чаң сукты, ә кайбер зыялыларыбыз, үз теле үлеп баручы халыкның үз дәүләте була алмый, дип сыкранудан узмады. Хәтта дәрәҗәле мөнбәрләрдән дә, үз ана телендә югары уку йорты да булмаган милләтнең киләчәге юк, диючеләр булды. Менә шул елларда: "Милләт үлүгә бара, чөнки татарның югары йортын ачу өчен бездә җирлек юк", – дип уфтанучыларның шикшөбһәсен җимерердәй дәлил эзләп, мин сәфәр чыктым. Татарстан авылларында йөрдем, якын күршеләргә дә, ерак-ерак өлкәләргә дә сәфәр кылырга туры килде. Һәм кайда гына булсам да, үз ана телендә укырга теләүче, милләтнең җәүһәрләре булырдай татар улларына, татар кызларына тап булдым. Өлкә җитәкчеләре белән дә сөйләшүләр алып бардым һәм аңлау таптым: алар үз төбәкләрендә яшәүче татар балаларының бездә укырга теләвен бик хуп күрделәр. Менә шушындый дәлилләр нигезендә, ТР Министрлар Кабинеты карары белән, 1992 елның августында милли уку йорты туды".

Башта бу милли уку йорты педагогик колледж буларак эшли. Татарстан Министрлар Кабинетының 993 нче карары (28.11.1996) нигезендә педагогик колледж Татар дәүләт гуманитар институты итеп үзгәртелде. Хәзерге вакытта Васил ага Гайфуллин шушы институтның ректоры булып эшли. Анда бүгенге көндә 8 кафедрада һәм 4 факультетта 170 тән артык укытучы эшли, 2000 нән артык студент укый. Алар арасында 28 өлкәдән килгән татар уллары, татар кызлары гына түгел, башка милләт вәкилләре дә бар. Институтта өч телне (татар, рус һәм чит ил телен) үзләштергән белгечләр әзерләү максаты уңышлы тормышка ашырыла. Институтка барган кешеләр аның милли рухлы булуына сокланып кайталар. Бүгенге көндә Васил Габдулла улы Татар милли университетын булдыру, аны ачу мәшәкатьләре белән шөгыльләнә. Ректорны бу тырышлыгы, хезмәтләре буенча, татар халкының бөек мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның дәвамчысы, дип әйтергә тулы нигез бар.

Ул фәнни эш белән дә ныклап шөгыльләнә, фән өлкәсендә төпле үз сүзен әйтә алган галим. Педагогиканың, мәгариф эшен оештыруның, физика укытуны камилләштерүнең иң мөһим мәсьәләләренә багышланган дистәләрчә китабы, дәреслекләре, методик кулланмалары, бихисап фәнни мәкаләләре басылып

чыкты һәм чыгып килә. Татарстанның атказанган укытучысы, атказанган фән эшлеклесе, педагогия фәннәре докторы, профессор, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Халыкара информатизация академиясе академигы да ул. Менә Васил Габдулловичның үзе һәм авторлар составында язган китапларының кайберләре: 1. *Физика – 7нче класс*. Казан, "Мәгариф" нәшрияты. 2. *Физика – 8нче класс*. Казан, "Мәгариф" нәшрияты. 3. *Физика – 9нчы класс*. Казан, "Мәгариф" нәшрияты. 4. Проблемалы ситуацияләр. 5. *Игровой* метод в обучении физики. 6. Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы. I һәм II кисәк. 7. Национально-региональный компонент стандарта образования: Татарстанский вариант. 8. Совершенствование обучения физики в сельской малокомплектной школе...

Васил Габдуллович әдәбиятка, сәнгатькә, җырга үлеп гашыйк кеше. Бу, беренче чиратта, табигать тарафыннан бирелгән мул сәләт нәтиҗәсе дә инде. Музыка, җыр аның гомерлек юлдашы булды. Күңеле тулганда ул бүген дә кулына тальян гармун ала, иң якын дуслары арасында рәхәтләнеп җыр суза, җаваплы дәүләт эшендәге киеренкелекне театрларда, концертларда җиңеләйтә.

Әйе, данлыклы мөгаллим, җитәкче һәм галим булу өстенә, талантлы музыкант һәм җырчы да әле ул Васил Габдуллович!

Сыйган бар татар язмышы
Шушы тавышка –
Күкләрдән җиргә инә җыр
Һәм күккә аша!

Васил ага хәзер дә җырлый. Гармунда, баянда, скрипкада, мандолинада, пианинода уйный. Яшьрәк чакта сәхнәләрдә җырлап, бөтен ил күләмендә лауреат исеме алган кеше дә ул!..

"...КДПИда укыган елларда Укытучылар йортына Хәбиб абыйның эстрада түгәрәгенә, Горький клубына Сара апа Садыйкованың хорына, Мехкомбинат клубына Х.Сәлимҗанов драма түгәрәгенә йөрдем. Хәзер боларның берсе дә юк. Институтта (ТДГИ) аларны үзебезгә оештырырга туры килә", – ди тынгысыз рухлы якташыбыз.

Васил ага Гайфуллин бөтен гомерен, язмышын мәгариф өлкәсенә багышлаган кеше – коеп куйган укытучы, мөгаллим һәм галим. Мөслим районында җидееллык авыл мәктәбендә гап-гади укытучыдан башлап, Татарстан Мәгариф министрына кадәр, институт ассистентыннан алып Гуманитар институт рек-

торына кадәр юл үткән күренекле шәхес. Аның тормыш юлы шактый катлаулы да, бай да.

Васил Габдулловичның үткән тормыш юлы – максатчанлыкның, хезмәт яратуның, һөнәри интеллектуаль камиллеккә омтылуның, гаҗәеп зур ихтыяр көченең һәм кыенлыкларны җиңә белү сәләтенең матур үрнәге ул!

Шунысы мөһим: Васил ага бу дәрәҗәләрнең һәммәсенә дә бары тик үз тырышлыгы, таланты белән ирешкән чын шәхес!

Гаилә мөнәсәбәтләре буенча да Васил ага хатын-кызны бик бәхетле итүче, балаларына милли тәрбия бирүче асыл ир-егет. Хатыны Тихния белән бер ул, бер кыз тәрбияләп үстерделәр, олы тормыш юлына чыгардылар. Тихния Миргалим кызы (шулай ук Мөслим ягыннан), гомер буе Казан мәктәпләренең берсендә татар теле һәм әдәбияты укытып, лаеклы ялга чыкты, 5нче класслар өчен татар теле дәреслеге авторы, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы. Улы Айрат – Татар дәүләт хокук һәм идарә итү институтының доценты, юридик фәннәр кандидаты. Кызы Лилия – табибә, аспирантурада укый. Ике оныклары – Алсу һәм Алисә үсеп килә.

Васил Габдуллович – табигате белән йомшак күңелле, ягымлы, миһербанлы кеше. Әңгәмәдәшенә үтә игътибарлы, бәхәсләрдә сабыр, сыгылмалы, әмма үзенең хаклыгын саллы дәлилле белүчән. Ул кешене үпкәләтергә, хәтерен калдырырга тырышмый. Бу аның гаделлегеннән, җитешсезлекләрне бетерү юлларын бергәләп эзләвеннән килә, диләр хезмәттәшләре. Киңәшмәләрдә, утырышларда киеренке, авыр мизгелләр килеп туганда, Васил ага Гайфуллин аларны бер-ике юмористик реплика, халык әйтемнәре белән җиңеләйтеп җибәрә. Җор теллелек, зирәк акыл – халкыбызның бу күркәм сыйфатлары безнең якташыбыз Васил абыйга бик тә хас.

Кешеләр белән аралашканда да Васил аганың гадилеге, тәкәббер булмавы күзгә ташлана. Нинди генә хезмәттә булмасын, кемнең кем булуына карамыйча, кешегә ярдәм итәргә әзер торуы белән нык аерылып тора ул. Шуның өчен дә аны яраталар, хөрмәт итәләр. Без дә аның тырышлыгына, талантына сокланабыз, китаплары буенча укытабыз, тәрбия чараларында кулланабыз.

Без, Васил Габдулловичның югары культуралылык, зыялылык, гаделлек, тыйнаклык, кешеләргә игътибарлы булу кебек матур әхлакый сыйфатлары каршында баш иябез. Үз халкына зур хезмәт куючы якташыбыз белән чын күңелдән горурланабыз.

“Татар кешесе, гомумән, КЕШЕ нинди булырга тиеш?” – диеп сорасалар, без: “Васил ага Гайфуллин кебек булырга тиеш!” – диеп әйтер идек.

Рафаэль Зарипов,
Түбән Табын урта гомумибелем бирү мәктәбенең физика һәм информатика укытучысы.

Күңел күгең аяз булсын!..

Сабакташым Васил Гайфуллинга
"Россия Федерациясенең атказанган
укытучысы" исеме бирелү уңаеннан

Аерылып татлы йокыдан мин
Радиоалгычны ачтым бүген дә...
Һәм ишеттем бик тә таныш моңны –
Тирән кереп калган күңелгә!

Күңелләргә уралган ул моңнар,
Җырлаучысын мин тиз таныдым.
Әйе, безнең Васил икән бит бу! –
Хаклы булуымны аңладым.

Тәбрик итәм, якын курсташым! –
Югары исем юкка бирелми...
Зур тырышлык бирә җимешләрен,
Тирләр, димәк, юкка түгелми!

Әле кайчан гына без студент идек,
Кай арада гомер үтелгән?
Васил өчен ул узмаган әле,
Зур уңышлар бары китергән!

Горурланам курсташым белән! –
Кеше булып калган гомергә.
Булса да бит бөек дәрәҗәсе,
Ишек ачык һәрчак – һәркемгә!

Әйдә, ач син, Васил, хакыйкатьне! –
Үрнәк алсын әле калганнар...

Көнләшкәннәр, әйдә, көнләшсеннәр,
Гыйбрәт алсын юлдан язганнар!

Исәнлегең теләп иссен җилләр,
Тынычлыгың теләп атсын таң.
Күңел күгең һәрчак аяз булсын,
Ә йөзләрең булсын елмайган!

Курсташың: Нурия Закирова.

Иделләргә агып чыктык...

Күренекле галим-мөгаллим, китаплар авторы Васил ага Гайфуллинга багышлыйбыз

Айлар ага, еллар ага
Чал тарихка төялеп.
Ыкка карап уйланабыз,
Бөдрә талга сөялеп.

Ык суына салдык инде
Яшьлекләрне, салларны.
Иделләргә агып чыктык,
Шунда таптык ярларны.

Агып килдек, урап килдек
Мөслим далаларыннан...
Академиклар да чыкты
Татар балаларыннан!

Резеда һәм Рәфкать Муллиннар.
1997нче ел

Сезнең гомер – тоташ Батырлык ул!..

Бер горурлык хисе яна җанда –
Васил Габдуллович, Сезнең өчен ул!
Үткәнебез безнең сикәлтәле
Һәм хәзер дә читен безнең юл...

Тик көчлеләр җиңә, тик гаделләр,
Хыянәтне белми беркайчан.

Безнең гомер – үзе олы тарих,
Кырыс тарих, әгәр уйласак.

Һәрвакытта Сез бит безнең белән!
“Көчнең, – дидегез, – куәте – белемдә!”
Ил язмышы – ул бит Сезнең язмыш,
Бәхетегез эштә, илемдә!

Безнең халык таный изгелекне,
Игелекнең көчен, бәһасен.
Шатлыкларга тулсын һәр көнебез,
Сезнең кебек ирләр яшәсен!

Сезнең гомер – тоташ Батырлык ул,
Матурлык та Сездә – рәттән!
Бармы икән җирдә зуррак бүләк
Яратудан, тирән хөрмәттән?!

Җанга якын көләч карашыгыз,
Сүзләрегез безгә – гел киңәш...
Яшик әйдә, Васил Габдуллович,
Ким дигәндә тагын – 60 яшь!..

Зур ихтирам белән:
Теләче район мәгариф бүлеге хезмәткәрләре.
20нче март, 1997нче ел

Ыкта – ак томан

Васил ага Гайфуллинга

Ыкта – ак томан...
Бүз томан Ыкта.
Сайрый чикерткә
Космик тынлыкта.

Ярда – балыкчы.
– Хәерле иртә!
...Ык суы талгын.
– Чиртәме? – Чиртә!

Гомер күзендә
Юаныр чаклар.

Яр тулып ята
Көмеш чабаклар...

Чиртә котырып
Кызыл канатлар...
...Балыкчы уяу.
...Йоклый талантлар.

Сайрый чикерткә:
– Әй, татар, уян!
Бүз томан Ыкта,
Ыкта – ак томан...

Чык суы тама
Елак таллардан.
Кайта кайтаваз
Ерак таулардан:

– Ыкта коенсаң –
Бәхстең зурдан!
...Балыкчы Ыкта
Кантырды чуртан.

Ыкның патшасы,
Ханы ул балык!
...Мөслимдә бер ай
Туй итте халык...

Госман Садә.
17нче май, 2006нчы ел

Хөрмәтле Васил Габдуллович!

Бик файдалы булды соңгы ике елда
Факультетка өргән сулышың...
Язның матур чәчәкләре кебек,
Матур булсын Синең тормышың!

Син җор сүзле үзең һәм бик топле! –
Шуңа Сине кеше ярата...
Әйткән җылы, матур сүзләрең дә
Бөтен хәсрәтләрне тарата!

Уңыш арты уңыш килсен Сиңа,
Берсе-берсе белән ярышып…
Килсен алар Сиңа бәйрәм булып,
Чаптар атлар кебек чабышып!

Кризисларны санга сукмый гына
Яшә әле, яшә – дөрләтеп!
Безнең белән бергә, җырдай итеп,
Гомереңне үткәр гөрләтеп!

Матур эшләр булыр киләчәктә,
Күп булырлар алар, галәмәт!
Карамыйча ыгы-зыгыларга
Мәңге яшә шулай сәламәт!

Теләкләрнең иң зурысы, дускай,
Сиңа шушы була торгандыр.
Яшәп күрсәт әле йөзгә чаклы –
Безнең барчабызны куандыр!

Иң изге теләкләр белән: коллегаларың

Пусть Вас хранит Судьба!..

Как трудно перестроить педагога!
Как сложно перестроить школу быстро!
Где точный выход, верная дорога?
Большая ноша на плечах министра!

Но были Вы министром не всегда.
И не забыли Вас, такого юного,
В те трудные, недетские года –
Односельчане-земляки в Муслюмово!

И пусть над Вами не свистели пули,
Но долетали в тыл сражений искры.
Наперекор всему, Васил Гайфуллин
Становится ученым и министром!

От краеведов юных и туристов,
От коллектива центра "Сәяхәт"–

Мы поздравляем нашего министра
И шлем ему свой пламенный привет!

Март. Солнцем согреваются поля!
Пусть Вас всегда ласкают небеса!
Все следопыты Вам кричат: “Салям!”
Пусть Вас хранит Судьба, Алла бирса!

Ваши коллеги

Хөрмәтле Васил абый, сөйкемле Тәкъмин апа!!

Бик гади Сез, бик гадел Сез
Бар кешегә карата –
Шуңа күрә яше-карты
Сезне бердәй ярата!

Котлар өчен жыелганнар,
Иң-иң якын туганнар...
Дусларыгыз да – янәшә,
Сезнең кебек уңганнар!

Исән-имин, тигезлектә
Һаман балкып яшәгез!
Сезгә без, һәрчак хөрмәтләп,
Нык яратып дәшәрбез!

Иң изге теләкләр белән:
Әлфия, Илдар Әхмәтҗановлар.
Март, 2007нче ел

Кояшларга арта Ир даны...

Чорыбызның күренекле шәхесе – замандашларыбыз арасында зур абруй казанган галим-мөгаллим, хөкүмәт һәм җәмәгать эшлеклесе Васил Габдулла улы Гайфуллинга

Сез – Жиһанның искиткеч бер улы:
Ходай өеп биргән байлыкны!
Тавышыгызда – Чишмә челтерәве...
Гаҗәп серле-сихри таллыкны

Үзенә оя иткән Сандугачтай,
Моң сибәсез туган төбәккә!
Ихлас башкарасыз халкым жырын –
Барып житә һәрбер йөрәккә!

Жыр – Байрак ул! Әйдәп бара безне
Яңа биеклекләр яуларга!
Алып чыга салкын кышлардан ул
Наз һәм сөю тулы язларга!

Күңелләрне күккә күтәрә ул,
Сабан тургаена иш итә!
...Мөслим улы башкарган ул жырны
Хәзер инде Дөнья ишетә!

Сезнең жырлар, Сез уйнаган көйләр
Бик тә тансык – Илен сөйгәнгә!
"Халкым минем балкып яшәсен!" – дип,
Курыкмыйча утка кергәнгә!

Сез дә – шулай! Йөрәгегез аша
Алгы сызыгы үтә Тормышның...
Сез бу жирнең фидакарь чын улы,
Тоясыз гел халкым сулышын!

Тоясыз гел халкым карашын да:
Өмет белән бага таңнарга!
"Киләчәктә телсез калмас өчен
Иман иңсен һәрбер балага!

"Туган тел"ен дога итеп ятлап,
Йөртсен күңеленең түрендә...
Әби-Бабай, Әткәй-Әнкәй телен
Саклаганнар гына үр менә!"

Шул Кыйблага һәрчак тугры калып,
Әләмегез итеп Хаклыкны,
Һаман-һаман утка керәсез лә:
"Матур яшәтик, – дип, – халыкны!"

Корыч кебек чыныктыгыз инде –
Чыңлап чыга һәрбер сүзегез:
"Яшәешнең Чын Хуҗасы булсак,
Җирдә горур басып йөрербез! –

Югалмаса әхлак-денебез,
Бетмәс булса Ана телебез!
Яшәрбез гел муллык-бәхеттә,
Мәңге какшамаслык тәхеттә!"

Ихлас, актыр һәрбер сүзегез! –
Тоеп тора шуны күң(е)лебез...
Рәхмәт Сезгә, әй, Ил агасы!
...Янасы да әле, янасы!..

Җырлыйсы да әле, җырлыйсы! –
Тормыш ямен-тәмен җуймыйсы...
Яшәеш ул – Көрәш мәйданы! –
Бәйгеләрдә туа Ил даны...

Көрәшләрдә арта Ир даны –
Һәм хөрмәтле шулчак Ил Аны!
Сез дә ирештегез шуңарга –
Сезне котлап, җиргә Җыр ява!..

Шаһинур Мостафин.
Май, 2010нчы ел

НӘШРИЯТЛАРДА, ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРДА БАСЫЛЫП ЧЫККАН ФӘННИ ХЕЗМӘТЛӘРЕМ

I. Монографияләр

1. Физика дәресләрендә проблемалы ситуацияләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты (ТКН), 1979.

2. Организация и методика проведения проблемных уроков физики. Казань, КГПИ, 1980.

3. Физикадан класстан тыш эшләр. Казан, ТКН, 1984.

4. Профориентационная работа на уроках физики. Казань, Таткнигоиздат (ТКИ), 1988.

5. Методические основы обучения физике во взаимосвязи с профессиональной подготовкой учащихся. Москва, АПН СССР, 1988.

6. Активизация познавательной деятельности учащихся на уроках физики. Казань, ТКИ, 1991.

7. Аз комплектлы авыл мәктәпләрендә физиканы укыту мәсьәләләре. Казан, ТКН, 1994.

8. Игровые методы обучения физики. Казань, "Магариф", 1997.

9. Проблемы согласия в теории и практике национальной школы. Казань, КГУ, 1998.

10. Национально-региональный компонент стандарта образования:Татарстанский вариант. Казань, ТГГИ, 1999.

11. Профессиональная направленность в обучении физики. Казань, ТГГПУ, 2008.

II. Әдәби-документаль язмалар

12. Язмыш борылышлары. Казан, "Сүз" нәшрияты, 2007.

III. Дәреслекләр, мәсьәләләр җыентыклары

13. Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы, I нче кисәк. Казан, ТКН, 1980.

14. Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы, II нче кисәк. Казан, ТКН, 1981.

15. 7 нче класс өчен физика дәреслеге. Казан, ТКН, 1993.

16. Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы, I нче кисәк. Казан, “Мәгариф”, 1993.

17. 8 нче класс өчен физика дәреслеге. Казан, “Мәгариф”, 1996.

18. Физикадан мәсьәләләр һәм күнегүләр җыентыгы, II нче кисәк. Казан, “Мәгариф”, 1996.

19. 9 нчы класс өчен физика дәреслеге. Казан, “Мәгариф”, 2005.

20. 10 нчы класс өчен физика дәреслеге. Казан, “Мәгариф”, 2009.

21. 11 нче класс өчен физика дәреслеге. Казан, “Мәгариф”, 2010.

IV. Методик ярдәмлекләр

22. Методические указания к выполнению лабораторных работ по методике преподавания физики. Часть I – Казань, КГПИ, 1985.

23. – часть II – Казань, КГПИ, 1986.

24. – часть III – Казань, КГПИ, 1987.

25. – часть IV – Казань, КГПИ, 1988.

26. – часть V – Казань, КГПИ, 1989.

27. – часть VI – Казань, КГПИ, 1990.

28. Учебно-методический комплекс по курсу “Теория и методика обучения физике”. Казань, ТГГПУ, 2008.

29. Учебно-методический комплекс по дисциплинам общей и экспериментальной физики. Казань, ТГГПУ, 2008.

30. Учебно-методический комплекс по дисциплинам математики и информатики. Казань, ТГГПУ, 2008.

31. Интеграция естественных и математических дисциплин, как средство вариативности учебно-воспитательного процесса. Казань, КГТУ, 2005.

V. Тәрҗемә

32. Таяну ноктасы. В.Ф.Шаталовның “Точка опоры” монографиясенең тәрҗемәсе. Казан, ТКН, 1990.

33. 10нчы класс өчен физика дәреслеге. (Н.Н. Сотский, Б.Б. Суховцев, Г.Я. Мякишевның “Физика – 10: учебник для общеобразовательных учреждений”(М., “Просвещение”, 2008) дәреслегенең тәрҗемәсе). Казан, “Мәгариф”, 2009.

VI. Газета-журналларда, җыентыкларда басылган мәкаләләр

34. Физика дәресләрендә проблемалы ситуацияләр. Ж. “Совет мәктәбе”, 1996, №5.

35. Физиканы проблемалы укыту буенча безнең тәҗрибә. Ж. “Совет мәктәбе”, 1971, №9.

36. Обучать развивая и воспитывая. Ж. “Народное образование”, 1972, №7.

37. К методике создания проблемных ситуаций на уроках физики. Краткое содержание докладов XXV Герценовских чтений. — Л., ЛГПИ им.А.И.Герцена, 1972.

38. О структуре и уровнях проблемности урока физики. Науч. доклады. — Л., ЛГПИ им.А.И.Герцена, 1973.

39. Методы решения проблемных ситуаций на уроках физики. — Л., ЛГПИ им.А.И.Герцена, 1973.

40. Мәсьәләләр чишкәндә укучыларның фикерләвен активлаштыру. Ж. "Совет мәктәбе", 1973, №1.

41. 6 нчы класста физикадан беренче дәрес. Ж. "Совет мәктәбе", 1973, №6.

42. Научно-технический прогресс и проблемы совершенствования содержания физического образования. Социально-экономические проблемы народного образования. Казань, ТКИ, 1973.

43. Организация проблемного обучения в различных звеньях урока. — Л., ЛГПИ им.А.И.Герцена, 1973.

44. Методика подготовки учителя к проблемному уроку. Доклады XXVII Герценовских чтений. — Л., ЛГПИ им.А.И.Герцена, 1974.

45. Пути и способы создания проблемных ситуаций на уроках физики. Сб. научных трудов. — Л., ЛГПИ им.А.И.Герцена, 1974.

46. Исследование успешности обучения в проблемном обучении. М.: НИИ СИМО АПН СССР, 1975.

47. Физика дәресләрендә укучыларның сәләтен үстерү. Ж. "Совет мәктәбе", 1975, №6.

48. Физиканы укытуның нәтиҗәлелеге. Ж. "Совет мәктәбе", 1976, №2.

49. Физикадан класстан тыш эшләр. Ж. "Совет мәктәбе", 1977, №2.

50. Физика дәресләрендә предметара бәйләнеш. Ж. "Совет мәктәбе", 1978, №2.

51. Исследование эффективности уроков физики. Сб. научн. трудов. — Куйбышев, КГПИ им.В.В.Куйбышева, 1979.

52. Аерым төшенчәләрне гомумиләштереп кабатлау. Ж. "Совет мәктәбе", 1979, №11.

53. Физика дәресләрендә профориентация эше. Ж. "Совет мәктәбе", 1980, №6.

54. Развитие познавательного интереса учащихся при изучении физики. Проблемы повышения работоспособности и интереса учащихся: Сб. науч. трудов. — Ульяновск, Ульяновский ГПИ, 1980.

55. Психологические основы применения и использования ТСО на уроках физики. Межвуз. сб. науч. трудов. — Ростовский-на-Дону пединститут, 1981.

56. "Физика һәм дин темасына кичә". Ж. "Совет мәктәбе", 1982, №6.

57. Укучыларның физикадан белемнәрен бәяләү. Ж. "Совет мәктәбе", 1983, №4.

58. Методические разработки для практических занятий по методике физике. — Казань, КГПИ, 1983.

59. Методические материалы в помощь слушателям ФПК. — Казань, КГПИ, 1983.

60. Докурсовые и послекурсовые задания по методике физики для слушателей ФПК. — Казань, КГПИ, 1984.

61. Активизация познавательной деятельности студентов на занятиях по методике физики. Межвузовский науч. сборник — Ростовский-на-Дону, пединститут, 1984.

62. Эшче профессияләргә профориентация булдыру. Ж. "Физика в школе", 1984, №3.

63. Укучыларның белемнәрен системалаштыру. Ж. "Совет мәктәбе", 1984, №4.

64. Профессиональная направленность уроков физики и внеклассных мероприятий. Сб. науч. трудов. — Запорожье, ЗГПИ, 1984.

65. Некоторые вопросы совершенствования профессиональной подготовки будущего учителя. Интенсификация подготовки учителя: Межвузов. сб. научн. тр. — Казань, КГПИ, 1984.

66. Роль ФПК в повышении квалификации организаторов народного образования по учительской специальности. Совершенствование стиля и методов руководства в общеобразовательной школе в условиях осуществления школьной реформы: Тезисы докл. — Барнаул, 1985.

67. Спецкурсы и спецсеминары, как средства активизации процесса повышения квалификации организаторов народного образования. Докл. научно-практич. конф. — Барнаул, 1985.

68. Управление учебным процессом по физике. — Казань, КГПИ, 1985.

69. Формирование профессионально- педагогических качеств будущего учителя физики на основе применения квалификационной характеристики. Межвузов. сб. научн. трудов. — Ростовский-на-Дону пединститут, 1986.

70. Физика дәресләренең максатын планлаштыру. Ж. "Совет мәктәбе", 1985, №9.

71. Иҗади эзләнүләр аша. Ж. "Совет мәктәбе", 1986, №7.

72. Урта мәктәптә физиканы проблемалы укыту. "Физика в школе", 1983, №6.

73. Физика дәресләрендә семинарлар. Ж. "Совет мәктәбе", 1987, №1.

74. Интенсификация методической подготовки студентов в условиях общего и профессионального образования. Межвузов. сб. науч. трудов. — Казань, КГПИ, 1988.

75. Микро ЭВМ ярдәмендә физика дәресләрен интенсивлаштыру. Ж. "Совет мәктәбе", 1988, №12.

76. Особенности формирования профессиональных навыков студентов физико-математической специализации в условиях интенсификации обучения. Москва, НИИ ВШ, 1989.

77. Физика дәресләренең профессиональ юнәлеше. Ж. "Совет мәктәбе", 1988, №10.

78. Применение логики объяснения при формировании понятий в процессе преподавания физики. Доклады науч. прак. конф. — Челябинск, ЧГПИ, 1988.

79. Физика дәресләрендә дидактик уеннар. Ж. "Мәгариф", 1990, №1.

80. Физика дәресләрендә укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру. Ж. "Мәгариф", 1990, №11.

***

81. Zur Gestaltung des Problem haften Unterrichts in verschiedenen Unterrichtsphasen. // Physik in der Schule. — 1975, №9.

82. Uber eine Methode zur Untersuchung des schwierigkeitsgrades von gleichwertigen. // Informationsberichte aus den naturwissenschaftlichen Methodikbereichen der Humboldt-Universitat. Heft 5. — Berlin, 1975.

83. Untersuchungen zur Effektiv // Informationsbereichte aus den naturwissenschaftlichen Methodikbereichen der Humbolt-Universitat/ —Wissenschaftliche Konferenz. Thema: "Schopferisches Lernen und ideologisches Werten im naturwissenschaftlichen Unterricht". Heft 6. — Berlin, 1977.

84. Problemlosen-Entwicklung. Wissenschaftliche Leitschrift der Humbolt-Universitat zu Berlin, Ges. — Sprachw. R. —1977, №11.

85. Optimierung der Denktatigkeit der Lernenden in problemhaft gestalteten Stunden im Fach Physik durch programmierte Unterrichtsmittel. // Informationsbereichte aus den naturwissenschaftlichen Methodikbereichen der Humbolt-Universitat. Heft 9. — Berlin, 1978.

86. Zur Befahigung zum selbstandigen Problemstellen und Problemlosen im Unterrichtsfach Physik. // Physik in der Schule. – 1978, №1/2.

***

87. Физика дәресләрен уеннар белән уздыру, Ж. "Мәгариф". – 1991, №2.

88. Мәгарифтә чишелмәгән проблемалар. Ж. "Мәгариф". – 1991, №5.

89. Укытучының актив формалары, Ж. "Мәгариф". – 1991, №4.

90. Мәгарифнең үсеш юнәлешләре. Ж. "Мәгариф". – 1991, №5.

91. Укыту-тәрбия процессы белән идарә итүнең актуаль мәсьәләләре. Ж. "Мәгариф". – 1992, №1.

92. Татар телен дәүләт теле итик! Ж. "Мәгариф". – 1992, №3.

93. Физика дәресләрендә танып-белү уеннары, Ж. "Мәгариф". – 1992, №5.

94. На путях гуманизации образования. Г. "Известия Татарстана" от 11 мая 1992 года.

95. Проблемы воспитания учащихся в современных условиях. Г. "Известия Татарстана" от 2 июня 1992 года.

96. Милли мәгарифне үстерү юллары. Г. "Мәгърифәт", 1992, №18.

97. Школа Татарстана: проблемы и перспективы. // Ж. "Народное образование", 1992, №6.

98. Яңа типтагы мәктәпләр. Ж. "Мәгариф", 1992, №7.

99. Киләчәгебез мәктәптә. Г. "Мәгърифәт", 1992, №22.

100. Чему учить и как учить. Ж. "Татарстан", 1992, №7-8.

101. Яңа уку елында яңа бурычлар. Г. "Татарстан хәбәрләре", 1992, 22 август.

102. Нәтиҗәләр һәм перспективалар. // Г. "Мәгърифәт", 1992, №23.

103. Татар мәктәбенең киләчәге. Ж. "Казан утлары", 1992, №10.

104. Сквозь призму прошлого опыта. Ж. "Деловая жизнь", 1992, №11-12.

105. Интенсификация подготовки будущего учителя. // Проблемы внедрения результатов научных исследований в учебный процесс в вузе. – Казань, КГПИ, 1992.

106. Үсеш юллары: бүгенгесе һәм киләчәге, Г. "Шәһри Казан", 1993, 21 гыйнвар.

107. Перспектив юнәлешләр. Г. "Ватаным Татарстан", 1993, 29 гыйнвар.

108. Шартлар – бер, ә нәтиҗәләр – төрле. Ж. "Мәгариф", 1993, №2.

109. Татар әдәбиятын укытуда яңалыклар. Г. "Мәгърифәт", 1993, 17 апрель.

110. Яңа белем бирү стандартлары. Ж. "Казан утлары", 1993, №3.

111. Насущные проблемы развития национального просвещения. // Материалы Всемирного конгресса татар, Казань, изд-во Каб. Министров РТ, 1992.

112. Право на эксперимент. // Ж. "Народное образование", 1993, №2.

113. Халык мәгарифендә яңа бурычлар. Г. "Мәгърифәт", 1993, 26 август.

114. Үсеш программасы. Ж. "Мәгариф", 1993, №9.

115. Мәгариф законын — тормышка! Г. "Татарстан хәбәрләре", 1993, 1 сентябрь.

116. Суверенитет и образование. Г. "Учительская газета" от 12 октября 1993 года.

117. Мәгарифтә халык педагогикасы. Ж. "Мирас", 1993, №9.

118. Возрождение и развитие национального образования // Материалы съезда народов Татарстана. Казань, 1993.

119. Педагогик белемнәрне пропагандалаучы. Ж. "Мәгариф", 1993, №11.

120. Новое о теории и методах воспитания. //Сб. "Форум новых граждан РТ". — Казань, 1993.

121. Мәгариф реформасы һәм яңа бурычлар. //Ж. "Мәгариф". 1994, №8.

122. Физика дәресләрендә укучыларның иҗади эшләре. // Ж. "Мәгариф". 1995, №7.

123. Мәгарифтә яңалыклар. Г. "Мәгърифәт", №31, 1995, 5 август.

124. Мәгариф стратегиясе. Г. "Мәдәни җомга", 1995, 5 август.

125. Проблемалар һәм перспективалар. Ж. "Мәгариф". 1995, №8.

126. Мәгариф реформасы. Г. "Ватаным Татарстан", 1995, 1 сентябрь.

127. Белемнәрнең төбәк стандарты. Ж. "Татарстан", 1995, №7-8.

128. В творческом поиске: поиски, находки, проблемы. // Тезисы докл. научно-пр. конференции. Казань, 1995.

129. Өзлексез педагогик белем. Г. "Мәгърифәт", 1995, 13 декабрь.

130. Проблемы интенсификации профессиональной подготовки учителя в творческом плане. // "Проблемы истории и культуры". Казань. 1995. (Матер. научно-прак. конференции).

131. Образование в Татарстане: проблемы и перспективы. // Ж. "Народное образование", 1995, №7.

132. Учебно-познавательные игры на основе информационной технологии обучения. // Интенсивные технологии уч.-позн. процесса в ср. и высш. школе. Елабуга, ЕГПИ, 1995.

133. Физика дәресләрендә уеннар. //Мәгариф. — 1996, №3.

134. Школа и национальное согласие. // Материалы научно-прак. конференции, Казань, 1996, с.3-15.

135. Педагогические традиции и современная школа. // "Пед. традиции народов и современная школа". Материалы научно-прак. конференции, Казань, 1996.

136. Национальная школа в системе образования. // Сб. "Развитие нац. школы, проблемы, перспективы", Казань, МО РТ, 1996.

137. Җәмгыятьнең киләчәге һәм мәктәп. Г. "Ватаным Татарстан", 1996, 15 май.

138. Национальная школа в глобальном измерении. // Информационно-методический бюллетень Аппарата Президента РТ, Казань, 1996, № 6.

139. Милли мәктәпнең киләчәге. Ж. "Мәгариф", 1996, №7.

140. Белемле шәхсләр тәрбиялик. Ж. "Мәгариф", 1996, №8.

141. Тотрыклылыктан — үсешкә! Г. "Мәгърифәт ", 1996, 16 август.

142. Фән һәм практиканың хезмәттәшлеге. Г. "Ватаным Татарстан", 1996, 21 август.

143. Приоритеты образования. Г. "Время деньги", 1996, 3 сентябрб.

144. Государственная образовательная политика: состояние, перспективы. // Бюллетень академии гуманитарных наук, С.-Петербург, 1996, №3.

145. Международное сотрудничество на рубеже столетий. // Ж. "Народное образование" (milli egitim) Истамбул, 1996.

146. Подходы к национальному образованию. // Информационно-методический бюллетень Аппарата Президента РТ, Казань, 1996, №8.

147. Проблемы развития регионального образования. Ж. "Татарстан", 1996, №11.

148. Специальный терминологический словарь бизнесмена. Казань, "Магариф", 1996.

149. Мәгърифәт нуры ачар... Ж. "Мәгариф", 1997, №11.

150. Концептуальные направления развития регионального образования. Ж. "Татарстан", 1996, №11.

151. Профессиональная направленность учебных занятий в педагогических училищах. // Профессиональное образование в регионе, Казань, 1996.

152. Мәгариф һәм милләт иреге. Ж. "Мәгариф", 1997, №8.

153. Гуманитар белем. Г. "Ватаным Татарстан", 1997, 25 ноябрь.

154. Милли университет проблемалары. Г. "Мәгърифәт", 1997, 29 ноябрь.

155. Разработка дидактической системы основ профнаправленности лабораторно-практических занятий на младших курсах естественных факультетов педвузов. Вопросы дифференцированного обучения // Межвузовский сб. науч. трудов, Казань, 1997.

156. Реализация регионального компонента стандарта образования. Ж. "Татарстан", 1998, №3.

157. Национальное образование в Республике Татарстан // Ученые записки ТГГИ, Казань, 1997.

158. О целях и задачах системы образования в период её реформы. // Разработка и внедрение национально-регион. компонента образования МО РТ, Казань, 1997.

159. Татар дәүләт гуманитар институты. // Ж. "Мәгариф", 1998, №4.

160. Реформируя содержание образования. // Аспекты гуманитарных исследований. Ученые записки ТГГИ, вып. 3, Казань, 1998.

161. Особенности современной системы образования. // Управление системой образования в РТ. – МО и ПО РФ, К., 1998.

162. Педагогикада эволюцион үсеш. // Г. "Ватаным Татарстан", 1998, 26 август.

163. Непрерывное педагогическое образование: проблемы и перспективы. // Ученые записки ТГГИ, вып.4. Казань, 1998.

164. Компьютерные экспериментальные модели в проблемном обучении. // Учебный физический эксперимент и его совершенствование: Тезисы четвертой Всероссийской научно-методической конф. 23-25 сент., 1998, Пенза.

165. Татар мәктәбенең бүгенгесе һәм киләчәге. // Г. "Ватаным Татарстан", 1999, 12 март .

166. Национальные и региональные компоненты стандарта образования // Ученые записки ТГГИ, вып.5, Казань, 1998.

167. Кадровое обеспечение национального образования. // Ж. "Магариф", 1999, №4.

168. Милли мәгарифне үстерүнең актуаль проблемалары.// Г. "Татарстан яшьләре", 1999, 13 май.

169. Методологические и практические вопросы возрождения и развития национальной школы. // Общественное развитие и гуманитарные науки. — Казань, изд-во ТГГИ, 19991.

170. Инновационные технологии. // Тезисы докладов научно-практической конференции ТГГИ. — Казань, 1999.

171. Татар мәктәбенең киләчәге. // Г. "Ватаным Татарстан", 1999, 12 март.

172. Национальный и региональный компоненты стандарта образования. // Ученые записки ТГГИ, вып.5. Казань, 19981.

173. Милли мәгарифкә кадрлар әзерләү. // Ж. "Мәгариф", 1999, №4.

174. Актуальные проблемы развития национального образования. // Ж. "Татарстан", 1999, №6.

175. Методологические и практические вопросы возрождения и развития национальной школы. // Общественное развитие и гуманитарные науки. Казань, изд-во ТГГИ, 1999.

176. Инновационные технологии. // Тезисы докладов научно-практической конференции ТГГИ. Казань, 1999.

177. Технологические подходы в педагогике. // Ученые записки ТГГИ. — вып.6, Казань, 2000.

178. Дидактика һәм педагогик технологияләр. // Ж. "Мәгариф", 2000, №2.

179. Шәхесне тәрбияләү сәнгате. // Г. "Ватаным Татарстан", 2000, 7 апрель.

180. Сынау еллары. // Г. "Мәгърифәт", 2000, 22 апрель.

181. Милли мәгариф — заман таләбе. // Ж. "Сөембикә", 2000, №5.

182. Просвещения луч. // Ж. "Мирас", 2000, №7.

183. Киләчәгебез − мәгарифтә. // Г. "Татар иле", 2000, 28 август.

184. Милләт язмышы мәктәптә хәл ителә. Ж. "Татарстан", 2000, №9.

185. О путях совершенствования профессиональной подготовки специалистов в гуманитарном (педагогическом) вузе. // Ученые записки ТГГИ, 2000, вып.8.

186. Региональный компонент образования, как средство активизации в учении школьников. // Ученые записки ТГГИ, 2000, вып.8.

187. Барысы да мәгарифтән башлана. // Г. "Мәдәни жомга", 2001, 12 гыйнвар.

188. Национальное образование: методология, концептуальные основы, проблемы. // Тезисы докладов научно-практических конференций ТГГИ, 2001.

189. Проблемы национального вуза. // Ж. "Идел", 2000, №12.

190. Научность – основа национального образования. //Ж. "Мәгариф", 2001, №6.

191. Концептуальные основы национального образования. // Ученые записки, ТГГИ, 2001, №9.

192. Естественно-научные и гуманитарные знания татар, возникшие с принятием ислама. // Ученые записки ТГГИ, К. 2001 г., вып.9.

193. Иностранный язык в сельской школе. // Г. "Татар иле", 2001, №34 (август).

194. Теоретические основы национального образования. // Национальное образование за 10 лет: итоги и перспективы. – Казань, 2001.

195. Через трении к национальному образованию. Ж."Татарстан", 2002, №2.

196. Развитие профессиональных качеств личности при обучении с применением компьютерных программ. //Доклады научной конференций. Казань, изд-во ТГГИ, 2002.

197. Халыкларны берләштерүче журнал. Ж. "Казан утлары", 2002, №4.

198. Воспитание на основе религиозных канонов. // Доклады научно-практической конференции. Поволж. отд. РАО, 29-30 окт. 2001, Казань.

199. Милләтнең киләчәге – милли үзаң тәрбияләү. // Г. "Ватаным Татарстан", 2002, 31 август.

200. Яңа чорның тәүге милли карлыгачы. // Г. "Шәһри Казан", 2002, 25 сентябрь.

201. Профессиональ уку йортында милли төбәк компоненты. // Национально-региональный компонент стандарта проф. образования в условиях нац. республики, К., 2002.

202. Традиции народной педагогики в действии. // Ученые записки ТГГИ, 2002, вып.10.

203. Знания арабов, пришедшие в булгарское государство на основе религиозных канонов. // Ученые записки ТГГИ, 2002, вып.10, с.65-77.

204. Безнең Акмулла. // Ученые записки ТГГИ, 2002, вып.10.

205. Первый национальный вуз в Республике Татарстан. // Г. "Мәдәни җомга", 2002, 25 октябрь.

206. Ислам в жизни татарского народа. // Ислам и проблема идентичности татар. Казань, изд. "Ислам", 2002.

207. Мәгариф реформалары һәм модернизациясе. // Ж. "Мәгариф", 2002, №11.

208. Эволюция в системе образования. // Материлы итоговой научно-практической конф. ТГГИ , 2002.

209. Мәгариф нурын тоеп. // Ж. "Мәгариф", 2003, №3.

210. Күңелдә – халык догасы. // Г. "Татар иле", 2003, 2 июль.

211. Янарыш һәм милли мәгариф. // Г. "Ватаным Татарстан", 2003, 9 апрель.

212. Народная педагогика – основа образования. Ж. "Татарстан", 2003, №7.

213. Концепция Татарского национального университета. // Модернизация системы нац. образования. Казань, "Школа", 2003.

214. Каюм Насыйри и современное татарское просвещение. // Ученые записки ТГГИ, 2003, вып.11.

215. Выдающийся просветитель. // Зеленодольск: проблемы истории и культуры. Материалы научно-практических конференций. Казань, Gumanitarya, 2003.

216. Каким быть национальному татарскому университету? // Ж. "Татарстан", 2004, №1.

217. Новые педагогические технологии. Ж. "Ялкын", 2004, №2.

218. Һәр кошның очар кыйбласы була. Г. "Ватаным Татарстан", 2004, 17 апрель.

219. Концептуальные аспекты модернизации национальной высшей школы. // Ученые записки ТГГИ, вып.12, 2004.

220. Глобализация в системе образования. Ж. "Мәгариф", 2004, №10.

221. Мы учим понимать друг друга. // Г. "Комсомольская правда", 2004, 21 октябрь.

222. Концептуальные аспекты модернизации национальной высшей школы. // Ученые записки ТГГИ, вып.12, 2004.

223. Тулы канлы мәгариф системасы булдырыйк! Г. "Ватаным Татарстан", 2004, 24 октябрь.

224. Киләчәгебез хакына. Ж. "Мәйдан", 2004, №10.

225. Чит илләргә чыгып гыйбрәт ал. Ж. "Мәгариф", 2005, 11 гыйнвар.

226. Хәтер почмагы. // Г. "Шәһри Казан", 2005, 4 февраль.

227. Бердәм дәүләт имтиханы: уйланулар һәм тәкъдимнәр. Ж. "Мәгариф", 2005, №2.

228. Глобализационные процессы в образовании. Ученые записки ТГГИ, вып.13, К., 2005.

229. Инновации в системе образования. Ж. "Магариф", 2005, №2.

230. Профильле укыту – заман таләбе. Ж. "Татарстан", 2006, №3.

231. Физиканы профессияләргә бәйләп өйрәнү. Ж. "Мәгариф", 2007, №3.

232. Иң кирәкле профессия — укыту. Г. "Мәгърифәт" 2007, 14 апрель.

233. Милли мәгарифнең үсеш юллары. Ж. "Казан утлары", 2007.

234. Пути интенсификации профессиональной подготовки учителей физики. // Доклады научно-прак. конф. "Проблемы исследования и преподавания дисц. физ-мат. цикла в вузе и школе", г. Елабуга, 2008, 14 август.

235. Педагогик белем бирү – көн таләбе. Ж. "Мәгариф", 2009, № 6.

236. Яңалыкның да чамасы бар. Г."Мәдәни җомга", 2009, № 35 (сентябрь).

VII. Өр-яңа басмалар

237. Инновационные технологии в методике // Инновационные образовательные технологии в естественно-научном образовании школы и вуза. Казань, изд-во "Школа", 2010.

238. Факультет физики сегодня. Казань, изд-во "Школа", 2010.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш сүз 4
Күренекле замандашыбыз
Укытучы, галим, җитәкче (Рамил Минһаҗев – автор турында).. 5
Хәтер кайтавазы
Туган авылым 14
Нәсел тармагы 19
Тихния 27
Печән кыйсасы 34
Бишнаратка барган идек... 35
Авылдаш-якташларым
Зифа Басыйрова 38
Агрономия конференциясе 40
Һади абый 43
Асия апа Лотфуллина 45
Мәрданов абый 47
Сәгыйть Шәйхрамов 49
Тапкыр Әфтах 54
Ногманов абый 55
Әкрәм абый 58
Йомры сүзле авылдашлар 60
Мөнәвәр абый 61
"Сыеры савылган"ны кем белә?... 62
"Чекист" 63
Шигъри мәҗлестә 67
"Бумеранг" 69
Замандаш-чордашларым
Илгизәр Гыйльфанов 71
Гаденән Садрыев 75
Миргалим Әюпов 79
Директорлар киңәшмәсендә 86
Иңдәшләрем-тиңдәшләрем 88
Әнвәр Хуҗиәхмәтов 94
Илдар Шакиров 97

Мидхәт Шәрифуллин 98
Равил Галиәхмәтов 102
Шәйхенур Гайнетдинов 104
Хәниф Хөсәенов 107
Марсель Бәширов 110
Ислам Әхмәтҗанов 113
Карл Әхмәтов 115
Рафаэль Гарипов 117
Адаш 122
Марсель Вәлитов 126
Хәләф Шәмсетдинов 128
Фриль Әхмәтов 134
Яшьтәшем Ранас 137
Дәреслек дулкынында
"Тыңлагыз, Казан сөйли!" (Интервью).. 139
Яңа ректор сайлау маҗаралары 153
Милли мәгариф дөньясында
Өзлексез педагогик белем – көн таләбе 161
Каюм Насыйри һәм хәзерге татар милли мәгарифе 168
Мәгарифле халык – иркле халык 178
Физика дәресенең максатын планлаштыру 194
Глобальләшү процессы һәм мәгариф системасы 199
Мәгариф реформалары һәм модернизациясе 205
Бердәм дәүләт имтиханы: тәҗрибә һәм уйланулар 215
Педагогикада технологияләр 220
Туган як сәламе
Мирасыбызны, шәхесләребезне барлыйбыз 232
Якташыбыз белән горурланабыз 233
Шигъри котлаулар
Күңел күгең аяз булсын!.. 241
Иделләргә агып чыктык... 242
Сезнең гомер – тоташ Батырлык ул!.. 242
Ыкта – ак томан 243
***Бик файдалы булды 244
Пусть Вас хранит Судьба! 245
***Бик гади Сез, бик гадел Сез... 246
Корәшләрдә арта Ир даны... 246
Нәшриятларда, газета-журналларда басылып чыккан фәнни хезмәтләрем 249

Гайфуллин Василь Габдуллович

МГНОВЕНИЯ ЖИЗНИ

(На татарском языке)

Мөхәррире *Ш.Ә. Мостафин*
Техник редакторы *Н.Ф. Гыймадиева*
Тышлык дизайнеры *И.И. Ибраһимов*
Корректоры *Ф.С. Маликова*

Басарга кул куелды 27.05.2010 Форматы 60×90¹/₁₆. "Peterburg" гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 16,5+ 2,5 вкл. Тиражы 500 данә. Заказ О-668.

"Сүз" ҖЧҖ
420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2.
Тел./факс: (843) 519-45-10.
E-mail: Slovopress-s@yandex.ru

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан ш., Декабристлар ур., 2.

Әлеге китабымда әдәби сюжет та, уйлап чыгарылган образлар да юк. Бары тик үзебез яшәгән заман, безне чорнаган тормыш һәм миңа якын кешеләр турында чын дөресе генә язылган. Монда мин үзем белән бергә эшләгән һәм аралашкан хезмәттәшләрем, дусларым, авылдашларым турында сөйләүне дәвам итәм.

В. Гайфуллин

Васил Габдулла улы Гайфуллин – педагогия фәннәре докторы, профессор, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе...